А. Г. ЯХИН

Әдәбият

8



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
8

Пауза

Характер

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
8 нче сыйныфы өчен дәреслек

Яңадан эшләнгән өченче басма

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән*

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2007

УДК 373.167.1:821.512.145*08
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Я89

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

УКЫТУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Шушы дәреслек белән эшләү өчен, А. Г. Яхинның «8 нче сыйныфта әдәбият дәресләре: Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

Аны сатып алу өчен «Мәгариф» нәшриятына мөрәҗәгать итегез.

Яхин А. Г.
Я89 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 8 нче с-фы өчен д-лек /А. Г. Яхин.— Яңадан эшләнгән өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2007.— 303 б.: порт. б-н.
ISBN 978-5-7761-1650-6

ISBN 978-5-7761-1650-6

© «Мәгариф» нәшрияты, 2007, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2007

КЕРЕШ

Без 7 нче сыйныфта әдәби жанрларны һәм язучылар иҗатын өйрәндек. Әдәби жанрлар күп, ә язучылар тагын да күбрәк. Шуңа күрә узган уку елында башлаган эшне быел да дәвам итәчәкбез. Жанрларның башкаларын өйрәнәчәкбез, бүтән язучылар иҗатына анализ ясап бәя бирәчәкбез.

Үзган уку елында өйрәнгәннәрне искә төшергәннән соң, эшне сезгә аз таныш булган жанрлар белән танышудан башлыйбыз.

> Искә төшерик. **Жанр** дип әсәрләрнең уртак сыйфатларына әйтәләр.

Әдипләр, әсәрләрен язар алдыннан, яраткан жанрларын сайлыйлар. Аннары шул жанр кагыйдәләренә буйсынып иҗат итәләр.

Жанр сыйфатларын белүнең әһәмияте зур. Әйтик, безгә нинди дә булса бер әсәргә анализ ясарга кирәк, ди. Эшне нидән башлыйбыз? Башта әсәрнең кайсы жанрга керүен ачыкласак, эшебезне җиңеләйтәбез.

Лирик шигырьләр жанры безгә, миңа кергән әсәрнең эчтәлеген хис сәбәбеннән эзлә, хиснең дәрәҗәсен тап, юануның ничек тасвирланганын бел, ди. Драма жанры үз әсәрләренең тышкы һәм эчке конфликтларын табарга куша. Әсәрне эчке конфликтның каршы якларына аер, конфликтка кергән каршы якларның сәбәпләрен ачыкла, әсәр эчтәлеген шунда табарсың, ди.

Быел, жанрлар үзенчәлегеннән файдаланып, шул жанрларга кергән әсәрләргә анализ ясаячакбыз. Аннан соң язучылар иҗатын өйрәнүгә күчәбез.

Язучының барлык әсәрләренә **язучы иҗаты** диләр. Язучы иҗат иткән әсәрләрнең уртак сыйфаты күренеп тора — аларның барысын да бер әдип язган. Ләкин

язучы төрле-төрле эчтәлекле, төрле жанрдагы әсәрләр дә иҗат итә бит. Барысын да бер кеше иҗат иткәч, аларның нинди дә булса уртак яклары булырга тиеш. Язучы иҗатына анализ ясап, менә шул уртак якларны табалар. Әсәрләренең уртак сыйфатлары **язучы иҗатының үзенчәлеге** була. Безнең максат язучы иҗатының үзенчәлеген табудан гыйбарәт булачак.

Әдәбиятны кайсы яктан өйрәнә башласаң да, барыбер әсәрләргә анализ ясарга кирәк. Шул сәбәпле быел да дәресләрнең күп өлеше әсәрләргә анализ ясауга багышланачак. Анализны, билгеле, алдагы сыйныфларда өйрәнгән юл белән ясаячакбыз. Ләкин быел без анализ ясауның башка алымнары белән дә танышырбыз. Иҗат эшенең серләрен тагын да тирәнрәк ачарбыз.

Ә төп максат үзгәрми: әдәбият дәресләрендә без, барыннан да бигрәк, мөстәкыйль уйларга, иҗат серләрен өйрәнеп, әсәрнең матурлыгын күрергә һәм үзебез дә иҗат итәргә өйрәнергә тиешбез.

КАБАТЛАУ

Сез әдәбият дәресләрендә, әсәрләргә һәм язучы иҗатына анализ ясап, фикерләргә күнегәсез. Ләкин әдәби әсәр үзе дә фикер җимеше бит. Без әдипнең образлы фикер нәтиҗәсен фән кагыйдәләре белән өйрәнәбез. Аерма түбәндәге мисалда ачык күренә.

«Буран» төшенчәсен энциклопедик сүзлек болай аңлата:

«Җир өстендәге җилнең карны бер урыннан икенче урынга күчерүе. Буранны, җәяүле һәм карлы буран дип, ике төргә аералар. Соңгысында җилләп кар ява».

«Буран» шигырендә Габдулла Тукай буранның шул ук сыйфатларын болай сурәтли:

Тик кенә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себреләә, кар котрына һәм кар ява.

Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап;
Һәр кара нәрсә бүре һәм һәр маяк булды карак.

Карны җиңгән кук төшә җиргә тоныкай яктысы;
Ай да куркынган шикелле: бер сары, бер ак төсе.

Көн буе яткан иде, үлгән җылан күк, юл тыныч;
Чыкты соң кайдан адаштыргыч буран — бу куркыныч?..

Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә.
Мин фәкыйрь михнәттә — гүя чарлагыннан бай көлә!

1912 ел

Бирем

Ике текст та буран турында. Беренчесен — галим, икенчесен шагыйрь язган. Фәнни аңлатма белән образлы сурәт аермасын сөйләп аңлатыгыз.

Мәкальләр һәм әйтемнәр

Биремнәр

1. Әйтемнәр белән мәкальләрнең аермалы якларын исегезгә төшерегез.

2. Мәкальләрнең һәм әйтемнәрнең тормыш вакыйгалары белән үзенчәлекле бәйләнешен аңлатыгыз.

Мисаллар

1. Үзе утырган ботакны кисә.
2. Төтен чыгарган үзе ысланыр.
3. Кече булсаң, зур булырсың. Зур булсаң, ... булырсың.
4. Белгәнеңне сөйләмә, ни сөйләгәнеңне бел.

Биремнәр һәм сорау

1. Мисалларны игътибар белән укыгыз. Дәреслегегезне ябыгыз да истә калган мәкаль-әйтемнәрне дәфтәрләрегезгә язып куегыз. Тагын бер кат укып чыгыгыз. Шундый ук юл белән истә калган яңаларын әлеге исемлеккә өстәгез. Өченче кат укыгыз һәм тагын шул ук эшне башкарыгыз. Исегездә калган әйтем, мәкальләрне санап чыгыгыз.

2. Мәкальләрнең һәм әйтемнәрнең тормыш вакыйгалары белән үзенчәлекле бәйләнешен аңлатыгыз.

3. Мисалларның кайсысы әйтем, кайсысы мәкаль? Аңлатыгыз.

4. Дүртенче мәкальгә сүз өстәгез.

5. Вөҗданлы, намуслы булырга өйрәткән мәкальләрне күрсәтегез. Аларның эчтәлекләрен әйтегез.

Җырлар

Агыйделнең аръягында
Сулар тонгандыр инде;
Һәркемдә дә бер үкенеч
Була торгандыр инде.

Агыйделгә төшкән идем,
Камышы ятьмә кебек;
Ялгыз башым чит илләрдә
Адашкан бәбкә кебек.

Биремнәр

1. Лирик җырларны һәм шигырьләрне өч өлешкә бүлеп өйрәндек. Нинди өлешләргә бүлдек? Исегезгә төшерегез.

2. Дүртьюллыкның соңгы ике юлы, ягъни икенче өлеше мондый:

Иртән искән таң җилләре
Булыр сезгә сәламем.

Баштагы ике юлын уйлап языгыз.

3. **Дүртьюллыкның баштагы ике юлы мондый:**

Агыйделдән агып килә
Ал сабын, сары сабын;

Дәвамын үзегез уйлап табыгыз.

Әкиятләр

АЛТЫН КОШ

Борын-борын заманда, булган икән, ди, бер патша. Аның булган алма бакчасы.

Көннәрдән бер көнне, бакчада йөргәндә, патша бер алмагачның алмасы югалганын сизә дә бакчаны үзе саклый башлый.

Караңгы төшү белән, патша бакчага чыгып утыра. Төне буена утырып чыга бу. Таң алды килеп җитү белән, моны да йокы баса башлый. Йокысы килсә дә түзеп утыра бу. Шулвакыт бер Кош очып килә дә зур гына бер алмагачына килеп куна. Кошның килеп кунуы була, патша, иплэп кенә килеп, Кошны тотып ала. Шакката бу Кошның матурлыгына — Алтын Кош булып чыга бу. Патша бу Кошны, кадерләп кенә алып кереп, алтын читлеккә ябып куя. Башка патшалар кебек үк, бу патша да бик мактанчык нәрсә икән: «Алтын Кош тоттым»,— дип, барлык чит ил патшаларына хәбәр җибәрә. Күрше патшаларның кайберләре көнчелек белән, кайберләре Алтын Кошны күрергә теләп, чакырылган вакытка килеп җитәләр. Патшалар, җыелышып, үзара мәҗлес корып утырганда, Алтын Кошлы патшаның малае Арслан укудан кайтып уйнап йөри икән, ди. Бу малай Алтын Кош торган бүлмәгә килеп керә. Угын атып җибәрүе була, моның угы Алтын Кош торган читлекнең эченә кереп кадала. Арслан укны алыйм дип читлек янына барса, Кош, телгә килеп, моның белән сөйләшә башлый.

— Угың монда,— ди икән Кош,— син башта читлек ачкычын алып килеп читлекне ач, аннан соң угыңны алырсың,— ди.

— Читлек ачкычы кая соң ул? — дип сорый Арслан.

— Әтиеңнең кесәсендә,— ди икән Кош.

Малай әтисенең кесәсеннән ачкычны барып ала. Читлекне ача. Читлек ачылу белән, Кош очып чыга да Арсланга әйтә:

— Кайчан да кайчан мин сиңа кирәк булсам, «Әй, Алтын Кош», дип кенә әйт, мин сиңа ярдәм итәрмен,— ди. Шулай ди дә тәрәзәдән очып чыгып та китә. Арслан хәзер ачкычны әтисенең кесәсенә илтеп куя да үзе тагын уйнарга чыгып китә.

Кичкә таба патшалар җыелып җитү белән, патша, Алтын Кошны алып чыгарга дип, бүлмәгә керә, читлек янына бара, карый, Кош юк. Шуннан соң бу бик зур кайгыга төшә. Патшалар янына күз яше белән елап килеп керә, бик борчыла инде бу: «Алтын Кошым югалган, кемдер, читлекне ачып, Кошны чыгарып җибәргән»,— ди. Чит патшалар, бик каты күңелсезләнеп: «Алай булгач дәшмәскә кирәк иде»,— дип үпкәләп, кайтып китәләр.

Кунаклары китү белән, патша үзенең хатынын, вәзирләрен, барлык сакчыларын чакыртып ала да: «Бер Алтын Кошны да саклый алмагансыз»,— дип, боларны астырукистерү белән куркыта башлый.

Кич булу белән, Арслан уеннан кайтып керә. Шул чакта моның әнисе үксеп-үксеп елап утыра икән, ди. Малайның килеп керүе була, әнисе әйтә моңа:

— Харап булдык, улым, безнең Алтын Кошыбыз югалды бит әле. Менә шуның өчен әтиең мине бик каты ачулана, рәнҗетә,— ди.

Арслан әйтә:

— Әй әни,— ди,— юк өчен кайгырып утырма әле син,— ди.— Алтын Кошны мин җибәрдем бит аны,— ди.

Патша, бу хәлне белеп, малаен бик каты ачулана.

Вәзирләрен чакыртып алып, шулар алдында малаеннан сорау ала патша:

— Алтын Кошны син чыгарып җибәрдеңме? — ди. Арслан, бик батырланып, мәҗлес уртасына килеп баса, бер дә каушамыйча гына:

— Алтын Кошның читлеген мин ачтым, Кошны иреккә мин җибәрдем,— ди. — Әгәр шуның өчен ачуланасың икән,— ди,— мине ачулан. Гаепсез кешеләргә кагылма син,— ди.

Патшаның моңа бик каты ачуы килеп, үзенең вәзирләрен чакыра.

— Бу малайны нишләтик икән инде? Бу малай кече яшеннән үк миңа каршы бара. Үсеп җиткәч, игелек күрсәтмәс бу. Моны йә хәзер үк астырам, йә инде гомерлек зинданга салдырам, башка чара юк моңа,— ди.

Бер карт вәзир торып әйтә:

— Малайны бу эш өчен генә астыру дөрес булмас,— ди. — Без аны,— ди,— үзебезнең патшалыктан гына чыгарып җибәрик,— ди. Сөйләшә торгач, болар малайны үз патшалыкларыннан куып җибәрергә булдылар.

Патшаның хатыны: «Үз балаңа шундый кансызлык күрсәтмә»,— дип, патшадан елый-елый үтенеп сораса да, патша үз сүзен итте.

Патшаның хөкемен Арсланга килеп әйтүләре булды, малай әнисе белән саубуллашты да, йорт-җирен ташлап, юлга чыгып китте. Юлда барганда, бу егет үзенең дус патша малае янына керде. Аның белән сөйләштеләр, киңәшләштеләр дә, бер-берсенә иптәш булырга сүз куешып, юлга чыгып киттеләр, ди, болар.

Атна китәләр, ай китәләр, ди, болар, бара торгач килеп җиттеләр, ди, бу ике егет бер су буена. Юлга чыгуларына күп тә үтми, патша малае иптәшенең хәйләкәр егет икәнен сизеп ала. Су буена килеп утырдылар, ашадылар, эчтеләр. Бер кич ял итеп, яңадан юлга чыгарга хәзерләнделәр. Юлга чыгып китәбез генә дип торганда, теге хәйләкәр малай әйтә:

— Менә, дус кеше,— ди,— хәзергә хәтле,— ди,— миннән бер яшькә олы булганга күрә, син баш булып, мин сиңа буйсынып килдем,— ди.— Моннан соң икебезгә дә патша малае булып йөрү килешми, беребез патша малае, икенчебез вәзир малае булып йөрик без,— ди.

Арслан әйтә:

— Минем өчен барыбер, — ди. Шуннан соң хәйләкәр малай:

— Менә, дус кеше,— ди,— хәзер мин сиңа баш булдым инде,— ди,— моннан соң мин кушканча гына йөрерсең, мин кушканны гына эшләрсең,— ди.

— Ярар,— ди,— Арслан әйтә,— син кушканча гына йөрермен,— ди.— Үзе эченнән генә: «Кемнең кем икәне киләчәктә күренер әле»,— дип уйлый.

Баралар, баралар болар икесе ике атка атланып, бара торгач, килеп керәләр зур бер шәһәргә. Бу патша тора торган шәһәр икән. Шәһәрнең иң зур урамыннан кереп китәләр, урам белән бара торгач, патша сараена барып җитәләр. Сарай яныннан атларын атлатып кына үтеп китәләр. Бу патшаның өч кызы бар икән. Егетләр патша сарае яныннан үткәндә, бу кызлар тәрәзә янында чигү чигеп утырганнар. Бу ике егетне

күрү белән, патша кызлары, һуштан язарлык булып, аларга гашыйк булганнар. Патша кызлары, әтиләре янына йөгереп чыгып:

— Әти, әти, безнең урамнан ике атлы егет үтеп бара, шундый матурлар, син ул ике егетне кире кайтарып безгә күрсәтсәнә,— диләр. Патша үзенең бер вәзирен чакырып ала да:

— Артларыннан куып җитеп, «безнең патша сезне кунакка чакырды» дип әйт, ул егетләрне үзеңнән калдырмый алып кайт,— диеп чыгарып җибәрә тегеләр артыннан. Егетләр, патша сараена кереп урнашкач, әйбәтләп ясаныптөзәнеп, патша янына кергәннәр.

— Сез нинди кешеләр, каян килеп, кая барасыз? — дип сорый патша.

— Мин фәлән патша малае, ә минем иптәш иленнән куылган вәзир малае,— ди теге егет.

Патша, озын-озак уйлап тормыйча:

— Минем патшалыгымда калырга теләсәгез, мин сезгә үземнең кызларымны бирәм. Әнә олы кызым патша малаена, уртанчысы вәзир малаена булыр,— ди.

Егетләр, үзләренең ризалыкларын биреп, патша кызларына өйләнәләр. Патша олы киявен яңа гына салынган алтын сарайга, кече киявен, вәзир малаена ярар әле, дип, ишегалдындагы бәләкәй генә бер йортка урнаштыра. Патша олы киявен, якын киңәшчем булыр, дип, гел үзенең янында гына, тәхет тирәсендә генә тота, ә кече кияве Арсланны санга санамый, исәпкә дә алмый икән, ди.

Ярар. Бу ике егет патша кызлары белән көн итәләр, атна торалар, ай торалар. Бара-тора патша үзенең кияүләренә төрле-төрле эшләр куша. Кече кияве Арслан патша кушкан эшләрне сәгате-минуты белән эшләп ыргыта да: «Тагын ни йомышыгыз бар?»— дип, яңадан эш кушканны көтеп кенә тора. Патша олы киявенә дә эшләр куша, ләкин тегенең рәте юк бер дә. Бу хәлне күреп, патшаның олы кияве Арсланнан бик каты көнләшә. «Арсланнан ничек кенә итеп үч алырга икән?»— дип уйлап йөри башлый.

Көннәрдән бер көнне патша малае хатынының әтисенә Арсланны мактаган булып сөйләп китә:

— Синең кече киявеңнең һөнәрләре бик күп бит аның,— ди,— ул аларны беркемгә дә белдермичә генә йөри, сиңа да белдермәскә тырыша ул аларны,— ди.

— Нинди һөнәрләре бар соң анының? — дип сорый патша.

— Ул,— ди олы кияве,— йөз баш атны алтын тояклы, көмеш йонлы иттерә ала, чакыртып алып шул эшне эшләргә куш әле син аңарга,— ди. Бу эшне эшли алмасаң, башыңны чаптырам дип әйт, шулай дип әйтмәсәң эшләмәс ул аны,— ди.

Патша малае шулай ди дә, үзе тиз генә патша яныннан чыгып китә. Патша Арсланны дәштереп ала да әйтә:

— Синең бик шәп һөнәрең бар икән, кияү. Йөз атны алып чыгып, алтын тояклы, көмеш йонлы иттереп алып кайт әле син,— ди. Үтәмәсәң, мин синең башыңны кистерермен,— ди.

Арслан патшаның йөз баш атын санап алып, сахрага алып чыгып таратып җибәрде. Арсланның мондый һөнәре юк бит инде, нишләсен, кырда кайгы-хәсрәт чигеп утыра бу. Утыра торгач, Алтын Кош исенә төшеп: «Әй Алтын Кош»,— диде бу. Шулай итеп әйтүе булды: «Егет, сиңа ни кирәк?» — дип, Алтын Кош моның каршысына килеп чыкты. Арслан, бик шатланып:

— Менә шушы йөз атны алтын тояклы, көмеш йонлы итеп алып кайтырга кушты миңа патша,— ди.

— Егет,— ди,— син бер дә кайгырма,— ди Кош. Шулай ди дә, кеше сыйфатына кереп, әлеге йөз атны, койрыкларыннан тотып, һавага ыргытты-ыргытты да Арсланны үзе белән бергә өенә алып кайтып китте.

Егетне бер сарайга алып керде дә үзенә аерым бер бүлмәгә урнаштырды бу. Шуннан соң, Арсланны үзенең сеңлесе белән таныштырып: «Менә мине шушы егет коткарды»,— дип, башыннан үткәннәрне сеңлесенә сөйләп бирде. Алтын Кош сеңлесенә бу егетне бик яхшылап кунак итәргә кушты. Арслан Алтын Кошларда кунак була, ял итә. Шуннан соң Алтын Кош әйтә:

— Бу егеткә,— ди,— нинди генә бүләк бирик икән соң? — ди. Сеңлесе әйтә:

— Әти-әнидән калган бер ашъяулык бар, шуны бүләк итик без аңар,— ди.

Ашъяулыкны бүләк итеп бирәләр дә:

— Менә без сиңа әти-әнидән калган ашъяулыкны бүләк итеп бирәбез,— диләр.

— Мин аны сезнең төс итеп, кадерләп кенә тотармын,— ди егет. Алтын Кош Арсланга әйтә:

— Бу ашъяулыкның хикмәте бар,— ди.— Җәеп җибәрсәң, ни теләсәң шундый аш була аның өстендә,— ди.

Шуннан соң Алтын Кош Арсланны элекке урынына илтә дә йөз атны койрыгыннан тартып төшерә башлый, ди. Арслан моңа шакката. Атлар танымаслык булып үзгәргән булалар: аларның тояклары алтын, йоннары көмеш була. Арслан атлар арасыннан бер бик матурын тотып алып шуңа атлана да башкаларын куып алып кайтып китә.

Бу кайтып җиткәндә, патша үзенең олы кияве белән балконда утыра икән, ди. Алтын тояклы, көмеш йонлы атларны күрү белән, патшаның исе-акылы китә, ди.

— Менә, кияү,— ди.— Арслан үзенең һөнәрен күрсәтте бит,— ди. Патша малае моңа бик нык гарьләнә, нишләргә белми. Аптырагач әйтә бу патшага:

— Син, бабай, белмисең икән әле,— ди.— Аның тагын бер һөнәре бар, ул йөз сыерны алтын мөгезле, чылбыр койрыклы итеп алып кайта ала, син аңа шул эшне куш,— ди.

Ярар. Арслан өенә, хатыны янына кайта. Хатыны, Арсланның исән-сау кайтуын күреп, бик шатлана инде.

Арслан өенә кайтып керү белән, боларга патшаның аш пешерүчесе килеп керә: «Патша сезгә ашамлык җибәрде»,— дип, бу боларга бер савыт ашамлык калдырып чыгып китә. Савытны ачып карасалар, аның эчендә вак-төяк, калдык-постык ашамлык кына икән, ди. Патшаның аш пешерүчесе чыгып китү белән, Арслан Алтын Кош бүләк иткән ашъяулыкны ачып җибәрә — җаның ни тели, төрле-төрле татлы, тәмле ашамлыклар килеп чыга. Рәхәтләнеп ашыйлар, эчәләр дә ашъяулыкны төреп, кадерләп кенә салып куялар.

Икенче көнне иртә белән патша Арсланны тагын үз янына дәштерә. Патша моңарга әйтә:

— Кияү, синең тагын бер һөнәрең бар икән, син йөз баш сыерны алтын мөгезле, чылбыр койрыклы итә аласың, имеш,— ди.

Бу нишләсен, башын иеп чыгып китә. Патша көтүенә барып, йөз сыерны сайлап ала да, тагын әлеге басуга куып алып барып, сыерларны таратып җибәрә. Шуннан соң бу читкәрәк китә дә: «Әй Алтын Кош»,— дип кычкыра. Күз ачып-йомганчы Алтын Кош тагын моның алдына килеп чыга...

Биремнәр

1. Шуннан соң ни булуын үзегез сөйләгез.

— Атна-ун көннән соң Алтын Кош сеңлесеннән сорый:

— Без аңа нәрсә генә бүләк итәрбез икән соң? — ди.

— Ата-бабадан калган бер әргән[1] бар бит безнең, шуны бүләк итеп бирик без аңа,— ди.

Бу унике винтлы бер әргән икән, моның һәрбер винты үзенә бертөрле көй чыгара икән, ди.

Бу егеткә ата-бабадан калган әргәнне бүләк итеп бирәләр дә, Алтын Кош Арсланны теге сыерлар калган басуга алып китә...

2. Дәвамын үзегез уйлап сөйләгез.

Патша торган шәһәргә кайтып җитә. Сыерларны, зур урам белән алып барып, патша сарае янына туктата. Алтын мөгезле сыерларның чылбырлы койрыкларыннан төрле-төрле тавышлар чыга икән, ди. Моны ишетеп, бөтен шәһәр халкы җыела. Бу вакытта патша үзенең ялганчы кияве белән балконда чәй эчеп утыра икән, ди. Алтын мөгезле, чылбыр койрыклы сыерларны күрү белән, патша шаккатып карап тора да сыерларны ишегалдына кертеп ябарга куша. Арслан сыерларны кертеп яба да хатыны янына кайтып китә.

Патшаның олы кызы: «Синең ирең бу китүеннән кайтмый инде»,— дип, Арсланның хатынына бер дә көн күрсәтми икән. Арсланның хатыны, иренең кайтуын күреп, бик нык шатлана, елашып күрешәләр болар.

Ярар. Хәзер инде патшаның теге олы киявенә килик. Ул, Арсланның патша кушкан эшне җиренә җиткереп эшләп кайтуын күреп, бик көнләшә инде. Патшага әйтә икән бу:

— Кече киявеңнең тагын бер һөнәре бар, син аны бик сыйлама, ашарына икмәк белән су гына җибәрт, югыйсә ул, тамагы туеп китсә, шул һөнәрен сиңа күрсәтмәс,— ди.

— Тагын нинди һөнәре бар соң аның? — ди патша.

— Ул,— ди,— йөз баш кәҗәне алтын мөгезле, көмеш йонлы итеп алып кайта ала,— ди.

---

[1] *Әргән* (орга́н) — агач һәм металл трубалар тезмәсеннән торган тынлы, клавишлы бик зур музыка коралы.

Патша, үзенең аш пешерүчесен чакыртып, кече кияве белән кызына икмәк белән су гына җибәрә. Аш пешерүче нәкъ патша кушканча эшләде. Бер кисәк икмәк белән су илтеп алларына куйды. Кияү белән кыз, бер сүз әйтмичә, моның кулыннан савытны алып калдылар. Әлеге ашъяулыкны алып, өстәл өстенә җәйделәр. Өстәл өсте төрле татлы-тәмле ризыклар белән тулды— җаның ни тели. Болар ирле-хатынлы, кара-каршы утырып, рәхәтләнеп ашапэчтеләр.

Шуннан соң Арслан Алтын Кош бүләк итеп биреп җибәргән әргәннең бер винтын борып җибәрсә, бик матур, болар гомердә ишетмәгән матур көй уйный башлый. Арслан, әргәннең унике винтын да бер-бер артлы борып, төрле-төрле матур көйләр уйнатты. Төн буена рәхәтләнеп күңел ачып утырдылар, ди, болар.

Иртә белән патша Арсланны үз янына чакыртып ала да әйтә:

— Кияү,— ди,— синең миңа белдерми йөргән тагын бер үнәрең бар икән әле,— ди.— Син,— ди,— йөз баш кәҗәне алтын мөгезле, көмеш йонлы иттерә аласың икән,— ди.— Әгәрдә мин кушканны эшләмәсәң, мәйданга чыгарып башыңны чаптырырмын,— ди.

3. Алынган вакыйганы үзегез сөйли аласыз. Дәвам итегез.

Өйгә кайтып керәләр. Өйгә кайту белән, Алтын Кош сеңлесен чакырып ала да әйтә: «Безнең кадерле кунагыбыз тагын килгән,— ди,— син аңа бик шәп итеп сый-хөрмәт күрсәт»,— ди.

— Яхшы ял иттеңме? — дип сорый егеттән Алтын Кош.

Шуннан соң Алтын Кош моны үзләренең бакчаларына алып чыга. Алмагачыннан бер алма өзеп бирә.

— Ашап кара әле менә шушы алманы,— ди. Егет ашый, моңа куәт кереп китә.

— Үзеңдә куәт барын сизәсеңме? — ди Кош.

— Бик сизәм,— ди егет,— хәзер минем,— ди,— әллә нинди зур тау-ташларны күтәреп алырлык куәтем бар,— ди.

Алтын Кош Арсланны яңадан өенә алып кереп китә. Өйгә кергәч, сеңелесеннән сорый:

— Бу егеткә тагын нәрсә бүләк итик икән? — ди. Сеңлесе әйтә:

— Безнең ата-бабадан калган өч бөртек кош йоны бар бит әле, шуны бирсәк ничек булыр икән,— ди. Алтын Кош бу өч бөртек йонны Арсланга бирә:

— Бу йоннарның бик зур хикмәте бар. Син аларны бик саклап тот, беркемгә дә күрсәтмә, үзеңә бик кирәк чагында берәр бөртекләп кенә яндырсаң, синең каршыңа бик матур бер акбүз ат килеп басар,— ди.

Егет, боларга бик зур рәхмәтләр әйтеп, юлга чыгып китә. Алтын Кош, Арслан белән бергә барып, әлеге кәҗәләрне һавадан тартып төшерә башлый, тарткан саен тегеннән алтын мөгезле, көмеш йонлы кәҗә килеп төшеп кенә тора. Йөз кәҗәне бер җиргә туплап: «Менә хәзер алып кайтсаң да ярый»,— ди. Арслан Алтын Кошка бик күп рәхмәтләр укып, үзе бик куәтле бер егет булып, өенә кайтып китә.

Алтын мөгезле, көмеш йонлы кәҗәләрне куып алып кереп китте, ди, бу шәһәр эченә. Шәһәрнең иң зур урамыннан китеп патша сарае янына барып җитүгә, туктата, ди, бу көтүне.

Алтын мөгезле, көмеш йонлы кәҗәләрне күреп җыелды, ди, халык, җыелды, ди, халык, исәбе-хисабы юк, ди. Халык патшаның кече киявен бик ярата икән. Аның куркынычлы сәфәрдән шулай исән-сау әйләнеп кайтуына бөтен шәһәр шатланган, ди.

Арслан шәһәргә килеп кергәндә, патша үзенең теге кияве белән сарае янында йөри икән, ди. Алтын мөгезле, көмеш йонлы кәҗәләрне күреп патша шаккаткан. Патшаның олы кияве хурлануыннан нишләргә белми икән. Ул, халыкның көлүеннән куркып, тиз генә сарайга кереп поскан, ди.

Кәҗәләрне патша кушкан урынга китереп япкан да, ди, Арслан тиз генә теге патша ишегалдындагы кечкенә генә өйгә, хатыны янына кереп киткән, ди. Арсланның хатыны ирен күреп бик шатланган, аны елый-елый каршы алып, болар бергә-бергә хикмәтле ашъяулыктан ашап, эргәнне уйнатып, икесе генә кәеф-сафа корганнар.

Икенче көнне йокыдан торып ашап-эчкәч, Арслан хатынына:

— Бар, әтиең янына кереп сора, ул миңа тагын нинди эш кушар микән? — ди. Патша кызы әтисе янына кереп сорый.

— Киявең: «Бабай миңа тагын да нинди йомыш кушар икән?»— дип әйтте, ди.

— Әй кызым,— ди,— патша,— минем башыма бик зур кайгы төште бит әле,— ди.— Менә мин сезне шушы ике егеткә бирүемә ачуланып, өч ягымнан өч патша миңа каршы сугыш ачты. Минем өч кызыма ул патшаларның өчесенең өч улы бар бит. Сугыш белән киләләр икән, миңа аларга каршы чыгарга кирәк бит,— ди.

Кызы әйтә:

— Көчең җитәрме соң аларга каршы сугышырга? — ди.

— Җизнәң белән без иртәгә таң белән гаскәрләрне алып,— шуларның берсенә каршы сугышка чыгабыз. Син кияүгә әйт,— ди,— әнә минем абзардан алты колачлы ала бияне алып чыгып, шуңа атланып, иртәгә ул да сугышка чыгып карасын әле,— ди,— берәр файдасы тимәсме икән,— ди.

Патша кызы әтисе яныннан күңелсезләнеп кенә чыгып китә. Ире янына кайтып, әтисе әйткәннәрне түкми-чәчми генә җиткерә.

Икенче көнне иртә белән Арслан алты колачлы ала бияне патша абзарыннан алып чыгып атланып китә; хатыны, бик каты елап, күз яше белән озатып кала моны. Патшаның олы кызы, Арсланның сугышка шулай соң гына чыгып китүен күреп, моны хурлап сөйли, көлә: «Синең юләр иреңнән бер эш тә чыкмас, безнекеләр әллә кайчан киттеләр инде, синең ирең барып җиткәнче, сугыш та бетәр»,— ди.

Ярар. Арслан, алты колачлы ала биягә атланып, шәһәр читенә хәтле чыкты да атыннан төште. Шуннан бу Алтын Кош бүләк итеп биргән өч бөртек йонның берсен алып яндыра. Йонның янып бетүе була, моның каршысына көмеш йөгәнле, алтын иярле бер бик сылу акбүз ат килеп чыга. Ияр өстендә алмаз кылычы да бар. Арслан, акбүз атка атланып, сугышка кереп китә. Гаскәр арасына барып керү белән, Арслан иң элек патшаның олы киявен — үзенең хыянәтче иптәшен эзләп таба. Артыннан куып җитеп, башта аны, шуннан соң патшаның вәзирләрен ат өстеннән бәреп төшерә. Тик шуннан соң гына дошман гаскәренә ташлана бу. Дошман гаскәрләрен тар-мар итеп кайтып китә.

Өенә кайтып, ашап-эчеп, әргәнне уйнатып, бик әйбәтләп ял итә бу. Ни гомердән соң гына патша үзенең олы киявен, вәзирләрең ияртеп кайтып керә.

Икенче көнне Арслан хатынына әйтә:

— Бар әле,— ди,— бабайдан барып сора әле син,— ди,—

ул миңа тагын нинди эш кушар икән? — ди. Патша кызы, курка-курка гына булса да, әтисе янына барып керә. Әтисенә әйтә:

— Киявең, бабайның тагын да нинди йомышы бар икән, ди, шуны белеп кайтырга җибәрде,— ди.

— Әй кызым,— ди патша,— кичә безнең бәхеткә бер дә көтмәгәндә әллә кайдан гына бер батыр килеп чыгып, без шуның аркасында гына дошманны җиңеп кайттык. Ул булмаса, безнең эш харап иде,— ди.— Иртәгә,— ди,— таң белән икенче дошманга каршы чыгып китәбез, алты колачлы ала биягә атланып ул да чыкса, бик яхшы булыр иде, — ди.

Патша кызы әтисенең сүзләрен иренә түкми-чәчми кабатлый. Арслан шунда ук атка атланып китә. Бу юлы да хыянәтче дустыннан һәм вәзирләреннән үч ала, аннан соң дошманга ташлана.

Тотына бу дошман гаскәрен кырырга. Моның бабасы: «Бу нинди батыр килеп керде»,— дип, бер читтән генә шаккатып карап тора. Теге яу белән килгән патшаның да бик көчле батырлары бар икән, ди. Арслан, үз янына бөтен халкын җыеп, теге патшаның батырларына каршы сугыша, ди. Батырлары кырылып беткәч, теге патша, мин җиңелдем инде, дип, килешү сораган, ди.

Сугыш бетү белән, Арслан, акбүз атына атланып, өенә кайта. Акбүз атны патша сарае янындагы бер баганага бәйләп куя. Хатыны белән күрешеп, күргән-белгәннәрен аңа сөйләп, хикмәтле ашъяулыктан ашап-эчәләр, әргәнне уйнатып, кәеф-сафа корып бик әйбәтләп ял итәләр, ди, болар. Шуннан соң Арслан йокларга ята. Йокларга ятканда: «Ат янына беркем дә якын килмәсен,— ди,— минем,— ди,— бу көннәрдә рәтләп йоклаганым юк, йокым туйганчы йоклыйм әле мин, үзем тормыйча, уятмасыннар мине»,— ди. Шулай ди дә йокыга китә бу.

Кич җитә. Кич җиту белән генә, патша да сугыштан кайтып керә. Капкадан килеп керү белән, баганага бәйләп куйган атка күзе төшә. Уртанчы кызыннан сорый:

— Бу нинди ат, бу кем аты? — ди.

— Бу безнең ат, киявең менә шушы акбүз атка атланып кайтты,— ди.

Ярар. Патша, теге батырның үз кияве икәнен белеп, харап итә инде бу безне дип, бик нык куркуга төште. Куркуга

төшеп, үзенең барлык олы әфисәрләрен, вәзирләрен чакыртып алды.

— Менә шулай-шулай булган икән, без, олы кияүнең сүзенә карап, Арслан кияүне ким-хур иткәнбез икән,— дип, олы киявен бик каты орышты.

Икенче көнне патша Арсланнан куркып, аның ишегалдыннан үзенең сараена хәтле хәтфә паласлар җәйдереп, Арсланның сарайга килә торган юлларына сакчылар куйдырды.

Иртә белән Арслан йокыдан торуга аңа бик зурлап чакыру җибәрде. Арслан килеп кергәч, патша, моңа бик зурлап баш иеп, аны үз янына утыртты.

— Әй кияү,— ди,— без синең батырлыкларыңны бик яхшы беләбез инде,— ди.— Олы кияү сүзләренә алданып, бик күп азап чиктердек без сиңа,— ди. Арслан әйтә:

— Миңа сезнең санга санавыгыз кирәкми,— ди,— миңа дөреслек кирәк,— ди.

— Соң, кияү,— ди,— олы кияүгә бу эшләре өчен нинди җәза бирергә кушасың син? — ди патша, үземне харап итәр дип курка бит инде.

— Мин аның начар иптәш икәнен юлга чыгу белән үк белдем, иптәш юлда сынала ул,— ди.— Менә монда килү белән, ул мине бөтенләй юк итәргә тырышып йөрде,—ди.— Аңа җәза шул,— ди,— ул минем күземә күренмәсен, бу патшалыктан бөтенләй чыгып китсен,— ди.

Шунда булган барлык халык Арсланның тугрылыгын күреп, батырлыгын мактап, үзләренә патша итеп куйдылар.

4. Тылсымлы әкият төзелешен исегезгә төшерегез. Өч өлеш бәйләнешен «Алтын Кош» әкиятендәге вакыйгалар белән исбат итегез.

ӘДӘБИ ЖАНРЛАР

ХИКӘЯЛӘР

Марсель Галиев

УТЫЗ ТИЕН

Ирәйчек.

— Культпоход оештырыйк, ди. Киноны мин үзем генә дә бик рәхәтләнеп карыйм аны.

— Гел бер-бер нәрсә уйлап чыгара шул.

— Үзен әллә кемгә куя ул.

Үзе югында Светлана турында малайлар шулай сөйләшә.

Дүшәмбе көнне Светлана 3 А сыйныфын җыйды да шундый тәкъдим ясады:

— Әйдәгез, КамАЗ китапханәсенә үзебезнең сыйныф исеменнән китаплар бүләк итәбез. Утызар тиеннән җыешабыз да сатып алабыз. Бүгенгә буфетка кермәсәк тә ярар...

Кызлар Светлананы бердәм хупладылар. Ә малайлар... малайлар да риза булды. Дәрәҗәне төшереп булмый бит инде кызлар каршында.

Кесәсендәге җылынып беткән көмеш акчаларны Данил капшап карады да кульъяулыгы белән төребрәк куйды. Бүген кармак сатып алырга уйлаган иде ул. Юк инде, кармаксыз калып булмый. Тиздән боз кузгалыр. Кабанда балык тотар чак җитәр.

Светлананы уратып алдылар. Китте шаулашу, акча зеңгелдәтү, бәхәсләшү. Бераздан читтә утырып калган Данилны искәреп алдылар.

— Минем... юк,— диде Данил, кызара төшеп,— иртәгә бирермен...

— Иртәгә соң була, әйдә, малайлар, аның өчен үзебез өстик.

Бөтенесе дә тыныч кына үтәр иде югыйсә, шул озын тәнәфес булмаса. Данилны бөтерчек дип йөртәләр иде.

Әй җитез дә инде үзе. Бүген дә аның күзенә ак-кара күренмәде. Кызып шаярган вакытта арткы партада утыручы бүкән Хафиз Данилны лапылдатып идәнгә аударды. Шулчак Данил кесәсендәге акчалар, чылтырап, идәнгә коелдылар. Данил акчаларны җыярга да, җыймаска да белмичә аптырап торды да бераздан иелеп чүпли башлады, чырае темсәрде[1], әйтерсең кесәсенә тараканнар җыеп тутыра иде ул. Беркем дәшмәде, сыйныфта уңайсыз-киеренке тынлык урнашты. Светлана гына:

— Ялганчы!!! — диде дә ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

Дәрес буе үкенеп утырды Данил. «Биргән булсам соң инде, утыз тиен генә иде бит... Кармаклар дигән булып...» Укытучы сүзләре Данилның колагына өзек-өзек ишетелә... «Укучылар, бу формула... Аермасы шунда...»

Укытучы Данилның дәрестән «читтә» йөрүен искәреп алды да, ниндидер бер билгеләмә әйткәннән соң:

— Шулай бит, Данил?! — дип, аңа төбәлеп эндәште.

Үз уе белән мәшгуль булып утырган Данил:

— Утыз тиен генә,— диде, кинәт сискәнеп. Сыйныф дәррәү көлә башлады.

Дәрес бетүгә, Данилның иптәшләре күзеннән югаласы килде. Акчаларын Светланага тәкъдим итәргә инде ул кыймады.

Менә ул ялгызы гына кайтып бара. Үз-үзен аклар өчен, аның кемгә дә булса яхшылык эшлисе, акчаларыннан котыласы килде. Шунда гына ул иптәшләренең нәфрәтен юар иде кебек. Данилның иске йорт ишегалдында уйнап йөргән нәни малайга күзе төште. Шуңа берәр уенчык алып бирергәме әллә? Малайның томраеп торган күзләре ятсынып карый иде.

— Исемең ничек синең, ә?

Малай башын селкеде.

— Йә, әйт инде, әйтсәң, мылтык бирәм үзеңә.

Малай башын селкеде.

— Ы!

— Мылтык кирәк түгелмени сиңа?

Малай башын селкеде.

— Ы!

---

[1] *Темсәрде* — караңгыланды.

Данил нәүмизләнеп[1] китеп барды. Олы мәйдан читендә, керләнгән кар өстендә бер төркем күгәрченнәр йөренә. Данил, башына килгән уйдан сөенеп, чаттагы кибеткә йөгерде.

Менә ул күгәрченнәр арасында. Йөземле күмәчне ваклый да кар өстенә сибә. Күгәрченнәр гөрләшә-гөрләшә чүпләнәләр. Үзен уратып алган күгәрченнәргә карап, Данил онытылып китте. Күңелендә әйтеп булмый торган җиңеллек, рәхәтлек кузгалды. Күгәрченнәрнең барысын берьюлы күккә чөясе, биеккә-биеккә очырасы килде аның.

Биремнәр

1. Данил холкы турында сөйләгез.
2. Данил холкына бәя бирегез.
3. Авторның безгә табарга кушкан теләген дәфтәрләрегезгә языгыз.

О. Генри

ФӘРЕШТӘЛӘР БҮЛӘГЕ

Бу хикәянең авторы Америка язучысы О. Генри белән сез бишенче сыйныфта таныштыгыз. Чирле кыз һәм карт рәссам турындагы «Соңгы яфрак» исемле хикәясенә анализ ясадыгыз. Хыял, өмет, игелек турында иде ул хикәя. Чирле кызның гомерен озайту өчен, тәрәзәгә яфрак ясаган һәм шул чакта үзенә салкын тидереп үлгән искиткеч матур холыклы карт рәссам образын кем оныта алыр икән? Мескен, шул ук вакытта искиткеч ихтыяр көченә ия булган ике кеше язмышын кыска гына хикәя кысаларына бик оста әдип кенә сыйдыра ала. «Фәрештәләр бүләге»нең темасы башка. Ләкин бу хикәя дә кешеләрне бөек итә торган хис — мәхәббәт турында. Хикәя жанрының иң күркәм әсәре белән танышам дип укыгыз.

Бер доллар да сиксән җиде цент. Бар булганы шул. Алтмышы берәр центлылар, калганы эрерәк акча. Бу бакыр акчаларның һәр центы өчен Деллага кибетче, яшелчә сатучы, ит сатучы белән аяк терәп сатулашырга туры килде. Оялудан колаклары ут булып янса да сатулашты ул, акчасын янга

[1] *Нәүмизләнеп* — күңелсезләнеп, боегып.

күбрәк калдырырга тырышты. Нишләсен, иртәгә бәйрәм иде шул — Раштуа бәйрәме.

Иртәгә бәйрәм, ә аның сөекле Джимына бүләк алырга нибары бер доллар да сиксән җиде цент акчасы бар! Айлар буе һәр цент өчен кан калтырап җыеп килде югыйсә, ә баксаң — әнә күпме генә тупланган! Менә хәзер Джимга, аның сөекле Джимына, бүләк эзләргә кирәк, ә акча — нибарысы бер доллар да сиксән җиде цент кына! Нинди дә булса үзгә, кадерле бүләк, аның Джимына азмы-күпме лаеклы булырдай бүләк кирәк. Шундый бүләк алу турында хыяллана-хыяллана күпме бәхетле сәгатьләр кичергән иде бит ул! Делла, тәрәзә яныннан китеп, көзге каршына килеп басты. Аның күзләре ялтырый, әмма йөзендәге кызыллык инде юкка чыккан иде. Бармакларын җитез генә йөртеп, ул чәчен беркеткән кыстыргычларны бушатты да толымнарын таратты.

Әйтергә кирәк, ирле-хатынлы Джим һәм Делланың дөньяда иң зур хәзинә итеп, горурланып саклап йөрткән ике кадерле нәрсәләре бар иде. Берсе — Джимның ата-бабасыннан калган алтын сәгате, икенчесе — Делланың чәче. Әгәр, әйтик, каршы йортта бизәнгән-ясанган патша хатыны яшәгән булса, аны шартлар дәрәҗәгә җиткереп көнләштерү өчен, Делла ханым көн саен тәрәзә каршысына килеп басар иде дә теге күргәндә юеш чәч толымнарын таратып киптергән булып маташыр иде. Әйтик, шул ук каршы йортта иксез-чиксез байлык иясе Сөләйман патша яшәсә, аны үз сакалын йолкыр дәрәҗәдә көнләштерү өчен, безнең Джим да, ул йорт яныннан үткән саен, кесәсеннән юри әлеге алтын сәгатен чыгарып караган булыр иде.

Делланың коңгырт чәчләре, агымсудай ялтырап һәм дулкынланып, җилкәсеннән таралып төште дә аяк балтырына тикле бөтен гәүдәсен каплады. Ханым бераз уйланып торгач, гүзәл чәчен яңадан баш түбәсенә җыярга керешә. Аннары борчылып, икеләнеп хәрәкәтсез басып торды. Иске келәмгә яңаклары буйлап ике-өч тамчы күз яше тәгәрәп төште.

Ханым җилкәсенә көрән төстәге жакетын салды, башына искереп-уңып беткән көрән эшләпәсен киде, күзендәге яшен дә сөртмичә, итәкләрен тулгандыра-тулгандыра, урамга чыкты.

Ул барып туктаган йортка «Чәчтән ясалган һәртөрле бизәнү әйберләре» дигән язулы такта кадакланган иде. Делла икенче катка чабып менде. Хуҗа ханымнан:

— Чәчемне сатып алмассызмы? — дип сорады.

Агымсудай җемелдәп, коңгырт чәч көлтәсе янәдән арка буйлап таралып төште.

Ханым калын-салмак чәч толымын учында тирбәткәләп, авырлыгын үлчәгәндәй итте.

— Егерме доллар.

— Ярар, бирегез тизрәк, — диде Делла.

Шуннан соңгы ике сәгать вакытны Делла кибеттән кибеткә чаба-чаба Джимына бүләк эзләп йөрде.

Йөри торгач, ниһаять, тапты. Нәкъ менә Джимга кирәклесен тапты. Алтыннан коеп эшләнгән, гүзәл сурәтле сәгать чылбыры иде ул. Аны хәтта Джимның алтын сәгате өчен махсус эшләнгән чылбыр диярге дә булыр иде. Бу чылбыр, һичшиксез, Джимныкы булырга тиеш дигән катгый фикергә килде Делла.

Делла кассага егерме бер доллар түләде. Чылбырны алып, калдык сиксән җиде центы белән өенә кайтып китте.

Менә хәзер Джим сәгатен теләсә кем янында чыгарып, вакыт карый алачак. Моңа кадәр менә дигән алтын сәгатен яшереп кенә карый иде, чөнки сәгать тетелеп-кыршылып беткән котсыз бер каеш бауга гына тагылган иде.

Өйгә кайткач, Делла чәч бөдрәләткеч тимер кыскыч алды. Мәхәббәт хисе аркасында киселгән чәчен рәткә китерде.

Бер кырык минуттан аның бөтен башы вак, каты бөдрәләр белән капланды. Хәзер ул дәресенә бармыйча качып калган шук малай кыяфәтенә кергән иде. Делла көзгедән үзен шактый озак карап торды.

«Йа Хода, мине күрүгә Джим йә бәреп үтерәчәк! Йә танымаячак»,— дип көрсенде.

Сәгать җидедә кофе кайнатылды, газ плитәсе өстендә, сарык итеннән әвәләнгән котлетларны көтеп, майлы таба чыжылдый башлады.

Джимның беркайчан да соңарып кайтканы юк иде. Делла, кадерле сәгать чылбырын учына кысып, ишеккә якынрак урындыкка утырды. Күп тә үтмәде Джимның аяк тавышлары ишетелде. Делланы курку басты. Ашыгып авыз эченнән генә: «Тәңрем, үзең сакла, Джимымның күңелен миннән биздерә күрмә!» — дип ялварды.

Бүлмәгә Джим килеп керде. Аның ябык чырае борчулы иде. Егерме ике яшьтә гаилә башы булу җиңел эш түгел шул! Аңа инде күптән яңа пальто юнәтергә вакыт, перчаткасы булмаганлыктан, куллары да туңгандыр.

Джимның күзләре Деллага төбәлде. Ул ишек төбендә тынсыз-өнсез калды. Аның бу күз карашының мәгънәсен һич аңларлык түгел иде. Мондый чакта көтәргә мөмкин булган нәфрәт тә, гаҗәпләнү дә, рәнҗү яисә курку хисе дә юк иде анда. Ул фәкать, үзенә бер төрле сәер, үзгәрешсез чырай белән, күзен алмыйча, Деллага карап тора иде. Хатыны тәмам курка калды.

Менә ул урындыгыннан сикереп торды. Ирен барып кочаклады һәм еларга җитешеп сөйләргә тотынды:

— Джим, сөеклем, зинһар, миңа андый күз белән карама! Мин сиңа бүләк алыр өчен толымнарымны саттым, чөнки бәйрәмдә сиңа бүләк алып бирмәсәм, миңа якты дөнья йөзе харам булыр иде. Син мине ачуланмыйсың бит, әйеме? Чәчем минем тагы үсәчәк, минем чәч бик тиз үсә ул. Чынлап, мин башкача булдыра алмадым, йә, бәйрәм белән котла мине. Әйдә бергәләп шатланыйк. Син минем нинди бүләк алганны белсәң иде!

— Син чәчеңне кистердеңме? — дип сорады Джим, ул әле һаман бу көтелмәгән яңалыкны башына сыйдыра алмый иде.

— Әйе, кистердем һәм саттым,— диде Делла.— Ләкин син мине барыбер яратырсың бит? Чәчем кыскарып калса да, мин үзем үзгәрмәгән, әүвәлгечә бит.

Джим, аптырап, бүлмәне күздән кичерде. Аннары мәгънәсез үҗәтлек белән янә:

— Димәк, хәзер синең озын чәч толымнарың юк, шулаймы? — дип сорады.

— Эзләп маташма, барыбер таба алмассың,— диде Делла.— Әйтәм бит: саттым мин аларны — кистердем дә саттым. Бүген бәйрәм киче, Джим. Минем белән ягымлырак бул, ник дисәң, бу эшне мин синең хакка эшләдем. Минем баштагы чәчне, бәлкем, бөртегенәчә санап чыгарга да мөмкиндер,— дип сүзен дәвам итте ул, һәм аның иркә тавышы кинәт кырыслана төште: — Ләкин беркем, беркем дә минем сиңа булган мәхәббәтемнең зурлыгын үлчи алмаячак! Табага котлет кыздырырга салыйммы, Джим?

Ниһаять, Джим аңына килде һәм, кулларын җәеп, сөекле хатынын кочагына алды. Без исә, тыйнаклык күрсәтеп, берничә секундка аларны үз ирекләренә калдырыйк та нинди дә булса бүтән нәрсә турында гәп сатыйк.

Фәрештәләр бәйрәм кичендә кыйммәтле бүләкләр китерә торган булганнар. Ләкин алар арасында иң кирәклесе күрен-

мәгән. Хәер, томанлы бу кинаябез алда үзеннән-үзе ачыкланыр.

Джим пальто кесәсеннән кечкенә бер төргәк тартып чыгарды да өстәл өстенә ташлады.

— Мине ялгыш аңлый күрмә, Делла,— диде ул.— Озын чәчлеме, кыска чәчлеме син — боларның берсе дә минем мәхәббәтемне киметә алмый. Ләкин менә бу төргәкне чишеп кара әле, ишектән кергән шәпкә минем ни өчен аптырап калуымны шунда аңларсың.

Ап-ак, нәфис, җитез бармаклар төргәкне сүтеп ташлады. Делла соклануыннан кычкырып җибәрде, һәм — йа Хода! — шуның артыннан ук, чын хатын-кызлар гадәтенчә, күз яше, сыктау-ахылдау башланды. Ярый әле гаилә башы, үз кул астындагы барлык чараларны эшкә җигеп, бу елау-сыктауга вакытында чик куеп өлгерде.

Еларлык та иде шул: өстәл өстендә, күз явын китәреп, ташбака кабырчыгыннан эшләнгән һәм вак-вак асылташлар белән бизәлгән өч тарак ята иде. Җитмәсә, төсләре дә Делланың коңгырт чәченә туры килеп тора. Аларның бик кыйммәт икәнен Делла яхшы белә иде, чөнки кайчандыр бик күптән Бродвей кибетләренең берсендә күреп, ул үзе дә аларга бик кызыккан һәм, һичкайчан сатып ала алмаячагын уйлап, озак вакытлар йөрәге әрнеп, пошынып йөргән иде. Менә хәзер шул тараклар аның күз алдында ята, алар — аныкы! Ләкин аларны кадап куяр өчен, аларның гүзәллеге белән сокланыр өчен, чәч толымнары гына юк!

Шулай да Делла таракларны кулына алып күкрәгенә кысты һәм бераздан башын чак кына күтәрде дә, яшь аралаш елмаеп:

— Минем чәчем тиз үсә, Джим! — дип куйды. Аннан кинәт суга төшкән мәче баласыдай сискәнеп китте.

— Йа Хода, оныткранмын да!

Джим әле үзенә дигән бүләкне күрмәде ләбаса! Һәм Делла, ашыгып, иренә таба ачык учын сузды. Делланың күңел түреннән кайнап чыккан самими шатлык хисләре нурында сәгать чылбыры тагы да гүзәлрәк төсмерләр белән уйнап ялтырагандай булды.

— Күрче, Джим, нинди матур! Моны эзләп, мин бөтен шәһәрне әйләндем. Хәзер инде сәгатеңне көненә йөз тапкыр кесәңнән чыгарып карасаң да оят булмас. Чылбыр таккач ничек күренә икән, карыйм әле.

Ләкин Джим хатынының үтенечен үтисе урынга, иске кәнәфигә барып чалкан сузылды да ике учын баш астына куеп көлемсерәп куйды.

— Делла,— диде ул әкрен генә.— Бүләкләребезне хәзергә яшеребрәк куярга туры килер, ахры. Әйдә, вакыты җиткәнче ята бирсеннәр. Әлегә алар безнең өчен артык әйбәтләр. Хикмәт шунда: сиңа бүләккә тарак алыр өчен, мин сәгатемне саттым. Ә хәзер инде котлетларыңны кыздыра башласаң да ярый торгандыр.

Мәгълүм ки, кайчандыр сабый балага бүләкләр китергән изге фәрештәләр гаҗәп тә акыллы җан ияләре булганнар, имеш. Бәйрәм кичендә бүләк бирү гадәте дә шулардан калган, янәсе. Акыллы җан ияләре булганга, аларның бүләкләре дә шундый ук акыллы булган, ягъни бүләк алучы бүләкне үзенә кирәксез санаса, ул аны бүтән нәрсәгә алыштыра алган — аның моңа хокукы булган. Ә монда исә мин сезгә сигез долларлы фатирда көн күрүче ике беркатлы сабый арасында булган акылсыз һәм кызыксыз бер вакыйганы сөйләп бирдем. Аларның беркатлылыгы шунда: алар бер-берсе хакына үзләренең иң кадерле хәзинәләрен корбан итәләр. Ләкин хәзерге заманның акыл ияләренә гыйбрәт рәвешендә шул да әйтелсен: бу икәү — барлык бүләк бирүчеләр арасында иң акыллылары. Әйе, барлык бүләк бирүчеләр һәм барлык бүләк алучылар арасында фәкать шушы ике сабыйга охшаганнары гына үзләрен чын мәгънәсендә акыллы дип саный ала. Һәркайда һәм һәр җирдә шулай. Чөнки алар — үзләре фәрештәләр.

Наилә Вәлитова тәрҗемәсе

Биремнәр

1. Төп персонажларның холкын әйтегез.
2. Хикәягә анализ ясагыз.

Анализ нәтиҗәсе

Мәхәббәт — кешенең гомере буена сузылачак бәхете. Ул сезнең иң кадерле, иң кыйммәтле әйберләрегездән дә кадерлерәк. Джим белән Делла — иң акыллы фәрештәләр, ди автор әсәренең ахырында. Алар әнә шул хакыйкатьне белгәнгә акыллылар. Сез дә акыллы булыгыз, мәхәббәтегезне түкмичәчми саклап тотыгыз, ди автор безгә.

ЛИРИК ШИГЫРЬЛӘР

Искә төшерик. Лирик шигырьнең эчтәлеге — хис. Ә хиснең эчтәлеге сәбәпләрендә. Димәк, лирик шигырь эчтәлеген табу өчен, лирик герой хисенең сәбәпләрен табарга кирәк. Лирик шигырьләргә анализ да, башка жанр әсәрләренеке кебек, өлешләргә бүлүдән башлана.

Марсель Галиев

ИМИН ТОРМЫШ АВАЗЫ

Әти чалгы чүки. Үзе бер моң булып
чыңлый якты урман аланы.
Кошлар сайравына кушыла моң —
бу бит имин тормыш авазы.

Әти чалгы чүки. Такыр башын
кыңгыр салган шундый бирелеп.
Чүкеч биеп йөргән дәртле тавыш
агачларда тора эленеп.

Арфа кылын чирткән кебек итеп
үткенлеген карый чалгының.
— Чәч алырлык булган...
Һәм тотына
тәмен белеп печән чабуның.

Калын покос арасыннан аның
сусыл эзе бара чигелеп.
Өстә тузгый черки өермәсе,
аста кала җиләк сибелеп.

Көйгә салып әти чалгы яный,
маңгаеннан эре тир ага.
Күләгәдә торган ат пошкыра,
башын чайкый, тибенеп ала...

Шушы көннең гади бәхетлеген
(искә төшәр ничә елдан соң)
ат түшеннән кигәвеннәр куып
торган малай белде микән соң?..

Биремнәр

1. Шигырь исеменең мәгънәсен автор беренче строфасында ук әйтә. Хезмәт моңы кошлар сайравына кушыла — имин тормыш

авазы шул, ди. Ләкин шигырь дәвам итә, димәк, исемнең мәгънәсе ачыклана төшәргә тиеш. Анализны дәвам итегез.

2. Соңгы строфаны үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

Сибгат Хәким

БАШКА БЕРНИ ДӘ КИРӘКМИ

Туып үскән шушы җирнең ямен
Алыштырмый икән һичнәрсәң.
Башка берни дә кирәкми,
Үзем чапкан печәннәрне
Бер туйганчы иснәсәм.

Миңа гына шулай тоела микән
Бөтен рәхәтләре соң анын?
Башка берни дә кирәкми,
Үзем тапкан чишмәләрнең
Ятып эчсәм суларын.

Үрләре дә зәңгәр дулкын-дулкын,
Ул үрләрнең чиге кайда соң?
Башка берни дә кирәкми,
Дусларның мин гомерем буе
Тойсам җылы карашын.

1959 ел

Биремнәр

1. Шигырьне өйдә ятлап килегез.

2. Анализ ясагыз: ике өлеш арасындагы сәбәп — нәтиҗә бәйләнешен табыгыз.

ПОВЕСТЬЛАР

Искә төшерик. Повестьларны ике сюжетлы, күп персонажлы хикәя дияргә дә була. Димәк, бу жанрга хикәя сыйфатлары хас.

Повестьларда автор яки персонаж хикәяләвенә игътибар бермә-бер арта.

Бер-берсе белән әледән-әле кисешүче ике яки өч сюжет агышына **сюжет сызыклары** диләр.

Садри Җәләл
(1891—1943)

Садри Җәләл (Садретдин Хәйретдин улы Вәлидов) элекке Тәтеш өязе, Апас авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәдрәсәсендә беркадәр белем алгач, данлыклы Буби мәдрәсәсенә укырга керә. Аннары Казанда Учительская школа тәмамлый. Революция алдыннан солдатка алына. Анда хәрби училищеда белем ала. Кайтып, Арчада укыта башлый. Казанда төрле газета-журналларда эшли. Ләкин барыбер яраткан эшенә кире кайта: сәнгать техникумында татар теле һәм әдәбияты укытуга күчә.

«Дим буенда» исемле күләмле повестен әдип Беренче бөтендөнья сугышы башланган елны ук тәмамлап бастыра. Повесть революциядән соң да аерым китап булып чыга. Элекке заманның яманлыгы, яңа тормышның матурлыклары турында укып туйган кешеләр үчсез, нәфрәтсез мирзалар тормышы эченә кереп сокланалар, гади кешеләрнең шатлыгын һәм хәсрәтен күреп үзләре дә шатланалар һәм кайгыралар. Әсәр сәхнәләштерелгәч, халык театрга ябырыла. Бу әсәр нигезендә хәтта опера да языла.

Ләкин кулакларга каршы көрәшкә күтәрелгән ил дошманлык, нәфрәт турында язылган әсәрләр язуны мәҗбүр итә. Кешеләрнең ихлас хисләре түрәләрне бөтенләй кызыксындырмый. «Дим буе»на халык биргән бәя, киресенчә, аларны куркыта гына. Байлар, мирзалар тормышын мактап язган дип, башта Садри Җәләлне тәнкыйтьлиләр. Аннары дошманга әйләндерәләр һәм 1931 нче елда ук төрмәгә ябып куялар. Әдип дүрт ел буена каторга хезмәтендә интегә. Сәламәтлеген югалткач, салкын кышларын туң җир казый алмас хәлгә

килгәч, 1935 елда гына аны өенә кайтарып җибәрәләр. Өендә ул ике ел дәвалана. Ләкин терелүен көтеп тормыйлар — турыдан-туры төрмә хастаханәсенә озаталар. Төрмә шартларында әдипнең сәламәтлеге начарланганнан-начарлана бара. Садри Җәләл аягына басып тора алмас хәлгә килә, тәмам сукырая. Ике елдан соң аны шул хәлендә өенә китереп ташлыйлар. Шул авырудан әдип терелә алмый, тагы ике елдан үлә. Бер гаепсез Садри Җәләлне репрессия тегермәне шулай харап итә.

Яманлап, гаепләп торуларына да карамастан, язучы кырыктан артык хикәя иҗат итәргә, дистәләгән әсәрне русчадан татарчага тәрҗемә итәргә һәм мәкаләләр бастырырга өлгерә. Аның бер генә әсәрендә дә Совет властена һәм партиягә каршы яман сүз әйткән бер генә җөмләсе дә булмый. Язучының ил һәм халык алдында бер гаебе дә юк. Садри Җәләл гомере буе язмышына буйсынучан, эчендә бураннар уйнаса да, кеше алдында күрсәтми торган сабыр, тыйнак, оялчан, үзенә йөкләнгән эшне намус белән башкаручы кеше була.

ДИМ БУЕНДА

I

Әнә күрәсезме, кояшның җылы нурлары астында, ялтырый-ялтырый, Дим ага.

Әнә аның кырыенда чиксез киң болынлык, аннан ерак та түгел,— таллык.

Әнә еракта Каш беленер-беленмәс кенә булып сузыла; зәңгәрсу һава аша аның өстендәге кара урман төтенләнеп күренә. Якты суның өстендә вәкарь белән[1] генә аккошлар йөзеп йөри; болынлыкта төрле кошлар сайрый; ара-тирә акчарлакларның ачы тавыш белән кычкырганнары ишетелеп китә; күк йөзендә карчыга дигән усал кошның, җентекләп, җирдән үзенә җим карап барганы күренә.

Монда һәрнәрсәдән иркенлек, бәхет аңкый. Бу киң болыннарга карау белән күңелгә: «Мондый матурлык, мондый байлык эчендә адәмнең бәхетсез булуы мөмкин түгелдер»,— дигән уй килә.

---

[1] *Вәкарь белән* — мәһабәт, горурланып.

Әнә тагын еракта Дим буена утырган ике мәчетле зур гына авыл. Якынрак барып карасаң, аның бер читендә урман шикелле куе бер бакчалык күренә. Бакча бик күптән утыртылган булса кирәк: андагы агачлар инде тәмам картайганнар. Бакчага карау белән, аңар инде күптәннән бирле адәм кулы орынмаганын белергә була... Агачлар арасыннан аслыөсле зур гына агач өйнең ташландык хәрабәсе күренә. Аның манзарасы[1] гаять күңелсез: тәрәзәләр такта белән томаланган, түбәсендәге калайларның буяулары күптән уңган. Баскычлар янтайган, морҗаларга чәүкәләр, тәрәзә башларына да күгәрченнәр оялаганнар.

Ишегалдына, йөрүче булмаганга, ямь-яшел чирәм үскән; бөтен җир буш, бөтен нәрсә тын гына нәрсәдер көтә...

Төннәрдә монда бигрәк тә тын була, тик ара-тирә шомлы кош — мәче башлы ябалакның ачы тавышы белән кычкыргалаганы гына ишетелә.

Әбиләр кышкы озын төннәрдә, орчык әрли-әрли, яннарына түгәрәкләнеп утырган балаларга ул хәрабә турында әллә нинди әкиятләр сөйлиләр...

Гомумән, алар бу нигезгә бер тәгъзыйм белән[2] карыйлар һәм яшьләрдә дә шул тойгыны уяндырырга телиләр булса кирәк: урыны чыкканда ул нигезнең әүвәлге хуҗаларының тормышлары, аларның иткән яхшылыклары, башларыннан үткән вакыйгалары турында бик озын иттереп сөйләргә яраталар; шундый бер гаиләнең болай эзсез-нисез юк булуына алар күп вакыт аптырыйлар. Аның сәбәпләрен төрлечә тикшерә башлыйлар һәм актыгыннан тагы, мәгънәле генә итеп: «Булмаса булмый икән инде ул...» — диләр.

II

Картларның сүзе буенча, элек унтугызынчы гасырның ахырларында, бу хәрабә Исхак мирза гаиләсенең кайнап торган оясы булган.

Мирза үзе дәүләтле, фәкыйрьләр өчен һиммәтле[3], бөтенесе белән тәмле телле, йомшак сүзле, икмәк-тозга юмарт, гыйлем һәм дәрәҗә иясе бер кеше булган. Аның ике улы һәм

---

[1] *Манзарасы* — төзелеше.

[2] *Тәгъзыйм белән* — кайгысын уртаклашу, хәленә керү.

[3] *Һиммәтле* — игелекле.

бердәнбер кызы булган. Улының олысы Рөстәм, кечесе Касыйм, кызы да Кәримә исемле булганнар. Мирзаның бикәсе Зөләйха абыстай уртача гына тәрбия күргән простой гына бер хатын була. Ул балаларын бик тә ярата, алар өчен җанын да кызганмый һәм барысын да иң әүвәл үзе тәрбияләп үстерә.

Шул килеш боларның тормышлары тыныч кына уза. Шул елларда гына Исхак мирзаның үзе белән бергә укыган дусты Шаһенгәрәй мирза үлә. Аның бердәнбер кызы Фәридә дә һичбер тәрбиячесез-нисез ятим кала. Анасы инде аның күптән, ул бала чагында ук үлгән була. Исхак мирза сигез яшьлек Фәридәне үз өенә тәрбиягә ала.

Менә шул вакыттан алып кара кашлы, кара күзле, әзһәр йөзле[1], аз сүзле, мөлаем табигатьле Фәридә Исхак мирза гаиләсендә яши, аның балалары белән бергә Уфадан китерелгән урыс кызы мөгаллимәдән укый, Зөләйха абыстайдан төрле догалар, намазлар өйрәнә. Үзе шикелле йомшак табигатьле Кәримә аңар бигрәк тә ошап китә. Чәчрәп чыккан матур, чиксез җитез, үткен Касыймны ул никтер бигүк яратып җиткерми. Киң маңгайлы, саргылт чәчле, соры күзле Рөстәм исә үзенең тынычлыгы һәм һәрвакыт җитдилеге белән аңарда әллә нинди бер олылау хисе уяндыра: ул аны абзасы иттереп таный.

Ул вакытларда Рөстәм — унике, Касыйм — тугыз, Кәримә җиде яшьләр тирәсендә була.

Шул килеш берничә еллар узып китә — мирзаның балалары уйныйлар, укыйлар һәм көннән-көн үсә баралар. Мөгаллимә Лиза ханым рояльдә уйнарга яхшы гына оста була. Ул Кәримә белән Фәридәгә музыкадан да дәрес бирә башлый... Фәридә бөтен көче белән аңарга бирелә. Ул бетмәс-төкәнмәс музыка бүлекләреннән үлгән анасының бишек янында көйләгән моңлы тавышын ишеткән төсле була. Шундый вакытлар була: ул уйный-уйный да ирексез үксеп еларга тотына.

III

Еллар берсе артыннан берсе тигез генә уза — Рөстәм инде унбиш, Касыйм да уникегә чыга. Исхак мирза инде аларны нинди дә булса берәр хөкүмәт мәктәбенә биреп укытырга уйлый. Озак уйлашкан, дус-иш белән киңәшкәннән соң, ул Рөстәмне: «Бусы азрак йомшаграк»,— дип, Казан гимназия-

---

[1] *Әзһәр йөзле* — ак йөзле, бик матур.

сенә, Касыймны да, үткен һәм җитез булганга: «Бусыннан бар да булыр, Ходай кушса»,— дип, Оренбург кадетский корпусына бирергә була.

Башта Рөстәмгә гимназиядә чит кешеләр арасында бик уңайсыз була.

Көннәр узган саен, мәктәпкәияләшә, дәресләрне яратып укый башлый. Ул үз галәмендә үзенең кадерле уйлары белән ялгыз гына яши һәм бөтен нәрсәсен эчендә генә сакларга белә.

IV

Рөстәмнәр укырга киткәннән соң, Исхак мирзаның өе, нәрсә дә булса югалткан шикелле, тын, күңелсез кала. Фәридә алар киткән көнне, атасы үлгән шикелле, уңайсызлык, күңелендә әллә нинди бер авырлык хис итә. Көннәр узган саен, ерактагы Рөстәм аңа якын, кардәш, туган абзасы төсле тоела. Ул күп вакыт төшендә әллә нинди бер чит урманның зур агачлары арасыннан атлап бара торган Рөстәмне күрә. Шул арада каяндыр Фәридәнең анасы килеп чыга да бер Фәридәгә, бер Рөстәмгә карый. Аның йөзе карт агачлар күләгәсеннән бик ачык беленми. Бервакыттан әллә нинди мәче башлы ябалак тавышына охшаган бер тавыш ишетелеп киткән төсле була. Фәридә дә куркып уянып китә. Шул арада аның янындагы Мәүли әби дә уяна. Фәридә:

— Мәүли әбием, җаным, барыбер йоклап булмый, бер әкият сөйләп җибәрче! — ди.

Мәүли әби башта кыстаткан була (аның һәрвакыттагы гадәте ул), аннары гына иске заманнар турындагы озын-озын әкиятләрен тәмле иттереп сөйләргә керешә. Калмый анда әллә нинди шаһзадәләр, калмый анда тулган ай тик матур йөзле хан кызлары. Шаһзадә белән хан кызы, берсен берсе күреп, үләрдәй булып гашыйк булышалар. Ләкин алар бик озак кавыша алмыйлар: әллә нинди кара көчләр аларның кавышуына манигъ[1] булалар. Шуңар күрә алар, Сак белән Сок шикелле, бер-берсеннән аерым яшиләр; кичләрен, бер-берсен сагынып, кан яшьләрен агызалар. Менә шулай төрле мәшәкатьләр күргән, газапланганнан соң, ахырында болар кавышалар...

Иртә белән чәйгә кадәр ул, Кәримә белән Зөләйха абыстайның кушуы буенча, иртә намаз укып ала, чәйдән соң Лиза

---

[1] *Манигъ* — каршылык, тоткарлык.

ханымнан дәрес ала. Инде ул урысчаны тәмам аңлый һәм, дәресләреннән бушангач, мадам Лизадан әдәби китаплар алып укый. Бигрәк тә Пушкинның әсәрләре аңа ошый. Төшләрендә ул «Бакчасарай фонтаны»нда тасвир ителгән Заримә исемле кызның Гәрәй ханны өзелеп яратулары, ханның аны ташлап, поляк патшасының кызы Мариягә гашыйк булулары белән саташып чыга. Ул рояльдә уйнарга көннән-көн остара. Аның кайгылы йөзе көннән-көн матурлана, кара күзләре дә аның көннән-көн мәгънәле, көннән-көн кайгылы карыйлар.

Инде яз якынлаша. Кояш көннән-көн югары күтәрелә, көннән-көн нурларын арттыра. Инде Дим дә дулкынлап-дулкынлап агуыннан туктый: юаш кына, тын гына ага, дөньяга агач күләгәләре аркылы мөлаеманә[1] күлә.

Инде Рөстәм дә укудан кайта. Өйдә тагы шатлык, сөенеч башлана.

Май ахырларында Исхак мирза, Оренбурга барып, Касыймны да алып кайта.

V

Көз җитүгә, Рөстәм белән Касыйм тагы укырга китәләр һәм алдагы җәйне тагы авылда үткәрәләр. Тагы кыш җитә.

Рөстәм бу елны бик нык тырыша, төрле хыялларга күп бирелми. Яз көннәрне, имтиханнарын тәмам биреп бетергәч, авылына кайта. Бу вакыт инде ул унсигез яшенә җиткән бер яшь егет була.

Рөстәмнең кайтуына Фәридә бөтенесеннән артык сөенә. Ул чәй яннарында аның ябык йөзенә, соры күзләренә, акыллы киң маңгаена карап туя алмый. Көннән-көн аның күңеленә Рөстәм иkenче кеше, үлгән атасы белән анасыннан да якын кеше, бер егет булып урынлаша бара... Ул әле үзендә яңа гына уяна башлаган бу яңа тойгыларны ни дип атарга да белми, йокысыз үткәргән кичләрдә: «Миңа ни булды икән?» — дип аптырый, уйлана; тик өченче әтәч кычкырган, сызылып таң аткан чакларда гына йокыга китә.

Төшендә ул тагы «Бакчасарай фонтаны»нда тасвир ителгән Заримәне күрә.

Ул да булмый, бөтенесе күздән юк була. Инде ишегалдында тәмам таң аткан була. Каядыр агачлар арасында, чут-чут иттереп, сандугач сайрап куя. Беравыктан аңар шул ук тавыш

[1] *Мөлаеманә* — мөлаем итеп.

белән икенчесе дә җавап бирә. Фәриданең күңеленә Мәүли әбинең мондый вакытта әйтә торган:

— Алар да, җаннарым, бер-берсенә дәшәләр, алар да шул бергә яшәргә яраталар...— дигән сүзләре килә.

Әйе, ул Рөстәмгә чын күңеленнән гашыйк була, аның сурәте көне-төне зиһененнән чыкмый. Ләкин ул аңар яратканын әйтү түгел, инде чәй яннарында: «Күңелемдәгеен белмәсә ярар иде...» — дип, йөзенә карарга да курка. Рөстәм исә әле һаман да Фәридәгә туганына караган шикелле карый, аны кардәше кебек якын күрә, абзалык мәхәббәте белән сөя, аның озын керфекләре арасына яшеренгән күзләрендәге әллә нинди тирән кайгыларны укып, аны чын күңеленнән кызгана.

Шулай Рөстәм кич белән бакчада ялгыз гына йөргәндә, кинәт аңар таныш рояль тавышы ишетелә. Ул әз генә туктап тора да ирексез шул сәмави тавышлар[1] ишетелгән якка таба бара. Күрә: анда рояль алдында ак күлмәктән Фәридә утыра. Фәридә исә нәзек бармаклары белән һаман уйный. Рояльнең моңлы тавышлары, берсен берсе куа-куа, кичке һавада юк булалар, алар артыннан икенчеләре туалар... Моны күрүгә, Рөстәмнең йөрәге әллә нишләп китә. Ул тыңлап тора-тора да:

— Әмма, Фәридә, матур да уйныйсың соң,— ди, үзе никтер кызарына.

Фәридә аңар ни дип тә җавап бирми, тик башын гына ия. Рөстәм исә:

— Ну ярый, китәргә кирәк,— ди дә китә.

Фәридә тәрәзәдән аның, теге ямьсез тавыш белән борын эченнән генә моңлы көен шыңшый-шыңшый, бакчадагы агачлар арасына кереп киткәнен карап кала. Бу вакыт аңар күктәге йолдызлар бөтенесе көлеп карыйлар, тик урман өстендәге тирән уйга калган айның саргылт төстәге тонык һәм моңсу нурлары аңар тирән кайгы белән карагандай була.

VI

Бер айдан соң Рөстәм, дарелфөнүннең тыйббия бүлегенә[2] керергә дип, Мәскәүгә китә. Аерылган чагында, аталары белән исәнләшкәннән соң, ул озатырга чыккан Фәридәгә:

— Ярый, туган Фәридә, син дә сау бул! — ди.

---

[1] *Сәмави тавышлар* — күктән иңгән тавышлар.

[2] *Дарелфөнүн тыйббия бүлегенә* — университетның медицина бүлегенә.

Бу вакыт ул Фәридәгә чиксез якын, чиксез кадерле, бөтен дөньядан, хәтта тормышыннан да кадерлерәк кебек тоела. Ул аның артыннан дөньяның ар ягына чаклы ияреп барырлык була. Рөстәмнең киткән чагында:

— Ярый, туган Фәридә, син дә сау бул!..— дигән сүзләре берничә көн аның колагы төбендә яңгырап торалар. Бер атнадан соң, хәсрәтеннәнме, әллә булмаса икенче бер сәбәптәнме, ул бик нык авырый, төннәрдә саташа, кызыша, еш-еш үлгән әнисен исенә төшерә...

VII

Рөстәм, Мәскәүгә барып, дарелфөнүннең тыйббия бүлегенә керә. Тырышып дәресләрен укырга тотына, бигрәк тә урыс әдәбиятында булган татарлар хакындагы тарихи китапларны ул яратып укый. Ул Фәридәне башта сагына, ләкин тора-бара аны оныта башлый.

VIII

Җәй җитү белән, ул тагы ике айга авылына кайта. Фәридә белән Кәримә икесе дә буйга җиткән, матурланган булалар.

Фәридә Рөстәмнең кайтуына чиксез сөенә. Көннәр бик кәефле уза башлый. Кайчагында кичләрен Рөстәм Фәридә белән Кәримәне, көймәгә утыртып, Дим өстендә йөртә, үзенчә фәлсәфә сата. Кайчагында кызып китеп:

— Инде укыган бөтен ирләребезгә, бөтен укыган хатыннарыбызга халык арасына чыгып хезмәт итәргә, аларны аз булса да агартырга тотынырга вакыт,— ди.

Шуннан соң үзенең курс бетергәч, шушы Дим буендагы авылларның берсенә доктор булачагын, киләчәктә ничек итеп тора башлаячагын бик якты буяулар белән тасвир итәргә тотына. Фәридә өчен аның авызыннан чыккан һәрбер сүздән мәхәббәт, гөнаһсыз саф мәхәббәт аңкый. Ул аларның барын да үзенә юрый, эченнән генә: «Әйе, шушы Дим буенда бергә яшәрбез: син фәкыйрь авыруларга ярдәм итәрсең, мин дә аларның балаларын укытырмын...» — ди.

Көннәр берсе артыннан берсе тын гына узып тора. Рөстәм буш вакытларда китап укый. Кайчагында алар Фәридә белән икәү генә бакчада йөриләр. Алар инде бер-берсеннән ул чаклы оялмыйлар, ләкин шулай да үзләренең тойгылары турында бер-беренә ләм-мим дә әйтмиләр.

Шул җәйне Рөстәм янына күрше мирзаның егерме ике яшьлек Ибраһим исемле офицер улы килеп-китеп йөри башлый. Ибраһим, килеп-китеп йөрүендә, кичләрен Кәримәнең тавышын мактавында дәвам итә. Озак та үтми, алар Кәримә белән бер-берсен яратышалар. Мирза белән Зөләйха абыстай инде аулакта гына Кәримәне Ибраһимга бирү турында планнар да кора башлыйлар. Көз җитүгә, Рөстәм тагы укырга китә.

IX

Икенче җәйдә Рөстәм Кәримәнең туена ике атнага гына кайтып китә.

Рөстәмгә бу җәйне Фәридә никтер күңелсезләнеп йөргән төсле тоела. Ул күп вакыт берүзе генә күңелсезләнеп бакчада йөри, уйлана, нәрсәдән дә булса курыккан шикелле, як-ягына карана. Инде аның рояльдә уйнаганы да бик аз ишетелә. Үзе ара-тирә йөткергәли иде. Боларны күргәч, Рөстәмдәге аны кызгану хисе тагын да арта. Аның Фәридәне татлы сүзләр белән башыннан сыйпыйсы килә.

Берсендә шулай Фәридә кич белән эңгер-меңгер чагында бакчаның ары башында берүзе уйланып утыра. Аның күңеле киләчәктә үзе өчен нинди дә булса бер начар эш булачагын сизенеп сызлана. Шул арада Рөстәм үзенең ямьсезрәк тавышы белән борын эченнән генә шыңшып агачлар арасыннан килеп чыга һәм Фәридәне күреп туктый:

— Исәнме, Фәридә, монда нишләп утырасың? Әллә авырыйсыңмы, төсең бик киткән,— ди. Фәридә аңар күтәрелеп карый:

— Юк, авырмыйм, болай гына...— ди, шуның артыннан ук ул тагы бер Рөстәмгә карап ала; ул аның күз карашлары белән тавышында үзенә чиксез бер якынлык тоя һәм ирексез әкрен генә:

— Эч поша, Рөстәм абый, чиксез эч поша. Мин нәрсәдәндер, анысын үзем дә белмим, куркам, миңа киләчәгем куркынычлы тоела, никтер елыйсы килә, ләкин инде мин, электәге шикелле, туйганчы елый да алмыйм, сез киткәч инде миңа тагы да уңайсыз була, иптәшкә Кәримә дә булмый. Бөтен өйдә япа-ялгызым калам,— ди.

Рөстәм аның кулыннан тота һәм, әкрен генә, ул мәсьәлә күптән хәл ителгән шикелле бик гади генә итеп:

— Инде, туган Фәридә, син дә ребенок түгел, мин дә, шуңа күрә откровенно әйтергә кирәк, җитәр инде, әле дә байтак

бернәрсә дә әйтми, яшеренеп йөрдек... Әйе, без бер-беребезне яратабыз, мин аны син әйтмәсәң дә беләм, синең прекрасный күзләреңнән беләм, аны яшереп торудан мәгънә юк,— ди.— Син инде ничек тә бер-ике ел түз, аннары бог даст...— дип, сүзен әйтеп бетерми, Фәридәнең кечкенә генә кулыннан чут иттереп үбеп ала. Фәридә исә бу вакыт үзендә һичбер авырлык хис итми...

X

Тагы бер ел узып китте. Бу кыш Рөстәм гаять дәрәҗәдә тырышып укый, шулчаклы ки, яз көне имтиханнардан соң докторлар аңар: «Исәнлегеңә зарар килүе ихтимал, нервларың бик какшаган»,— дип, кымызга барырга киңәш итәләр. Шуңа күрә Рөстәм язын, авылга бармыйча, Оренбур губернасына кымыз эчәргә китә. Касыйм исә авылга кайта. Ул инде матурланган, тазарган, унҗиде яшәр егет була. Матур гына иттереп эчә, очраган матур ханымнарга тәмле генә сүзләр кыстырырга остарган була.

Авылга кайтуына аның күзе Фәридәне күреп кызыша, ул эченнән генә ничек тә булса «бу кошны» кулдан ычкындырмаска карар биреп куя. Ләкин шул арада гына аңар Оренбурга китәргә туры килә.

Көз көне Рөстәм, ярыйсы гына тазарып, Мәскәүгә кайтып тагы укырга башлый. Гыйнвар башларында ул өеннән Кәримәнең баладан үлүе турында хат ала. Рөстәм аның үлүенә бик ул кадәр кайгырып тормый: өйдәгеләргә тәэсирле генә бер мәктүп яза да тагы укуында дәвам итә.

XI

Май урталарында авылга иң әүвәл офицер киеменә киенгән Касыйм кайта, кайтуына тагы, бик тырышып, Фәридә артыннан йөрергә башлый. Үзенең бетмәс-төкәнмәс комплиментлары белән аны бөтенләй аптыратып бетерә. Бу эшкә Фәридә азаплана, ни эшләргә белми. «Тизрәк Рөстәм абый кайтса ярар иде»,— дип, аның кайтуын түземсезлек белән көтә.

Рөстәм исә әле һаман кайтмый. Инде май ахырлары да якынлаша. Берзаман ул, имтиханнарны биреп бетергәч, иленә кайтырга чыга.

Рөстәм юл буе өйдә ничек тора башлавын, Фәридә белән ничек очрашачагын уйлап бара.

Аның кайтуына пристаньга ат килеп торган була. Юлда барганда түгәрәк кенә сакаллы, өреп тутырган шикелле тулы йөзле, тәбәнәк кенә буйлы Хисами кучер Рөстәмнең:

— Соң, Хисами абзый, өйдә тагыниләр бар? Карт нишли, бетеренмәдеме әле? — дигән сөаленә, баштa бик мәгънәле генә итеп:

— Бетерә инде, ул да бетерә: картая, бакчы Касыймны да: «Бик акчаны әрәм итә, юк-бар нәрсә артыннан йөри»,— дип сөйлиләр,— ди.— Касыйм инде күптән кайтты. Ул инде зур үскән, тазарган, матурланган. Теге сездә тора торган Фәридә бар бит әле. Әнә шуның бөтенләй башын әйләндереп бетерде инде, әтиләр күрер, дию дә юк, нитү юк, һаман аның артыннан йөри дә йөри. Беркөн шулай бакчада карап торам. Алдан сүз куешканнар булса кирәк: Фәридәсе бакчаның ары башыннан шулай әкрен генә бара, як-ягына карана, ярый. Шул арада Касыймның да агачлар арасыннан ут шикелле килеп чыкты.

— Ә, җаным Фәридә, синме? — ди.

— Мин,— ди, тегесе әйтә.

— Сине күрүемә мин бик шатмын, җаным Фәридә, — ди, ә Фәридән юри чытланып:

— Җитәр, Касыйм,— ди,— минем белән уйнама,— ди,— нигә син мине болай мыскыл итәсең,— ди,— мин дә ич,— дигән була,— кеше ич! — ди. (Алар һәрвакыт шулай чытлыкланган булалар, ул инде кызларның гадәте.) Касыймың чая: тотты да тегенең алдына тезләнде:

— Җаным, бәгърем...— ди,— мин,— ди,— менә җир йотсын, чәчрәп китим,— ди,— синең белән уйнарга теләмим,— ди,— мин,— ди,— җаным,— ди,— сине бик яратам.— Тагы шунда әллә ниләр, әллә ниләр ди. Малай ничу егет, әйтергә дә түгел... Аннары нәрсә булгандыр, анысын белмим: мине ат җигәргә бай дәшеп алды.

Бу сүзләр төрле якты уйлар белән өенә кайтып бара торган Рөстәмгә ут шикелле нык тәэсир итә, аның йөрәгендә нәрсәдер өзелеп киткән төсле була. Ул, кинәттән бик кадерле нәрсәсен югалткан кеше шикелле, бик аптырап, як-ягына карана; башы тәртипле эшләми башлый, уйлар тарала, күңелгә әллә нинди кызыксыз уйлар килә. Аның күңеле никтер ачына, эченнән генә:

— Нигә соң әле бу болай икән? — ди.

Шуның артыннан ук: «Ул башканы сөя, башка белән йөри»,— дигән уй кылт итеп исенә төшә. Озак та үтми, атлар авылга барып керәләр. Менә инде иске капка да, борын эченнән

генә әллә нәрсәләр мыгырдый-мыгырдый, әкрен генә ачыла... Шул арада аннан-моннан гына киенгән Касыйм килеп чыга:

— Кайттыңмы? Менә рәхмәт! Без инде сине көтә-көтә зарыгып беттек,— ди.

Зөләйха абыстай шатлыгыннан ни әйтергә дә белми; аның улы белән күрешкәндә иреннәре калтырый. Карт мирза улын утырган җирдән каршы ала. Рөстәмнең аның картайганлыгын күреп исе китә. Шул арада ишектән әкрен генә Фәридә дә килеп керә. Ул Рөстәм белән әзрәк кызара төшеп күрешә:

— Исән кайттыңмы, Рөстәм абый? — ди. Рөстәм аны күрүгә башта ирексез шатлана. Ләкин шуның артыннан ук: «Ул башканы сөя, ул әнә шул матур егетне сөя»,— дигән уй аның башына килә. Ул эченнән генә: «Юк инде, мин малай түгел, алдатмам»,— ди. Фәридә белән дә бик гади генә исәнләшә.

Фәридә, аның күз карашын күреп, никтер куркып китә, аңар Рөстәм үзенә ачуланып караган төсле була. Шуның артыннан ук ул: «Юлда арыгандыр, мескен»,— дип, күңелен юата. Бичара, әле ул усал кара көч алдагы көннәр өчен үзенә ниләр хәзерләгәнен бер дә белми.

Озак та үтми, өстәлгә самовар килеп утыра. Рөстәм, бер чит гаиләдә утырган шикелле, үзендә әллә нинди бер авырлык хис итә. Ул кулларын кая куярга белми аптырый. Аның никтер бертуктамый сөйләнеп утырган Касыймга, үзеннән күзен алмый торган анасына, буларын чыгарып кәефләнеп утыра торган самоварга,— кыскасы, каршындагы бөтен нәрсәгә чиксез ачуы килә, гүя бөтенесе аның дошманнары, гүя алар Рөстәмнең иң кадерле нәрсәсен тартып алганнар.

Төнне ул бик уңайсыз уздыра, әллә нинди начар төшләр күрә... Бер юлда барган Хисаминың сузып кына:

— Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е...— дип җырлаганын ишеткән, бер университетта иптәшләре арасында утырган төсле була. Тагы шуның артыннан ук:

— Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е...— дигән тавыш ишетелә...

XII

Рөстәм кайтканнан соң, берничә көн күңелсез генә үтеп китә. Рөстәм һаман уйлана. Ул әле ялгыз гына бакчада йөри, әле су буена төшеп утыра. Касыйм белән бер бүлмәдә ятмас өчен, ул бакчаның аргы башындагы беседкага күчә һәм шунда тора башлый. Кайчагында ул эченнән генә Фәридәгә ачу-

лана: «Нигә инде мине алдарга?» — ди. Шуның артыннан ук үзенең аңар ачуланырга һичбер хакы юклыгын игътираф итәргә[1] мәҗбүр була. Өйдәгеләр аңар карап бөтенләй ни әйтергә дә белмиләр.

Фәридә никтер аның күзенә күренергә, янына барырга, аның белән ялгыз калырга курка. Ул көне-төне:

— Рөстәм абый нигә болай үзгәрде икән? — дип баш вата. Ләкин бер төпле нәрсә дә уйлап чыгара алмый.

Рөстәм кайтканнан соң, биш көн узып китә. Рөстәм һаман беркая чыкмый-нитми, тик үзенең беседкасында яши. Инде ул, бик озак уйланганнан соң, Фәридә белән элеккечә сүзгә керешергә карар бирә.

Беркөнне Касыйм, гадәте буенча, азрак кәефләнгән була. Ул үз-үзенә:

— Хезмәткә китәргә дә инде вакыт җитә, ә мин, ачык авыз, һаман шул Фәридә белән эшне рәтли алмыйм,— ди. Үзе залның бер почмагыннан бер почмагына йөри, үзе эченнән генә: «Әллә инде мин бөтенләй влюбляться иттемме?» — ди, тагын да ачуы килә. Шул арада ул тәрәзәдән бакча эчләп бара торган Фәридәне күрә дә:

— Ни булса да булыр, бүген эшне бетерәм! Алай малайлар шикелле куркырга ярамый,— дип, тиз генә өйдән чыга. Ул, өйдән чыгуына ауга бара торган мәче шикелле, посып кына бакчаның ар башына икенче сукмак белән китә. Фәридә исә бернәрсә дә белми. Ул, инде төннәрен йокламыйча бик күп уйлаган, бик күп азапланганнан соң, Рөстәмне күреп сөйләшергә, аның белән бөтенесен аңлашырга уйлый һәм хәзер дә: «Аны ничек тә аулакта очрата алмаммы?» — дип, бакчага бара. Ул арада булмый, куаклар арасындагы кечкенә сукмактан шпораларын шалтыратып ялт итеп Касыйм килеп чыга һәм, Фәридәне көтмәгәндә очраткан төсле итеп:

— Ә, мамзель Фәридә, сезмени! — ди, килеп Фәридә белән исәнләшә, бик каты итеп аның кулын кыса. Рөхсәт сорапнитеп тормый, аны кысып кына култыгына ала. Фәридә бөтенләй аптырап кала, ни дип җавап бирергә белми.

Алар инде бакчаның ары башына, иң аулак җиренә якынлашалар. Фәридә: «Инде ничек кенә моның кулыннан ычкыныйм икән?» — ди. Шуның артыннан ук:

---

[1] *Игътираф итү* — хаксызлыгын тану.

— Касыйм абый, мине җибәрегезче, минем эшем бар иде! — ди.— Зинһар, җибәрегез мине, җибәрегез дим ич инде! — дип тартына башлый.

Шул арада Касыйм көчле куллары белән аны нечкә гәүдәсеннән кысып кочаклап ала да битеннән үбә башлый. Фәридә кычкырырга тели, ләкин булдыра алмый — инде аның башы әйләнергә, күз аллары караңгыланырга тотына.

Фәридә бераз онытылып тора. Шул арада аның колагына Рөстәмнең борын эченнән генә теге мәгълүм көен шыңшыганы ишетелеп киткән төсле була. Ул тиз генә күзен ача һәм үзеннән биш адым чамасы ераклыкта аптырап катып калган Рөстәмне күреп ни эшләргә дә белми.

— Уй! — дип, бик каты кычкырып җибәрә.

Башта ул Касыймнан ычкынуына Рөстәм абзасына атылырга, аңар Касыймның үзен тәхкыйрь итүен[1], бөтенесен сөйләп бирергә уйлый, ләкин никтер курка һәм кулы белән битен угалап өйгә йөгерә. Касыйм бер йөгереп киткән Фәридәгә, бер үлек төсле ап-ак булган абзасына карый да:

— Черт его знает, что такое? — дип, чырт иттереп, бер төкерә һәм, бернәрсә дә булмаган шикелле, сызгыргалап икенче якка китә. Рөстәмнең энесенә дә, Фәридәгә дә, үзенә дә,— кыскасы, бөтенесенә чиксез ачуы килә. Бу манзараны күргәннән соң, ул Фәридәнең Касыймны яратуына аз гына да шөбһә итми. Ул тиз генә беседкасына бара, караватына йөзтүбән ята. Аның ничек тә булса бу авырлыктан онытылып торасы, аларны күрмәс өчен, беразга гына булса да күзен йомып торасы килә. Инде тышта тәмам караңгылана. Ул аталары янына кичке чәйне эчәргә дә бармый.

XIII

Икенче көнне ул соң гына уяна. Күңелдәге теге авырлык һаман да бетмәгән була. Аның кем белән булса да утырышасы, сөйләшәсе килә. Ул беседкасында аннан-моннан гына чәй эчә дә Хисамига ат җигәргә куша, эченнән генә:

— Шул карт доктор янына барып утырыймчы, беразрак күңел ачылмасмы? — ди. Озак та үтми Хисами:

— Әйдә, киттекме, атлар җигелде,— ди.

Өйлә алларында алар, матур гына су буена утырган кечерәк кенә бер урыс авылына җитеп, хастаханә янындагы җый-

---

[1] *Тәхкыйрь итү* — мыскыллау.

наклы гына бер өйгә туктыйлар. Аларга каршы озын гына буйлы, пеләш башлы, ябык йөзле доктор Соколов үзе чыга.

Менә инде Рөстәм: «Күңел ачылмасмы?» — дип, шушы картка килә. Ул докторның сөальләренә иренеп кенә җавап биргәләп утыра. Доктор:

— Сез, иншалла, чәйне коньяк белән эчүгә каршы тормыйсыздыр бит, эч пошкан чагында ул бик яхшы тәэсир итә,— ди.

Бу вакыт Рөстәмнең күңеленә: «Тукта әле, болай итеп карарга кирәк»,— дигән уй килеп төшә, ул әкрен генә:

— Мөмкин булса, миңа бөтенләй тутырып бер стакан салып бирегез әле,— ди.

Доктор аңар гаҗәпләнеп карый:

— Бу елдагы яшьләрне аңлап бетерә алмассың,— дип, Рөстәмгә берне салып бирә; Рөстәм дә берьюлы аны эчеп җибәрә. Аның инде эчендәге бар авырлыгын шул мөлаем йөзле картка сөйләп бирәсе, аннан киңәш сорыйсы килә. Киная белән генә үзенең бер кызга кечкенәдән үк гашыйк булганын һәм хәзерге көндә аның тарафыннан алданганын сөйли.

Доктор бераз туктап тора да:

— Менә, туган, нәрсә: сүзне озайтуда мәгънә юк. Бер кызның алдавына карап, минемчә, менә сез ни эшләгез: тотыгыз да моннан китегез, ныклап эшкә ябышыгыз. Ә теге кызыгызны бөтенләй истән чыгарырга, авыр булса да онытырга тырышыгыз.

Рөстәм әкрен генә урыныннан тора да:

— Ну, Василий Васильевич, яхшы киңәшегезгә рәхмәт, мин китим, мәшәкатьләгәнем өчен ачуланмагыз,— ди.

Күктәге аксыл болытлар, ерактагы урман белән кырлар — бөтенесе Рөстәмгә бертуктамый әйләнгән төсле тоела. Кайчагында аңар Хисаминың атлар куалаганы, «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е...» — дип сузып җырлаганы ишетелгән шикелле була. Ул кучерның каешланып беткән аркасына мәгънәсез генә бераз карап тора да эченнән генә: «Әйе, үтте инде, бар да үтте...» — ди.

Эңгер-меңгер чагында алар өйгә кайтып җитәләр. Зөләйха абыстай әле һаман эшне аңлап җиткерә алмый. Ул, аптырап:

— Ни булды соң, бәбкәм, сиңа болай? — ди, үзе Рөстәмгә якынрак бара. Шул арада аның борынына эчемлек исе килеп бәрелә. Ул да, кинәттән башына суккан кеше шикелле, бер урында катып кала. Чиксез аптыраган тавыш белән:

— Әй бәбкәм, бәбкәм!..— ди дә туктый.

Рөстәм аның тавышын ишетүгә айнып киткән төсле була, ул аналык шәфкате белән әйтелгән шул сүзләрдән әллә нинди тирән мәгънәләр аңгара. Бу вакыт анасы аңар зерә дә кызганыч тоела, ул нинди дә булса бер сүз әйтергә тели, ләкин булдыра алмый, тик:

— Әни, миңа ачуланма! — ди.

Зөләйха абыстай өйгә керүенә еларга тотына. Ул әлегә чаклы Рөстәмне тәүфыйклы, юаш улы дип йөри һәм, хәзер аның да Касыйм төсле икәнен белгәч, аңар чиксез авыр була. Шул арада аның янына Фәридә килеп керә. Хәзер ул Рөстәмнең ни өчен әчеп кайтканын белә, шуңар күрә аның өчен Зөләйха абыстайдан да бигрәк кайгыра.

Фәридә әкрен генә Зөләйха абыстай янына бара, аңар үзенең елаганын белдермәскә тырышып әкрен генә:

— Еламагыз, дәү әни! — ди.— Мин бик яхшы беләм, Рөстәм абый әчми, ул — безнең барыбыздан да яхшы, барыбыздан да саф кеше. Аның күңелендә нинди дә булса хәсрәте булгандыр... Анакаем җаным, кил, зинһар өчен, аңар ачуланмагыз! — ди, Зөләйха абыстайны кочаклый һәм, аның ачуланмавына бик нык ышанган төсле итеп: — Ачуланмыйсыз бит, анакай? — ди.

Зөләйха абыстайга Фәридәнең сүзләре яхшы гына тәэсир итә. Аның күңеле тынычланган төсле була.

Алар инде икесе дә тынычланалар. Фәридәнең үз сүзләре үзенә тәэсир итә: аңар инде иртәгә Рөстәм абзасына барып бөтенесен сөйләп бирү бик ансат булыр төсле тоела. Ул инде эшләрнең тагы рәтләнәчәгенә, Рөстәмнең үзенә тагын ачык йөз белән карый башлаячагына чынлап ук ышана һәм, шулай татлы хыялларга чумган килеш, таң алдыннан гына татлы йокыга китә.

Шулай яшь йөрәк киләчәк өчен төрле якты уйлар кора, аларга чын күңеленнән ышанып юана һәм алдагы якты көннәрне түземсезләнеп көтә — тәкъдир аңар бөтенләй аның киресен хәзерли.

XIV

Рөстәм иртәгесен соң гына уяна. Аның никтер үзенә чиксез ачуы килә. Ул эченнән генә: «Докторга бару — анысы яхшы эш, ну нәрсәгә инде, сапожник төсле әчеп кайтырга!» — ди. «Әйе, докторның сүзе дөрес, ничек тә моннан ычкынырга,

чынлап эшкә ябышырга кирәк, югыйсә, не дай Бог, монда акылдан язарсың. Бөтенесен ташларга да, бүген-иртәгә кая булса да китәргә кирәк»,— ди. Бик озак уйлагач, иң әүвәл Мәскәүгә барырга карар бирә: «Анда баргач күз күрер әле»,— ди.

Кич алдыннан аның янына Зөләйха абыстай килә. Ул инде эченнән генә күптән узган кичәге эш өчен улын гафу иткән була, тик индедән соң аның андый эш артыннан йөрмәвен үтенергә тели һәм беседкага килеп керүенә йомшак кына тавыш белән Рөстәмнән исәнлек-саулык сораша. Аның тавышын ишетү Рөстәмгә бик каты тәэсир итә; аның Зөләйха абыстайны кочаклап, аңар үзенең алдануларын, бөтен якты өметләренең юкка чыгуын сөйләп бөтенесеннән зарланасы, елыйсы килә... Бу вакыт ул үз-үзенә дә чиксез кызганыч тоела. Ул инде анасыннан гафу үтенеп торырга хаҗәт тә күрми. Бераз тора да:

— Анакай, мин иртәгә беразга Мәскәүгә китәм, азрак эшләр бар иде. Конечно, сез мине җибәрерсез. Мин анда озак тормам,— ди.

Зөләйха абыстай:

— Азрак безнең янда тору кирәк иде,— ди.— Хәер инде, без сине тота алмыйбыз... Китәсең килә икән кит...— ди.

Тагын ул шуның артыннан ук нәрсәдер әйтергә тели дә булдыра алмый, аның еларга теләгән шикелле иреннәре калтырана башлый:

— Җаным-бәгърем Рөстәм, кил, Алла разый булсын, юкбар артыннан йөреп, минем йөрәгемне өзмә. Минем инде Касыйм белән мәрхүмә Кәримә өчен елый-елый да күзләрем калмады,— ди. Рөстәм аны төрле сүзләр белән юата, яхшы булырга вәгъдә бирә.

Зөләйха абыстай киткәч, ул үзендә бер җиңеллек хис итә: «Аллага шөкер, анакай ачуланмаган икән әле»,— ди.

Инде җир йөзен тәмам караңгылык томалый. Кич алдыннан азрак басылып торган яңгыр тагы иренеп кенә ява башлый, салкын җил өрә.

Мирзаның өендә инде ут күренми: бар да йоклыйлар, тик Фәридә генә йоклый алмый. Аның инде башы әйләнгән, уйлары таралган... Аның йөрәген «иртәгә Рөстәм китә» дигән уй тырный. Шуның артыннан ук аның күңеленә «мин инде аның каршында алдакчы, очраган бер ир белән йөри торган начар кыз» дигән уй килә. Бу уй аңар бик авыр тәэсир итә. Ул уйлый-уйлый да: «Ни булса да булыр, хәзер барып, үзенә

бөтенесен сөйләп бирим»,— ди. Һәм шул ният белән ул әкрен генә торып ишегалдына чыга. Бакчада коточарлык караңгы була.

Вак кына яңгыр сибәләп ява, җил өрә, тәрәзә капкачларын шалтырата, бакчадагы агачларны селкетә. Күңелгә әллә нинди куркыныч уйлар килә. Бөтен тормыш шушындый караңгы, суык төннән гыйбарәттер, аны яктырткан бер йолдызың да юктыр төсле тоела... Менә инде ул беседкага да килеп җитә, ләкин туры анда барып керергә курка, иң әүвәл тәрәзәдән барып карый. Күрә: беседканың эче туздырылган. Рөстәм исә идән буйлап әрле-бирле йөренә, кашларын җыерып, нәрсә турындадыр уйлый, үзе борын эченнән генә иләмсезрәк тавышы белән нәрсәдер шыңшый. Фәридә ишек янына барып әллә ничә мәртәбә ача башлый, ләкин ниндидер куәт аны туктата. Ул үзен үзе: «Куркак, булмаган нәрсә!» — дип ачулана. Тагын гайрәтләнеп китеп ишек тоткасын тота, ләкин булдыра алмый. Ахырында суыктан калтыранган, рухы төшкән хәлдә, үзенең уйлары янына өйгә кайтып китә.

XV

Аны озатырга бөтен өй җәмәгате чыга. Бөтенесе белән исәнләшкәннән соң, Рөстәмнең күзе читтә генә «күрешим микән, күрешмим микән» дигән төсле боегып тора торган Фәридәгә төшә. Бу вакыт ул аны никтер кызганып җибәрә һәм, ирексез, ачык тавыш белән: «Фәридә, син дә сау бул!» — ди. Фәридә моны ишетүгә сискәнеп китә, ашыгып кына Рөстәм абзасына кулын бирә һәм каушавыннан бернәрсә әйтә алмый, тик аңар бер тутырып кына карый. Шул арада атлар кузгалып китә. Фәридәнең күз аллары караңгылана башлый, тамак төбенә нәрсәдер килеп тыгыла. Аның бик каты: «Рөстәм абый, мине дә үзең белән алып кит!» — дип кычкырасы, аның артыннан йөгереп барасы килә. Ул тиз генә хәл җыя да үз бүлмәсенә үзенең кара бәхете өчен кайнар яшьләрен агызырга йөгерә.

Көн аяз, җылы, һава да тын була. Атлар һаман чабалар да чабалар. Юл буендагы картаеп беткән каеннар, беленер-беленмәслек кенә итеп башларын селки-селки, Рөстәмнәрнең артыннан карап калалар. Аңар инде күптәннән бирле үзе шулай юлда барган, күптәннән бирле Хисаминың шулай: «Үтте ич рәхәт җәйләре-е-е...» — дип җырлаганын ишеткән, үзенең күптән бөтенесе тарафыннан ташланган, рәхәт, тыныч көннәр

бер дә булмаган төсле тоела. Ул Мәскәүгә баргач ни эшлисен, анда баргач күпме торасын — берсен дә белми.

Озак та үтми, ул Мәскәүдә бер карт докторның кулы астында хезмәт итә башлый. Бер еллар чамасы вакыт узып китә. Шул арада аны Киевка доктор итеп җибәрәләр, ул яңа урынга баруга җитди генә эшкә керешә. Гомумән, ул анда кешегә күп катышмый, үзе генә яшәргә ярата. Бу соңгы вакытларда аны ялгызлык азаплый. Күп вакыт ул үз-үзенә: «Еллар берсе артыннан берсе үтә, кызыксыз гомер һаман кими...» — ди. Янында бер якын кешенең булмавы аны көннән-көн борчый, үзе һаман уйлана: «Әллә булмаса, шул Сарага өйләнергәме?»

Сара дигәне инде анысы егерме ике яшьләр чамасында матур гына бер еврей кызы була. Алар анасы белән икәү генә үз йортларында торалар. Көнкүрешләре аларның ярыйсы гына була.

Рөстәм үзенең өйләнүе турында өйгә бернәрсә дә язмый. Сара башта Рөстәм янында үзен тәмам бәхетле саный. Рөстәм дә үзен бәхетле исәпләргә тырыша, ләкин һәрвакыт аның эчен нәрсәдер тырный, күп вакыт ул ирексез үз-үзенә: «Мин көткәнчә барып чыкмады бу»,— ди.

Ул, Сара белән ялгыз калганда шатланып-сөйләшеп утырасы урында, аның төсен, кыйланышларын Фәридәнеке белән чагыштырып карый. Гомумән, бу соңгы көннәрдә ул Фәридәне еш-еш исенә төшерә. Аш янында Сара гына сөйли, Рөстәм гел күңелсез утыра.

Башта Рөстәм: «Ихтимал, тора-бара мин аңарияләшермен»,— дип, үзен юатырга азапланса да, көннәр узган саен, ул Сарага салкыная бара, никтер ул аны бөтенләй чит күрә. Тора-бара Сара да күңелсезләнә башлый.

Бер ел үтеп китә. Октябрь урталарында Рөстәмгә хат килә. Хатны бу юлы Фәридә яза:

«Сентябрь ахырларында атакай кинәттән үлде,— ди,— хәзер без дәү әни белән өйдә икәү генә калдык, инде ни эшләргә дә белмибез, дәү әни көне-төне елаудан туктамый. «Ичмасам балаларым да янымда юк!» — ди. Бу соңгы айларда Касыймнан һичбер хат-фәлән булмавы аны бигрәк тә борчый. Әгәр дә вакытыгыз булса, үзегез кайтып китсәгез дә яхшы булыр иде, чөнки әгәр дә Гали абый килсә, аның белән гыйнвар ахырларында үземнең Кырымга китүем дә ихтимал: докторлар анда барырга кушалар, сәламәтлегең бик начар, диләр».

Рөстәм бу хатны укуга бөтенләй аптырап китә.

Кич белән Рөстәм, тәмәкесен авызына капкан килеш, арлы-бирле йөренә, тышта җил өргәнне азрак тыңлап тора да тагы теге иләмсезрәк тавышы белән борын эченнән генә шыңшый башлый. Аның күз алдына Фәридә килеп утыра: күңеленнән аның хатындагы «Инде нишләргә дә белмибез...» дигән сүзләре килә, ул, мәгънәсез генә итеп: «Инде нишләргә дә белмибез...» — ди.

XVI

Зөләйха абыстай ни эшләргә дә белми. Рөстәмнең дә болай булып китүе аны бөтенләй аптыраашта калдыра. Почтадан хат китерделәрме, ул коелып төшкән төсле була, калтырана башлый: «Инде тагы ниләр генә яздылар икән?! Атасы ачуланмаса ярар иде!» — ди.

Фәридәнең инде күләгәсе генә кала. Ул көне-төне Рөстәм турында уйлана, аны күреп сөйләшмәгәнлеге өчен үз-үзенә ачулана, юаш кына, акыллы гына Рөстәмнең болай юк-бар нәрсәгә бирелеп китүен бөтен өй эчендә ялгыз ул гына аңгара. Кайчагында аның Рөстәм янына Мәскәүгә барып, аңар: «Әйдә, Рөстәм абый, кайтыйк, ташла боларны барын да: мин сине яратам ич!» — дип әйтәсе килә. Кичләрдә аның күзен йокы алмый. Инде аның рояльдә уйнаган көйләреннән өметсезлек, кара бәхеттән зарлану, ачынып елаулар аңкый. Ул көннән-көн ябыга, көннән-көн саргая бара, ара-тирә йөткергәли дә башлый. Шундый вакытлар була ки, аның бөтенләй артык түзәрлеге калмаган төсле була: башы әйләнә, күз аллары караңгылана, йөрәк еш-еш тибә, бик каты кычкырасы, кемнәргәдер ачуланасы, ничек тә булса шул йөрәкне тырнап тора торган авырлыктан котыласы килә... Мондый вакытларда кинәт кенә аның күңеленә Мәүли әбидән ишеткән: «Хак ни язса, безгә шул булыр, бәлки шатлык көннәр дә булыр...» — дигән шигырь килә. Күңел ни өчендер тынычланган төсле була. «Ихтимал, минем өчен дә якты көннәр килер...» — ди. Һәм ул якты көннәрнең кайчан да булса бер киләчәгенә ныклап ышана вә шуның белән күңелен юата башлый.

Бер ел, ике ел үтеп китә, ә якты көннәр һаман күренми. Көннәрнең берсендә Исхак мирза Мәскәүдән Гали мирза дигән кешедән хат ала. Хатны язучы Гали мирза Фәридәнең атасы мәрхүм Шаһенгәрәй мирзаның якын кардәше булып чыга. «Мәрхүм кардәшем Шаһенгәрәй мирзаның кызы

Фəриданең сездə торганын ишеткəч, үземнең дөньяда икəнлегемне белдерүне бурычым дип белдем,— ди,— бу көнгə кадəр кардəшемне йортыгызда тəрбия итүегез өчен затыгызга чын күңелемнəн рəхмəтлəр укыйм һəм индедəн соң Фəридəгə гаит[1] булган бəгъзе бер мəсьəлəлəрдə миңа мөрəҗəгать итсəгез, аның өчен төрлечə ярдəмдə булуны үзем өчен изге бурычым дип санар идем»,— ди...

Фəридəнең исəнлеге һаман начарланганнан-начарлана бара. Докторлар аның авыруын җитди табалар: «Авыруның тиз көннəн чахоткага əйлəнүе ихтимал, шуңар күрə тизрəк Кырымга алып китəргə кирəк»,— дилəр.

Моның турысында əлеге Гали мирзага хəбəр итəлəр. Озак та үтми, аннан җавап килə: ул гыйнвар ахырларында Фəридəне Кырымга алып китəргə вəгъдə итə.

Соңгы көннəрдə Фəридəне «Рөстəм абый кайтырмы юкмы? Миңа инде ничек карый башлар?» дигəн уй борчый. Ул түземсезлек белəн теге дəү атасының үлүе турысында язган мəктүбенə җавап көтə.

Менə берзаман, гыйнвар ахырларында, көтелгəн хат килеп җитə. «Язсыз кайта алмыйм, яз җитүгə, бөтенлəйгə сезнең янда торырга кайтырмын, Ходай кушса, аңар чаклы ничек тə түзегез инде»,— ди.

Бу хатны укыгач, Фəридəнең эче жу итеп китте. «Гали абый килер дə мине Кырымга алып китəр, тагы Рөстəм абыйны күрə алмам...» дигəн уй аны бигрəк тə борчый, аның күңеленə «Рөстəм абыйны күрсəм, йөткерүем дə бетəр, ябыкканым да, тагы əүвəлге шикелле шат тора башлармын» дигəн уй килə.

Көннəрнең берсендə, өйлə алларыннан капка алдына бер пар атлы килеп туктый. Фəридə тиз генə эченнəн: «Гали мирза шулдыр инде»,— дип уйлап ала һəм, Зөлəйха абыстайга барып: «Дəү əнкəй, нидидер бер кеше килде»,— ди. Кунакны өйгə алып керəлəр. Ул, исəнлек-саулык сорашканнан соң, үзенең Гали мирза икəнен һəм Фəридəне үзе белəн Кырымга алып китəргə килгəнен сөйли. Моны ишетүгə, Зөлəйха абыстай елап җибəрə.

— Соң инде мин Фəридəдəн башка ни эшлəрмен? Миңа үлəргə генə кала инде...— ди. Фəридə дə түзə алмыйча елап җибəрə.

---

[1] *Гаит* — кагылышлы, бəйле.

Гали мирза:

— Карагыз әле монда, Зөләйха абыстай, мин бит аны гомерлеккә алып китмим ич. Аның авыру икәнен үзегез дә беләсез. Менә Кырымда азрак хәл алсын да тагы сезгә кайтыр,— ди.

Сөйләшкәннән-киңәшкәннән соң, иртәгесен өйлә алларыннан юлга чыгарга карар бирәләр. Ул көн Фәридә бик тә күңелсез йөри. Бакчаны берничә кат әйләнеп чыга... Иртәгесен мирза өенә Фәриданең авылдагы таныш кызлары озатырга җыела башладылар, алар барысы да Фәриданең ни өчен кайгырганын белмәсәләр дә, аны кызганалар.

Зөләйха абыстай, елый-елый, Фәридәгә юл киемнәре кидерә. Калтыранган куллары белән аңар яулыкка төргән бер нәрсә тоттыра:

— Мә, бәбкәм, кирәгеңә тотарсың,— ди.

Бу вакытта аңар дөньяда Фәридәдән дә якын кешесе юктыр төсле тоела.

Менә бар да утырып, бик озак иттереп дога кылалар. Менә Фәридә, калын толыпка төренгән килеш, ишегалдына чыга.

Гали мирза калын тавыш белән: «Ярый инде, сау булыгыз!» — ди. Атлар кузгалалар. Фәридә дә аз-аз гына акылын башына җыя. Тиз генә ул үзенең ничә еллар шунда уйнаган, шунда шатланган, көенгән, киләчәк өчен әллә нинди якты планнар корган, ничә еллар рәттән шунда саф мәхәббәт белән газапланган җиреннән китәчәген уйлап ала. Тиз генә түбәсе ап-ак кар белән томаланган өйгә җыелган бик күп хатыннарга, тирән уйга чумган бакчага бер карый, аның йөрәге сызылып киткән төсле була. Ул күңеленнән:

— Бөтенегез мәңгегә сау булыгыз! — ди.

Әнә инде искергән, картайган мәчет тә артта кала. Әнә инде Дим өстеннән чыгалар. Әнә ап-ак кар белән томаланган дала, аның кырыйлары үзалдына төтенләнеп торалар. Кар бөртекләре кояш каршында җем-җем итеп ялтырыйлар. Олы юлның кырыена утыртылган, картаеп беткән каен агачлары берсе артыннан берсе артта кала бирәләр. Алар үзенең сөйгәненә кавышыр өчен ашыга торган бәхетле егетне, бөтен нәрсәсеннән аерылган арестантны да, урманнан утын урлап кайтып килә торган мужикны да, хәлдән тайган җитмеш яшәр фәкыйрь картны да, — кыскасы, бөтен юлчыны шулай салкын кан белән, башларын селки-селки, күздән югалганчы озатып калалар.

Фәридә артына борылып карaганда инде, офыктагы авылның тик мәчет манаралары гына күренә. Хисами ара-тирә җырлый. Рөстәм белән баргандагы шикелле сузып кына: «Үтте ич рәхәт җәйләре...» — ди.

Беренче станцадан ул кире кайтып китә. Фәридә белән күрешкәндә, ул никтер кинәт кенә йомшап китә. Бу вакыт аңар Фәридә чиксез якын тоела, аңар нинди булса бер йомшак сүз әйтәсе, бернәрсәгә дә карамыйча, барып аны кочаклыйсы: «Сау бул, бәбкәм!» — диясе килә. Ул аңар кесәсеннән унбиш тиен акчасын да алып бирергә уйлый, ләкин азрак уйлагач, никтер ул ниятен үзе дә килештереп бетерми. Аның иреннәре калтырана.

Кырга чыккач ул, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, туйганчы елый. Аның күңеленә асраулардан Фәридә турында ишеткән «Ул Рөстәмгә гашыйк булган, имеш, Рөстәм ни өчендер аны ташлап киткән, имеш, Фәридә дә шуның хәсрәтеннән авыруга сабышкан, имеш...» дигән сүзләр килә. Аннары ул тагы җырлый башлый, сузып-сузып кына: «Ай-вай, Зәйнәбе шул, Зәйнәбе-е-е... үтте ич рәхәт җәйләре-е-е...» — ди.

XVII

Фәридә вокзал ишеге өстендәге язудан «Бакчасарай» дигән сүзне укый. Пушкинның «Бакчасарай фонтаны», анда тасвир ителгән Заримә кылт итеп аның исенә төшә.

Поезд кузгалып киткәч тә, ул ап-ак озын манаралар белән ямь-яшел бакчаларына карап бара. «Әнә инде Заримә шул озын агачлар арасында гыйшык уты белән янган, шунда газапланган!..» — ди.

Кырымның матур һавасы, төрле зиннәтле бакчалары, күккә тиеп тора торган кыялары, очы-кырые күренми торган диңгез — берсе дә Фәридәнең күңелен ача алмыйлар: ул үзенең Дим буен, андагы урманнарын, үзенең бакчадагы сөекле урыннарын, һәрвакыт ялгыз гына борын эченнән иләмсезрәк тавышы белән мырлап йөри торган Рөстәмне сагына.

XVIII

Май аенда Рөстәм, Сара белән бөтенләй шунда торырга дип, авылга кайта.

— Мирзаның улы Рөстәм марҗа алып кайткан икән,— дигән хәбәр яшен шикелле тиз арада тирә-якка таралып өлгерә. Зөләйха абыстай да аның бу эшен яратмый.

— Мәрхүм атаң белән без бу малларны бер марҗадан туган бала өчен җыймаган идек тә инде... Ни эшлисең, язмыш шулайдыр инде,— ди.

Рөстәм никадәр аларга игътибар итмәскә тырышса да, үзен әллә нинди бер җинаять эшләгән кеше шикелле хис итә. Авылга кайтканнан соң, ул, үзе дә сизмичә, Фәридә турында еш-еш кына уйлый, залның читендәге рояль дә, бакчадагы агачлар да,— кыскасы, өйдәге бөтен нәрсә аңар Фәридәне искә төшерәләр.

Сара да авылга кайткач бик үзгәрә: Зөләйха абыстайның Рөстәмгә дә, үзенә дә кырын каравы аңар начар тәэсир итә. Ул, уйлаган саен, үзенең Рөстәм белән тора башлавының ялгышлыгына ышана бара.

Зөләйха абыстай көз җитүгә мирзаның хәсрәтеннәнме, бала-чага сагышыннанмы, әллә булмаса картлык авыруыннанмы үлеп китә. Ул үләр алдыннан, Рөстәмне янына чакырып, аңар ачуланмаганын сөйли.

— Рөстәм бәбкәм, кил, зинһар өчен, мине гүремдә тыныч яткыр: шул Сара белән торма...— ди. Тагын ул нәрсәдер әйтергә тели, ләкин «Ф...ә...р...» дигән сүзеннән башкасын аңгарып булмый. Шул көнне ул кич алдыннан җан тәслим итә. Тагын бер ел узып китә. Рөстәм инде ярыйсы гына үзгәрә, картая төшә, яңаклары эчкә бата, йөзләре саргая.

Бервакыт шулай ул, бик эче пошкач, докторга барып бик озак утыра да кич белән генә аннан кайтырга чыга. Берзаман күз ачкысыз буран күтәрелә. Туктыйлар. Буран һаман куәтләнгәннән-куәтләнә бара... Хисами, чана янына килеп, махоркасын тарта башлый. Аннан ары, үз-үзенә сөйләнгән шикелле:

— Моннан ике-өч еллар чамасы элек Фәридәне озатып кайтканда шулай бер адашкан идем, япа-ялгызым кырда кундым,— ди. Шуның артыннан ук Фәридә турында сөйли башлый: — Менә кыз дисәң дә кыз иде, ичмаса! Матурлыкмы дисәң, акыллылыкмы дисәң — бөтенесе килгән иде инде... Бичараның шулчаклы моннан китәсе килмәде. Ә бит беләсең нәрсә: юкка гына бит аны Касыйм белән йөри дип чыгарганнар. Ул Касыйм никадәр ялынса да, төптә аның белән йөрмәгән. Дөрес булса, ул сине сөйгән һәм син киттең бит әле, әнә шуннан соң ул кайгысыннан авыру булган...

Рөстәм арыган, дөньядан туйган, якты көннәрдән өметен өзгән килеш кыр уртасында тора, алга барырга юл юк, тирәяк аның бәхетеннән дә караңгы: җил өрә, буран уйный, әнә Хисами карт җырлый. Ул да яшь чакларын сагына. «Үтте ич

рәхәт җәйләре-е-е...»н сузып тора. Рөстәм дә күңелсез генә: «Әйе, үтте рәхәт җәйләре, бар да үтте...» — ди.

Таң атар алдыннан буран азрак басыла төшә, юлчылар да кузгалып китәләр. Рөстәм юлның юл буена калтырана, үзе бертуктамый Фәридә турында уйлый:

— Ничек соң ул чагында мин бернәрсә дә сизенмәдем?! — ди. Инде ул Фәридәнең гөнаһсыз икәнлегенә аз гына да шөбһә итми.

Менә шул көннән соң аңар дөньяның кызыгы бөтенләй китә. Ул иртәдән алып кичкә хәтле гел Фәридә турында гына уйлый. Сара инде үзе дә аннан тәмам туя. Киевка анасы янына беразга булса да кунакка барырга тели. Рөстәм кайчагында аннан бөтенләй аерылырга уйлый. Ләкин соңыннан: «Ул тагын нинди вөҗдансызлык!» — дип, үз-үзенә ачулана һәм аның турында уйламаска тырыша. Ләкин бу соңгы көннәрдә ул фикер еш-еш кына аның күңеленә килә. Ахырында ул башыннан үткән бөтен эшне — берсен дә калдырмый карт докторга сөйләп бирә: «Инде мин ни эшлим? Зинһар, миңа бер киңәш бирегез, менә бу газаптан коткарыгыз!» — ди.

Доктор, ак сакалын аралаштыра-аралаштыра, бик озак уйлый, трубкасын бик озак иттереп суырып тора да:

— Әйе, нервларыгыз чиксез какшаганнар, сезгә хәзер мөмкин кадәр тыныч яшәргә, әнә ул Сарагыздан да бер дә сырланмый-нитми генә аерылырга кирәк. Барыбер сез аңар рәхәт тормыш бирә алмассыз, ул сезгә. Аның белән торып, сез һаман газапланырсыз, көннән-көн нервларыгыз какшар, менә, шулай итеп, ахырында халык үзенең бер иң файдалы кешесен югалтыр. Аннары сезгә һич юктан бер-ике ай ял итми ярамый, шунда беразга Сараны да Киевта калдырсагыз, бигрәк тә яхшы булыр,— ди.

Рөстәм, бераз уйлап торгач:

— Мин нигә дә Сараны үзем илтеп анда ташлап китә алмыйм, аңар минем көчем җитми,— ди.

Бик озак сөйләшкәннән соң, карт доктор яз җитүгә Сараны үзе Киевка «аналарына кунакка» дигән булып илтергә, юлда бөтенесен аңар бик һәйбәт кенә иттереп аңлатып бирергә, Рөстәмнән аерылуның тиешлеген бик төпле дәлилләр белән исбат итәргә карар бирәләр. Доктор кайтканнан соң, Рөстәм бер-ике айга Кырымга ял итәргә барырга була.

Рөстәм докторның кайтканын түземсезлек белән көтә, аның мөмкин кадәр тиз, Кырымга барып, Фәридәне табасы,

ничек кенә булса да аны күрәсе килә. Доктор кайтуга, ул, дәваланырга дип, ике айга отпуск ала да Кырымга китә. Ул Алушта, Ялта, Алупка шикелле диңгез буендагы бөтен шәһәрләрне йөреп чыга, дачадагы кешеләрдән, докторлардан Фәридәне сораша, ләкин һичбер аны белгән кешегә очрамый. Ул, бөтен нәрсәдән өметен өзеп, өйгә кайтырга җыена башлый. Шул арада ул Алупкада үзе төшкән кунакханәдә кырымлы бер татар бае белән таныша. Бай:

— Ул Гали исемле абзасы белән иеме? — ди.— Алай булса, мин аларны беләм. Алар безнең авылда ике еллап тордылар. Алар моннан өч айлар чамасы элек ватаннарына кайтып киттеләр.

Моны ишеткәч, Рөстәм нишләргә дә белми.

— Тагы аларны куып Мәскәүгә барыргамы? Ә соң алар анда булмасалар?

Кич белән поезд Бакчасарайга беразга гына туктый. Рөстәмнең никтер монда төшәсе килә. Ул монда нишләячәген үзе дә белми һәм аның турында уйламый да, ләкин әллә нинди бер яшерен куәт аны, нәрсәләрен җыеп, вагоннан төшәргә, вокзалдан чыгып, ерактан җем-җем итеп утлары күренә торган шәһәргә барырга мәҗбүр итә. Аңар шул ялтырап утлары күренә торган шәһәр эчендә үзе өчен бик кирәкле бернәрсә бардыр төсле тоела.

Фаэтон зур гына бер йорт алдына барып туктый. Рөстәм, аның «Төп кунакханә» икәнен белгәч, фаэтончыга акча бирә дә каршы чыккан яшь кенә татар хадименә нәрсәләрен алып керергә куша. Аңар кечкенә генә бер бүлмә бирәләр. Ул, караватына барып яту белән, өстеннән бик зур бурычын төшергән кеше төсле тыныч кына йокыга китә.

XIX

Гали мирзаның исәнлеге ярыйсы гына төзәлсә дә, Фәридәнең арткан җире күренми, ул һаман көннән-көн кибә. Шуңа күрә ул хатынына:

— Гел Кырымда торып булмас, инде кайтырга кирәк, безнең Фәридәнең барыбер тереләчәге юк, докторлар: «Аңарда чахотканың иң куәтлесе башланган»,— диләр.

Озак та үтми, алар кайтырга чыгалар.

Пароходта суык тидергәннән булса кирәк, Фәридә поездда бик ныклап авырый башлый. Шуңар күрә Гали мирза Бакчасарайда туктарга мәҗбүр була. Фәридәне кунакханәгә бөтен-

ләй хәлсез килеш алып киләләр. Кич алдыннан Фәридә саташа башлый. Ап-ак чәчле, җыерчыклы битле Мәүли әбине күргән, аның йомшак кына тавыш белән: «Елама, бәбкәм, бәлки шатлык көннәр дә булыр...» — дигән тавышын ишеткән төсле була. Әкрен генә: «Әйе, бәлки, шатлык көннәр дә булыр»,— ди. Якындагылар аны саташа, диләр. Кинәт кенә аның күзләре ачыла. Ул тирә-яктагыларга акыллы гына бер карап ала да тирән генә итеп сулый. Ул күзләре белән кемнедер эзли, ләкин таба алмый. Бу вакыт аның йөзе чиксез газаплануны аңарта. Ул күзләрен азрак йома төшеп һәм кабердән ишетелгән шикелле акрын, ләкин шулай да матур сынык тавыш белән саташып җырлый. Шул актыгы тәһлилен[1] әйтүгә, Фәридә әкрен генә тына. Инде аның мәгъсум[2] рухы бу газап урыны булган җирне ташлап, мәңгелек бәхет, мәңгелек сәгадәт урыны — күккә, үзе шикелле мәгъсум фәрештәләр янына оча...

XX

Икенче көнне кунакханә хадиме юлчыдан кайдагы икәнен сораша. Сөйләшә торгач, Рөстәм аннан-моннан ике-өч айлар чамасы элек шушы кунакханәдә Фәридәнең үлгәнен белә.

Рөстәм, уйланып, бик озак бүлмәсендә утыра, ахырында көндезге сәгать өчләрдә аннан-моннан аш ашый да, теге яшь егетне алып, Фәридәнең каберенә китә. Менә алар шәһәрнең керәле-чыгалы тар гына урамнарыннан баралар.

Менә инде алар, шәһәрдән чыгып, тау өстендәге зиратка җитәләр. Бераз баргач, алар яңа кабер алдына туктыйлар. Ул Фәридәнеке була.

Аның күз алдына Фәридәнең бөтен гомере, аның азапланулары, бөтен гомерендә һичбер рәхәт, һичбер шатлык күрмәүләре килә. Аңар, шулкадәр азапланып янып-янып та, аларның һичбер мәкяфәтен[3] күрмичә үлеп китү зур хаксызлыктыр төсле тоела. «Шулай ук без бары үләр өчен генә яратылган микәнни инде?!» — ди.

Рөстәм иске ханнардан калган, хәзерге көндә «Хан сарае бакчасы» дип йөртелә торган бакчага китә. Бара-бара йөрү-

---

[1] *Тәһлил* — мәет күмгәндә укыла торган дини дога.
[2] *Мәгъсум* — саф.
[3] *Мәкяфәт* — игелек, рәхәтен күрү.

чеэләр сирәкләнә. Һава гаять дәрәҗәдә тын. Тик якындагы бер бакчада скрипка уйнаганы гына ишетелә. Анда туй. Уйнаучы — кырым татарлары арасында сирәк-сирәк кенә очрый торган оста скрипкачы картлардан берсе булырга кирәк. Ул ярыйсы гына оста уйный. Көй ачы чыга. Ул адәм балаларының бүгенгә чаклы никадәр азаплансалар да, тел белән аңгарта алмаган тойгыларын кемгәдер сөйли, ачы, йөрәкне кистерерлек итеп сөйли, аның тавышы тамырлардан йөгерә, югарыга күтәреләсе килә. Уйнаучының йөрәге, дәртенә чыгып җитә алмыйча, скрипканың өстенә чыгып, телләре арасында тиберчеңгән кебек була...

Синең йөрәк күтәрелгәннән-күтәрелә. Ул түзми — скрипка белән бергә елый, сызлана башлый. Тамак төбенә нәрсәдер килеп тыгыла. Нарасый балалар кебек бер үксеп-үксеп елыйсы килә.

Менә берзаман хан сарае мәчетенең мәзине чиктән тыш матур тавыш белән иртәнге азан әйтергә башлый. Аның тавышы музыкадан да ягымлы, сөйкемле тоела, ул бөтен тамыр буенча йөгерә.

Бу музыка, бу матурлык Рөстәмгә шулкадәр нык тәэсир итә ки, ул никадәр азаплануы өчен беренче мәртәбә елап җибәрә. Ул хәзер дөньяда бөтен авырлыкларда үзенә ярдәм итә, булыша торган югары бер көчнең барлыгын адәм балаларының бөтен эшләре, елаулары, шатланулары шул көчкә бәйләнгәнен томанлы гына сизенә.

Шул көнне ул кичке поезд белән өенә китә.

Инде ул авылда тын гына тора башлый. Хастаханәдә бик тырышып эшли. Йомыш белән килгән мужикларга кулыннан килгән кадәр ярдәм итә. Хастаханәдә ул кайчагында килгән авыруларга акыра, ләкин шулай да мужиклар аны яраталар.

Аның дөньяда иң якын ике кешесе була. Берсе — Хисами, берсе — теге карт доктор. Ләкин озак та үтми, алар икесе дә картлыктан үләләр. Рөстәм дә үзенең кылый күзле озын бөдрә чәчле Актырнак исемле эте белән ялгыз кала. Инде ул ярыйсы гына картая.

Кайчагында ул бүлмәсендә китап укып утыра. Менә берзаман Рөстәм, укудан туктап, тәмәкесен тартырга, агара башлаган сакалын чәйнәргә башлый... Үткәндә булган эшләр берсе артыннан берсе аның күңеленә киләләр. Ул теге иләмсезрәк тавышы белән борын эченнән генә шыңшыйсы урында, Хисамидан өйрәнгән җырларын көйли, моңая, үзенең

хәзерге ялгызлыгын уйлый. Озак кына иттереп: «Үтте ич рәхәт җәй-ләре-е-е...» — ди.

Рөстәмнең күңеленә Фәриданең Киевка язган хатындагы: «Инде нишләргә дә белмибез...» — дигән сүзләре төшә... Ул Актырнакка карый да:

— Әйе, инде нишләргә дә белмибез...— ди.

* * *

Еллар уза. Рөстәм инде үлгән була. Касыймның кая икәнен белгән кеше булмый. Тик халык арасында «Сибириядә йөри, имеш, урыс булган, имеш» дигән хәбәрләр генә йөри.

Мирза җирләрен ниндидер ерак варисы, килеп, юк кына бәһасенә авыл халкына сатып китә.

Дим әкрен генә ага да ага, еллар һаман берсе артыннан берсе уза торалар. Гайса мирзаның бакчасы да, өйләре дә инде көннән-көн искерәләр, көннән-көн кайгылы төскә керә баралар. Анда бөтен җир буш, бөтен нәрсә тын гына нидер көтә... Төннәрен монда бигрәк тә тын була. Тик ара-тирә шомлы кош — мәче башлы ябалакның ачы тавышы белән кычкыргалаганы гына ишетелә.

Әбиләр кышкы озын төннәрдә, орчыкларын эрли-эрли, яннарына түгәрәкләнеп утырган балаларга ул хәрабә турында әллә нинди куркынычлы экиятләр сөйлиләр. Картлар исә, аның яныннан узганда, тирән уйга чумган бакча белән ишелеп бара торган өйгә бер карап алалар да, мәгънәле генә итеп:

— Бичара мирзаның балаларына бу нигездә рәхәт күрергә язмаган икән инде!..— диләр, тагын шуның артыннан ук:

— Мал да бар иде, дәүләт тә... Булмаса булмый икән инде!..— диләр. Гомумән, алар бу нигезгә әллә нинди бер ихтирам белән карыйлар һәм яшьләрдә дә шул тойгыны уяндырырга телиләр булырга кирәк. Урыны чыкканда, аның әүвәлге хуҗаларының тормышлары, башларыннан үткән вакыйгалары, аларның иткән яхшылыклары турында бик озын иттереп сөйлиләр; шундый зур бер гаиләнең болай эзсез-нисез юк булуына алар күп вакыт аптырыйлар, аның сәбәпләрен төрлечә тикшерә башлыйлар һәм, актыгыннан мәгънәле генә итеп:

— Булмаса булмый икән инде ул...— диләр.

1914 ел

«Дим буенда» повестенең эчтәлеге

Кешене күңелендәге хәсрәткә әйләнергә генә торучы, шуңа күрә бик кадерләп сакланырга тиешле үтә зәгыйфь матур хисләр бәхетле итә. Шуларның иң гүзәле — мәхәббәт хисе.

Шунысы кызганыч: мәхәббәт чит кешеләрнең яман күзеннән дә, саксыз сүзеннән дә, ямьсез уйларыннан да, хәтта якын кешеңнең салкын карашыннан да үзен саклый алмый. Фәридәнең мәхәббәте шундый. Аның мәхәббәте — кеше гомерендә бер генә мәртәбә туа торган тирән, гүзәл мәхәббәт.

Бу хисне бәхет, шатлык, гүзәллек сыйфатында шиңдермичә ничек сакларга?

Кешене кеше итә торган иң күркәм сыйфат — игелек. Игелек башкаларга риясыз ярдәм итү, мохтаҗ кешеләргә малыңны кызганмау булса, мәхәббәт — игелекнең иң югары дәрәҗәдәгесе, чөнки мәхәббәт — яраткан кешеңә үзеңнең бөтен барлыгыңны бүләк итү ул. Гомер буе яратышып торган ир белән хатын башка кешеләрне дә хөрмәт итә, башка кешеләрнең хисләренә зур ихтирам белән карый, теләсә кемгә игелек итәргә әзер тора.

Рөстәм —ярата белә торган кеше. Ул яраткан кешесенә вакытын, хисен бирергә әзер, ләкин горурлыгын, бөтен барлыгын түгел. Ул үзен барыннан да ныграк ярата. Аның хисенә, мәхәббәт дәрәҗәсенә җитү өчен, игелек җитми.

Садри Җәләл Исхак мирза гаиләсенә бәяне авыл картларыннан бирдерә: алар мирзалар нигезенә ихтирам белән карыйлар, яшьләрдә дә шул тойгыны уятырга телиләр, ди. Исхак мирза белән Зөләйха абыстай, калган гомерләрен тулысынча балаларына багышлап, балаларының бәхетле, тәүфыйклы булып үсүләренә өметләнеп яшиләр. Ләкин көтмәгәндә кызлары Кәримә үлә, уллары Касыйм бозык юлга баса һәм каядыр китеп югала, Рөстәм эчүгә сабыша һәм шулай ук карт эти-әнисен ташлап китә. Өстәвенә үз кызлары кебек яратып үстергән Фәридә чирли башлый. Ата-ананы хәсрәт баса. Бу хәсрәтне алар күтәрә алмыйлар, икесе дә дөнья куялар.

Олы җанлы, киң күңелле авыл халкы Исхак мирза гаиләсенең хәсрәтен ихтирам итә. Кабатлап әйтик, хәсрәтне ихтирам итә.

Әсәрдә ана мәхәббәте сурәтләнгән урыннарның берсен генә искә төшерик. Тәртипле, ипле, сүз тыңлаучан Рөстәм эчеп

кайткач, Зөләйха абыстай шашып кала. Әмма улына куркуын да, хәсрәтен дә, үпкәсен дә күрсәтми. Нибары: «Әй бәбкәм, бәбкәм»,— дию белән чикләнә. Ләкин бу сүзләргә ул йөрәгенә кертеп яшергән бөтен әрнүен, сыкравын һәм шул ук вакытта мәхәббәтен сала. Рөстәм — әнисенең бу хисләрен аның күзләреннән, тавышыннан ук аңларга өйрәнгән бала. Ул әнисен кызгана, ләкин әнисен юату урынына: «Әни, миңа ачуланма!» — дию белән чикләнә.

Рөстәм, гафу үтенергә дип, икенче көнне дә әнисе янына керми. Аның үзен гаепле санавы, гафу үтенүе, гадәттәгечә, күңелендә йомылып кала. Менә шуннан соң автор безнең өчен бөтенләй көтелмәгән, әмма мирза гаиләсе өчен бик табигый булган вакыйга турында яза: Рөстәмне сынар өчен, Зөләйха апаның үзен улы янына кертә. Зөләйха абыстай йомшак кына тавыш белән Рөстәмнән исәнлек-саулык сораша... Нинди генә кимсенүләргә ризалашмый ана йөрәге! Рөстәм әнисен эченнән генә кызгана, ярата, ләкин бу юлы да әнисен юату турында башына да китерми, хисләрен тышка чыгармый. Бу юлы да үзен юату белән генә чикләнә. Шул урынны тагын бер күздән кичерик:

«Аның тавышын ишетү Рөстәмгә бик каты тәэсир итә; аның Зөләйха абыстайны кочаклап, аңар үзенең алданулары, бөтен якты өметләренең бушка чыгуын сөйләп бөтенесеннән зарланасы, елыйсы килә... Эченнән генә бер тавыш аңар: «Синең якын кешең бары шул гына бит инде»,— дигән төсле була. Бу вакыт ул үз-үзенә дә чиксез кызганыч тоела. Ул инде анасыннан гафу үтенеп торырга хаҗәт тә күрми».

Менә шундый хәсрәтле, шатлыклы, үтә зәгыйфь мәхәббәт турында яза Садри Җәләл. Аны язмыш белән тиңләштерә: кеше гомеренең мәгънәсен мәхәббәттә дип саный, әсәрендә бу хиснең гомер бәясе торуын исбатлый.

«Дим буенда» әсәрен язганда, Садри Җәләл яшь егет булган. Бәлки шуңа күрә дә үтә катлаулы, нечкә яшерен бу хисне шулай тәэсирле итеп күрсәтә алгандыр. Ләкин бу яшь егет ата-ана мәхәббәтен дә, аларның уллары өчен җаннарын бирергә әзер торуларын да яшьлек мәхәббәте белән бер биеклеккә куеп сурәтли. Яшь-яшь авторның газаплы, шатлыклы хисләргә соклана белүе гаҗәпкә калдыра. Әсәрне укып чыкканнан соң, авторның үзен яратасы килә, бу гаять дәрәҗәдәге киң күңелле, шәфкатьле, игелекле кешене үзеңнең бер танышың итеп күрәсе килә башлый.

Башка кешеләр кичерешен һәм үз хисен Садри Җәләл беренче чиратта интонация аша ача. Чәчмә әсәрләрдә интонация чаралары азрак була. Ләкин Садри Җәләл әдәбиятның бу төренә дә лирик шигырь генә тудыра алган интонация байлыгы сала алган.

И с т ә к а л д ы р ы й к. Кыскартып әйткәндә, **интонация** дип әдәби әсәрләрдәге эчке көйгә әйтәләр. Интонация сорау, өндәү, хикәяләү төрләренә бүленә. Язучының интонациясе әсәрдән күренеп тормый. Без аны әлеге алымнар аша сизәргә, укыган чакта тоярга тиеш булабыз.

Интонация — язучы стиленең бик әһәмиятле күренеше, укучылар белән самими әңгәмәгә керү өчен теле, күңеленең сүз белән әйтеп бетерә алмый торган ихласлыгы ул. Оста язучы үз хисләренең тирәнлеген, башкаларның фикерләренә, кичерешләренә мөнәсәбәтен һәм бәясен интонация алымнары белән тулырак итеп сөйли ала.

Әсәрдә, мәсәлән, Фәридәнең үз интонациясе бар. Ул салмак кына, йомшак кына, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп сөйли. Аның һәр сүзендә юашлык, курку, оялу посып тора. Ә автор, үз сүзләрен, җөмләләрен кабатлый-кабатлый, Фәридәгә теләктәшлек белдерә. Сөйләү тизлеген арттырганнан-арттыра барып (җөмлә артыннан шул ук фикерне, хисне кабатлап килгән җөмләләрне ирексездән тизрәк укый башлыйсың), тавышын бер куәтләтеп, бер төшереп, хисләр өермәсе тудыра. Фәридә турында сөйли башладымы, һәр җөмләсе белән бу кешегә ярдәм кулы сузасы килүен, үзенең ярдәм итә алмавына үкенүен сиздереп тора. Аннан соң хәл ала — пауза ясый да, башка бүлеккә күчеп, Рөстәм турында сөйли башлый. Рөстәмнең үз эченә йомылып, үз хисләре белән генә мәшгуль булуын борчыла-борчыла хәбәр итә дә пауза ясый, бераз сулыш ала, укучыларга уйлау өчен вакыт бирә, аннары, хисләр өермәсе күтәрү өчен, тагын Фәридә янына әйләнеп кайта. Шулай ике арада интонациясен үзгәртә-үзгәртә Садри Җәләл әсәренең иң әһәмиятле мәсьәләсен — идеясен ачыклый: мәхәббәт — бер кеше хәсрәте яки шатлыгы гына түгел, ул хәтта бөтен бер гомер мәгънәсе генә дә түгел, ким дигәндә, ике гомер мәгънәсе. Мәхәббәт — ул хис кенә түгел, син яраткан, сине яраткан кеше

өчен җаваплылык та, ди. Үз хисләреңә генә йомылып яшәп, башка берәү язмышына кул селтәү — әхлаксызлык, үз хисләреңә дә, яраткан кешең хисләренә дә хыянәт итү, ди.

Мәхәббәт ул — беренче чиратта җаваплылык дигән сүз. Әйдәгез, бу хакыйкатьне онытмыйк.

Садри Җәләл Рөстәмне акылы, әдәплеге өчен, бигрәк тә аны Фәридә яраткан өчен ярата. Ләкин Рөстәмнең Фәридәгә сүз биреп, аны ышандырып та, үз сүзенә, кыз мәхәббәтенә җавапсызлыгын кичерә алмый. Рөстәмне үз үкенечләре, хәсрәтләре белән япа-ялгызын калдыра. Ялгызлык — бик зур җәза ул.

Биремнәр

1. Фәридә холкы турында тулырак итеп сөйләгез.
2. Рөстәм холкы турында тулырак итеп сөйләгез.
3. «Дим буенда» повестеның эчтәлеге» бүлеге әсәргә анализ нәтиҗәләренең бер өлеше генә. Анда төп персонажларның холкы һәм сюжет сызыклары арасындагы бәйләнеш ачыклана. Повестьның тулы эчтәлеген табу өчен, ул гына җитми. Тулы эчтәлек әсәр эчендәге кабатлауларның үзара бәйләнешен һәм мәгънәләрен тапканнан соң тулырак ачыла.
Анализны үзегез теләгәнчә тулыландырып, әсәргә үз бәягезне әйтеп языгыз.

БАЛЛАДАЛАР

Баллада дип сюжетлы моңсу шигырьләргә әйтәләр. Аның сюжеты, гадәттә, тарих яки легенда материалыннан файдаланып төзелә. Чөнки, лирик жанр булып саналса да, эчтәлегендә фикер-фәлсәфә өстенлек итә.

Шәүкәт Галиев

КЫЯ ҺӘМ КЕШЕ

Хәсән Туфанга

Диңгез ярында
Алар икесе;
Торалар бергә —
Кыя һәм Кеше.

Кыя — мәңгелек,
Какшамас, нык таш.
Тамыры белән
Тауларга тоташ.

Ә Кеше япь-яшь,
Үзе бик чандыр,
Күзләре уйчан,
Нигә уйчандыр...

Өермәләрне
Сизми дә Кыя,
Кеше җилдән дә
Чайкалып куя...

Давыллы еллар
Екмасмы аны?
Көрәш диңгезе
Йотмасмы аны?

Эндәшә Кыя:
— Егет-егетем,
Пос син ышыкка,
Тыңла үгетем!

Беләм, карышып
Файда юклыгын...
Эх, булса синдә
Кыя ныклыгы!

Мин бит — мәңгелек,
Какшамас, нык таш.
Тамырым белән
Тауларга тоташ!

Ул көннәрдән соң
Күп еллар үткән.
Дауларда Кеше
Күп юллар үткән.

Кырык давылда
Айкалган Кеше,
Кырык батып та,
Сау калган Кеше.

Чәче — ак дулкын,
Үзе гел чандыр...
Бу якларда ул
Булган кайчандыр.

Бүген дә алар
Тагын икесе:
Торалар бергә
Кыя һәм Кеше.

Күптәнге бәхәс
Инде чишелгән —
Кыя яртылаш
Иңгән, ишелгән...

Сизә карышып
Файда юклыгын:
— Эх, булса миндә
Кеше ныклыгы!..

Сораган Кыя:
— Әйт, Кеше, сөйлә,
Мондый көч синә
Кайлардан килә?

Һәм Кеше әйткән:
— Кыя, кыя таш,
Йөрәгем минем
Халыкка тоташ!

1962 ел

Әсәрне, Кыя һәм Кеше турында дип, ике өлешкә бүлә алабыз. Ләкин эчтәлекне тулырак ачу өчен, «Көчле, нык Кыяның җилдән дә чайкалучы көчсез Кешене кызгануы һәм көчсез Кыяның Кеше ныклыгына соклануы» дип бүлү дөрес булыр.

Автор балладасын күп еллар буена Сталин лагерьларын үтеп, көчле рухын саклап калган халык шагыйре Хәсән Туфанга багышлаган.

Хәсән Туфан кулга алынганчы ук, халык яратып өлгергән талантлы шагыйрь була. Аңа каршы ачылган һөҗүмнең көннән-көн көчәя баруын халык ишетеп-күреп тора. Тиздән кулга алачакларына да берәү дә шикләнми. Шик астына алынган кеше яныннан үткәнеңне күреп калсалар да, «дошман»га әйләнә торган заман — 1937 ел. Хәсән Туфан шундый шартларда«Сүзсез генә» шигырен яза.

Бирем

«Кеше ни өчен кыя таштан ныграк?» соравына җавапны «Сүзсез генә» шигыре эчтәлегеннән файдаланып табыгыз.

Хәсән Туфан

СҮЗСЕЗ ГЕНӘ

Ул көннәрнең кайбер шомлы хәлен
Берничек тә «төшенә» алмагач,
Кабатланмый торган антым булып
Җаннан бүтән нәрсәм калмагач,
Чәчкәләрен койган көнбагыш күк
Иелеп төшкән иде минем баш,—
Кабатланмый торган антым булып
Җаннан бүтән нәрсәм калмагач...

Сиздерден син миңа, туган илем,
Кайбер шомлы, четерек кичләрдә,
Сүзсез генә, күзең белән генә
Исәнләшеп үтеп киткәндә,
Ымладың да ышандырдың мине
Йөрәгеңдә яшим икәнгә,
Сүзсез генә, күзең белән генә
Исәнләшеп үтеп киткәндә...

Үз итүең безне
Шундый көчле:
Кырлар үтә, сулар кичә ул,
Йорттан йортка, телдән телгә күчеп,
Безнең янга килеп җитә ул.
Йөрәкләрне җылы кулы белән
Җанландырып сыйпап китә ул. —
Өйдән өйгә, телдән телгә күчеп,
Безнең янга килеп җитә ул.

Синең шундый җылы күз карашың
Нурландырды боек җанымны.
Бөгелмәслек, иелмәслек итеп
Күтәрдем мин тагын башымны.

1937 ел

Мөдәррис Әгъләмов

СОҢГЫ СҮЗ

Иң беренче зур сугышка керәм бүген,
Иң беренче зур сугышны күрәм бүген.
Идел буйларында якты киңлекләрдә —
зәңгәр күгем,
Зур сугышка керәм бүген.

Көтә мине яр астында инеш,
Суы көмеш.
Мин кайтырга тиеш исән килеш,
Мин кайтырга тиеш.

Мин кайтырга тиеш туган илгә,
Мин кайтырга тиеш туган өйгә.
Сабантуйга алган затлы киемнәрем
калды чөйдә, —
Мин кайтырга тиеш өйгә.

Көтә мине яр астында инеш,
Суы көмеш.
Мин кайтырга тиеш исән килеш,
Мин кайтырга тиеш.

Инде күптән гөрләп ташу акты бездә,
Инде күптән очар кошлар кайтты бездә,
Мин бердәнбер көтеп алган малай идем
нәселебездә,—
Мин кайтырга тиеш өйгә.

Көтә мине яр астында инеш,
Суы көмеш.
Илгә кайтыр өчен исән килеш,
Без җиңәргә тиеш.

1975 ел

Биремнәр

1. Шигырьне вакыйга итеп сөйләгез.

2. Лирик геройның хис-кичерешләрен аңлатыгыз.

НОВЕЛЛАЛАР

Новелла дип кыска хикәягә әйтәләр. Кыска булу сәбәпле, ул персонажларының хис-кичерешләрен дә, катлаулы холыкларын тасвирлауны да үз эченә сыйдыра алмый. Персонажның холкы булырлык бер генә сыйфаты ялтырап ачылып китә. Аның каравы мәзәкләрдәгедәй төзелеше белән хаклы рәвештә мактана ала.

Нурихан Фәттах

ШИФАЛЫ ДАРУ

Доктор янына бер әби килеп керде. Исәнлек-саулык сорашты да буш урындыкка килеп утырды. Шуннан соң ул кесәсеннән пөхтәләп төрелгән бер кәгазь кисәге чыгарды.

— Син язып биргән даруның шифасы тиде, балакаем... рәхмәт төшсен,— диде әби.— Менә тагын килдем әле. Даруыңны яңа кәгазьгә күчереп кенә бирмәссең микән?

Доктор әбинең кәгазен алды да әйләндергәләп карады. Бу, чыннан да, аның язуы иде.

— Шифасы тиде дисең, алайса? — диде ул.— Ничек эчтең соң? Мин әйткәнчә, көненә өч мәртәбә, аш алдыннан берәр аш кашыгы белән эчтеңме?

— Әйе, әйе, аш кашыгы белән эчтем,— диде әби.

— Рецепт кәгазең бик таушалып беткән икән. Яңгырга эләктеңме әллә? — диде доктор.

— Шуның өчен килдем дә инде, балакаем,— диде әби.— Язуы бетте шул. Мин аны тәлинкәдә җебетеп, шуның суын эчкәнием.

1965 ел

Бирем

Новеллада каршылыкта торган ике өлеш булырга тиеш. «Шифалы дару» новелласы мисалы белән исбат итегез.

Госман Бакиров

АРТИСТ

Хәсән ашык-пошык кына чәй эчте дә өстенә киенә башлады.

— Мин киттем, әни!

— Кая барасың кич булгач?

— Клубка.

— Клубка?

— Бүген анда яңа спектакль куела. Мин дә катнашам. Күрәсегез килсә барыгыз!

— Ай Аллам, син дә артист булдыңмыни?

— Артист шул, беркем дә башкара алмый торган рольне бирделәр миңа, менә вәт!

Ул мактанган сыман телен шартлатып куйды да:

— Барырга уйласагыз, соңга калмагыз,— дип чыгып та китте.

Әтисе, «Нишлик, барып карыйбызмы әллә, анасы?» дигән кебек, Хөснижамал апага карап алды. Ул, шуны гына көткәндәй:

— Йокым кала димәсәң карап кайтыйк. Артист булдым ди ич, күрик, ничек маймылланыр икән?

Алар клубка килеп кергәндә, зал шыгрым тулы иде, шулай да алдагы рәткә узып, бала-чаганы урыннарыннан кузгаттылар. Хәсәннәре уйный торган спектакльдә артта утырмаслар бит инде.

Озакламый пәрдә ачылды. Кап-кара мыеклы ферма мөдире сыер савучылар арасында буталып йөрде-йөрде дә, әллә нинди эшләр кушып, күздән югалды. Ул Хәсән түгел иде. Икенче пәрдәдә җырлар, биюләр булды, монда да Хәсән күренмәде. Әтисе белән әнисе бер-берсенә карашып тордылар да:

— Юри әйткән икән, малай актыгы, безне театрга чакыруы булгандыр инде,— дип, соңгы пәрдәне дә карарга булдылар.

Соңгы пәрдә дә бетеп килә, ләкин Хәсән һаман әле күзгә-башка күренми. Тракторчы егет белән фермада эшләүче бер кыз каен төбендә таң атканчы сөйләшеп утырдылар, күктәге йолдызларны да санап чыктылар. Хәсән һаман күренмәде. Таң ату билгесе итеп, сәхнә артында әтәч кычкырды.

— Кикирикү-ү-үк!

Нәкъ чын әтәч инде менә!

Хәсәннең әтисе, чыннан да таң ата мәллә дип, урыныннан ук кузгалды, ләкин юкка гына борчылган икән. Ул әтәчнең чын тавышы булып чыкмады. Шуның белән спектакль дә бетте. Халык ду килеп кул чапты да өйләренә тарала башлады.

Әтисе белән әнисе алдануларын сизенеп кайтырга чыкканда, артларыннан Хәсән килеп җитте...

Бирем

Новелланы язып бетерегез.

САТИРИК ШИГЫРЬЛӘР

Сатирик шигырь тормыштагы ямьсез күренешләрне мактаган булып, ямьсезлекне раслый.

Сатирикларның тагын бер яратып куллана торган алымы — арттыру. Мондый очракта өлешләр болай бүленә: бер якта чиктән тыш арттырып мактау, икенче ягы әсәрдә юк. Аны табу өчен, авторның юри арттыруын аңларга кирәк. Димәк, арттырып мактау эчендә без абайлап алган тәнкыйть ята дигән сүз.

Әхмәт Исхак

БӘРӘҢГЕ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Базарга барырга вакыт
Калмагач, йөгреп кенә
Бәрәңге алырга кердем
Яшелчә кибетенә.
Чираты да юк диярлек.
«Менә нинди шәп!» — димен.
Сатучыга: — Ике кило
Бир, сеңлем, үлчәп,— димен.
Сатучы кыз: — Күбрәк итеп
Ал бер кергән юлны,— ди.—
Ике кило нигә җитә?!
Үлчик, бабай, унны,— ди.
Ә мин әйтәм: — Карчык белән
Без тик икәү яшибез.
Бу ике килоны да без
Бер өч көнләп ашыйбыз.
Мин шулай кайгыртуына
Сокландым сатучының...
Ә кайтып әрчи башлагач,
Хикмәтен белдем моның.
Сеңелнең: — Ал ун кило,— дип
Әйтүе белеп икән:
Яртысы ярым каралган,
Чиреге черек икән.
Ә әрчелгән кабыкларын
Күрсәң исең китмәле!
Өч көнгә дигән бәрәңгем
Бер ашка да җитмәде!
Ашаганда карчык мактый: —
Йа, уңган син, картым! — ди.—
Мондый татлы бәрәңгене
Каян табып кайттың! — ди.—
Алып кайт бер унбиш кило,
Барып иртүк иртән,— ди.—
Бәрәңгесе, бал кук кабып,
Чәй эчәрлек икән! — ди.

Биремнәр һәм сорау

1. Әсәргә анализ ясагыз: икегә бүлегез. Өлешләр арасындагы бәйләнеш үзенчәлеген аңлатыгыз.
2. Шигырь тормышның кайсы ягын тәнкыйтьли?

Шәүкәт Галиев

ЯСЫЙР

Йокыдан торгач Ясыйр,
Көн дә зарядка ясый.
Ясый бик тә яратып,
Бар дөньясын онытып.

Бер урында атлап-атлап,
Каядыр барган итә,
Ух-вух диеп, киерелеп
Утын да ярган итә.
Бер кузгалып, бер тукталып
Яңадан йөреп китә —
Себеркесен селтәп-селтәп
Себергән кебек итә...

Шулай зарядка ясый,
Юына, шәпләп ашый
Һәм хәлдән таеп, арып
Ава ышыкка барып.
Шелтәли ул әтисен,
Шелтәли ул әнисен:
— Файдасын аңламыйсыз,
Зарядка ясамыйсыз!
Кайчан культура керер?! — дип
Ята Ясыйр орышып...

1965 ел

Бирем

Шигырьнең соңгы ике юлын (икенче өлешен) үзегез языгыз.

ПОЭМАЛАР

Поэма — лирик әсәр. Бу яктан ул лирик шигырьләргә охшаган. Шул ук вакытта бу жанр әсәрләрен сюжетлы итеп тә язалар. Бу яктан ул хикәяләргә дә охшый.

Лирик шигырьләргә охшагач, поэмаларга анализ ясап, лирик геройның хис-кичерешләрен табабыз. Ләкин сюжетлы поэмаларны, хикәяләргә анализ ясаган кебек, вакыйгаларга таркатабыз, ә төп герой хисенең сәбәбе аның холкында булырга тиеш, дибез.

ТАНЫШ МОҢНАР

Гармун моңы йөрде урам буйлап

Һәр җир тынган.
Ә син ялгыз гына
Йомшак чәчләреңне тарыйсың,
Ефәк тасма белән үрә-үрә,
Зур көзгегә таба карыйсың.
Ай-һай, гәүдәң бигрәк сылу икән!..
Син үзең дә
«Уф!» дип куйдың,—
Ахры, түзмәдең...
...Ник, матурым, бигрәк моңайганнар
Төн карасы кебек күзләрең?
Аклы ситсы буй-буй күлмәгеңне
Саласың да тагын киясең.
Резидәкәй матур, ни кайгың бар,
Нигә башың түбән иясең?
Өстәлеңдә яткан китапларны,
Дәфтәрләрне укып ардыңмы?
Әллә инде килер көннәреңне
Уйлый-уйлый сүзсез калдыңмы?
Резидәкәй матур,
Яшермәче,
Өй яныңнан җырлап кем үтәр?
Йом күзеңне,
Инде төн үтәр...
Йомшак төн җилләре тын гына
Алып керде аның йөрәгенә
Тальян моңы белән җыр гына:
«Йомшак җилләр булып исәрмен дә
Тәрәзәңне килеп кагармын,
Мин кагармын, син качарсың —
Йөрәгемә утлар ягармын.
Гөлчәчәкләр булып үсәрмен дә
Тәрәзәңә үрелеп карармын,
Мин карармын, син качарсың —
Сөю ялкынында янармын.
Йолдыз булып күккә менәрмен дә
Өй турында балкып янармын,

Мин янармын, син качарсың —
Төсең итеп кемгә багармын?»
Әллә ничек шунда,
Бу матур җыр
Бик таныш та кебек,
түгел дә,
Әллә ничек шунда,
Бу төнге җыр
Дәрт кузгата ярсу күңелдә.
Резидәкәй матур,
Ялындырма,
Гармунчыны ялгыз калдырма,
Йә утлар сип,
Йә сулар сип егет йөрәгенә,—
Яндырма...
Кыз бакчага төште тәрәзәдән.
Ярый әле кеше күрмәде.
Җил,
Син беразга гына шаярмый тор,
Уйнатмый тор аның күлмәген.
Бу матурга түбәнчелек белән
Баш иделәр төнге сиреньнәр.
Кыяр-кыймас кына,
өзелеп-өзелеп
Кыймылдады шулчак иреннәр:
— Зөфәр...
— Саумы, Резидә?..
Ачулансаң, әйдә, ачулан,
Түзәлмичә килдем сагынуыма
Эш киеме белән басудан.
— Килмә, дидем, башка минем янга,
Узма, дидем, безнең урамнан,
Син уйнасаң сузып гармуныңны,
Моңлы күңел белән уянам.
Эштән кайткан чакта, бар авылны
Дәртләндереп җырлап узасың,
Шул җырларың,
Шул моңнарың белән
Йөрәк тынычлыгын бозасың.
— Синең өчен уйныйм гармунымны,
Ачуланма миңа, Резидә...

Саклап йөргән барлык уйларымны
Әйтеп калыйм...
Көч табалмыйм бүген үземдә.
Менә тиздән сызылып таң да атар,
Иртә таң белән Син китәрсең...
(Нинди авыр булыр аерылышу
Җаның сөйгән матур яр белән!)
Беләм,
Китәрсең дә мине онытырсың...
Ләкин
Син киткәнче
Әйтеп калыйм...
— Әйтмә, Зөфәр...
Сүзен әйтәлмичә туктап калды,
Ул оялды, ахры, дәшмәде.
Сүтелмәсәләр дә үргән булды
Ефәк кебек йомшак чәчләрен.
Ничек кенә итеп юатсын да,
Ниләр генә әйтсен ул аңа?
Йөрәгендә туган каршылыкны
Аңлатуы авыр шул аңа.
Керфегеннән аның нурлар тама,
Яшерен сагыш туа күңелендә,
Шушы егет белән аерылышу
Ямансу да кебек, түгел дә.
Ник, ичмасам, үзәкләрне өзеп,
Кулларында гармун булды икән,
Гөлчәчәккә кунган күбәләктәй,
Мәхәббәте килеп кунды икән?
Резидәне көтә институт,
Театрлар, асфальт урамнар,
Шәһәр парклары, яңа дуслар,
Татлы уйлар, татлы хыяллар!
Ә ул кала
Тузан, май эчендә,
Аңламыйча артта каласын,
Менә шуның,
Менә шуның белән
Көчәйтә шул йөрәк ярасын.
Их син, егет,
Ун ел белемеңне

Нигә инде җилгә ташладың?
Килер көннәреңне уйламыйча,
Тракторда эшли башладың?..
Сирень яфраклары соң мәртәбә
Үбәргә дип кызга үрелде...
Күңелең тулып елап җибәрерсең,
Резидәкәй, тизрәк кер инде!..
— Әйтмә, Зөфәр,
Оныт кына мине, уйлама,
Җырларыңны миңа багышлама,
Минем өчен гармун уйнама.
Мин онытмам, Зөфәр, синең белән
Бергә булган матур көннәрне,
Ләкин
Күңелеңә авыр алма, зинһар,
Син тап инде үзеңә тиңнәрне...
— Килдем,
Син киткәнче барлык хисләремне
Әйтеп калырга дип килдем мин.
Сөйдем,
Яшьлегемдә иң беренче тапкыр
Шундый көчле итеп сөйдем мин.
Сөю көче белән тракторым
Алга ыргый, мотор дерелди...
Юк, йөрәгем минем шулай дулый:
«Резидәкәй, сөям сине»,— ди.
Мин бит
Үз эшемне сөю,
Сине сөю белән көчлемен;
Шул көч белән, әгәр кирәк булса,
Тау-ташларны җимерер төслемен.
Ә син мине ике зур бәхеттән
Аерырга, ахры, телисең.
Син боларны әйттең ялгыш кына,
Резидәкәй,
Йә, көл әле?

...Бакча уртасында бер кыз тора,
Маңгай чәчен
Җилфердәтеп җилләр тарыйлар.
Бакча уртасында торган кызның

Керфекләре түбән карыйлар.
Ул күтәрде авыр керфекләрен:
Нишләгәнен белми үзе дә.
— Зөфәр!..
Беркем дә юк... Җилләр генә исә...
Их, Резидә!..
Шушы таңда ялгыз гармун йөрде,
Авыл урамнарын уратып,
Тәүге тапкыр өзелеп сөйгән ярын,
Яшьлек мәхәббәтен югалтып.
Гармун моңы йөрде озак-озак,
Агып керде тып-тын өйләргә:
«Уйныйм әле гармунымны
Үзем белгән көйләргә,
Резидәкәй, өзелә үзәккәй,
Белмим кемгә сөйләргә».

Биремнәр

1. Укыган бүлекнең вакыйгасын үз сүзләрегез белән әйтегез.
2. Йөрәгендә туган каршылыкны
   Аңлатуы авыр шул аңа,—
дип яза автор. Резидә хисләрендәге каршылыкны аңлатыгыз.

Институтка бер кыз килде

...Август иртәсендә
Институтка
Бер кыз килде.
Сумка — кулында.
Ак күлмәктән.
Гүя бер күбәләк
Очып килеп зәңгәр болыннан
Карап тора:
Кунып булыр микән,
Ай-һай биек, диеп бу чәчәк.
Юк,
Бу — чәчәк түгел,
Бу — куаныч,
          шатлык,
                    яшьлек, киләчәк!

*

Ул студент булыр,
Әнисенә
Сөенә-сөенә язар хатларын:
«Әнкәй бәгърем,
Мин бәхетле бүген —
Институтка таба атладым».
Тик нигәдер,
Кайчак шундый моңсу булып китә...
Нәрсә җитми аңа,
ни җитми?
«Көлемсерәп карауларың
Күз алларымнан китми».
Кара чәчле кыска буйлы егет
Көлемсерәп басып тора да
Әллә кая китеп югала.
Югала...
Үзе Резидәнең йөрәгенә
Ефәк тасма булып урала.
Тик шул чакны трактор гүли башлый.
Тузан чыга...
Ул егетнең
Ак тешләре генә күренә.
Бер минутка гына Резидәнең
Мәхәббәте тагын сүрелә.
...Резидәбез менә имтиханда,
Каушый-каушый ала билетын,
Билет, билет,
Бик үк авыр булма —
Якынайт син бәхет минутын...
Нишләдең син,
Нишләдең син, сеңлем Резидә?..
Ул өстәлдән башын күтәрде дә
Яшь аралаш өзелеп карады.
«Белмим... абый...
бу сорауны белмим...»

Зөфәрнең Резидәгә язган хаты

Тракторым гөрли,
Син Резидә,
Яратмыйсың аның тавышын.

Шушы тавыш мине алга әйди,
Баса төшә сөю сагышын.
Теләкләрем буразналар булып
Уелып кала туган җирләрдә,
Хыялымда инде ишелеп уңган
Ашлык дулкыннары тирбәлә.
Нинди рәхәт гади эшең өчен
Кешеләрдән рәхмәт ишетү
Һәм үзеңне
Тормыш, илең өчен
Кирәк кеше итеп хис итү!..

Резидәнең күңел дәфтәреннән

Барысы бетте.
Яшьлек хыялларым
Чәчәк атмады.
Күзләремне,
Дәртле күзләремне
Яшьләр каплады.
Беләм. Юатырлар...
Нигә кирәк хәзер юату...
Нигә кирәк
Көйрәп-көйрәп
Янган йөрәгемә ут ату...
Институт!
Юкка гына
Биек баскычыңнан үрләдем.
Залларында,
Шаулы залларында
Бәхетем калыр диеп белмәдем.
Хәзер,
Үкси-үкси,
Туган авылыма кайтыйммы?
«Әни, нишлим,
Вузга керәлмәдем,
Юат мине»,— диеп әйтимме?
Китәм... киткән юлларымда
Гөлләр сулалар...
Су сипсәң дә, үсмәс шул алар...

Бу шәһәрдә белмим беркемне дә

Бу шәһәрдә белмим беркемне дә,
Узучылар таныш түгелләр,
Бер ялгызым йөрим урамнарда,
Күтәрелмәс инде күңелләр.
Алсу йөзем нурлы булмас инде,
Юатмагыз гына, туганнар.
Кайчан, кайчан
 минем күз алдымнан
Таралырлар икән томаннар?
Бакчаларга керәм,
Яшел бакча
Август кояшында коена.
Кояш көлә...
Ләкин һәммә нәрсә
Миннән көлгән кебек тоела.

3. Резидәнең хис-кичерешләре ничек үзгәрүе турында сөйләгез.

«Без көтәбез, кичкә килерсең»

Классташлар,
Ике ай булмады,
Сагынырга инде өлгердем.
Кайберегез сезнең студенттыр,
Кайберегез,
Бәлки, минем кебек йөридер.
Бергә укып йөргән дусларымның
Очратырга иде берәрсен...
Бетәр иде хәсрәт-сагышларым,
Рәхәт булыр иде сөйләшү...
Уйларымны белеп торган кебек,
Шулчак
Сөмбел килеп чыкты алдыма.
Шатлыгымнан белмим нишләргә дә —
Үзен кысып кочып алдым да
Түзмәдем —
Күңелем тулып елап җибәрдем.
— Резидәкәй җаным,
Әй сагындым, ә син?
Тукта инде, елама.
Нинди җил ташлады бу якка?

— Сорама.
Син сорама, Сөмбел, ул хакта,
Үзең аңла...
Авыр, авыр миңа
Искә төшсә әгәр ул чаклар...
Ул аңлады,
Башка сорамады.
— Ә мин,— диде,— эшлим заводта.
Сменага барыш. Ачуланма.
Үтеп бара икән вакыт та...
— Син заводта?!
Гади эшче булып?!
Шаяртма ла инде.
Юк! Булмас...
— Нигә гаҗәпләндең?
Минем белән
Бергә эшли Роза һәм Ильяс.
Ярый, дускай,
Вакыт җитә инде.
Без китәбез, кичкә килерсең.
Ышанмасаң, барып,
Барсын-барсын
Үз күзләрең белән күрерсең.

Резидәнең әнисенә язган хаты

Әнкәй бәгърем, син рәнҗемә,
Сизә күңелем,
Сөйгән Резидәңнең сүзләренә
Йөрәгеңнең риза түгелен.
Дуслар чакыралар үзләренә,
Күп уйладым,
Белмим нишләргә.
Ахыр чиктә инде риза булдым
Бер заводка кереп эшләргә.
Бу заводта бер ел гомеремне
Ничек кирәк, алай үткәрим.
Әнкәй, зинһар,
тыңла инде, яме!
Калмыйммын бит монда күпкә мин.

4. Резидәнең хис-кичерешләре ничек үзгәрүе турында сөйләгез.

Күңел дәфтәренең дәвамы

Китәрмен дә бик тиз онытырмын
Дигән идем...
Ә нигә соң шулай уйланам?
Шул егетне, гармун тоткан килеш,
Төшләремдә күреп уянам.
...Резидәкәй,
Салкын күзләр җитә,
Су сип гөлләреңә,
        корытма.
Син бит аны үзең ташлап киттең,
Оныт аны...
. . . .
Юк, юк, онытма!..

Шундый рәхәт миңа

Маңгаемнан кайнар тирләр ага,
Арыганмын,
Талган кулларым.
Әмма
Шатлыгымнан елмаям мин,
Шундый рәхәт миңа, дусларым!
Кулбашларым сызлый, баш әйләнә,
Кара таплар — алсу йөземдә.
Шул вакытта әйтеп бетергесез
Көч артуын тоям үземдә.
Станоклар шавы уртасында
Басып торам.
Дуслар, килегез!..
Үз хезмәтем кергән иң беренче
Деталемне менә күрегез!
Җыелдылар дуслар — иптәшләрем,
Минем өчен алар шатланган.
«Болай булгач була!» — дигән кебек,
Хәмит абый сөя аркамнан:
Кыенлыклар алда бик күп әле,
Син шуларга, кызым, әзерме?
Бүгеннән соң синең һәр минутың
Завод өчен кыйммәт, кадерле.
Бөтен цехка кычкырасым килде.

(Кычкырсам да гаеп итмәсләр!..)
Мин булдыксыз түгел,
мин эшләрмен,
Ышаныгыз миңа, иптәшләр!..

5. Резидә хисе тагын үзгәрде. Ничек үзгәрде?

Сөю хисен җиңеп буламы?

Ул егетне үзем ташлап киттем,
Үзем уйлыйм иртә-кичләрен,
Үзем сөйдем аны, үзем качтым,
Нишләдем мин, дуслар, нишләдем?
Тирән сагынуымны басалмаган,
Йокламаган төннәр күп була.
Айлы төндә, гармун уйный-уйный,
Зөфәр җырлап килгән күк була.
Сөмбел җаным,
Сөйлә ни булса да,
Юкмыни соң бер дә серләрең?
Гомер-гомерлеккә яр булырлык
Бармы синең өзелеп сөйгәнең?
Сөйгәнеңне бик нык сагынганда,
Нигә моңсу була таң ату?
Әйтче, Сөмбел, нигә шулкадәрле
Көчле була икән ярату?
Кайнар йөрәгеңә каршы барып,
Сөю хисен җиңеп буламы?
Иң беренче яшьлек мәхәббәтем...
Ничек итеп онытыйм мин аны?

Резидәнең әнисенә язган хаты

Кайтыр юлларыма карый-карый
Чыгасыңдыр таңнар атуга.
Бик күрәсең килсә,
бик сагынсаң
Чык та, әнкәй, иркен басуга
Язгы ташкын кебек шау-гөр килгән
Хезмәт җырын туктап тыңлап тор,
Шул чагында, кырлар яңгыратып,
Җырлый-җырлый узар трактор.

Без эшләгән трактор гөрләвеннән
Резидәнең җырын ишетерсең.
Авыл буйлап:
«Минем кызым бик зур кеше булган»,—
Дигән матур хәбәр йөртерсең.
Балачакта мин бик тели идем
Башкалар күк эшләп үсәргә,
Тели идем сиңа булышырга,
Су ташырга, утын кисәргә.
Ә син әйтә идең:
«Ташла, кызым,
Үзем исән чакта,
Андый эшкә кулың тимәсен!»
Киләчәктә мине килә иде
Үзең кебек доктор итәсең.
— Вузга керәлмәде кызым,— диеп,
Юкка, әнкәй, өметең өзелгән.
Көндез эшче булыр,
Ә кичләрен
Вузда укыр синең Резидәң.

Якын булсын икән аралар

Күз җитте дип, гөлләр, саргаймагыз,
Чәчәкләрне җиргә сипмәгез.
Их, дусларым, сөйгән ярыгызны
Минем кебек ташлап китмәгез!
Үзем сөям, үзем хат та язмыйм...
Нихәл итим, юк бит чаралар.
Их, дусларым, сөйгән ярың белән
Якын булсын икән аралар.
Таба алмам башка мәхәббәтне,
Тик берәүгә күңелем омтыла...
Аны уйлау миңа шатлык бирә,
Барлык сагышларым онытыла.
Уйнатыгыз, кызлар, мандолина,
Уйнатыгыз, һич тә тынмагыз.
Яшьлек лирасында тормыш җырын,
Хезмәт, сөю җырын җырлагыз.
Тукта,
туктагыз!

Бүлмә буйлап таныш моң җәелә,
Тыңла,
тыңлагыз!
Бу бит, бу бит
Минем моңым,
минем хисләрем,
Бу — ул,
Мәхәббәтем минем — Зөфәрем.
Көчәйтегез, дуслар, радионы,
Юып китсен сөю сагышын.
Ишетәсезме?
Һава дулкыннары алып килә
Сөйгәнемнең таныш тавышын.
«Резидәкәй, зәңгәр күлмәгең,
Кайсы елгаларда чайкадың?
Синнән гүзәл ярлар күрмәдем мин.
Синнән гүзәл ярлар тапмадым.
Резидәкәй, матур эзләрең
Шаулы урамнардан эзләдем,
Эзләдем, тик барыбер мин тапмадым,
Бер җырладым өзелеп, түзмәдем.
Сине эзләп сулар буйладым,
Синдә генә минем уйларым,
Резидәкәй бәгърем, ник дәшмисең,
Кайда синең зифа буйларың?»

. . . .

Синең җырың миңа канат булыр
Һәм ямь булыр тормыш юлымда.
Мин дә кушылам сиңа,
җырла, Зөфәр,
Яшьлек яме — сөю турында.
Уйнатыгыз, кызлар, мандолина,
Уйнатыгыз, һич тә тынмагыз.
Көрәшләрдә туган бәхет көен,
Хезмәт, сөю көен җырлагыз.
Гармун моңнарыдай якын икән
Синең тракторың тавышы.
Зөфәр, Зөфәр,
барсы турында да
Бер сөйләшсәк иде кавышып.

Синең җырың, Зөфәр, шундый таныш,
Шундый якын синең моңнарың.
Зөфәр бәгърем,
дустым, мәхәббәтем,
Мин ишетәм сине,
монда мин!

1954—1955 еллар

6. Резидәнең соңгы бүлекләрдәге кичерешләре турында сөйләгез.
7. Резидәнең холкы турында әйтегез.
8. Авторның әсәрдә поэманы иҗат итүче, хикәяләүче, укучысы белән әңгәмәгә керүче булып катнашуын беләбез. Ләкин бу әсәрендә Илдар Юзеев персонажларының берсе буларак катнаша. Шуны исбат итегез. (Авторның Резидәгә киңәш биргән, аның өчен шатланган, аны кызганган урыннарын табыгыз.)

ЯЗУЧЫ ИҖАТЫНА АНАЛИЗ

Быел узган елда башлаган теманы — язучылар иҗатын өйрәнүне дәвам итәбез. Максат үзгәрми: быел да язучы иҗатының үзенчәлеген табарга күнегәбез.

> Искә төшерик. Әсәрләрендә кабатланган уртак сыйфатлар **язучы иҗатының үзенчәлеге** була.

Әсәр эчендәге өлешләрне кушу өчен, бер сыйфат та җитте. «Ни турында? Тагын ни турында?» сораулары бирдегез дә темалары уртак булганнарын куштыгыз. Шулай ук язучы иҗатына кергән әсәрләрне дә темалары кабатлана дип куштыгыз (гомумиләштердегез). Ләкин хәзер әсәрләрнең сез табасы охшаш сыйфатлары бермә-бер арта. Язучылар әсәрләрендә кабатланган тема да, укучысы белән сөйләшер өчен язучының үзе яраткан, шуңа күрә еш кулланган алымнары да әдип иҗатының үзенчәлеге була.

Кабатланган сыйфатларны табу өчен, язучы иҗат иткән әсәрләргә анализ ясадыгыз. Әсәргә анализ ясаганда да, жанрларны өйрәнгәндә дә, әдәбият төрләрен өйрәнгәндә дә әсәрне таркаттык, охшаш өлешләренә уртак исем биреп, бер генә өлешкә калдырдык. Аннан соң өлешләрне аерым-аерым өйрәндек, нәтиҗә ясадык. Язучы иҗатын өйрәнгәндә тагын шул ук гамәлләрне кабатлыйбыз: таркатабыз, өлешләрне аерым-аерым өйрәнәбез, нәтиҗә ясыйбыз. Бер үк гамәлләр белән эш итеп кабатланмыйбызмы?

Нәрсәне генә өйрәнсәк тә, фикерләүнең ике юлы бар: йә гомумидән шәхсигә төшү (жанр сыйфатларыннан файдаланып, әсәрләргә анализ ясадык), йә шәхсидән гомумигә менү (язучы әсәрләрен берәм-берәм өйрәндек тә охшашларын кушып, үзенчәлек шушы, дидек). Күрәбез: фикерләү нигезендә таркату, кушу, нәтиҗә ясау гамәлләре ята. Шуңа күрә язучылар иҗатын өйрәнгәндә сез, язучының иҗади фикерен үзләштерүдән тыш, фәнни фикерләргә дә күнегәсез.

Һади Такташ
(1901—1931)

Тукай, Сәйдәш, Такташлар — халыкның киләчәккә барган юлы буена чыгарып куйган маяклары алар.

Сибгат Хәким

Һади Такташ беренче гыйнварда элекке Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва Республикасы Тарбеево районы) Сыркыды авылында крестьян гаиләсендә туган. Әтисе Хәйрулла абзый, зур гаиләсен туйдырыр өчен, күп эшләргә мәҗбүр булган. Шуңа күрә кечкенә Һади анасы Шәмсениса тәрбиясендә үсә. Белемле, нечкә күңелле Шәмсениса апа улын укырга һәм язарга үзе өйрәткән. Әкиятләр сөйләп, җырлар җырлап, улын искиткеч бай хисле, маҗаралы хыял дөньясы белән таныштырган. Өстәвенә ул бәетләр дә иҗат иткән. Улы Һади үлгәнне ишеткәч язган бәетендә шагыйрьнең әнисе Шәмсениса үзенең кайгысын менә ничек матур итеп тасвирлаган:

Син утырткан ятим каеннарга
Күз яшьләрдән сулар сибәмен,
Таң алдында каен яфракларын
Җылы йөзең итеп үбәмен.

Һади башта үз авылларындагы мәктәптә укый. Аннан соң заманында алдынгы саналган Пешлә авылы мәдрәсәсенә күчә. Җәйләрен, Сыркыдыга кайтып, әтисенә булыша. Ләкин тиздән унөч яшьлек малай укуын ташларга мәҗбүр була. «Мин, ата-аналарыма ярдәм итә алырмын дигән өмет белән,

Төркстан якларына эшкә киттем»,— дип яза шагыйрь үзенең Бохара шәһәренә китүе турында. Өч ел дәвамында ул хуҗаларына идән, кер юа. Кибетләрдә өйрәнчек булып эшли. Буш вакытларын китап укып үткәрә. Шигырьләр яза башлый. Бер шигырен Ташкенттагы газетада бастырып та чыгара.

Революциядән соң, туган авылына кайтып, балалар укыта. Оренбургка китеп, газетада җаваплы секретарь булып эшли. 21 нче елгы ачлыктан качып, Ташкентка китә. Монда да шул ук эшен дәвам иттерә. Бер ел үткәч, Казанга килеп урнаша. «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре», «Азат хатын», «Чаян» журналларында җаваплы секретарь вазифасын башкара.

Такташ кебек гади хезмәт кешесе өчен 20 нче еллар бик авыр чор була. Мәскәүдә китап нәшриятында эшләүче Мәхмүд Максудка язган хатында ул: «Бернәрсә эшләр хәл юк. Яшәү өчен акча кирәк. Ә минем тормыш ягы бик авыр»,— дип зарлана. Тагын дүрт елдан соң, 1929 елда шул ук зарын кабатлый: «Акча юк, билгеле. Ун тиен көмешкә җанымны сатарга әзер»,— ди.

Әтисенә, кулак дип, зур налог салалар. Сеңлесе Хәнифәне, кулак баласы дип, техникумнан куалар. Өстәвенә яраткан хатыны Гөлчирә белән аерыла. Газета-журналларда, Такташ шигырьләрен тәнкыйтьләп, мәкаләләр күп басыла. Сыйнфый көрәш темасына игътибар итми, төрле кош-корт турында яза дип, коткы тараталар.

Газетка да берәр милиционер кую кирәк иде,
Югыйсә
Безне артыграк сыйлыйлар,
Тәнкыйтьчеләр дигән сукбайлар бар,
Көнаралаш тотып кыйныйлар, —

дип ачынып та, көлеп тә яза шагыйрь «Милиционер» шигырендә.

Шундый авыр шартларда да ул үзенең үткен акылын, көр күңелен саклап кала алган. Туганы Габидулла Такташевка җибәргән бер хатында: «Дөнья үзенең авырлыгы белән матур икән»,— дип, үз тормышына елмаеп бәя бирә. Шул вакытта да шигырьләренең күбесен юмор белән яза. Такташ талантының иң күркәм сыйфатларыннан берсе — үзеннән-үзе көлү югарылыгына күтәрелүе.

Һади Такташ «Күмелгән кораллар», «Югалган матурлык», «Камил» исемле пьесалар да иҗат итә. Дистәләрчә мәкалә

бастыра. Зур роман язарга керешә. Ләкин көтмәгәндә чирли башлый һәм берничә көннән үлә.

1916 елны унбиш яшьлек Һади «Газраилләр» исемле шигырен яза.

«Җир уллары трагедиясе» һәм башка шигырьләр» исемле беренче китабы 1923 елда басыла.

Китап укучыларга татар әдәбияты өстендә яшен яшьнәгәндәй тәэсир итә.

Башкортстанның танылган шагыйре Сәгыйть Агиш болай яза:

«Мин 1923 елда Уфага килдем. Бу вакытта инде Һади Такташ татар, башкортлар яшәгән урыннарда иң популяр, иseme иң нык таралган шагыйрь иде».

Татар язучысы Мирсәй Әмир үзенең истәлек язмасында Такташның беренче китабы ясаган тәэсирнең сәбәбен дә әйтә:

«Җенләнеп чыга идем мин ул чорда Такташ шигырьләрен укып. «Җир уллары», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Күләгәләр», «Урман кызы» кебек әсәрләр мине тәмам сихерләделәр... Такташ үзенең яңалыгы, серлелеге белән аеруча дулкынландыра иде... алар дөньяның каршылыклары турында уйландыралар. Яшь йөрәккә тынычланырга ирек бирмиләр, өзлексез көрәшкә өндәп, яшәүгә, тормышка дәртләндереп, ялкынланып торалар... Романтик шигырьләре аша Такташ үзе дә минем алдыма әллә нинди фантастик сыйфатларга төрелгән серле кеше булып... чиксез кодрәтле, кырыс чырайлы герой булып килә иде. Озакламый ул минем хыялымда җиргә төште... Гаять үткен, акыллы кешегә әверелде... Такташ имзасы куелган һәр шигырь гүзәл, изге иде минем өчен».

Хәсән Туфанның иң якын дусты — Такташка биргән бәясе белән танышыйк.

«Татар поэзиясендә әлегәчә күренмәгән вакыйга булып килгән Такташның беренче җыентыгы (1923) минем тормышымда яңа борылыш тудырды, дулкынландырды, язмаска мөмкин булмаган хәлгә китерде. Бу көн гомер юлларындагы иң бәхетле көннәремнең берсе булып истә калды. Такташның талантлы, тылсымлы шигырьләре, йөрәкне биләп, чорнап алды. Шундый шигырьләрне иҗат итә алган шагыйрь җирдә, анадан түгел, легенда-эпослар эченнән килеп чыккандыр кебек тоелды».

Күпләрне язучы иткән беренче китабындагы әсәрләрен язганда, Такташка нибары 15—16 яшь була! Дөньяга ул

гашыйклар, хыялыйлар күзе белән карап кына бәя бирә ала әле. Ә дөнья катлаулы; авыл малае түгел, күпне күргән укымышлы аксакаллар да аңларлык түгел. Сугыш өстенә сугыш, революция өстенә революция, ачлык өстенә ачлык. Фаҗиганең очы-кырые күренми. Шагыйрь күңеле өзгәләнә, хәсрәтләнә. Ябь-яшь Һадиның укучысын тетрәткән, дулкынландырган, тормышында яңа борылыш тудырган әсәрләр белән танышыйк.

ГАЗРАИЛЛӘР[1]

(1914 елгы Европа сугышына каршы)

Тау өстенә утырган ул, уйга баткан;
Канатлары талган килеш җиргә яткан;
Маңгаенда — нурлы йолдыз; күзләренең
Шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан.
Таңнар аткан, күренеп тора ерак илләр;
Яшрен генә аңа килеп сөйли җилләр:
— Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт,
Монда үлем, монда патша — газраилләр!

Ул фәрештә моннан бик күп еллар элек
Бу йолдызга күктән очып килгән иде.
Төзер өчен мәңге рәхәт — бәхет багын,
Кызыл гөлләр чәчеп, сулар сипкән иде.
Сипкән иде...
Җырлый-җырлый мәхәббәт һәм күк көйләрен,
Җир йолдызын тезеп, җәннәт иткән иде;
Бизәр өчен җәннәтен ул, гөлләр өчен,
Тагын очып кире күккә киткән иде.
Киткән иде...
Күчеп тиз-тиз бер йолдыздан бер йолдызга,
Бик күп еллар матур гөлләр җыеп йөрде...
Кайтса кире җир йөзенә: нинди дәһшәт[2]!
Сөякләрдән таулар, каннан күлләр күрде.
Котырган ил. Болгый-болгый кулларында
Ялтырата сөңгеләрен. Юлларында

---

[1] *Газраил* — җан алучы фәрештә.
[2] *Дәһшәт* — курку сала торган зур көч.

Үлгән ирләр өелеп кала, аунап шунда;
Җәһәннәмдәй утлар уйный унда-сулда.
Хәят[1] иле — матур йолдыз — янып сүнгән;
Тапталып гөл баглары[2] көлгә дүнгән[3];
Матур кырлар, бәхет-җәннәт урманнары
Гакылсызлар йорты булып әверелгән.
— «Кемнәр алар, җәннәтемә кемнәр килгән?
Нинди явыз ерткыч җаннар?
Кайсы илдән?»
Җавап бирми берәү дә... Тик үкереп-үкереп,
Туплар оча фәрештәнең баш өстеннән.

Тау өстенә утырган да уйга баткан;
Канатлары талган килеш җиргә яткан;
Маңгаенда — нурлы йолдыз; күзләренең
Шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан.
Таңнар аткан, күренеп тора ерак илләр,
Яшрен генә аңа килеп сөйли җилләр:
— Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт!
Монда үлем! Монда патша — газраилләр...

1916 ел

Әдәбиятта чынбарлыкны дөрес итеп тасвирлауга **реализм юнәлеше** диләр. (Игътибар итегез: күзгә күренгәнне язу түгел — дөрес итеп язу.)

Кешенең иң матур теләге (идеалы) белән чынбарлык каршылыгы тудырган җан әрнеткеч хисне тасвирлауга **романтизм юнәлеше** диләр. Бу тасвир бөтендөнья явызлыгына каршы юнәлгән.

Биремнәр

1. «Газраилләр» шигыренең романтизм әсәре булуын исбат итегез.
2. Үзе уйлап тапкан вакыйгага авторның мөнәсәбәтен әйтегез.

---

[1] *Хәят* — тормыш, тереклек.
[2] *Баг* — җимеш бакчасы.
[3] *Дүнгән* — әверелгән.

ТӨРКСТАН САХРАЛАРЫНДА

(Өзек)

Таң атамы? Яктырамы?
Нишли дөнья, нишли ул?
Ник күренми якты көннәр?
Ник томанлы якты юл?

Кайда соң ул нурлы таңнар?
Ай, кояшлар балкыйлар?
Кайсы илләрне матурлый,
Бизиләр һәм аңкыйлар?!

Кайда хөрлек[1], инкыйлаблар[2],
Кайда таңнар сыздыра?
Рухлы тормышлар ясарга
Дөньяны пыр туздыра?!

Юк төсле ак күңелгә...
Монда михнәт, монда төн,
Монда сахра, моңлы сахра...
Барчасы тоткын бүген!..

1917 ел

Бирем

«Төркстан сахраларында» шигыре дә — романтизм әсәре. «Газраилләр» шигыре белән охшашлыгы шуннан гыйбарәт. Шигырьләрдә катнашкан лирик геройларның гаделсезлеккә каршы көрәшләрендәге аерманы табыгыз.

АНТЫМ

(Өзек)

Кычкырам:
Килегез, әй, адашкан,
Канга баткан мәзлум ил халкым!
Түзә алмый канга, вәхшәткә,
Мәхәббәт байрагын алдым.—

(Алып каннан, сәгадәткә
Чыгарырмын эшчеләр халкын!)
Хакыйкать мин басам; баскан
Эземдә тетриләр таулар!..
Өзелә бер генә кул селтәвемнән
Мәңгелек баулар...
Еланнар! Сезгә юк тормыш,
Куып юлдан, буып сезне,
Ачам юллар сәгадәткә!
Җуям җирдән фәхеш эзне...

1920 ел

---

[1] *Хөрлек* — ирек.
[2] *Инкыйлаб* — революция.

Һади Такташның өч шигыре дә Беренче бөтендөнья сугышы һәм революция елларында иҗат ителгәннәр. «Антым» шигырен алданрак язылган ике шигырьнең дәвамы итеп өйрәнә алабыз.

Бирем

«Антым» шигыренең алда өйрәнгән ике шигырь белән охшашлыгын һәм аермасын аңлатыгыз.

Язучы иҗатын өйрәнү алымнарын искә төшерик.

Максатыбыз язучы иҗатының үзенчәлеген табарга өйрәнү иде. Моның өчен ни эшләдек?

1. Бер әсәрнең төп үзенчәлеген таптык. Вакыйгаларның җирдәге вакыйгалар булмавын, персонажларның миф яки әкият персонажлары булуын, лирик геройның бөтен дөньяны яулап алган явызлыкка каршы ярсый-ярсый көрәшүен күрдек. Шигырьнең бу сыйфатлары — романтик рухта язылган шигырьләргә хас сыйфатлар, дидек.

2. Тагын ике әсәрне өйрәнеп, алар да романтик рухта язылуын белдек.

> Әсәрләрне берәм-берәм өйрәнеп, нәтиҗәләрен гомумиләштергәннән соң (кушып), Һади Такташ әдәбиятка романтик шагыйрь булып килеп керә дигән уртак бер фикергә киләбез.

Әсәр тормышчан булырга тиеш, дибез. Ә без өйрәнгән шигырьләрендә Һади Такташ үзе уйлап тапкан дөнья турында яза, дип, үз вакытында әсәрләренә тәнкыйть өстенә тәнкыйть яудыралар. Ләкин романтик рухта язылган Такташ әсәрләрен яшьләр дә, өлкәннәр дә яратып укыганнар һәм укыйлар.

Тормыш чынлыгыннан ерак торган бу әсәрләр ни өчен элек тә һәм хәзер дә шулай дулкынландыра ала соң?

Такташ шигырьләрендә интонация алымнары күплеген күрдегез. Моңа кадәр безнең әдәбиятта бер генә әдип тә лирик геройлары һәм үз-үзе белән, табигать күренешләре, укучылары белән, кара-каршы утырып, сораулар яудыра-яудыра сөйләшкәндәй, үз итеп сөйләшмәде.

Бүген таң алдында торып сәлам сөйлим.
— Кемгә?
— Белмим.

Бүген таң алдында торып сәлам сөйлим.
— Кемгә?
— Белмим.
Илчем-җил аркылы сәлам сөйлим, сезгә:
Чәчәкләргә, гөлләргә,
Нәфис лаләләргә, сөмбелләргә,
Сахраларга, барлык җирләргә!..

Бөтен дөнья явызлыгына каршы сугыш ачарга батырчылык иткән Такташ үзе янына башкаларны да чакырды:

Әй сез! Кунак булып җиргә килгән
Юлаучылар, талган юлчылар!
...Кем булсагыз да сез, аермасыз,
Килегез бүген миңа кунакка.

Укучы Такташ шигырьләрендә лирик геройның үзенә җылы мөнәсәбәтен күреп шатланды. Шуңа күрә Такташ укучысының якын танышына, дустына әйләнде. Хәзер аның җир өстендәге бөтен явызлыкларны күреп торуына, «газраилләргә каршы сугыш ачуына», «күктән йолдызлар чүпләп йөргән фәрештәне күзәтеп торуына» һәм «фәрештәнең, хәсрәткә батып, җирдә елап утыруын да күреп борчылуына» ышанасы килде. Укучыларның да Такташ кебек үзе өчен генә булса да ирекле үз хаклыгына ышанган горур шәхес буласы килде.

Такташ Казанга кайта. Революцияне, гражданнар сугышын, ачлык елларын кичергән 21 яшьлек егет дөнья белән һаман тату түгел әле. Ул бу елларда да романтик шагыйрь булып кала бирә. Хәзер аның максаты бар дөньяны елату түгел. Ул явызлыкны мәхәббәте белән җиңәргә ниятли:

Түзә алмый канга, вәхшәткә,
Мәхәббәт байрагын алдым,—

ди.

Бу елларда Такташ хыялы тудырган кыз матурлыгын аңа кадәр бер шагыйрь дә шулай укучысы гашыйк булырлык итеп язганы юк иде әле.

«Урман кызы» шигырендәге өзеккә күз салыйк:

Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан агалар?!

Кайчак күзләреңнән көчләр алып,
Биеклеккә табан ашам мин,
Ә кайчакта башым түбән иям,
Әй Әминәм, синнән качам мин.
Син кем, белмим, синең шаян күзләр
Нигә, белмим, болай багалар;
Нинди көчләр, сөйлә, әй аппагым,
Керфек очларыңнан агалар?

Урман биргән аңа матурлыгын,
Күлләр саф суларын сипкәннәр,
Гөлләр, йоклаганда, яшрен генә
Иелеп-иелеп аны үпкәннәр;
Таң җилләре аның, исә-исә,
Озын чәчкәйләрен тараган;
Төн ае, төннәрдә йокламыйча,
Ана булып күктән караган.
Карурманның барлык матурлыгы,
Бар серләре анда җыелган,
Зифа буе булган ак мәрмәрдән,
Күзе сихри нурдан коелган.

Такташ «Кояш күктә шулай мәңге йөзәр» шигырендә «үткәннәрнең тимер ишегеннән... колынга атланып» чыккан кызны болай тасвирлый:

Аһ, әгәр мин бер зур рәссам булсам,
Тәрсим итеп[1] ул кыз баланы,
Бүләк итәр идем сезгә,
Бүләк итәр идем мин аны.

Җир йөзенең бөек рәссамнары!
Килегез дә миңа сөйләгез!
Аның тузган чәчен буяганда,
Нинди буяу белән буйыйм да,
Зәңгәр күзкәйләрен җанлы итеп,
Ничек кенә буяп куйыйм да,
Ничек тәрсим итим мин аны?!

*

Иркә җир кызларын буяу белән
Җанлы итеп буяп буламы?
Булса,
Ничек буйыйм, ничек кенә буйыйм мин аны?

---

[1] *Тәрсим итү* — рәсем төшерү.

Күрәсез: Такташ, бу өзектә мин рәссам булсам, ул кызны матур итеп ясар идем, ләкин рәссам түгел шул, дип гап-гади сүзләр әйтә. Рәсемен ясарга теләгән кызы да җир кызы түгел бит әле югыйсә — хәтере төбеннән колынга атланып чыккан фәрештә генә. Ләкин Такташ, аңа мәхәббәте турында язганда, шигыренең бер үк юлларын кабатлый-кабатлый, хисләрен өермә итә. Тойгыларын дулкын итеп, берсе артыннан икенчесен йөгертә. Кемнәргәдер сораулар бирә-бирә, юкның барлыгына безне тәмам ышандыра. Без шигырьне укыганда колынга атланган кызның чиксез чибәрлегенә дә, лирик геройның ул кызга мәхәббәтенә дә ышанабыз.

Һади Такташ интонация алымы ярдәме белән менә нинди могҗизалар тудыра алган.

Әсәр эчтәлегендә хис дәрәҗәсеннән тыш, аның сәбәбе дә булырга тиешлеген беләбез. Ни өчен шулкадәр өзгәләнәләр соң лирик геройлар?

Шигырьләрдә гаделсезлек төшенчәсе бар, хәтта газраил үтергән тау-тау мәетләр бар, ләкин төшенчәнең эчтәлеге юк. Акылдан шашар дәрәҗәдәге мәхәббәт бар, ләкин шагыйрьнең лирик геройлары — йә пәри кызлары, йә урман кызлары — бар да автор хыялы тудырган кызлар. Хәер, лирик геройлар — үзләре дә автор хыялында туган персонажлар.

Такташ иҗат иткән романтик шигырьләрнең үзенчәлеге безне көтелмәгән нәтиҗәгә китерә: Такташның бу елларда язган шигырьләрендә башта хис туган, шуннан соң сәбәп табылган. Башкача әйтсәк, сәбәпне яшь егетнең хисе тудырган.

Һади Такташ, дәреслеккә кергән шигырьләреннән тыш, тагын берничә романтик шигырь һәм «Җир уллары трагедиясе» исемле пьеса иҗат итә. Шуңа күрә, гомумиләштереп, Һади Такташ әдәбиятка романтик шагыйрь булып килеп керде дигән нәтиҗә чыгарабыз.

Такташ, иҗатының икенче чорында да, кешеләрне бәхетсез итүче көчләргә каршы көрәшче булып кала. Ләкин хәзер, киресенчә, шагыйрь хисләрен тормыш үзе тудыра.

Еллар үтү белән, язучының тормышны танып белү дәрәҗәсе арта. Хәзер ул дөньяга башкача бәя бирә башлый. Яратып куллана торган сәнгать алымнары да алмашына. Мондый очракта язучы иҗатын үсештәге иҗат диләр һәм чорларга бүләләр.

Лирик геройның хисе тормыш вакыйгаларына җавап булса, андый шигырьләргә **реализм юнәлешендә язылган әсәрләр** диләр.

Шагыйрь иҗатының икенче чорына реалист Такташ иҗат иткән әсәрләр керә. Әлеге чор, гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, илне төзекләндерү, яңа тормыш төзү вакыйгалары белән бәйле. Бу елларда да тормыш бик авыр була. Такташ шәхес культы дип йөртелгән яман елларда иҗат итә. Бу елларда яшәеш хакыйкатен әйтү властька каршы бунт күтәрү белән бер санала. Илдә бердәнбер хакыйкать — властьның үз сүзе (идеологиясе) хөкем сөрә.

Истә калдырыйк. **Хакыйкать** — сүзнең чынбарлык белән тәңгәллеге ул.

Гомере буе ачлы-туклы яшәгән Һади Такташ тормыштагы чынбарлык белән власть сүзе арасындагы аерманы бик яхшы күрә. Дөреслекне язса, үзенең язмышы ни белән тәмамлануын да аңлый.

Язучы алдында ике генә юл кала: хакыйкатьне язса, ирегеннән мәхрүм ителә, партия кушканны язса — исән кала, ләкин үзенә үзе хыянәт итә. Такташ исә шул ике юлның уртасын сайлый.

Такташның шундый шигырьләре белән танышыйк.

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Кем кабренә чәчәк ыргытсам да,
Әрәм китмәс төсле чәчәгем;
Мин җирдәге һәрбер сукбай белән
Дус абыйдай тату яшәдем.

Поезд ыргый таныш урманнардан,
Тәгәрмәчләр шаулап баралар,
Уйлар һәр очраган ак каенның
Ботагына асылып калалар...
Юл буенда йомылып йоклап яткан
Урман чәчәкләре сискәнеп
Уяналар...
Поезд килгән якка
Керфекләрен ачып карыйлар,

Ул үтүгә тагын тыналар,
Урман тынлыгына чумалар...

Ах,
Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен;
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем...
Поезд ыргый, ә мин тәрәзәдән
Күрмәмме дип, бер-бер танышны,
Һәрбер станциядән күзем алмый
Карап барам үтеп барышлый...
Кем соң кирәк миңа?
Станциядә
Арлы-бирле йөргән халыклар —
Ертык бүрке, тузган чабатасы белән
Миңа якын, миңа танышлар...
Мин гомрем буе шул кешеләрнең
Йөрәк тавышларын тыңладым,
Каныма манчып язган һәр җырымны
Алар теле белән җырладым.
Алар арасында, матурланып,
Бөдрәләнде яшьлек чәчәгем.
Давыллы елларда, киң кырларда
Алар белән бергә яшәдем...

Поезд ыргый,
Ә мин тәрәзәдән
Озатып калам һәрбер танышны,
Һәрберсенә җылы хисләр белән
Елмаямын үтеп барышлый...

1928 ел

Биремнәр

1. Шигырьне сәхнәдә укысагыз, ничек укыр идегез? Шулай укып күрсәтегез. Тиешле урында пауза ясагыз, кирәк урында тавышыгызны көчәйтегез. Бәлки, акрынрак яки тизрәк укый торган урынын табарсыз.

2. Шигырь лирик геройның табигатьне һәм гади кешеләрне яратуы турында дияргә була. Шигырьнең башка эчтәлеге турында сөйләгез.

АК ЧӘЧӘКЛӘР

(Идиллия)

Ул,
Эретеп туңган тәрәзәне,
Мыштым гына карый урамга,—
Ак чәчәкләр ява урамда...

Берәү,
Борын очын кулына кысып,
Сүгенеп узды кышкы салкыннан, —
Җил ияреп китте артыннан.

Алар,
Чана тартып җырлый-җырлый,
Тау шуарга икәү уздылар,—
Ә бераздан кире сыздылар...

*

Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Кар астында йоклар урамнар,
Төне матур булса, төн үтүгә,
Таңнар алып килер бураннар...
Дөнья матур,
Шуның өчен дә бит
Сүгенә-сүгенә кайтам салкыннан;
Ә җил мыштым гына, эндәшмичә
Ияреп килә минем артымнан...
Белмим, нигә, әллә гыйшкы төшкән,
Кайда барсам, шунда бара ул;
Өйгә кергәндә, җиргә ятып,
Чыкканымны саклап кала ул...
Шуның өчен дә мин чыкмый гына
Тәрәзәдән карыйм урамга —
Ак чәчәкләр ява урамда...
Ак чәчәкләр ява, дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...

1929 ел

Шигырьгә анализ

Биремнәр

1. Шигырьне ашыкмыйча, аңларга тырышып укыгыз. Аңлашылмаган урыннарын дәфтәрләрегезгә языгыз.

Без моңа кадәр өйрәнгән шигырьләрне икегә генә калдырып бүлә идек тә өлешләр арасындагы бер яки ике генә бәйләнешне таба идек. Әсәр эчтәлеге әнә шул бәйләнешләрдән гыйбарәт иде.

«Ак чәчәкләр» шигыренең эчтәлеге дә өлешләр арасындагы бәйләнешләр аша табыла. Шигырьдә мәгънәләрен без табарга тиешле бәйләнешләр күп. Аларны табарга шагыйрь безгә үзе ярдәм итә. Язучының беренче хәйләсе шигырьнең жанрында: Һади Такташ шигыренең жанрын «идиллия» дигән.

> Истә калдырыйк. Табигать матурлыгына сокланып язылган лирик шигырьләргә **идиллия** диләр.

Такташ: «Бу шигыремдә мин табигать матурлыгы турында язам»,— дип, алдан ук кисәтеп куя. Ләкин без «Үтеп барышлый» шигырендәге серне яхшы беләбез. Шуңа күрә яшерен эчтәлекне әсәргә анализ ясап табабыз.

«Үтеп барышлый» шигырен искә төшерик. Анда Такташ әсәренең яшерен эчтәлеген (субъектив эчтәлек дип өйрәндек) табигать матурлыгы турындагы вакыйга эченә яшергән иде. Бу шигырь дә матурлык турында. Язучыларның яраткан алымнары булуын искә төшерәбез дә, Такташ бу шигырендә дә матурлык эченә төп эчтәлеген (хакыйкатьне) яшергән булырга тиеш, дибез.

Максат табылды. Әсәргә анализ ясыйк.

2. Шигырен автор үзе дүрт өлешкә бүлгән. «Ул», «Берәү», «Алар» дип, һәркайсына исемнәр дә куйган. Соңгысына исем табыгыз.

Такташ хәйләсен табу нияте белән, шигырь өлешләрен берәм-берәм өйрәник.

3. «Ул» өлешенең вакыйгасын үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз. Аңлашылмаган урынга сорау куегыз.

4. Шигырьнең икенче өлешендә «Берәү» артыннан ияреп китүче җилгә игътибар итәбез һәм, әсәрдә җил мәгънәсе дә ачылырга тиеш дип, дәфтәргә язып куябыз.

Башка өлешләрне дә шул рәвешле өйрәнеп чыгыгыз.

Өченче өлештәге яшьләр салкынны сукмиләр. Ләкин туңудан куркып, өйләренә кереп качалар.

5. Дүртенче өлештәге лирик герой сыйфатларын ачыклагыз. Бу бүлектә алдагы бүлектә аңлашылмаган урыннарның, сүзләрнең мәгънәсе ачыклана. Түбәндәге анализны укыганчы, әсәр эчтәлеген үзегез табарга тырышыгыз.

Соңгы өлештәге (бүлектәге) лирик герой да, икенче өлештәге «Берәү» кебек, салкынны сүгә. Аның артыннан да җил ияреп китә. Ләкин «Берәү», җилне күрмичә, салкынны сүгүен дәвам итә, ә безнең лирик герой җилне күреп ала да тиз генә җылы өйгә кереп кача. Шуннан соң ул тәрәзәдән карап торучы мыштым кешегә охшый. Ул да, җылы өйдән тәрәзә аша карап, табигать матурлыгына соклана. Ләкин мыштым кеше кебек, «дөнья матур» дисә дә, җөмләсен «шундый матур булып тоела», дип тәмамлый. Игътибар итегез: Һади Такташ лирик герой сүзләренә бик әһәмиятле «тоела» сүзен өсти. Бу сүзне ул ике мәртәбә кабатлый. Һәм аның «кебек күренә» мәгънәсен күз алдында тота.Башкача әйтсәк: матур булып тоела гына. Чынлыкта матур түгел.

Автор бу бүлектә без мәгънәсен белергә тиешле «мыштым» сүзен дә кабатлый.

Ә җил мыштым гына, эндәшмичә
Ияреп килә минем артымнан,—

ди.

Без җилнең фәкать салкынны сүккән кешеләр артыннан гына ияреп китүен күрәбез. Салкын чана шуарга чыккан яшьләргә дә охшамаган иде, ләкин алар салкынны сүкмәделәр. Салкынны яратмауларын сиздермичә генә качтылар. Шуңа күрә алар артыннан җил ияреп китмәде.

Хәзер безгә «мыштым» сүзенең мәгънәсе ачыкланды. Беренче бүлектәге «Ул», «мыштым гына», ягъни кеше күрмәсә ярар иде дип, урамны күзәтә. Ә үзен күрмәсеннәр өчен, туңган тәрәзәгә өреп, кечкенә генә тишек ясый. Җил дә салкынны сүгүче артыннан «мыштым гына», ягъни күренмәскә тырышып ияреп китә. Болары да — охшаш персонажлар.

Инде салкын белән җилнең мәгънәләрен табарга кирәк.

Татар әдәбиятында элек-электән салкын — тормыш авырлыгы, ә яз образы киләчәккә өмет мәгънәләре белән кулланылалар.

Кышкы салкын белән яз шул ук мәгънәләрдә Такташның күп шигырендә кабатлана. Һади Такташ тормыш авырлыгын, кышкы салкын метафорасына әйләндереп, беренче тапкыр «Сыркыды авылы» шигырендә яза. Җилнең, теләсә кая тыкшынып, кешеләргә төрле явызлыклар эшләп йөрүен дә башта шул ук шигырендә сурәтли. Әдипнең баштарак язган шигырьләре белән таныш укучы «Ак чәчәкләр»дәге кышкы салкын белән җилнең шагыйрь күз алдында торткан мәгънәләрен җиңел таба. Укучы шигырьдәге:

Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...

юлларына игътибар итә.

Шагыйрь, аяз күктән чәчәк кебек матур кар ява, дип яза. Һәм укучыларына «Аяз күктән яңгыр да, кар да яумый. Шуңа күрә мин матур-матур дип мактаган кар берничек тә кар була алмый. Йолдызларга да башка мәгънә бирдем», — ди. Хәзер без чәчәк кебек матур карның мәгънәсе хөкем итүче идеология булуын белдек. Халыкның ни өчен салкынны сүгүен, ни өчен алар артыннан мыштым «җил» ияреп китүнең дә мәгънәсенә төшендек. Идеология халыкка биргән вәгъдәләре белән матур. Ләкин ул кешеләрне туңдыра, алдый, яшәргә ирек бирми, хакыйкатьне эзләүчеләрне эзәрлекли, ди Такташ.

Нәтиҗә

Такташның егерменче еллар уртасында иҗат иткән ике шигыре белән таныштык. Аларның уртак сыйфатларын күрдек:

Такташ шигырьләрен ике эчтәлекле итеп язган. Укучысының сәнгать теле белән әйтелгән хакыйкатен аңлавына ышанган.

Укучы, әсәрне укып чыккач, табигать матурлыгы һәм аны шаяра-көлә тасвирлаучы авторны күрә. Табигать матур, кешеләр аңа сокланып туя алмыйлар. Ә игътибар белән укучы әсәрдә шагыйрь яшәгән еллардагы тормыш авырлыгын күрә.

* * *

Айга күптән инде мең яшь тулган,
Ә ай аны үзе оныткан;
Кичә саташкан ай, кыш дип белеп
Төн уздырган күктә толыптан...

Ай кебек без озак яшәмәбез,
Көчләр сүнәр,
Куллар талырлар,
Картаербыз;
Соңгы көрәшләргә
Яшьләр генә, ахры, барырлар.
Яшьләр белән мин дә барырмын дип
Алдыйм болай үзем алдавын,
Ләкин
Бил авырткан чакка туры килер,
Ихтимал, шул бара алмавым...
Их, яшьлекнең үтәр алсу таңы,
Мин туктатмыйм синең агымны,
Үтәр өчен килгәч карышып тормыйм,
Җырлап озатам яшьлек чагымны...
Әле картлыкның да үз вакытында
Матурлыгын таба белербез;
Октябрятлар безне эштән куса,
«Тавык комиссиясе» төзеп,
Тавыкларның
Тормышларын рәтләп йөрербез.
Тавыклар да ун ел безнең белән
Бер аякка басып бардылар,
Салам ояларга
«Совет өчен»
Ап-ак йомыркалар салдылар...
Ах җир,
ах җир!
Синең матурлыгың
Шундый тигез итеп таралган:
Һәр дуңгызың, һәрбер песи кызың
Чәчәк кебек матур яралган...
Һәр әтәчкә бүркем салып үтәм,
Совет саулык бирсен аңарга,
Һәрбер эткә, үзе тели икән,

Рөхсәт итәм борным яларга...
Һәрбер сыер, мине бозавы итеп,
Ап-ак сөте белән имезгән,
Һәрбер сарык, тунын салып биреп,
Кышкы суыкларда кигезгән...
Ә ай ялгыз,
Айда бернәрсә юк,
Әтәч тә юк анда, песи дә;
Катык та юк анда, ипи дә юк
Безнең ише ярлы кешегә...

1928 ел

Һади Такташ шигыренең башында да, ахырында да ай турында яза. Димәк, ай образы аның өчен бик әһәмиятле. Шуңа күрә әсәрне «Ай һәм Җир турында» дип ике өлешкә бүлик.

Ике өлеш арасындагы күзгә күренеп торган бәйләнешне табыйк. Төп бәйләнеш — автор Җирне ай белән чагыштыра. Ничек чагыштыра?

Романтик әсәрләрендә Һади Такташ Җир шарындагы гаделсезлеккә каршы берүзе көрәште. Күктәге явыз көчләрнең тетмәсен тетте. Ярсыды, нәфрәтләнде, нәләтләр укыды... Ләкин тормышның ачысын-төчесен үз башыннан кичергәч үзгәрде — илдәге тормыш гаделсезлеге турында язды.

«Ак чәчәкләр» белән «Үтеп барышлый» шигырьләрендә дә төп теманың гаделсезлек булуын күрдек. Ләкин хәзер ул язган гаделсезлек — тормыш гаделсезлеге. Такташ тормыш гаделсезлегенә дә әрни, нәфрәтләнә, ләкин тәнкыйтен дә, хисләрен дә елмаюы, соклануы астына яшерә. Хәзер Такташ хәйләле. Дөнья матурлыгын мактый-мактый, аңа «мыштым» гына тормыш ямьсезлеген каршы куя. Шундый хәйлә Такташ иҗатының үзенчәлеге түгелме? Моны тагын бер шигырь мисалында дәлиллик.

Такташ «Ай кебек без озак яшәмәбез...» шигырендә дә матурлык турында яза, ә шул матурлык эченә кереп поскан тормыш гаделсезлеген укучысыннан таптыра.

Шул үзенчәлекне күздә тотып, әсәргә анализ ясыйк.

Әсәрнең фокусы

Без 7нче сыйныфта «фокус» атамасы белән танышкан идек инде. Шәриф Камал иҗатын өйрәнергә керешкәнче, сәнгать әсәренең бу бик мөһим үзенчәлеге белән якыннанрак танышыйк.

> Автор, укучысы белән сөйләшкәндә, әсәре эчендәге төрле эпизодларны, вакыйгаларны үзара бәйләнешкә кертеп аралаша. Ләкин аның белән генә канәгатьләнеп калмый, барлык өлешләрне бер ноктага җыючы образ да иҗат итә. Менә шул мөһим ноктага **фокус** диләр.

Фокусның әдәби әсәрдә нинди әһәмиятле урын алуын бөек рус язучысы Лев Толстой болай аңлата:

> «Сәнгать әсәрләрендә бөтен нурларны үзенә җыеп яисә өлешләргә үзеннән чәчеп торучы ниндидер бер урын булырга тиеш. Бу бик әһәмиятле урын. Ул **фокус** дип атала. Фокусның эчтәлеген сүз белән аңлатып бетереп булмый. Сәнгать әсәре үзенең эчтәлеген бөтен тулылыгы белән фәкать шул фокуста гына ача ала».

«Фокус» атамасын татарның күренекле галиме, язучысы Нәкый Исәнбәт «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә болай аңлата: «Линза аша үткән параллель нурларның кисешкән ноктасы... Нинди дә булса үзлекләрнең (асыл сыйфатларның. — *А. Я.*), күренешләрнең, вакыйгаларның үзәге, тупланган урыны».

Әсәр эчендәге фокусны автор куя. Ләкин фокус икәнлеген әйтми. Аны укучы табарга һәм, өлешләрен җыеп, шуңа ялгарга тиеш була.

Фокусны ничек табарга?

Автор әсәрендәге фокус урынын берничә гамәл белән күрсәтә:

1. Әсәренең исеме итә.
2. Фокус вазифасын үтәүче күренешне, эпизодны сюжет эченә кертми.
3. Фокус әсәрнең иң киеренке урыны була.
4. Автор фокусны әсәр эчендә кабатлый.

Әсәр исеме фокус вазифасын үтәгән очракны мисал белән ачыклыйк.

Әмирхан Еники өч повестен бер китапка җыеп бастыра һәм барысына да уртак булган «Кичке шәфәкъ» исеме бирә.

Гадәттә, авторлар әсәр исеменең мәгънәсен укучылардан таптыралар. Башка китапларында һәм әсәрләрендә Әмирхан Еники дә шулай итә. Ләкин «Кичке шәфәкъ» исеменең мәгънәсен үзе аңлатып бирә. Китабының керешендә әдип болай яза:

«Сезнең кулыгыздагы бу китапта өч әсәр: «Йөрәк сере», «Вөҗдан», «Гөләндәм туташ хатирәсе»... Ләкин ни өчен мин аларны «Кичке шәфәкъ» дигән бер исем астына җыеп чыгаруны кирәк таптым? Чөнки алар өчесе дә мәхәббәт турында. Әмма өчесендә дә сүз гамәлгә ашмыйча үтеп киткән, инде искә төшереп сөйләргә генә калган сагышлы, үкенечле мәхәббәт турында бара. Шуңа күрә ул «кичке» — якты көн үткән инде; шуңа күрә ул «шәфәкъ» — яктылык әле сүнеп бетмәгән... Кичке шәфәкъ ул,— минемчә, кешенең нәкъ менә моңсу сагышка бирелә торган чагы...»

Китапта өч өлеш — өч повесть бар. Китап исеме аларның өчесенә дә «нур чәчә», авторның кешеләр язмышындагы яшерен күренешне, күңел дөньясын тоярга ярдәм итә. Гадәттә, ул бу эшне безгә — укучыларына тапшыра.

Әмирхан Еники китап исемендәге табигать күренешенең әсәр вакыйгалары белән бәйләнешкә керүче сыйфатларын санап чыга.

Әсәр исеме табигать күренешеннән гыйбарәт. Шәфәкънең иртәнгесе дә, кичкесе дә була. Ул — Кояш чыгар һәм баер алдыннан туа торган кызыллык.

Мин кичкесе турында язам. Кояш чыкканны да, баеганны да күргәнегез бар. Иртәнге шәфәкъ кызыллыгы матур, без аны шатланып күзәтәбез. Кичкесе дә матур, ләкин Кояш баю бездә моңсу хисләр уята. Шәфәкъкә соклану, шул ук вакытта моңсулану каршылыгын мин кешеләр күңелендәге хис-тойгылар каршылыгы белән бәйләнешкә китердем, ди. Кыскасы, әсәр исеменең мәгънәсен безгә дә шул рәвешле табарга киңәш итә.

Күзәтүчән укучы әсәр эчтәлеген үз зиһене белән баета. Аңа персонажлар кичереше, хәтта, автор үзе тапмаган нечкәлекләре белән ачыла. Сәнгать әсәренең бер мөһим могҗизасы шуннан гыйбарәт.

Фокусны табу ни өчен кирәк?

Әсәрдәге фокусны тапсак, анализ гамәле беркадәр үзгәрә һәм җиңеләя төшә.

Шәриф Камал
(1884—1942)

Укырга керешкәнче, роман жанрының үзенчәлеге белән танышыйк. Уку дәвамында төп сюжет сызыкларын ачыклыйк.

> Роман әдәбиятның чәчмә төренә керә.
>
> 1. Башка жанрлардан сюжет сызыкларының һәм персонажларының күплеге белән аерыла.
>
> 2. Төзелеше (өлгесе) җәмгыять белән шәхес арасындагы конфликттан гыйбарәт. Конфликт төп геройның җәмгыять тәртипләре белән килешмәве аркасында туа. Кеше йә җәмгыятьнең идеалы, йә шул идеалга бару юлы белән килешми.

Әсәрне ашыкмыйча, игътибар белән укыгыз.

Гадәттә, романның исемендә автор әсәренең төп темасын әйтеп куя. Ә төп теманы белү — әсәр эчтәлеген ачу өчен ачкыч бит ул. Шәриф Камал да әсәренең исеме белән безгә ярдәмгә килмиме? Автор роман «матурлык» турында дип әйтеп тора. Әсәргә анализ ясап, матурлыкның үзе күргән үзенчәлеген табарга кирәк. Ләкин романының исемен ни өчендер «Матурлык» димәгән, «Матур туганда» дип куйган. «Матур туганда» исеме белән Шәриф Камал матурлык туганда тагын нәрсәләр булуы турында кисәтә бит. Ләкин ни өчендер кисәтеп кенә куя — әйтеп бетерми. Ни өчен әйтеп бетерми? Җөмләнең икенче өлеше нинди булырга тиеш?

Болай уйлыйбыз: сәнгатьчә фикерләүнең төп бәйләнеше — каршылык. Ә матурлыкның каршы ягы — ямьсезлек. Димәк,

матур туганда аңа ямьсезлек йә комачаулый, йә ямьсезлек тә матурлык белән бергә туа... «Матурлык» һәм «ямьсезлек» турындагы сюжет сызыклары романның ике өлеше түгелме? Авторның «матур» дип нинди вакыйгаларга, күренешләргә бәя бирүен әсәрне укыганда дәфтәрләрегезгә яза барыгыз. Романда ямьсез күренешләр дә, вакыйгалар да, кешеләр дә күп. Ләкин безгә автор фаш иткән төп ямьсезлекне табарга кирәк.

«Матур туганда» романы 1937 елда аерым китап булып басыла. Романның язылу һәм китап булып басылу елларын белү бик әһәмиятле.

МАТУР ТУГАНДА

(*Роман*)

I

1920 елның декабрь ахыры иде.

Әхмәт, мәгариф эшчеләре союзы[1] правлениесеннән кайтканда, култык астында сары кәгазьгә төрүле бер төенчек алып килде.

Фәрихә, бәрәңге котлетларын пычак очы белән әйләндереп маташкан килеш, Әхмәткә карап елмайды да, эчке бүлмәгә ымлап:

— Кунаклар бар бит,— диде.

Эчке бүлмәдә Әхмәткә таныш булмаган бер кеше һәм Каюм утыра иделәр.

— Менә бу безнең Мостафа иптәш,— диде Каюм,— авылыбызның аңлы кешеләреннән... Фронтларны айкаган егет.

Ул кеше, Әхмәт белән күрешкәндә, азрак елмаеп алды.

— Айкалып йөрдек шул,— диде.

Ул, Әхмәтнең кулын кысмыйча, тегеләй тотып караган төсле генә кул эченә алып күреште. Аның кулы бияләй кигән төсле салкынча, кытыршы һәм киң иде. Ул озынча саргылт йөзле. Елмайган чагында, ияк тирәләре җыерчыкланып, эре ак тешләре күренә; сирәк кенә кара мыеклары бөкрерәк һәм озынча борыны астында югала язып кала. Шуның белән бергә, аның зур һәм ялтырап торган шомырт төсле кара күзләре бөтен чыраена аерым ягымлык бирәләр.

---

[1] *Союз* — бу урында: сүз профсоюз турында бара.

Әхмәт самовар күтәреп кергәч, Каюмның чырае тагын да ачыла төште:

— Йә, Әхмәт, үзең ни эшләр каерасың? Һаман союзда эшлисеңме әле? — диде.

— Һаман шунда эшләгән булабыз.

Каюм утырган килеш, бер аягын алгарак сузды да, кулы белән тезенә сугып:

— Менә күрәсеңме? — диде.— Брюка. Сезнеке ич... союз брюкасы.

Ул учы белән кара чалбар өстеннән тез башын ышкып торган килеш өстәде:

— Әйбәт булды әле бу. Юкса тәмам рәт беткән иде.

— Сиңа да эләктемени ул? Кара син аны!

— Эләкмәскә! Месткомда эшлибез ич.

Әхмәт, Мостафага күз кысып:

— Шулай. Месткомнар үзләрен алдатмыйлар! — диде.

— Өязгә бик аз тамызгансыз, күбесенә эләкмәгән бугай,— диде Мостафа.

Каюм ярым шаяру тоны белән:

— Болар бит шәһәрдән артканны гына өязгә җибәрәләр,— диде.

Әхмәт бераз уңайсызланды:

— Юк, алай дип уйламагыз... Шәһәргә дә, өязгә дә бертигез бүленде. Биш членга бер брюка. Месткомнарга таратканда, стаж, общественный эш, мохтаҗлык шикелле нәрсәләр искә алынырга кирәк, дип әйтелде.

— Әлбәттә, шулай булырга тиеш,— диде Каюм...

Шул арада Фәрихә бәрәңге котлетлары алып керде. Френчик белән оекларны, бер-бер өсле итеп, комод ящигына куйгач, кунакларны сыйлый башлады.

Каюм, зур-зур гына ике котлетны бетереп, өченчесен читеннән томырып алгач:

— Бәрәңгене кайдан аласыз? — диде.

— Нигә? Тәмсезрәкме әллә? — диде Әхмәт.

— Юк, тегеләй, әллә ничек... тозсызрак төслеме шунда...

— Белеп ашарга кирәк, агай-эне,— диде Әхмәт,— ерак җирнең җимеше ул. Гупродком көз көне әллә кайдан, Рязань губернасыннан китерткән диме... Юлда килгәндә туңып беткән, союзлар аркылы членнарга тараттылар. Фәрихә рәхәтләнде генә. Базга төшеп йөрисе юк. Утын сараеннан шакылдатып тәяп алып керә, мин сиңа әйтим. Шуннан соң нишләтәсең аны Фәрихә?

— Кичтән кертеп, салкын суга салып куям...

Каюм, аз гына уйланып торгач:

— Беләсең нәрсә, Әхмәт? Без бит зур гына эш кузгатырга йөрибез,— диде.— Коммуна[1] оештырабыз, иптәш... Авыл хуҗалыгы коммунасы,— диде.

Әхмәтнең Каюм белән таныш булуына ел ярым чамасы гына иде.

1919 елның җәендә Әхмәт шәһәрнең татар көтепханәсенә барып, анда кыяр башы төсле итеп очланган бәләкәй сакаллы бер кешегә үзенең вакытлы рәвештә көтепханәдә эшләргә җибәрелгәнлеген кәгазьгә өстәмә итеп тел белән дә аңлаткач, алар көзгә хәтле көтепханәдә бергә эшләделәр. Көз көне Каюм авылга күчте. Әхмәткә болай дигән иде: «Авылда ныклап эшләргә кирәк, анда бик нык наданлык хөкем сөрә. Анда минем яхшы гына сөтле сыер бар, икмәк тә мондагыга караганда мулрак». «Дәлилләр» игътибарга алынырлык иде. Губерна мәгариф бүлеге аны Кигәвенле авыл көтепханәсенә мөдир итеп җибәрде. Ул анда, күрәмсең, сельсовет члены булып алган. Хәтта председательнең урынбасары икән.

Бу юлы да Әхмәт, Каюмны күрү белән: «Мөгаен, тагын берәр зур гына җәмәгать эше белән килгән булыр бу»,— дип уйлап куйган иде. Һәм ялгышмады.

— Коммуна диген, ә? Кайдан уйлап чыгардыгыз? — диде Әхмәт.— Интересный әйбер... Ну, әйбәт нәрсә уйлагансыз... Аерым участок кистерәсездер бит?

— Менә дигән урында билгеләдек. Авылдан ике генә чакрым. Су буенда, гаҗәп матур җирләр, шунда ук әрәмәлек, балыклы күлләр... Җәй көне бер тамаша инде менә.

— Ничә гаилә катнаша? — диде Әхмәт.

— Унбер гаилә... Теләсәң, сине дә катнаштырырга мөмкин. Монда туңган бәрәңге ашап ятканчы, Фәрихә иптәш, анда, ичмасам, менә дигәннәрен үзең үстерәсең и тундырмыйсың,— диде Каюм.

— Рәт юк шул, чёрт возьми! — диде Әхмәт.— Шәп булыр иде булуын. Минем карчык уракны да бик шәп ура. Буш кул белән бернәрсә дә эшләп булмас бит.

— Безнең үзебездә дә хозяйство яклары әллә нәрсә түгел... Унбер гаиләдә биш ат, җиде сыерыбыз бар,— диде Мостафа.

---

[1] *Коммуна* — күмәк хуҗалык.

— Эшне адәм рәтле итеп куяр өчен, ул гына җитми, әлбәттә,— диде Каюм,— безгә губземотдел ярдәм итә: ун ат, биш пар үгез бирергә ышандырдылар. Җитмәгән җиргә орлык та бирәселәр.

— Менә нәрсә, иптәшләр,— диде Әхмәт,— мин, анысын-монысын дигәндәй, өй әйберләрен сатып, бер атлык җыйнармын дип уйлыйм. Фәрихә минем сүзгә каршы килми ул.

— Нәрсә әйткәнеңне аңлыйбыз,— диде Каюм.— Чынлап катнашырга исәбең булса, язга хәтле син монда коммунаның представителе булырсың... Бер-ике атнадан алтмышлап ат килә, диләр. Йоклап калырга ярамас.

Әхмәт, Фәрихәгә карап:

— Тәвәккәллибезме, карчык? — диде.

II

Роща дигән дачалыклар шәһәргә тоташ диярлек.

Әхмәт, берникадәр дачаларны караштырып барганнан соң, куе агачлыкларны үтеп, Урал елгасының шәһәрдән көнчыгышка таба борылган култыгындагы ачыклыкка чыкты.

Морадимов дачасында Әхмәтне ике эт бик ачуланып каршы алдылар. Бобикның хуҗасы, бишмәт төймәләрен эләктерә-эләктерә:

— Нәрсә бар? Ни кирәк? — диде.

— Мин горсоветтан килдем. Исемегез ничек?..

— Исемем... Галләметдин лә.

— Менә нәрсә, Галләметдин агай,— диде Әхмәт,— сез миңа мондагы водокачканы күрсәтегез, миңа карарга кирәк.

— Бик әйбәт. Әйдә, кара... Нигә карамаска. Әйбәтләп кара. Һәммә нәрсәсе исән-сау, Алла боерса.

Водокачка җыйнак кына җил тегермәне рәвешендә шактый биек һәм пөхтә итеп эшләнгән. 7—8 метр югарылыкта зур тимер шан урнаштырылган, түбән ягы дүрт кырыйлап такта белән кыршыган[1] һәм баштанаяк аксыл-соры буяу белән буялган.

Галләметдин, печән астыннан чыккан насосның цилиндрлары өстендәге тузаннарны бишмәт чабуы белән сөртә-сөртә:

— Менә шушы инде аның главный машинасы,— диде.

Будкадан чыккач, Галләметдин, кулларын артына куеп, Әхмәткә карады да:

---

[1] *Кыршыган* — әйләндереп алынган.

— Водокачканы берәр җиргә күчерергә чамалыйсызмы әлләэ? — диде.

Әхмәт, аз гына уйлап торгач, кыска гына җавап кайтарды:

— Бәлки, күчерергә туры килер.

III

Бу бүлектә, Садыйк бай дачасын саклаучы Галләметдин, Әхмәт китү белән, бай янына бара һәм аңа Әхмәтнең водокачка белән кызыксынуы турында сөйли. Садыйк бай курка кала. Водокачка баганасы төбенә аның алтыннары, бриллиантлары күмелгән. Бай сакчысына, ят кешегә серне ачмасын өчен, нәселле сыер вәгъдә итә.

IV—V

Әхмәт, төзеләчәк коммунаның вәкиле буларак, шәһәр Советында водокачканы алып кайту өчен рөхсәт юллап йөри. Ә анда бюрократ өстендә икенче бер бюрократ утыра. Әллә ничә көн йөреп, ниһаять, шәһәр башлыгы Дунаевтан гаризасына кул куйдыра. Аннан соң, ордер яздырырга дип, бүлек мөдире янына керә. Бу вакыйганы ул менә ничек сурәтли:

Ул, отдел башлыгына кәгазьне биргәч, теге аны әйләндереп-тулгандырып карады да гаҗәпләнгән сымак иңбашларын тартып куйды.

— Ярар,— диде һәм каршындагы буш өстәлгә ымлап өстәде: — Менә хәзер делопроизводитель ордер язып бирер.

Әхмәт, делопроизводительне көтеп, бераз эндәшми торгач, сүз югыннан сүз итеп дигәндәй:

— Ордерда «установкасы белән» дип күрсәтергә кирәк булыр,— диде.

Отдел башлыгы, өстәлдәге гаризаны яңадан кулына алып, күзлек өстеннән Әхмәткә карады да:

— Ничек установкасы белән? — дип сорады.

— Менә, например, аның насосыннан башка әйберләре бар ич: шаны, будкасы, приводлары һәм башкалар.

— Эһемм... юк шул, аларны бирә алмыйбыз.

Әхмәтнең башыннан салкын су койган төсле булды. Ул кинәт үзенең ялгышын аңлады: «Телең коргыры! Нәрсәгә кирәк булды соң сиңа «установкасы белән» дигән булып лыгырдап эшне буташтырырга, телең авызыңа сыймады бугай»,— дип, чәнчердәй булып, үз-үзенә ачуы килде.

— Нишләп бирә алмыйсыз? — диде.

— Шулай, бирә алмыйбыз... чөнки иптәш Дунаев водокачка бирергә кушкан, ә сез монда тагын әллә нәрсәләр сорыйсыз. Ярый, водокачканы, то-есть насосын бирергә мөмкин.

— Ә соң насос белән генә без нишләтә алабыз?

— Теләсәгез нишләтегез... Качать итәрсез...

— Сез шаярасызмы әллә?

— Һич шаярырга уйлаганым да юк һәм сезгә дә шаярырга киңәш бирмим.

Әхмәт ачулы тавыш белән:

— Юләрлек сатмагыз, зинһар өчен,— диде,— бирегез минем гаризаны, мин тагын Дунаевка барам.

Теге кешенең муен тамырлары кабарып чыкты. Шулай да, салкын канлылык сакларга тырышып:

— Сакланыбрак сөйләшүегезне сорыйм, гражданин, монда дурака валять итеп йөрисез бугай,— диде.

Әхмәт, иза чигә-чигә, ниһаять, теләгенә ирешә. «Водочканы бай җиреннән алып, коммунага бирергә» дигән кәгазьгә кул куйдыра. Шәһәрдән авылына кайткач, аның янына булачак коммунарлар җыела. Аңа коммуна өчен ике йөз кырык дисәтинә[1] җир бүленеп бирелүе турында сөйлиләр. Каюм үзләре өчен Әхмәтнең водокачка юллавы турында әйтә. «Водокачка» сүзен ишеткәч, Чуртан Халикъ исемле коммуна әгъзасы сүзгә кушыла.

Чуртан Халикъ — озынча йөзле, кылыч борынлы, урта яшьләрдән үткән кеше. Кызгылт чәч һәм кызгылт сакалына чал кергән, борын тирәләре сипкелле, аскы ирене алга чыгыбрак тора.

Матур гына зәңгәр күләч күзләре һәм балыкныкы төсле авызы белән ул шаян балаларга охшый төшә.

Халикъның иреннәре балыкныкы төсле кызу-кызу селкенә иде.

— Нәрсә, Каюм, водокачка дисеңме?

— Әйе, водокачка, Халикъ абзый.

— Бәй! Ни эшкә ул? Безнең вакзалыбыз юк лабаса. Тимер юл вакзалларында була ич ул! Без кая куярбыз ул нәгъләтне?

— Яшелчә бакчасы өчен бик кирәк нәрсә ул. Безнең яшелчә бакчаларыбыз булачак,— диде Каюм.

— Һемм... төшендем хәзер. Ызначытсы, кәбестәләргә, кыярларга су сиптерергә? Вакзалы булмагач та, су чыга микәнни?

— Бик чыга, Халикъ абзый! Аның машинасы бар!

---

[1] *Дисәтинә* — 1,09 гектар.

— Ә... Алай булгач, бигрәк яхшы. Машинасы булгач, булды дигән сүз. Сызгырта дамы әллә?

Мостафа көлде:

— Булмаса, түбәсенә менеп, үзең сызгырып утырырсың! — диде.

Халикъ, эшнең рәтсез икәнен аңлата торган рәвештә, тел очын чылт иттереп куйды:

— Минем тиле-миле тагын котырып чыгар инде? — диде. Каюм төшенеп җитмәде:

— Кем, Нәсимә җиңгиме? Нәрсә өчен,— диде.

— Нәрсә өчен? Садыйк бай Хөснуллага җизнә тиешле.

— Булса ни?

— Әнә бүген җир кисү чутыннан приговор яздырдык, әйе диген... Ә минем тиле-миле пыр туза. Чукынып кына бет, хаҗәтемә кирәгең юк, ди. Минем, дигән була, кеше хакы ашап ризыкланыр хәлем юк.

— Ничек инде ул кеше хакы?

— Әлеге инде шушы Тубылгы аланында Хөснулланың тарыга сөргән җирләре безнең участыга кала, янәсе... Мостафа, Һидияткә борылып:

— Сезнең Мәликә нишли? Дуламыймы? — диде.

— Нишләп дуласын? Хөснулланың туганы түгел лә.

Каюм, Чуртанга төбәп:

— Нәсимә түти дә Хөснуллага ике туган баласы түгел ич, ә шулай да Хөснулла өчен кайгыра дисең.

— Тиле-миле бит ул. Аның кайгыруы белән шатлануы янәшә тора.

VI—X

Романның шактый өлеше байларның, кулакларның коммунага каршы астыртын эш алып баруына багышлана. Сыйнфый дошманнарның көннән-көн явызлана баруы турындагы уйдырманы язучы үзе язарга теләмәсә дә, язарга мәҗбүр булган. Шуңа күрә дошманнарның корткычлыгы турындагы урыннарның шактый өлешен төшереп калдырдык.

Бу бүлекләрдә шулай ук Кигәвенле авылында яшәүче ярлыларның авыр тормышы һәм үзара ызгышып, бозылышып яшәүләре турында да күп языла. Җәнҗал хәтта гаилә эчендә дә гадәти хәлгә әверелә.

Бүлекләрнең кыскача эчтәлеге мондый:

Садыйк бай водокачка сакчысы Галләметдингә дәшмәү хакына сыер бирүдән баш тарта. Сыер урынына кәҗә бирермен дип ышан-

дыра. Галләметдиннең саран байга ачуы килә, һәм ул водокачканы алырга килүче Әхмәтләргә, Халикъларга бай күмгән алтын-көмешнең кая күмелгәнлеген әйтә.

Байлар — үз эшләре, ярлылар үз эшләре белән мәшгуль. Григорий исемле офицерның тегермәнен тартып алганнар, ул үч алырга йөри. Садыйк бай үзенең алтыннарын эзли. Ул да түгел, авыл кешеләре партия ячейкасы оештыралар. Партиягә, коммунарлар эшенә аяк чалу өчен, Садыйк бай белән Хөснулла кулакның куштаны Нәгыйм дигән кеше дә керә. Ячейка төзүдә ярдәм итәргә романның төп геройларының берсе Фәтхи кайтып төшә.

Менә хәзер Фәтхи Татбашбюро[1] инструкторы сыйфаты белән ячейка оештырырга килгән иде. Фәтхинең тәкъдиме буенча, ячейка секретарьлыгына Мостафа сайланды. Дүртенче гариза җыелышка кызык кына тәэсир ясады һәм кайберәүләрдә елмаю тудырды.

Бу гаризаны бирүче Мәдинә Сабитова иде. Аның монда килеп керүенә кешеләр гаҗәпләнмәделәр. Моннан ике ел элек аның ире Нуретдин Сабитов Верховный Урал фронтында Дутов бандаларына каршы сугышта каты яралана һәм ике атна лазаретта ятканнан соң үлә. Мәдинә сигез яшьлек бала белән тол көе дөнья көтәргә кала. Аның иреннән бер ат, бер сыер, дүрт сарык, бәләкәй шома гына нарат өй һәм шуңар ятыш җыйнак кына такта өйалды, читән абзар һәм ат сарае калган иде. Ире сугышта вакытта бу бер ел чамасы шушы зур булмаган хуҗалыкны тырышып-тырышып саклап килде. Нуретдинның «кырык кичәсе» дә үтте, «ел ашы» да үтеп китте, хәтта аның үлүенә ике ел да тулды, ә Мәдинәнең әле йортка кияү керткәне юк. Шулай да йорт таркалмый, шактый тотрыклы күренә. Хәтта чак-чак кына ныгу галәмәтләре дә күзгә бәрелә. Мәсәлән, элекке бер сыер, дүрт сарык урынына хәзер аның йортында бер сыер белән бер тана һәм алты сарык күшиләр. Үзенең һәм баласының өс-башлары да элеккедән начар түгел, хәтта бераз шомара төшкәнлек күренә. Ә болар бер дә гаҗәп әйберләр түгел. Чөнки ул — чибәр яшь хатын (ул хәзер егерме сигез яшьтә иде) булу белән бергә, эш кешесе. Аны теләсә кайда очратып була. Кыр эшләрен дә үзе башкара, тегермәндә дә үзе йөри, калага да үзе бара, җәмәгать эшләренә дә, авыл Советы җыелышларында да актив катнаша. Абзар

---

[1] *Татбашбюро* — губерна партия комитеты.

читәннәрен сылау, өй агарту, морҗа корымнарын әрчү шикелле эшләрдән башлап, ат тугару, ат җигү, көлтә йөге төяү, аны бастырыклау һәм башка шуның кебек, гадәттә, ирләр эшли торган эшләрне дә менә дигән итеп башкара.

Хатын-кызлар, гомумән, Мәдинәне яратмыйлар. Ирләр, киресенчә, гел генә диярлек аны мактап телгә алалар: «Әмма булдыклы, каһәр, шуның өстенә чибәр тагын». Мәдинәнең алсу йөзендәге беленер-беленмәс вак һәм сирәк кенә шадралары, аның килешле борын һәм ярым елмаюлы кечкентәй матур иреннәренә, нечкә кара кашлар һәм хыялый зәңгәрсу күзләренә чынлап та аерым ягымлылык, курчак матурлыгына башка булган җылы сөйкемлелек биреп тора иделәр. Ул моны үзе дә яхшы белә.

Мәдинә тавышка куелган чагында, Халикъ, Ишмай һәм Кара Хәсән дә, бер-берләренә карашканнан соң, үзләрен партиянең яңа членнары дип хисаплап кул күтәрделәр. Җыелышның рәсми өлеше шуннан соң ябылды. Актыктан Фәтхи сорау куйды:

— Нишләп коммуна оештырдыгыз? Ни өчен артель түгел?

Коммуна членнарына бу сорау ятрак тоелды булырга кирәк, алар бер-берләренә карап елмайдылар. Бераз вакыт нәрсә әйтергә аптырап торганнан соң, Һидият:

— Менә Каюм абзый коммуна төзергә димләде һәм уставларын да алып кайтты,— диде.

«Менә сиңа председатель,— дип, Фәтхи эчтән уйлап куйды. — Димәк, үзенең билгеле бер фикере дә юк».

Һидият,— чынлап та, киң фикерле кеше түгел. Ул — таза гәүдәле, киң алсу йөзле, зәңгәр күзле, хәйләсез, намуслы, аз сүзле, шуның белән бергә, бик эшчән егет. Өе коммуна членнарының башкаларыныкына караганда иркен һәм яхшырак.

Аның эшчәнлек һәм намуслылыгы белән бергә, коммуна членнарының җыелышларын ясау өчен өенең иркен булуы да күз алда тотылып, ул беравыздан — председательлеккә, Каюм секретарьлыкка сайланган иделәр.

Ишмай белән Фәтхи җыелыштан бергә чыктылар. Мәдинә дә аларга кушылды. Ишмайның өе турысына барып җиткән иделәр.

— Ишмөхәммәт абзый, мин Мәдинәне чак кына озатып барам, хәзер кайтып килермен,— диде Фәтхи.

Бара торгач, алар, үзләре дә сизмәстән, аяк адымнарын акрынайттылар. Бераз эндәшми барганнан соң, Мәдинә зарланган төслерәк тавыш белән:

— Син бит бик күптәннән бирле авылда булганың юк,— диде.

— Әйе, мин авылга кайткан елны син кияүгә чыктың. Шул чагында, сиңа үпкәләп, туеңа да бармадым. Хәтерлисеңме?

— Бик яшь идек без ул чагында.

Алар Мәдинәнең капкасы янына килеп җиттеләр.

— Кереп утыр дияр идем, хәзер инде соң диярсең? — диде Мәдинә.

— Әйе, вакыт соң инде, кайтырга кирәк.

— Киткәнчегә хәтле бер килеп чык, Фәтхи.

— Әлбәттә, саубуллашырга кереп чыгармын.

Кул кысыштылар.

— Онытма, кил, яме,— диде Мәдинә.

— Ярар, тынычлы кич, татлы йокы.

Фәтхи, караңгы урам буйлап, Ишмай өенә кайтып килгәндә, бик аз тәрәзәләрдә генә утлар күренә иде.

Алар икесе дә бер яшьтәгеләр. Ул чагында унсигез яшь иде аларга. Кече яшьтән әткәсе Нәбиулла белән шәһәргә күчкән Фәтхи ул вакытта инде өйрәнчек слесарь булып эшли иде. Җәй көне кыска вакытлы отпускысында әткәсе белән әнкәсенең киңәшләре буенча авылга, Ишмай абыйсына кунакка килде. Абыйсы аны бик хуплап каршылады: «Килүең әйбәт булды, энекәем, менә озакламый бездә туй була, туйны да күрерсең, күңелең ачылыр»,— дип, үзенең шатланганын белдерде һәм аңлатма бирде: «Үзебезнең ерак кардәшләрдән түбән очның Фәхриҗамал исемле тол хатын үлеп, җиде яшьлек кыз баласы калган иде. Шушы баланы үзебезгә кызлыкка алып үстердек. Инде шуны Нуретдин исемле бер егеткә кияүгә бирәбез. Туй дигәнем менә шушы инде. Кызны үзебездән аерырга да кызганабыз. Кыз бик әйбәт. Малай да начар түгел шикелле».

Фәтхи монда ун көннәр кунак булды. Ишмай абыйсының «кадерле әманәт» дигәне Мәдинә исемле яшь кыз үзенең матурлыгы, ягымлылыгы белән кыска гына вакыт эчендә Фәтхинең йөрәгенә ялкын булып кереп урнашты. Ул аның белән сөйләшә алмый, берәр сүз эндәште исә, кызарына, әйткән сүзе кирәксез, мәгънәсез төсле тоела иде. Беркөн алар өйдә бераз

вакыт Мәдинә белән икәүдән-икәү калып тордылар. Фәтхи, үзенең йөрәк тойгысын аңлатырга һичбер сүз таба алмыйча аптырап торгач: «Туй буламыни, Мәдинә?» — диде. Мәдинә елаган тавыш белән: «Мыскыллама, зинһар өчен, Фәтхи. Абыең белән җиңгәң шулай итәләр ич!» — диде. Фәтхи, бөтен көчен җыеп, мондый җавап кайтарды: «Мин сине мыскылламыйм. Син аларны тыңлама, теләсәгез нишләгез, бармыйм, диген». «Ул чагында бит алар мине куып чыгарырлар. Аннары мин кая барырмын?» Фәтхи уйга калды. Аның маңгаена бөртек-бөртек тирләр чыкты: «Мин сине әткәйләргә алып барыр идем дә... бүлмәбез бик бәләкәй, чәнчелгересе! Җәнҗал куптарырлар. Тагын сиңа уңайсыз булыр. Шуңардан куркам»,— диде. Иртәгә туй буласы көн ул тагын Мәдинәне ялгызын очратты. Бу юлы кыюрак тон белән: «Барырга булдыңмыни инде, Мәдинәкәй?» — диде. Теге дә шулай ук бер дә каушап тормыйча җавап бирде: «Бармыйча,— бирәләр ич!» — «Теләсәгез нишләгез, мин бармыйм дип әйттеңме соң?» — «Гөлбикә җиңгигә әйткән идем: теләсәгез нишләгез, мин әйтәм, мин Нуретдингә кияүгә чыкмыйм, дим. Шуннан... Шуннан, илаһи, күзләрен акайтты, илаһи акайтты. Тыныңны чыгарасы булсаң, ботыңнан тотармын да стенага бәрермен, ди. Шуннан соң Ишмөхәммәт абыйга әйтә алмадым, курыктым».— «Син үзең Нуретдингә барырга телисең бугай. Юкса Ишмөхәммәт абыйга да әллә кайчан әйткән булыр идең».— «Валлаһи, җир йотсын әгәр, теләмим. Мин боларга әйтмичә үк тә синең әткәләреңә китәр идем. Бүлмәбез бик бәләкәй дисең ич...» Фәтхи, нәрсә әйтергә дә белмичә, бераз аптырап торгач, янаган тавыш белән: «Үзем слесарь булып алыйм әле. Бүлмәне ничек итеп зурайтып була икәнен күрсәтермен мин аларга»,— диде. «Шулай шул, күрсәтергә кирәк»,— диде Мәдинә. Фәтхи кискен итеп өстәп куйды: «Син, чынлап та, Нуретдингә кияүгә чыгасы булсаң, мин барыбер сиңа рәнҗим». Шушының белән аларның сүзләре бетте. Туй көнне Ишмай белән Гөлбикә Фәтхине туйга барырга нихәтле кыстасалар да, Фәтхи барырга риза булмады. Шул ук көнне авылдан шәһәргә кайтып китте. Ул ничә еллар буенча шушы вакыйганы онытмады, исенә төшергән саен һәм кызганычлы, һәм көлкенечле тойгыларга бирелә иде. Еллар үтү белән, аның Мәдинәгә булган яшь вакыттагы беренче саф мәхәббәт хисе, әлбәттә, сүрелде. Шулай да, Нуретдиннең фронтта үтерелү хәбәрен ишеткәч, ул Мәдинәнең язмышы белән

шактый кызыксынды, аны күрү теләге уянды. Ләкин моңарчыга хәтле авылга кайтуга һич тә уңайлы вакыт туры китерә алмаган иде.

Менә хәзер отпускысы бетәргә бары ике көн калды. Ә иртәгә, коммуна членнарының кайберләре белән генә булса да, аерым-аерым сөйләшәсе бар.

Фәтхи караңгы урам буйлап Ишмай өенә кайтып килгән чакта гел уйланып килде.

Нуретдиннең үлгән хәбәрен ишеткән чакта, Фәтхи Мәдинәне шактый картайган, таушалып ямьсезләнгән кыяфәттә күз алдына китергән иде. Юкса нишләп ике ел буена кияүгә чыкмый торыр иде? Әмма Фәтхинең болай итеп уйлавы чынбарлыкта дөрес булып чыкмады. Мәдинә картаймаган да, таушалмаган да, матур күзле, кечкенә алсу авызлы, нык, зифа гәүдәле, гаять сөйкемле яшь хатынга әверелгән. Фәтхи үзенең бу турыдагы ялгышуына үзе дә сизмәстән чак кына шатланды һәм чак кына кайгырды. Сугыш һәм революция елларын кичергән, иреннән калып, ике ел тол көе яшәгән хәлдә аз гына да бирешмәгән Мәдинәне моннан ун ел элек Фәтхи кеше булу ягыннан бөтенләй аңламаган, димәк. Ул чагында аларның трагедиясе «бүлмә кечкенә» булуда төенләнде. Хәзер Фәтхинең бүлмәсе кечкенә түгел, һәм шулай ук Мәдинәне дә һичкем өйдән куып чыгарырга уйламый. Димәк, шартлар бөтенләй икенче. Ә тойгылар? Тойгылар да шулай ук. Моннан ун ел элек Фәтхинең йөрәгендә калган эзләрдән яктылык шәүләләре, чагылып, йомшак кына дулкынлана иделәр.

Апрель урталарында Мостафаның каенагасы ике ат белән шәһәргә барып, гаиләсе белән Әхмәтне һәм аның вак-төяк әйберләрен алып кайттылар.

Коммуна членнарының җыелышында, Каюмның тәкъдиме буенча, Әхмәтне Нәгыйм өенең бер як яртысына урнаштырырга карар бирелгән, һәм Нәгыйм дә моңар каршы килмәгән иде.

Алар Каюм квартирасына бардылар. Анда Мәдинә дә утыра иде. Каюм Әхмәт белән Мәдинәне таныштырды.

— Иптәшнең исеме ничек? — диде Әхмәт.

— Мәдинә. Фамилиясе — Сабитова.

— Ә! Мәдинә иптәш сез буласыз икән... Фәтхи исемле егетне беләсез, әлбәттә. Слесарь, партия члены. Без китәр алдыннан, квартирага килеп, сезгә бер бәләкәй төенчек бирде.

Мәдинә салкын гына тон белән:

— Рәхмәт инде, алайса,— диде. Каюм:

— Яхшы, акыллы егет,— диде.— Чибәр генә, сәяси белеме бар.

Мәдинә китәргә кузгалды. Аны артык утырырга кыстамадылар.

Мәдинә төенчекне, чишәргәме-чишмәскәме дип, бераз икеләнеп торгач чишәргә булды. Кәгазьләр эченнән фиолет төсендә ефәк баш яулыгы һәм яулык эченнән хат чыкты.

Хатта мәхәббәт турында бер сүз дә булмау ни өчендер Мәдинәгә бик ошады. Ул аны тагын бер кабат ашыкмыйча, бик дикъкать белән укыды. «Киткән вакытта сине күрә алмавыма бик борчылам»,— дигән сүзләрне укыганда, күзләренә яшьләр килде.

XI

Кигәвенле авылының чакрым ярым төньягында Сакмар елгасына якын Үрге әрәмәлек дигән урын җәй көннәрендә табигатьнең матурлыгы, балыклы күлләрнең күплеге белән генә түгел, бәлки монда җиләк-җимешнең муллыгы белән дә кешеләрне үзенә тарта. Бу урыннарда табигать төзү ягыннан төрлелек бирә алуда үзенең искиткеч осталыгын күрсәткән. Монда эчпошыргыч тигез бертөрлелек юк. Монда матур музыкага тартым кискен алмашлылык, төрлелек, матур гармония ярылып ята. Авылдан чыгып киткәч тә, тигез басуның сул ягы буйлап таба кырые төсле түбән төшеп киткән ялпак[1] тау киртләче сузылып бара. Шушы төшенке киртләч Үрге әрәмәлеккә хәтле өзелми. Өске як басудан барган кешегә киртләчнең түбән ягы матур әкият даласы төсле булып күренә. Анда яшел хәтфә өстеннән, борылып-борылып, елышып барган көмеш елан төсле, Сакмар елгасы ага. Анда, уннарча чакрымнарга сузылган хәтфә келәм күпертеп эшләнгән каралҗым яшел чәкәннәр төсле, күзләрне иркәли торган уйдым-уйдым тубылгы болынлыклары күренә. Алар арасында ераклы-якынлы, зурлы-кечкенәле, әкиятләрдәге тылсымлы көзгеләр төсле, матур күлләр ялтырап ята. Шушы «әкият даласы»ның югары ягыннан тау киртләче буйлап тигез басудан чакрым ярым барганнан соң, киртләч кинәт уңга борыла, һәм синең алдыңда бөтенләй яңа күренеш ачыла. Монысы Үрге әрәмәлек дип атала. Аның алгы планындагы инеш буйлап уң якка

---

[1] *Ялпак* — җәенке.

таба куе үлән һәм биек камышлар белән каймаланган тезмә күлләр сузылып китә, ә инешнең аръягында дулкынланып торган төсле чиратланган, ялпак, шуның белән бергә, биек булмаган күтәренке таучыкларны каплаган әрәмәлек — бәләкәй урманлык башлана. Кигәвенле авылына бара торган юл, шушы урында уңга борылып, әлеге инешне ике чакрым чамасы урап, Сакмарның югарыгы ягына китә, ә әрәмәгә бара торган юл, сукмак диярлек дәрәҗәдә кечерәеп, туп-туры инеш аркылы үтә. Коммуна кыштан ук үзенә Үрге әрәмәлек инешнең төньягындагы ялпак тауның көньяк итәген һәм өске ачык өлешендәге тигез җирне билгеләгән иде.

Монда апрель башыннан ук эш кайнап китте. Коммунаның бөтен ир членнары гына түгел, хатын-кызларның да һәммәсе диярлек бик зур дәрт белән эшкә катнаштылар. Егерме бишләп кеше, язгы матур һавада җырлап, көйләп, уенкөлке белән эшнең авырлыгын сизмиләр, бәлки мондый күңелле күмәк эш аларга шактый зур шатлык һәм какшамаслык көч бирә иде.

Каюмның шатлыгы эченә сыймый. Иртәдән төш вакытларына хәтле ул шлея-камыт төзәтү, арба, күчәр юнәтү шикелле эшләр белән шөгыльләнә. Төштән соң әрәмәгә бара. Кичкә хәтле көрәк яисә китмән белән тал әрчи, җир йомшарта. Кешеләрнең күңелләрен күтәрерлек сүзләр сөйли. Аларның ашау-эчү хәлләре бик үк шәптән түгел. Иртәдән авылдан сөтләп чәй эчеп киләләр. Төш вакытында бәрәңге яисә тары ярмасы белән бәрәңге салып пешерелгән өйрә ашыйлар. Шулай да аштан зарланучы юк.

XII

Коммунарлар җыелышы. Крестьяннар язның коры килүенә зарланалар. Чәчүгә чыгарга әзерлек турында сөйләшәләр. Эш бүлешәләр. Бөтен нәрсәне бергәләп хәл итәләр. Игътибар итик: коммунаның председателе дә, аның ярдәмчесе дә, секретарь да, партия оешмасы җитәкчесе дә — бар да башкалар белән беррәттән эшләргә тиеш булалар. Шуңа күрә автор Һидият турында «председатель сыйфаты белән», ди. Монда түрәләр дә, аларга буйсынган кешеләр дә юк. Җыелыштан кайткач, Мәдинә Фәтхигә хат яза. Менә ул хат:

«Фәтхи, сиңа чын күңелдән бик күп сәламнәр җибәрәм. Бик матур бүләк җибәргәнсең. Аның өчен сиңа бик зур рәхмәт. Хатыңны бик яратып һәм шатланып укыдым. Киткән вакытта күрешмичә китүеңә күңелем бик ярсыган иде. Лә-

кин синең хатыңдагы ягымлы җылылык йөрәгемне эретте, күңелемне йомшартып җибәрде. Әйтергә уңайсыз булса да әйтәм: күзләремнән мөлдерәп яшьләр агып китте, һәм син җибәргән кадерле бүләк — ефәк яулык белән күз яшьләремне сөртү миңа чиксез ләззәт, очсыз-кырыйсыз бәхетлелек тойгысы бирде. Инде коммуна турында берничә сүз: соңгы атнада огород өчен җир хәзерләү эшендә булдык. Ир белән хатыннар күмәк булып бергә эшләдек. Бигрәк тә күңелле бергә эшләве. Огородыбыз Үрге әрәмә дигән урында. Искиткеч матур җир. Каюм абзый әйтә: җәен шунда алачыклар, чатырлар корып торырбыз, ә бераз байый төшкәч, шунда ук һәйбәт йортлар салырбыз, ди. Чөнки зрә дә матур җир. Шәһәрдән килгән әлеге Әхмәт иптәш Каюм абзый белән икесе хатыннар белән бергә огородта эшләргә билгеләнделәр. Коммунага керүемә бик шатланам һәм читтә, шәһәрдә аның белән кызыксынучы кешенең минем йөрәгемә якын булуы мине тагын да шатландыра. Бик кайнар хөрмәт белән, Мәдинә».

Хатны конвертлап, адресын язды һәм чынаяклар шкафының түбән тартмасына салып куйды. Чишенеп урынга ятканнан соң да, ул, көндезен огородта эшләү, кич җыелышта булуына карамастан, шактый озак йоклый алмады. «Отпуск вакытында кил, килми калма»,— дип язганда ничек булыр икән? Фәтхи моңар ничек карар иде? «Бу бик бәйләнчек хатын, нәкъ сагыз икән бу»,— дип, начар уйлар идеме? Әллә югыйсә: «Болай кыска итеп чакыргач, чынлап ярата булырга кирәк, шулай булгач бармыйча ярамый»,— дип уйлар идеме икән? Теге вакытта ул, һичшиксез, мине яраткан иде, ләкин шуңар карамастан алып китәргә батырлык күрсәтә алмады. Бүлмә кечкенә булуны, әткәләре ягыннан җәнҗал күтәреләчәкне уйлап чигенде. Ни әйтсәң дә, Фәтхи кыюсыз...

XIII

Бу бүлектә сыйнфый дошманнарның коммунарларга каршы һөҗүмгә әзерлекләре турында сөйләнә. Садыйк байның улы Әмирҗан кайта.

XIV—XV

Яңгыр һаман юк. Коммунарлар утырткан яшелчәгә суны чиләк белән ташып сибәләр. Водокачканы һаман эшләп бетерә алмыйлар әле. Бер якта җир сөрәләр, икенче якта карабодай чәчәләр... Эшнең шундый кызу вакытында Һидият белән Мостафаны шәһәргә партия комитеты секретарена чакыралар. Коммуна җитәкчеләре эштән

аерылганга зарлана-зарлана баралар. Алар анда ашыгыч рәвештә барып җитәргә тиешләр. Юл озын. Бүген чыгып, иртәгә генә барып җитәрлек.

Һидият белән Мостафа иртән сәгать тугыз ярымда губкомга[1] бардылар. Сәмигуллин эшли торган бүлмәдә техник секретарь гына бар иде.

— Сәмигуллин килмәдемени әле? — дип сорады Мостафа.

— Килде. Губком секретаре янында.

Утырдылар. Бер ярты сәгать вакыт үткәч, кызу-кызу адымнар белән Сәмигуллин керде. Болар исәнләштеләр.

Сәмигуллин, китеп барышлый, кәгазьгә карамыйча гына:

— Беләм, беләм, чак кына көтегез, бюро утырышы,— диде дә чыгып китте. Болар тагын утырдылар. Бер ярты сәгать утырганнан соң, коридорга чыгып, махорка төрделәр. Һидият эч пошулы тавыш белән:

— Әйттем ич: шулай булыр,— диде.

— Ничек дип әйттең?

— Так себе, кирәксезгә чакырганнардыр дип. Кирәкле эш булганда неужели бер биш кенә минут сөйләшергә вакыт тапмас иде.

— Бюро утырышы диде ич.

— Биш кенә минут дим?

— Сиңа шулай да бит... Монда икенче төрле, һәр эшкә җитди карала.

— Ярар, икенче төрле булгач, көне буе көтеп утыр инде менә!

Тәмәке очларын почмакка ташлап, аяк белән басканнан соң, алар тагын кереп утырдылар.

Бүлмә тын. Секретарь яза да яза. «Протоколлар күчерә ахрысы»,— дип, Һидиятнең күңеленә килеп китте. Бераз утыргач, ул:

— Минем тагын тәмәке тартасы килә,— дип, коридорга чыгып китте.

Ул тагын Мостафа янына кереп утырды. Теге егет һаман эндәшми-тынмый каләм белән кыштырдатып утыра.

Һидият, Мостафаның колагына иелә төшеп, акрын тавыш белән:

— Мин бу бәндәдән сорап карыйм әле, нәрсә дияр икән...— диде һәм, урыныннан торып, үкчәләрен идәнгә

---

[1] *Губком* — партиянең губерна комитеты.

тидермичә, аяк башлары белән генә баскан килеш, теге егетнең өстәле янына барды:

— Сез белмисезме, туганкай, безне нәрсәгә чакырып китерделәр икән? — диде.

Теге егет, яза торган җиреннән тукталып, башын чак кына күтәрде. Бер Һидияткә, бер Мостафага күз төшереп алганнан соң, үгетләгән төслерәк тавыш белән:

— Нәрсә соң син, койрыгы пешкән мәче төсле бер урында утыра алмыйча, әрле-бирле йөрисең? Чак кына кәтеп утырырга мөмкиндер бит! Кешеләр көне буе бер урында эшләп утыралар, анда да эчләре пошмый. Нәрсәгә чакырганнар, имеш! Кирәк булганга чакырганнардыр. Кирәкмәсә чакырып тормаслар иде,— диде һәм, бернәрсә дә булмаган төсле, язуын дәвам иттерергә кереште. Һидият, бер сүз дәшмичә, кәефсезләнгән хәлдә Мостафа янына килеп утырды. Байтак вакыт тавышсызтынсыз утырганнан соң, Һидият Мостафаның колагына иелде. Бу юлы элеккеләренә караганда да акрынрак тавыш белән:

— Тәмәке тартырга чыгабызмы? — диде һәм, баягыча, аяк башларына басып чыгып китте.

Ул чыккач, секретарь Мостафага карап сорау бирде:

— Теге кеше сезнең авылда кем булып эшли?

— Ул — безнең коммунаның председателе.

— Шушы тупас кешедән башка председательлеккә рәтлерәк кеше таба алмадыгызмыни?

— Безгә бик ул хәтле тупас түгел төсле...

— Танымаган, кемлеген белмәгән кешене «бәндә» дип мыскыллы сүз белән атау, сезнеңчә, тупаслык түгелдер шул. Хәлбуки капиталистик системаның зәһәрле җимешләреннән берсе ул. Хәзер без капитализм агачын аудару белән бергә аның зәһәрле тамырларын да әрчергә тиешбез. Син ячейка секретаре булгач, моны аңларга тиеш идең. Хәлбуки син теге кешене «тупас түгел төсле» дип акларга маташасың...

Бик озак көттергәннән соң гына, Сәмигуллин Һидият белән Мостафаны кабул итә һәм, сыйнфый дошманнар белән көрәшү өчен, мылтыклар биреп җибәрә. Эш кешеләрен шуның өчен генә чакыртып, көне буе көттергәннәр икән.

XVI

Бу бүлектә дә авыл байларының, кулакларның һәм куштаннарның коммунага каршы мәкерле планнар коруы турында сөйләнә. Болар Гает бәйрәмен үзләренчә үткәрергә әзерләнәләр.

XVII—XVIII—XIX

Авылга җәйге каникулга студентлар кайтып төшә. Бу бәйрәмне алар да үзләренчә үткәрмәкче булалар. Җырчылар, биючеләр табалар. Каюм доклад әзерли. Кичәгә бик күп халык җыела. Ләкин байлар ягы да тик ятмый. Нәгыйм котыртуы буенча, Нокта Вәли исемле бандит, концерттан кайтканда, Мәдинәгә һөҗүм итә, аны яралый, ләкин җиңә алмый.

XX

Бүлектә әдип партия түрәләренең ялы турында яза. Губерна җитәкчесе Сәмигуллин, Гыйльманов һәм бюро әгъзасы Фәтхи балык тотарга баралар.

Алар, юк-барны сөйләшеп бара торгач, тимер юл күпере янына барып җиттеләр. Уралның түбән ягына таба бер ярты километр чамасы бардылар. Бу бик матур җир иде. Монда суның култыкланып эчкә кергән өлеше бик акрын ага, кырыйлары ямь-яшел чирәм.

Гыйльманов үзенең кармаклар бәйләменнән Сәмигуллин белән Фәтхигә икешәр кармак аерып бирде, үзенә өчне алды.

Сәмигуллин белән Фәтхи кармакларына, Гыйльманов әйткәнчә, селәүчәннәр утыртып, аларны суга җибәрделәр.

— Күперне кара, күперне! — диде Сәмигуллин.— Ерактан нинди көяз күренә. Нечкә бармаклар белән чигелгән матур чәкән төсле һавада асылынып тора!

— Әйбәт күпер, сөйкемле күпер! — диде Фәтхи.— Нечкә бармаклар дигәннән күңелгә килде әле. Мин өйләнергә чамалап торам бит, Сәмигуллин. Синнән киңәш сорарга исәпләп йөридер идем. Менә хәзер уңай туры килде.

— Бик мәслихәт. Нигә өйләнмәскә? Әллә кайчан өйләнергә кирәк иде инде сиңа. Теге хатының бит ул хатын түгел, әллә нәрсә иде. Кайдан шул торгаш-спекулянт кызына килеп капкансың! Әнә, әнә, әнә чиртә! Тарт тизрәк!.. Һуп! Ярый бу! Китер миңа. Алабуга бу. Йә, өйләнү мәсьәләсен сөйли идең. Ничек, кайдан, кемгә өйләнмәкче буласың? Фу, шайтан алгырысы! Тукта әле, сөйләми тор, минеке чиртә башлады... Ии, селәүчәнне сыпырткан. Йә, сөйлә инде хәзер.

— Мәсьәлә болай: мин бервакыт, моннан ун ел элек...

— Әй, әй, әй! Әнә чиртә ич! Тизрәк тарт.

— Менә шул вакытта...

— Кайсы вакытта?

— Моннан ун ел элек...

— Хәзер инде минеке тамырга эләкте!

Фәтхи Сәмигуллинга үзенең өйләнү планын сөйли алмады да сөйли алмады. Чөнки сөйләргә дип авызын гына ачтымы, йә берсенең калкавычы күз кыса башлый, йә икенчесенеке.

Төш вакыты җитәр алдыннан:

— Әйдә, кайтабыз,— диде Сәмигуллин.— Мин нихәтле дәрт белән синең әлеге өйләнү мәсьәләсен тыңларга телим, юк, булмый бит, булмый да булмый! Нишләтәсең? Ярар инде, миңа керерсең, шунда иркенләп сөйләшербез.

Кич белән ул, Сәмигуллинга барып кергәч тә:

— Иртәнчәк син миннән: өйләнергә уйлаган кешең кем? Хатынмы, кызмы, эшчеме, крестьянмы яисә прочиймы? — дип сораган идең бит. Менә минем өйләнергә уйлап йөргән кешем, әлеге вакыйгада яраланган хатын турында сөйләдем бит — шушы үзе инде.

Фәтхи, унсигез яшендә чагында, Мәдинәне үлеп яраткан-лыгын һәм үзенең яшьлек тәҗрибәсезлеге аркасында бик көенечле хәлдә Мәдинәдән ераклашуын сөйләде. Шуннан соң ун ел үткәч кенә, бу ел язның башында аның белән яңадан очрашуларын, хат алышуларын вак-төяк тәфсиленә кадәр[1] сөйләде.

— Әгәр кызыксынсаң, хатны да күрсәтергә мөмкин,— диде ул.

Хатны ул (Сәмигуллин. — *А. Я.*) бик җитди чырай белән һәм шактый озак укыды. Укып бетергәч, чыраенда шундый ук җитдилек сакланган хәлдә әйтте:

— Бу хат миңа ошады, дускай, акыллы язылган, җылылы-гы да җитәрлек. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы бар. Ул якны исәпкә алганда, синең аңар өйләнүең мәслихәт күренми.

Фәтхи Сәмигуллинның нәрсә әйтергә уйлаганын сизенде:

— Әйт, нәрсә ул? — диде.

— Бик әһәмиятле момент ул. Мәсәлән, сез үзара тормыш гармониясе төзү белән бер үк вакытта хезмәт гармониясен бозмыйсызмы соң? Әнә ул үзенең хатында: коммунага керүемә шатланам, ди. Һәм коммунаның эшләре турында бик дәртләнеп яза. Син аны монда шәһәргә алып килсәң, ул сиңа, дөресрәге икегезгә, аш пешереп, кер юып торырга мәҗбүр булачак. Авылда үскән, авылда яшәгән бер хатын, ул эшләрне дә бик шәп итеп эшли торгандыр, дип уйлап булмый. Әшкә,

---

[1] *Тәфсиленә кадәр* — бөтен нечкәлекләре белән.

хезмәткә керү мәсьәләсе дә квалификация булмаганда җайлы ук булмас. Ике арадагы тигезлеккә уңайсызлык китерер. Ә син үзең, авылга барып, иген эшен эшләп тора алмыйсың, син аңар хәзерләнмәгән.

— Аны мин җәй көне эшеннән аермыйча, үземнең отпускы вакытында анда барып торам. Ә кыш көне аны монда алып киләм, аш пешерүне ул кирәгенчә рәтли алмас дип мин уйламыйм. Сәләтле кеше ул. Булдырыр ул аны. Шәһәрдә калсам, хатынны укытырга, аннан эшкә тартырга мөмкин булачак.

— Бу акыл бу, Фәтхи. Уйлап та торма, туганкай, тәвәккәлли генә бир, мин сиңа чын дусларча әйтәм.

XXI

Кичкырын Мәдинәнең өенә фельдшер белән врач килеп керделәр. Врач башлап Мәдинәнең яңагын карады. Зарарлы әйбер тапмады. Аннан соң фельдшер бармактагы марляны сүтеп ташлады. Тезне карадылар.

Фельдшер белән врач чыгып киткәннәр генә иде, авыл исполнителе Фәррах Мәдинәгә хат кертеп бирде. Ул, беркадәр дулкынланган хәлдә, хатны укырга кереште:

«Мәдинә дус, бүген ял көне булудан файдаланып, иртәнчәк сиңа бик сагынулы хат язарга утырган идем. Ике иптәш килеп, үземне көчләп алып киткән төсле, Урал буена балык тотарга дип алып киттеләр. Аның берсе — үзебезнең губком янындагы татбашбюроның җаваплы секретаре Сәмигуллин, икенчесе аның ярдәмчесе — техник секретаре. Урал буенда булган хәлләрне хәзергә мин сиңа язмыйм. Мин Урал буеннан кайтуга, Хәйбул абзый Шихрай мине көтеп тора иде. Мин аңардан сездә булып үткән зур вакыйга турындагы хәбәрне ишеттем. Бу вакыйгада мине нык дулкынландырган нәрсә — синең бик зур батырлык күрсәтүең, тимер белән коралланган бандитка каршы, әлеге Сәмигуллин иптәшнең сүзләре белән әйткәндә, яшь ана Арслан төсле, бирешмичә көрәшүең. Хәйбул абзыйның фельдшердан ишетеп әйтүенә караганда, синең яраларың куркынычлы түгел икән, мин моңар чиксез шатланам. Көндез (сезнең вакыйганы ишетмәстән элек) Сәмигуллин белән вәгъдәләшүебез буенча, кич белән мин аның квартирасына бардым. Әлеге сезнең вакыйганы сөйләдем һәм, шул уңайдан, моннан ун ел элек синең белән икебезнең арада булган кыска мәхәббәт вакыйгасын һәм бу соңгы команди-

ровкам вакытында синең белән яңадан очрашуыбызны аңлаттым. Чөнки ул — миңа бик якын дус, иптәш. Бу соңгыларны мин аңар көндез Урал буенда балык тоткан вакытта ук сөйләмәкче булган идем, ләкин балыкларның бик еш чиртүләре һәм шул арада әледән-әле кармакларның тамырга эләгүләре моңар комачаулады. Сүз арасында монысын да әйтергә кирәк: кармак белән балык тоту бик бәрәкәтсез эш дигән карарга килдек. Аның белән күбесенчә өйләнмәгән яисә минем шикелле тол кешеләр генә шөгыльләнәләр икән. Шушы бәрәкәтсез кәсепкә бирелеп китү куркынычыннан котылу өчен, Сәмигуллин миңа да өйләнергә киңәш бирә. Беренче баруда бик биздем бизүен. Ләкин Сәмигуллин әйтә: ул беренче баруда гына шулай кызыксыз тоела икән. Икенче, өченчеләрендә кеше башы-аягы белән шуңар чумып китәргә мөмкин. Бигрәк тә хатынсыз кешеләр өчен ул куркыныч зур, ди. Ул моны, әлбәттә, үзенә якын булган тәҗрибәдән чыгып сөйли. Синең өчен моның әһәмияте дә, кызыгы да юктыр, әлбәттә. Тик әле сүз уңае белән әйтеп китәргә туры килде. Шулай Сәмигуллиннан мин бернәрсә дә яшермәдем. Сине яратуымны әйтү генә түгел, хәтта синең рөхсәтеңнән башка ук, миңа язган хатыңны да күрсәттем. Чөнки югарыда әйткәнчә, ул миңа якын дус һәм шуның өстенә партиянең ышанычлы кешесе, монысы минем өчен бигрәк тә кыйммәтле. Ул миңа һичбер вакытта начар киңәш бирәчәк түгел. Мин аны белеп торам. Ул синең хатың турында болай диде: «Акыллы язылган, җылылыгы да җитәрлек, җәмәгатьчелек тамырлары да бик нык сизелеп тора».

Ул бу соңгыларны синең коммуна эшенә бирелүеңә карап әйткән булыр. Һәм болай дип өстәде: «Яхшы хатын өчен кирәк булган төп сыйфатларны бу хатта беркадәр күреп була»,— диде. Якын иптәшнең синең турыда мондый фикер әйтүе мине бик шатландырды, Мәдинә. Мин аның белән саубуллашып чыгып киткән чакта, миңа болай диде: «Хат язганда Мәдинә иптәшкә миннән дә хөрмәт белдерүемне һәм батырлык күрсәтүе белән котлавымны яз». Менә мин аңардан кайткач та үземнең бүлмәмдә сиңа хат язарга утырдым һәм шушы югарыдагыларны яздым. Тагы ни языйм икән? Чын күңелдән тизрәк сәламәтләнеп җитүеңне телим. Онытa язганмын икән: бер айдан отпускы алам. Шулвакыт күрешәбез, димәк. Читтә чын күңелдән сине якын дус күрүче, кайнар йөрәк белән сөюче кешең барлыкны исеңнән чыгарма, яме! Маңгаеңнан һәм күзләреңнән үбеп, Фәтхи».

Фәтхинең беренче хатында мәхәббәт турында бер сүз дә булмау Мәдинәгә нихәтле ошаган булса, монысында сөю дигән сүзнең булуы аннан да артыграк ошады. Хатны бер кат укыгач та, ул, йөзен куллары белән каплаган килеш, байтак вакыт уйланып торды. Анда ачыктан-ачык сөю турында әйтелү белән бергә, әйләнмәлерәк рәвештә булса да, хәтта өйләнү турында да әйтелгән. Ә андый мәсьәлә турында Фәтхи ашыгып язса, аның нинди коммунист, нинди организатор һәм нинди пропагандист булуы мөмкин иде! Мәдинә, шуларны уйлап-уйлап торгач: «Озак җавап язмау һәм аның өчен акланып маташмау белән бик яхшы иткәнсең, җаным Фәтхи...» — диде дә хатны күзләренә каплады...

XXII

Бу бүлектә авылның алдынгы кешеләре коммунарларга зыян ясаучыны эзлиләр. Җинаятьне оештыруда Нәгыйм гаепле булырга тиеш, дип шикләнәләр. Аны җыелышта партиядән чыгаралар, ләкин коммунада калдыралар.

XXIII

Үрге Кигәвенле ягыннан, чыбык тарантаска утырып, волком секретаре Жуков килеп чыкты.

— Менә нәрсә, иптәшләр,— диде Жуков.— Верхнеуральск ягында оешкан Охранюк бандаларының кайбер отрядлары бу якларга таба хәрәкәт итү турында хәбәр бар. Һәр ихтималга каршы винтовкаларыгызны ышанычлы җирдә чистартылган, майланган көе әзер тотарга кирәк. Алар, унбиш-егерме кешелек аерым отрядларга бүленеп, кинәт һөҗүмнәр ясау тактикасын тоталар икән. Һәр сәгать, һәр минут хәзер булып торырга кирәк. Бигрәк тә төннәрен берәр кеше каравылда тору кирәк булыр.

Жуков саубуллашып китте. Мостафалар күл буена, учак корылган җиргә, төшке аш ашарга төштеләр. Якын басудагы пар сөрүчеләр дә килгән иделәр. Кәбестә кыючы, чүгендер утаучы хатын-кызлар да җыйналдылар.

— Иптәшләр,— диде Мостафа,— ашап беткәч, бер биш кенә минутка алачыклар янына барыйк әле. Кыска гына киңәш бар.

Киңәшеп, җәйгә эш урыннарына — кырга күчеп килергә карар кылалар. Монда байлар төзегән коралллы бандалардан саклану уңайлырак булыр, дигән нәтиҗәгә киләләр. Куну урыны — алачыклар эшләү өчен, кешеләр билгелиләр.

XXIV—XXVI

Күчену, урнашу дигән әйбердә, гомумән, үзалдына азмыкүпме бер яңалык, күңеллелек була. Табигатьнең матур булып балкыган урыннарында бу бигрәк тә ачык һәм үткер хис ителә. Монда аерым-аерым гаиләләрнең матур гына, җыйнак кына итеп читәннән эшләнгән һәм түбәләре камыш белән ябылган алачыкларга урнашулары, чыннан да, бик күңелле булды.

Коммуна әгъзаларының күңелләре күтәренке иде. Азыклары яңага хәтле җитәрлек. Эш хайваннары да, бурыч итеп алган үгезләр белән бергә, яхшы гына канәгатьләндерәләр. Азыклык хайваннар күп булмаса да бар. Печән һәм урак өсләрендә бер тана, ике-өч сарык суярга чамалап торалар. Нәгыйм белән Миңсылуның беркадәр буташтырып маташуларын искә алмаганда, эш турында үзара: мин күп эшлим дә, син аз эшлисең, дигән шикелле бер-береннән ризасызлык күрсәтүләр булганы юк. Ир, хатын һәммәсе рухланып, шат күңел белән көчләрен аямыйча эшлиләр. Унике гаиләгә — унбер сыерлары (бары Сафиның гына сыеры юк); катык-сөт җитә. Чәй янына еш-еш кына каймак, май да куела. Кыскасы, хәзергә кадәр эштән дә, тәртиптән дә зарланган кеше юк.

Ләкин соңгы бер-ике атна эчендә һәммәсенең күңелләрен бер әйбер борчый: яңгырсызлык. Сабан ашлыгы чәчелгәнчегә хәтле дә рәтле яңгыр яумады. Чәчелгәннән бирле дә булганы юк. Кич белән эштән туктауга инде ике зур казан астында — берсе чәйгә, икенчесе уха пешерергә — гөрләп утлар яна.

Кешеләрдә кайгы, өметсезлек әсәре күренми. Уйнап-көлеп, чыр-чу килеп, ду күчерәләр...

XXVIII

Шәриф Камал бу бүлектә дә түрәләрнең булдыксызлыкларын күрсәтә. Иң зур җитәкченең үзе чакырган халыкны көттерүен дә, хәтта кечкенә генә түрә Гыйльмановның да үзен әллә кемгә куеп, буш кеше булуын тагын, тагын ача. Түрәне бу юлы үз кешеләре Фәтхи дә көне буе көтеп утыра. Сүз юктан сүз булсын дип, нидер язып утыручы Гыйльмановка эндәшә.

Гыйльманов бу юлы, үзе дә абайламыйча, аз гына сүз белән чиновникларның холкын ачып сала: «Хикмәт балыкны күп тотуда түгел. Бөтен хикмәт аның чиртүендә, иптәшкәй; тик әле күп кешеләр аны аңлап җиткермиләр»,— ди.

— Ничек тә тагын да бер балыкка барасы иде,— диде. Фәтхи шулай гына дигән иде, Гыйльманов эреде дә төште һәм күпереп тә китте:

— Әйдә, киттекме хәзер? — дип, ул кычкырып җибәрүгә якын бер тавыш белән Фәтхидән сорады һәм, җавап та көтмичә, каләмен сөртергә үк кереште.— Барабыз, бетте-китте. Мин хәзер чәй китертәм, бер-икешәр стакан кумәчләп чәй эчәбез. Аңынчы Сәмигуллин да килер. Аның белән сөйләшеп алырсыз. Шуннан безгә китәргә дә вакыт була яза. Чөнки аның сине ни өчендер балык тотарга бик өйрәтәсе килә. Билгеле инде, үз файдасын күзәтә булыр. Янәсе, үзе белән йөрергә солидный иптәш әзерли. Белмәгән кеше белән йөрергә, үзең беләсең, бик күңелле түгел бит. Сиңа, әлбәттә, өйрәнмичә ярамый. Их, беркөн сез Сәмигуллин белән китеп кенә барган идегез. Башланды хикмәтләр! Өзлексез чиртә дә тора инде менә, билләһи әгәр!

— Күп тоттыгызмы соң?

— Юк, ул хәтле тотмадым тотуын. Өчне менә бу бармактан да зурракларны эләктердем. Ләкин бит хикмәт аның күп тотуында түгел. Бөтен хикмәт аның чиртүендә, иптәшкәй; тик әле күп кешеләр аны аңлап җиткермиләр.

Фәтхи губком ишегалдындагы бакчага чыгып утырды. Теге кешенең кыланышы аңа көлке дә, кызганыч та тоела иде. Бакчаның икенче ягындагы эскәмиядә өч кеше кызу-кызу сөйләшеп утыралар. Ара-тирә көлешеп куялар. Тыш кыяфәтләре белән районнардагы җаваплы хезмәтчеләрне хәтерләтәләр. Бакчаның кайсы ягы беләндер кызыксынганлыклары күренә. Хәлбуки Фәтхи үзе дә ул бакча һәм йорт турында вакыт-вакыт уйлаштыра. Йорт бер генә катлы. Ләкин үзенең архитектура стиленең матурлыгы, нечкәлеге белән шәһәрдәге иң матур йортлар арасында беренче урынны тота дип әйтергә мөмкин. Өйнең эчке бүлмәләрендәге бөтен ишекләр, орнаментлаштырылып, көрән төстәге имәннән эшләнгән; түшәмнәрдә уңмый торган кыйммәтле путал каймалар белән уратылып, художестволы табигать күренешләре сурәтләнгән. Зур ишегалдының бер ягы зәңгәрсу-кара бронза рәшәткәләр белән киртәләнеп, матур бакча эшләнгән. Бакчаның уртасында, зур түгәрәк фонтан күлендә, мәрмәр бала-фәрештә скульптурасы курай аркылы югары су пошкыртып тора.

XXIX

Бу бүлектә Хөснулла бай белән куштан Нәгыйм Садыйк бай алтыннарын табып, үзара бүлешү турында план коралар. Ләкин Нәгыймнең табачак байлыкны иясенә генә түгел, Хөснуллага да бирәсе килми.

XXX

Водокачканың насосы һич канәгатьләнерлек эшләми. Һидияткә слесарь китертүне йөкләделәр. Слесарь бер дә уйламаган нәрсә ачты.

— Юри ватканнар,— диде карт слесарь. Кешеләр, елмайган килеш аптырап, бер-берсенә карадылар:

— Менә әйттем ич,— диде Әхмәт,— тегендәге сторож бер ат белән әйләндереп шанны тутыру бер сәгатькә дә бармый дигән иде. Ә без, ике ат йөртеп, көне буе көчкә-көчкә ике шан тутырабыз.

Икенче көнне иртәнчәк Һидият насосны шәһәргә алып китте.

Төшке аштан соң Мостафа берничә кешегә бер сәгать чамасы вакыт винтовка куллану рәтләрен өйрәтү белән шөгыльләнде. Монда Каюм белән Мәдинә дә бар иде.

Нәсимә өйрәтү эшенә катнашмый чыдый алмады:

— Син, Мостафа, Мәдинәне әйбәт кенә өйрәт, ул бәгырькәем, буш кул белән Нокта Вәлигә бирешмәгәнне, кулында винтовка булгач, теләсә нинди бандитыңны тәгәрәтә алыр, — диде.

— Дөрес, дөрес, Нәсимә түти,— диде Мостафа. Каюм өстәп куйды:

— Нәсимә җиңги кайчагында бик дөрес сүзләр дә әйтеп куя.

Ул Халикътан ун яшьләр кече. Төскә-башка хәзер дә әле зарарсыз. Хатын-кыз өчен булган урта буйдан бераз озынчарак һәм буена күрә гәүдә тазалыгы да җитәрлек. Эре ак йөзле, кара зур күзле, борын очы чак кына югары күтәрелгән. Нечкә иреннәре бәлешләнебрәк тора, ләкин ямьсез түгел. Күз төбендәге җыерчыкларга якыннанрак караганда, аңар утыз биш яшьләрдән артык бирерлек түгел. Аның сүз һәм кыланышларында хисапсыз каршылыклар булу белән бергә, табигатендә үзалдына шактый уңай яклар да юк түгел. Мәсәлән, Халикъны үзе тел белән чиксез каты үртәгән хәлдә, башка кешеләрнең Халикъка тел тидерүләренә аз гына да түземлелек күрсәтә алмый, үлгәнче тиргәшергә әзер тора. Аның соңгы көннәрдәге кыланышы да Каюм көткәндәгедән бөтенләй киресе булып чыкты. Ак бандитларның башка җирләрдә дә һөҗүмнәр ясаячаклары турында хәбәрләр ачыктан-ачык сөйләнә башлагач: «Нәсимә котырыныр инде. Үзенең дә коты алыныр, башкаларны да паникага төшерер»,— дип, Каюм эченнән уйлаган иде. Ләкин, Каюмның гаҗәпләнүенә каршы, Нәсимә котырынмады да, паникага да төшмәде. Шушы

эшләрне электән үк белгән төсле, бу хәбәрләрне Нәсимә бер дә исе китмичә салкын кан белән генә каршылады. Мостафаны үтеп барган җиреннән туктатып:

— Кара әле, Мостафа, Мәдинә белән Гөлбануны да винтовкага өйрәтәсең дип ишеттем. Гөлбану ул — бала-чага, нишләр икән? Булмаса, Мәдинә белән үземне генә өйрәт. Чуртаннар, Ишмайлар хәтле генә ата алырмын, Алла боерса.

XXXI

Шәриф Камал сыйнфый дошманнар турында сөйләвен дәвам итә. Хөснулла, Садыйк байны күрергә дип, шәһәргә килә. Сүз Садыйк өендә дә элеге алтын-көмеш турында бара. Хөснулла белән Садыйк бай бу байлыкны коммунарлар яшергән дип уйлыйлар. Шымчылары Нәгыйм ярдәмендә аны кулга төшермәкче булалар. Ләкин байлык табылгач, Нәгыймне өлешкә кертмичә, икесе генә бүләргә ниятлиләр. Шул ук вакытта бер-берсеннән шикләнәләр дә.

XXXII

Әхмәткә шәһәрдә ике көн торырга туры килде. Башта ул остаханәгә Фәтхине дә алып барды. Фәтхи, насосны караштырганнан соң, остаханә мөдире белән җайлап кына сөйләште, элеге насосның төзәтелеп эшкә ашырылу мәсьәләсе белән губкомның да кызыксынганлыгын аңлатып куйды.

Әхмәт ике көн остаханәдән ашарга, эчәргә генә чыгып керде. Бөтен вакытын диярлек шунда үткәрде. Шулай итеп, ул китүенә өч тәүлек тулмас борын насосны Үрге әрәмәгә алып кайтты.

Алар өчәү (Каюм белән Мостафа Әхмәткә булышып тордылар), бер сәгать чамасы вакыт эчендә насосны урнаштырып, бер яктан күлгә барып төшкән трубаны, икенче яктан шанга су коя торган трубаны насоска беркеттеләр. Алар привод тирәсен ике тапкыр әйләнгән иделәр[1], югарыдан гөрләгән тавыш килә башлады.

— Йә әле, Габделхәй, бер атны ычкындырып ал,— диде Әхмәт.

Бер генә ат та шулай ук диярлек җиңел йөреп китте. Моңар тагын да шатландылар. Бер сәгать вакыт үтмәгәндер, биш йөз чиләкле шан тулып ташып та китте.

— Юләрлек эшләгәнбез,— диде Нәгыйм,— башта ук Иван Иванычка күрсәтәсебез калган.

---

[1] *Привод тирәсен әйләнү* — су насосын атны әйләнә йөртеп эшләтү.

— Техниканың рәтен белмәвебез һәм шуның өстәвенә сиңа ышануыбыз аркасында харап булганбыз шул. Син бит гел: «Аның көче шулай гына, мин аларның рәтләрен беләм»,— дип, безнең башны әйләндереп тордың,— диде Мостафа.

«Үзем бозганны төзәтергә киңәш биреп торырга әллә юләр дип белдеңме?» — дип, эченнән уйлады Нәгыйм.

Кичке аштан соң коммуна членнары Һидият тора торган зур алачыкка киңәшкә җыелдылар.

Киңәшмә бетеп бара иде инде, алачыкның тышында:

— Әй! Кемнәр бар анда? — дип кычкырган тавыш ишетелде. Шихрай (авыл Советы председателе.— *А. Я.*), ат өстеннән төшеп, эчкә керде.

— Егетләр, болай ярамый бит! Дошман килеп чыкса, сезне яланкул белән тотып ала бит! Сакта тору дигән нәрсә бармы, юкмы сездә? Эш болай... Григорьевкага әле яңарак кына унбишләп атлы килеп кергән. Григорьевкадан алар безнең авылга, аннан, мөгаен, монда киләчәкләр.

Димәк, куркыныч борын төбендә. Кешеләр тиз арада үз алачыкларына таралдылар һәм винтовкаларын алып чыктылар, тавышсыз-тынсыз гына барып, таучык буена сузылдылар. Юлларда адәм заты күренмәгәч, кешеләр бер урынгарак җыелдылар.

— Бер командир кирәк, егетләр,— диде Халикъ. Шихрай җавап бирде:

— Менә ячейка секретаре инде безнең командир! Башка тагын нинди командир сиңа?..

— Менә нәрсә, иптәшләр,— диде Мостафа,— йокысы килмәгәнрәк берәр иптәшне монда калдырып, башкаларыбыз тегендә кайтып йокларга мөмкин. Бүген монда килмәүләре дә ихтимал. Киләләр икән, юллар еpактан ук күренә ич, монда калган иптәш барып уятыр. Кирәгенчә каршыларбыз.

Бу фикерне мәслихәт таптылар. Комсомолецлар постта үзләре калырга тәкъдим ясадылар.

— Юк инде, иптәшкәйләр, мин үз чиратымны берегезгә дә бирмим,— диде Мәдинә.

— Командир нәрсә әйтер,— диде Халикъ,— аның сүзе закон булырга тиеш.

Мостафа кыска гына итеп мәсьәләне чишүте:

— Мәдинә чиратын бирергә теләми икән, без аңар каршы килмик. Юкса аңар ышанмау төсле бернәрсә аңлашырга мөмкин. Хәлбуки без аңар ышанабыз.

Кешеләр китеп бардылар.

Төн уртасы. Төнге тынлыкта бары өзлексез зерелдәгән чикерткә тавышлары арасында күл бакаларының бакылдашулары һәм ерак-еераклардан ара-тирә авыл этләре өргән тавышлар ишетелгәләп тора. Ай, һаман да бер күренеп, бер яшеренеп, качышлы уйнаган балалар төсле кылана. Яңгырсыз сыек болытлар агалар да агалар. Яңгырларын да тартып китерсеннәр иде. Шулай да күңелле. Ячейка секретаре: «Мәдинәгә ышанабыз»,— ди. Авыл советы председателе Шихрай да моңар каршы килми. Коллектив берсүзсез моңа кушыла. Менә-менә дошман һөҗүм итә дигән куркыныч астында торган чагында, аңар коллективның язмышы ышанып тапшырыла. Чиксез зур бәхет ич бу! Бу бәхетне якыннан уртаклашырга шәһәрдәге дус та монда булса икән.

Берәр сәгать чамасы вакыт үткәннән соң, Кигәвенле юлында шактый еракта нindидер карачкылар күренә башлады. Бу вакытта ай чыккан иде. Мәдинә, бик дикъкатьләп бераз вакыт карап торгач, аларның бире таба хәрәкәт итүләрен һәм алардан Сакмар ягына таба тузаннар авышып торганлыкны аермачык күрде. Һәм тиз генә өйләргә йөгерде. Бер-ике минут эчендә һәммәсе торып, таучыкка йөгерделәр.

Атлылар инешкә җитәргә егерме-утыз метр гына калгач, Мостафа кинәт каты тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Остановитесь!..

Шуның артыннан ук инешнең аръягыннан:

— Мостафа! — дигән тавыш яңгырады. Бу — Жуков тавышы.

— Ярый әле, малай, атмадым,— диде Һидият. Мостафа, аңар кул биреп:

— Сез нәрсә, кешеләр куркытып, эскадроныгыз белән йөрисез монда? — диде.

— Без анда митинг үткәрдек. Атларны ашатып, чәйләр эчтек.

XXXIII — XXXIV

Коммунаны дошман күргән Хөснулланың үчле ямьсез уйларын бүлдереп, төн уртасында Садыйк бай улы Әмирҗан килеп керә. Әмирҗаннар бандасы коммунага һөҗүм итәргә әзерләнә. Әмирҗан монда шул уңайдан килгән икән. Шымчы Нәгыймне чакыртып китерәләр. Ул коммуна әгъзаларының күпме мылтыгы барлыгын, ничек каравыл торулары турында әйтә.

XXXV

Фәтхи отпуск алып монда кайткан чагында, коммунаның уракка чыгуына өч көн булган иде инде. Ул кичкырынрак килеп төште. Инештән чыгып, үргә күтәрелде. Ул шулай уйлана-уйлана, кызу адымнар белән бара торгач, уракчыларга якынлашканын сизми дә калды. Дүрт ат җигелгән урак машинасы («лобогрейка»), өч-дүрт гектар чамасы бер күләм җирне уратып, өзлексез зырылдаган тавыш чыгарган хәлдә, кыркып бара. Аның арт кырыена утырган Мостафа, лобогрейка канатлары астына җыйнала барган солы кисентеләрен кулындагы агач сәнәге белән бертуктаусыз почмакка тартып, өемнәр ясый һәм бер чама үлчәү белән җиргә салып бара.

— Эшләр кызу бара, күрәм! — диде Фәтхи.

Мостафа маңгай тирләрен киндер бияләенең аркасы белән сыпырып җибәрде:

— Вакыты шундый, туганкай! Ә син соң нишләп монда килдең? Тегендә, безнең алачыклар шәһәрендә ял итеп торырга кирәк сиңа. Кич кайткач, әйбәтләп сөйләшербез,— диде.

— Анысы, әлбәттә, шулай,— диде Фәтхи,— мин сезне эшегездән бүлдереп әңгәмә куертырга килмәдем, бәлки, булдыра алсам, ярдәмләшергә дип килдем.

Бераз тарткалашкач, Мостафа риза булды һәм лобогрейканың почмагына җыйнала торган кисенте өемнәрен җиргә төшереп җибәрүнең техникасы турында беркадәр аңлатма бирде.

Мостафа бүлемне буйдан буйга бер кабат, лобогрейка янында әйләнеп чыкты. Фәтхинең эшне җайлы алып барганлыгы күренә иде.

Мостафа чак кына уйланып торды да чүмәлә салучылар янына китте. Кояш шактый түбәнәйгән, һәм, аның эсселеге сүрелә башлаган булуга карамастан, кешеләр, җилсез бөркү һавада кызу эшләгәнгә күрә, шабыр тиргә баткан иделәр. Мостафа, Халикъ янына барып:

— Халикъ абзый, бир әле миңа сәнәгеңне, үзең утырып ял ит азрак,— диде.

Халикъның борын очында һәм маңгаенда борчак-борчак тир тамчылары ялтырый иде.

— Теге кем соң ул? — диде Халикъ.

— Фәтхи отпускыга кайткан.

— Эшкә дә тотындымыни? Машинаны ваттырмасмы соң?

— Слесарь ла ул! — диде Мостафа һәм, Халикъның сәнәген алып, кешеләр белән ярышып, чүмәлә салу эшенә керешә.

Халикъ, солы чүмәләсе күләгәсенә утырып, махорка төрде. Мостафа йөгерүгә якын кызулык белән чүмәләгә солы өемнәре ташый иде. Халикъ, тәмәкесен тартып бетергәч тә, Мостафа янына бармыйча, өем асларын тырмалап йөрүче Фәрихә янына барды:

— Йә әле, Фәрихә килен, тырмаңны карап карыйм,— диде ул. Фәрихә эшне аңлап җитмәде. Эшләгән җиреннән туктап, тырманы әйләндерә-тулгандыра караштырган килеш:

— Үземнең көн саен эшли торган тырмам ич! — диде.

— Бир әле, карыйм...

Фәрихә карышмады, бирде.

— Син әнә чирәмгә утырып ял ит,— диде Халикъ, — мин үзем бераз тырмалап карыйм...

— Мин арымадым, Халикъ абзый. Сез үзегез — өлкән кеше, ял итәргә кирәк.

— Ярар, күп сөйләмә, өлкән кеше әйткәнне тыңларга кирәк,— диде Халикъ һәм зур сәләт белән тырмаларга кереште.

Кояш та инде, план буенча алынган солы җире дә урылып бетте.

Юлда кайткан чагында, Мостафа Фәтхине коммунаның эшләре һәм иген җыйнауның барышы белән таныштырды. Мостафаның әйтүенә караганда, коммунаның бодайлары урта дәрәҗәдән югарырак булып, менә мондагы арпа һәм солылар белән бергә исәпләгәндә, барсы да урта дәрәҗәдә туры килә.

Кояш иңгән як офыкта бөдрәләнеп торган сыек болытлар, алтынлы парчалар төсле, күз камаштырырлык ачык алсу нурга манчылганнар, агач башларына, водокачка чанына һәм шулай ук кешеләрнең йөзләренә дә беленер-беленмәс кенә алсу шәүләләр төшерәләр, матур һәм дәртле моңлылык биреп торалар.

Тубылгы аланыннан да кешеләр кайттылар. Алар һәммәсе Фәтхи белән бик җылы исәнләштеләр. Фәтхи Мәдинәнең кулын бераз вакыт уч эченә кысып тотты. Мәдинәнең уч эчендә бераз кытыршылар барлык сизелә һәм шушы кытыршылар аркылы Фәтхинең йөрәгенә ягымлы һәм матур мәгънәле җылылык агып торган төсле тоела иде.

Аш әзер иде. Ирләр бер табында, хатын-кызлар икенче табында аш ашадылар.

— Каюм абзый күренми, кайда соң ул? — дип сорады Фәтхи.

— Ул бүген постта тора, — диде Мостафа.

— Бүгеннән үк әйтеп куям: иртәгә минем чират булыр,— диде Фәтхи.

Мостафа бераз эндәшми торгач әйтте:

— Иртәгә Мәдинәнең чираты бугай. Ул үз чиратын кешегә бирми торган иде.

Фәтхи Ишмай карт алачыгына кереп яткач, Мостафаның Мәдинә турында әйткән баягы сүзләре аның исенә төште һәм «үз чиратын кешегә бирми торган» Мәдинә винтовка тотып постта торган килеш аның күз алдына килде...

...Беррәттән ике тапкыр мылтык аткан тавышка Фәтхи уянып китте. Шул ук вакытта Каюмның бераз еракташ ачы тавыш белән: «Иптәшләр!» — дип кычкырган авазы һәм тагын берничә кабат мылтык шартлаган тавышлар ишетелде. Алачыкның читән чыбыклары арасыннан таң яктысы саркылып тора иде. Фәтхи һәм аның артыннан Ишмай, үзләренең винтовкаларын алып, ишеккә ыргылдылар. Башка алачыклардан да кешеләр винтовкалар тотып ыргылып чыктылар.

* * *

Канлы көрәш нәтиҗәсендә бандитлар тар-мар ителделәр. Алардан дүрт кеше үтерелде. Әмирҗан һәм тагын да биш кеше каты яраланган көе кулга алындылар. Көрәш әле шактый кызу барган чакта, Үрге Кигәвенле ягыннан ЧОН[1] отряды килеп чыкты. Шуннан соң бандитлар таркала һәм кайсы кая кача башладылар. Аларның өчәве, инеш буйлап качып барган чакта, ЧОН отряды тарафыннан тотылып кулга алындылар. Коммунарлардан Каюм һәм Ишмай картның улы комсомолец Мәхмүт үтерелделәр, Һидият шактый каты яраланды. Фәтхи терсәктән югары як беләгеннән җиңелчә яраланды. Хатын-кызлардан Гөлбану белән Нәсимә дә азрак яраланган иделәр.

Әмирҗанның кесәсеннән табылган кәгазьләр арасында коммуна членнарының һәм комсомолецларның списогы да бар иде. Мостафа Нәгыймнең кул язуын таныды. Милиция башлыгы Юрьев, бер милиционер алып, Нәгыймне кулга алырга авылга китте.

1937 ел

---

[1] *ЧОН* — часть особого назначения. Илнең эчке дошманнары белән көрәшү өчен төзелгән гаскәр.

Романга анализ

Әсәр исеме фокус була алуын күрдек. Язучыларның яраткан сәнгать алымнарын кабатлавын да беләбез. Шуңа күрә анализны роман исеменең мәгънәсен ачыклаудан башлыйбыз. Без шулай ук фокуста каршылык булырга һәм каршылык әсәр эчендә чишелергә тиешлеген дә беләбез. Ләкин роман исеме бу хәлендә метафора да, каршылык та була алмый. Шәриф Камал аны тәмамланмаган җөмлә иткән.

Без: «Матур туганда нәрсә туа?» — дип сорау бирәбез һәм, романны укып чыкканчы ук, ул матурлык һәм ямьсезлек турындагы сюжет сызыкларына бүленергә тиеш дигән нәтиҗәгә киләбез.

Биремнәр һәм сораулар

1. Шәриф Камал коммуна урнашкан урындагы табигатьне матур дип бәяли һәм исбат итә. Автор мондагы матурлыкны нәрсәдә күрә?

2. Коммуна төзеп яңа тормыш башлаучы крестьяннарга да автор бәясе шундый. Коммунарлар матурлыгы турында сөйләгез.

3. Романдагы партия җитәкчеләренә багышланган күп санлы вакыйгаларны бер сюжет итеп сөйләгез.

4. Партия җитәкчеләренә багышланган сюжет сызыгын коммунарларга багышланган сюжет сызыгы белән чагыштырыгыз.

Ике сюжет сызыгының бер-берсенә капма-каршы булуын исбат итик.

Һидият белән Мостафаны, кызу урак өстендә эштән аерып, шәһәргә Сәмигуллин янына чакыралар. Очрашу вакыты билгеләнгән булса да, эш кешеләрен ярты көн көттерәләр. Өстәвенә юк кына бер чиновник — җыелыш протоколлары күчереп утыручы техник секретарь Гыйльманов — үзләрен мыскыл итеп, булмаган акылын өйрәтеп җибәрә, Һидиятне председатель итеп сайламаска куша.

Һидият Мостафа колагына «бу бәндә» дип әйткән өчен, Гыйльманов Һидиятне халык дошманы дип гаепләргә керешә. Аңа капитализмның зәһәрле тамыры дип бәя бирә.

Шул ук сюжетның тагын бер вакыйгасы: Фәтхи, Сәмигуллин бүлмәсенә кергәч, крестьянның ут йотып йөргән вакытында, бүлмә тулы көтеп утыручы авыл кешеләрен күрә.

Сәмигуллин бу юлы да үзе кешеләр чакырган, үзе каядыр киткән. Техник секретарь исә, бик зур эш майтарган кеше сыман, башын да күтәрми каләм кыштырдатып утыра. Хәтта бюро әгъзасы Фәтхигә дә исе китми. Ә менә бөтенләй мәгънәсез эшкә — балык тотарга бөтен эшен ташлап китәргә ашкынып тора.

Бу кешеләр өчен иң мөһим нәрсә — балык чирткәнне карап утыру. Аларга хәтта балык та эләкми. Бар тотканнары бармак буе ике-өч алабуга була.

Партия җитәкчеләренең балык чирттереп утыру вакыйгасын Шәриф Камал тәмләп, күп итеп яза. Бу хакта кабат-кабат сөйли. (Дәреслектә ул шактый кыскарды.)

Эләкмәгән балык чиртүенә шатланып, шуңа канәгать булып утыруны юк эш белән шөгыльләнү дип әйтә алабыз. Димәк, Шәриф Камал Сәмигуллин, Гыйльманов, Фәтхи хезмәтенә күз буяу, юк эш белән маташу дип бәя бирә.

Фәтхинең «Мәдинәгә өйләнимме?» дип сораган киңәшенә, Сәмигуллин болай дип җавап бирә: «Син аны монда шәһәргә алып килсәң, ул сиңа, дөресрәге икегезгә, аш пешереп, кер юып торырга мәҗбүр булачак. Авылда үскән, авылда яшәгән бер хатын, ул эшләрне дә бик шәп итеп эшли торгандыр, дип уйлап булмый. Эшкә, хезмәткә керү мәсьәләсе дә, квалификация булмаганда җайлы ук булмас. Ике арадагы тигезлеккә уңайсызлык китерер... Шуңа күрә ул синең өчен мәслихәт түгел».

Партия җитәкчесе, шулай итеп, Фәтхигә өйләнмәскә куша. Төп сәбәп итеп, инде бюро әгъзасы булып күтәрелгән Фәтхигә ярарлык тәмле аш пешерә алуына шикләнә. Тәмле итеп пешерелгән аш бу кешеләр өчен мәхәббәттән дә, кеше язмышыннан да кадерлерәк булып чыга. Алар үзләреннән түбәнрәк торган кешеләр турында уйлап та карамыйлар. Үз мәнфәгатьләре турында гына уйлап яшиләр. Ә башка кешеләрне кармакка эләктерә торган вак балыкка тиңлиләр. Үзләрен бу вак балыкларга суалчаннарны бүлеп бирүче дип исәплиләр.

Өлкә түрәләренең вак балыкка мөнәсәбәте белән аларның гади халыкка мөнәсәбәте арасында, шулай итеп, тиңдәшлек, эчке охшашлык табыла. Укучысының игътибарын шул охшашлыкка юнәлдерү максатыннан чыгып, Шәриф Камал бу ике вакыйганы ачыктан-ачык бәйләп куя. Бу хакта Сәмигуллин: «Ул каһәр суккан балык тоту дигән нәрсә,

бигрәк тә әнә теге вак балыклар булганда, кешенең башын бик нык әйләндерә. Эресе алай ук түгелдер дип уйлыйм. Үзебездән генә гыйбрәт ал: иртәдән төшкә хәтле бер рәтле сүз сөйләшергә вакытыбыз булмады. Әле аяк чишен, әле брюка сал, әле селәүчән утырт, әле тегеләй, әле болай, бере артыннан бере һич өзелмичә килә дә тора бит!» — ди. Бу сүзләре белән Сәмигуллин үзләрен эре балыкка исәпли. «Вакытлары булмау»ның, ягъни эшләренең нинди булуын ачыктан-ачык әйтә.

Автор Сәмигуллинга вак балыкларның кем булуын да әйттерә. Фәтхи, Мәдинә турында сөйли башлагач ук: «Ә бөтен гаеп әнә шул Гыйльмановның бәләкәй балыкларында булды. Син хәзер дә, «моннан ун ел элек...» дип, сүзләрне башлау белән миңа тагын да каядыр бик якында нәрсәдер чиртә төсле тоелды. Димәк, теге сүзләр белән чирту арасында ниндидер ассоциация туып өлгергән. Менә бит алар — нинди заразительный мәхлуклар! Бигрәк тә бәләкәйләре...» — ди. Бәләкәй балыклар белән Мәдинәне китереп бәйли.

5. Әсәрдә Мәдинә белән Фәтхи мөнәсәбәте турындагы вакыйгалар аеруча күп. Ул вакыйгаларны бергә җыйсак, өченче сюжет сызыгын тапкан булабыз. Ләкин бу сюжет сызыгы да коммунарлар белән түрәләр бәйләнешен ачыклау вазифасын үти. Шуны исбат итегез.

Нәтиҗә

1. Романны таркаттык, өлешләрен аерым-аерым өйрәнеп чыктык һәм, берләштереп, икегә генә калдырдык. Анализның чираттагы гамәле — өлешләр арасындагы бәйләнешне табу, чөнки романның төп эчтәлеге шунда булырга тиеш. Өлешләр арасындагы бәйләнешне табу — аларның нинди дә булса охшашлыгын табу дигән сүз. Беренче өлештә — сүз коммуна әгъзаларының күңел матурлыгы, ә икенчесендә түрәләрнең күңел бушлыгы, хис ярлылыгы турында баруын белдек. Шулай булгач, бу ике өлеш арасында нинди тиңдәшлек, охшашлык булырга мөмкин?

Нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Әсәрнең исеме үк романның матурлык турында булуын әйтеп тора. Өлешләрдән дә шуны эзлик.

Автор коммунадагы хезмәт тудырган матурлыкны вакыйга урыны белән чагыштырып та, турыдан-туры да әйтеп бирә.

Лəкин Сəмигуллиннар белəн бəйле вакыйга урынында да матурлык бар. Бу урынны табып, тагын бер мəртəбə укыгыз: Фəтхи, Сəмигуллинны көтеп-көтеп тə очрата алмагач, партия комитеты бакчасына чыга. Анда ул бакчаның һəм комитет бинасының матурлыгына сокланып туя алмый. Бинаны шəһəрнең иң матур бинасы, ди, бакчаны иң матур бакча, ди. Лəкин кисəтеп куя, бу матурлыкны Сəмигуллиннар тудырмаган, бина — элекке хуҗалары тудырган матурлык, ди. Бу сүзлəрдəн соң без əсəр башындагы табигать матурлыгына һəм коммунарлар төзегəн тормыш матурлыгына ирексездəн əйлəнеп кайтабыз. Бина һəм бакча матурлыгын коммуна матурлыгы белəн чагыштырабыз. Коммунарларның торган җирлəре дə, киемнəре дə телгə алып сөйли торган матурлык түгел. Əмма бу йорт эчендəге, алачыкларда яшəүче кешелəрнең эчке матурлыгын хəтергə төшерəбез һəм Сəмигуллиннар белəн чагыштырабыз. Ə бит монда бөтенлəй киресенчə икəн, тышкы матурлык бар, ə эчендə — күңел бушлыгы, дəрəҗəле кеше булып кылану, ясалмалылык.

Əсəр шул рəвешле ике зур өлешкə: матурлык — ямьсезлек өлешлəренə бүленə.

Фəтхи белəн Сəмигуллин җитəкчелегендə төзелгəн яңа тормыш нинди була ала? Шəриф Камал бу сорауга ачык җавап бирми. Хəтта җавабы булса да, ул заманда əсəрендə ачык итеп əйтə алмас иде. Əмма өлешлəр арасындагы бəйлəнеш автор фикерен шактый ачык җиткерə: матурлыкны хезмəт кешелəре тудыра. Туып килə торган яңа бюрократлар аны ямьсезли генə алалар, ди.

Хəзер əсəр исеменең мəгънəсен əйтə алабыз. Автор, «Матур туганда», ди һəм җөмлəсен əйтеп бетерми. Туган чагында матурлык шактый авырлыкларга очрый. Аңа көнче кешелəр дə, үзара ызгышлар да, юньсез җитəкчелəр дə комачаулый. Алар күбəйгəннəн-күбəя баралар. Матурлык белəн янəшəдə ямьсезлек тə туа, куəт ала. Əсəр исеменең мондый дəвамын бөтен эчтəлеге əйтеп тора.

Төп нəтиҗəне үзебез чыгарабыз: матур тормышны халык кына төзи ала. Лəкин моның өчен аңа ирек бирү кирəк. Кайсы җиңəр? Халыкмы, түрəлəрме? Роман язган елларда Шəриф Камал үзе куйган бу сорауга җавап бирми.

Шəриф Камал, Такташ, Хəсəн Туфан кебек, хакыйкатьне читлəтебрəк булса да яза алучы батыр язучы булган.

Əдип иҗатының бер үзенчəлеге шуннан гыйбарəт.

2. Әдип әсәрендәге вакыйгаларның барысын да матурлык — ямьсезлек фокусы белән тоташтыра. Әсәрдә крестьяннар урнашкан табигать тә, гади хезмәт кешеләренең рухи яктан үсүе дә матур. Партия түрәләре урнашкан бина да искиткеч. Ләкин тышкы матурлык эченә автор җыен булдыксыз, юньсез кешеләрне кертеп утырткан.

Коммунарларның өс-башлары да, яшәгән алачыклары да ямьсез. Әмма бу йорт эчендәге алачыкларда яшәүче кешеләр үзләре матур.

Әсәр шул рәвешле матурлык — ямьсезлек өлешләренә бүленә. Романдагы барлык эпизодлар, вакыйгалар, сюжет сызыклары шул төп фокуска килеп тоташа.

3. Шәриф Камал — холыклар тасвирлау остасы. Ул вакыйгаларын, образларын күзгә күренерлек итеп, вак-вак детальләренә кадәр җентекләп язарга ярата.

Әдипнең бу сыйфаты да — аның үзенчәлеге.

Мәҗит Гафури
(*1880—1934*)

«Гомерем йомгагы» исемле шигырендә Мәҗит Гафури болай яза:

Җыеп караганда, алай бик зур
Төсле түгел гомерем йомгагы,
Сүтеп караганда, чак күренә
Аның бер ягыннан бер ягы.

Әдип йомгак кебек кечкенә генә шигырендә тормыш юлын ике өлешкә бүлә. Бер карыйсың — гомер күзгә дә күренмичә үткән дә киткән. Шатланып искә алырлык вакыйгалары да юк кебек.

Мәҗит Гафури Башкортстанның Гафури районы Җилем-Каран авылында укытучы гаиләсендә туган. Әнисе Мәрзия апа, әдип үзе исенә төшергәнчә, йомшак күңелле юаш хатын булган. Әтисе Нургали турында әдип, каты күңелле, кырыс кеше иде, дип яза. Мәҗит Гафури унбер яшьтә ятим кала. Шуңа күрә сабый чактан ук үз көнен үзе күрергә тиеш була.

Җәйләрен эшләгән акчага Троицкий мәдрәсәсендә белем ала. Башка язучылар кебек үк, андагы тәртипләргә риза булмыйча, мәдрәсәне ташлап китә. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып йөри. Мәдрәсәдә чакта ук шигырьләр яза башлый. Язучы булып танылгач, туган ягы Башкортстанга китә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши.

Ләкин йомгакны сүтеп караганда, Мәҗит Гафуриның гомере, чыннан да, бик озын булып чыга. Ул казакъ далаларында укытып йөри. Анда җиде тапкыр бара. Троицкий тирәсендәге авылларда ялланып эшли: уракчыларга аш

пешерә, ипи сала, сыер сава. Хезмәтнең һәр төре аның өчен таныш. Ул торф чыгара, алтын шахталарында җир казый, корректор, ягъни хата төзәтүче булып берничә ел эшли...

Мәҗит Гафуриның сүтелгән йомгагы өч революция һәм Беренче бөтендөнья сугышы, илдәге ачлык һәм колхозлар төзү вакыйгалары аша үтә. Шагыйрь Октябрь революциясен шатланып каршы ала, гражданнар сугышы башлангач, акларга нәфрәтләр яудыра, кулакларны сөрүне хуплый, партияне, коммунизмны мактый... Кыскасы, ул заман язучысы була. Тик шулай да шагыйрь күңеле тынычсызлана, сызлана:

Шайтан алгыры! Нәрсә булды соң миңа?
Төрле яктан шөбһә тулды күңелемә...
Күңел йөзә яры күренмәгән
Чиксез уй диңгезе эчендә.
Шаулап торган дулкын арасында
Диңгезнең иң тирән төшендә,—

дип яза.

Гомер йомгагын сүткәндә, шагыйрь үзенең күңел хатирәсен актара башлый. Башыннан кичергән вакыйгалар барысы да шагыйрь күңелендә шатлыклары белән бергә рәнҗү, кимсенү, үпкә, кайгы-хәсрәт өеп калдырган. Гомере йомгагын ул күңелендә сакланган хисләр тезмәсе итеп сүтә. Ә дүрт кенә юллык тагын бер шигырендә хисләр тезмәсен болай ачыклый:

Утыз ел саклады̆м вөҗдан,
Утыз ел сатмадым вөҗдан,
Шуны саклар өчен бик күп
Авырлыклар күтәрде җан,—

ди.

Алай да Мәҗит Гафури бәхетсез кеше булмаган.

«Мохит начар, ялгызлык эч пошыра, иркен эшләргә юл юк иде... Тормышның мәгънәсе юк иде. Шушы вакытларда Зөһрә исемле бер кыз белән таныштым... Мин аңа үземне тәкъдим иттем»,— дип яза әдип үзенең истәлекләрендә. Игътибар итегез: кулын сорадым түгел, миңа кияүгә чык түгел, «үземне тәкъдим иттем», ди. Зөһрә белән Мәҗит Гафури тату яшиләр, бер-берсен яратышалар.

Мәҗит Гафури бик күп шигырьләр, хикәяләр, повестьлар, поэмалар, пьесалар иҗат итә. Күренекле шагыйрь булып таныла. Иҗат эше — үзе бәхет ул. Заманында әдип Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал кебек күренекле

кешеләр белән якын дус булган. Шундый якын дусларың булсын иде әле...

«Шагыйрьнең алтын приискасында» повесте — әдипнең үз тормышыннан алып язылган әсәре. Аның хикәяләүче төп герое да — автор үзе. Ләкин истәлек белән сәнгать әсәре арасында аерма бар. Аерма беренче чиратта сәнгать әсәрендә фокус булудан гыйбарәт.

ШАГЫЙРЬНЕҢ АЛТЫН ПРИИСКАСЫНДА

(Повесть)

Апрель числосы керү белән, мәдрәсәдәге бай шәкертләр таралып беттеләр. Тик, безнең кебек, бай малайларына аш пешереп, чәй кайнатып көн күргән ярлы укучылар гына торып калдылар.

Мәдрәсәдә укулар да тукталганга күрә, без укусыз да, эшсез дә торып калдык. Хәзер безнең башка «Нишләргә инде, кайда китәргә?» дигән уй төште.

Безнең иптәшләр берәмләп, икешәрләп тарала башладылар: кайберәүләре җон юарга мойкага, кайберсе байның көтүен көтәргә киттеләр. Бара торгач, без мәдрәсәдә өч-дүрт кенә шәкерт торып калдык.

Һәр көн төрлебез шәһәрнең төрле җирендә йөреп, эш эзләп тә карыйбыз, һаман рәт чыкмый: йә бөтен җәй буена егерме тәңкә генә бирәләр, яисә вакытлы эшләр генә күрсәтәләр. Боларның һәр икәүсе безнең корган планга туры килеп бетмиләр.

Безгә җәй буе өзлексез эшләнә торган һәм иң азында утыз-кырык тәңкә хосул[1] китерә торган эш кирәк.

Шулай беркөн иртүк торып шәһәр арасына чыгып киткән Зиннәт мәдрәсәгә кичкә таба гына әйләнеп кайтты.

Ул үзе алтын тапкан кебек шатланган, кайтып керү белән:

— Мин бүген базар мәхәлләсендәге мәдрәсәдә укыган якташлар янында булдым. Алар иртәгә алтын казый торган җиргә китәләр, моннан йөз алтмыш чакрым җирдә «Восьмой» дигән алтын приискасы бар икән... Аның хуҗалары мөселманнар икән,— дип, приисканы мактап китте һәм үткән ел шул приискага эшкә барган кайсыдыр бер шәкертнең, җәй буе эшләгәннән соң, ашаудан арттырып, кырык тәңкә саф

---

[1] *Хосул* — табыш.

акча алып кайтканын, быел да шунда эшкә киткәнен үз күзе белән күреп торган кебек сөйләде.

Без анның бу шатлыклы хәбәрләрен колакларыбызны торгызып тыңладык, хәзер үк «алтын тавы» тапкан кешеләрчә шатландык:

— Әйдәгез, без дә шунда китәбез!

— Ул прииска кайсы якта икән соң? — дигән сүзләрне әйткәнебезне сизми дә калдык.

Зиннәт анның кайсы якта икәнен һәм анда кайсы юлдан, нинди авыллар аша барырга кирәклеген бик төпчеп сорашкан икән.

Мин Зиннәткә:

— Булды, китәбез. Ә соң йөз алтмыш чакрымга ничә көндә җитәрбез икән? — дигән сөальне бирдем.

— Биш көндә җитәрбез...

— Ну, алты көн китсен, мәгәр безгә бару белән эш кенә табылсын.

Зиннәт эш табылуына бик нык ышанган бер төс белән:

— Рәзе алтын чыккан җирдә эш булмый, мин үзем барам тек барам. Тагын шунысы бар икән әле: анда шәп яңгырлар артыннан, үткән кыш юылып өелгән балчыклар өстеннән алтын эзләргә чыгаралар икән. Шунда кайбер бәхетле кешеләр менә шулчаклы зурлыкта, баш бармагын күрсәтеп, алтын кисәге табалар икән. Шул ук байлар үзләре шул алтынның мыскалын шунда ук ике тәңкәдән сатып алалар икән...

Анның бу сүзләрен ишеткәч, безнең колаклар үрә торды.

— Вәт әй, кайда икән кәсеп!

— Бәхеткә каршы, берәр кисәк алтын тапсак, сатарбыз да акчасын уртаклашырбыз, аннан без бай малайларына самавыр куеп торудан бөтенләй котылырбыз,— дип, хәзер үк самородкы[1] тапкандай шатландык һәм безнең алдагы көннәр яп-якты булып киткәндәй булды.

Без Зиннәт белән икәү, юллык акча рәтләп алу белән, «Восьмой» приискасына китәргә карар бирдек, юллык акча табу мәсьәләсен сөйләргә керештек.

— Әйдә, укый торган китапларыбызны сатабыз, Фәхри хәлфә шундый нәрсәләрне ала бит.

Иртүк торып китапларны кулга алдык та Фәхри хәлфәнең йортына киттек. Ул әз генә уйлап торды да:

---

[1] *Самородкы* — табигатьтә әзер килеш очрый торган алтын кисәге.

— Икәүсенә илле тиен бирәм,— диде.

Юлда ашарга кирәк булыр дип, шундагы кибеткә кереп, бер каравай калач, алты мыскал чәй, бер чирек шикәр алып, мәдрәсәгә кайтып кердек.

Тулган ай кебек балкып торган зур каравай калачның күз алдында торуы авызлардан сулар китерә. Ниһаять, без чыдый алмадык, «кайда булса да ашарга алынган калач бит ул...» дип, чәйнек белән чәй кайнаттык та, алтын приискасын сөйли-сөйли, чәй эчәргә керештек.

II

Алтын чыккан җиргә китеп бару болай күңелле булса да, күптән түгел яуган яңгырдан пычранып калган юл белән җәяү баруы башта ук авыр булыр төсле сизелде.

Иске читекләр өстенә кигән яңа чабаталар, ике-өч чакрым җир киткәнче үк шешенеп, аякларны кыса башладылар. Үзләренең табаннарына бер илле чамасында балчык ябышты.

Төшкә таба көн бераз җылыта төште. Шунда без бер күл буена туктап, үзебез белән алган чәйнектә чәй кайнатып, калачлап торып чәй эчеп җибәрдек. Хәзер безгә җан керде. Рух күтәрелде. Без, хәлләнеп, тагын да алга киттек.

Берлин дигәннәре — зур гына бер урыс авылы икән. Ул да артта калды, без, бүген Тарутинга җитеп, җылы өйдә кунарбыз дигән уй белән барсак та булмады. Ерак түгел генә сабан сөреп йөргән кешеләр янына бардык. Алар шул тирәдәге бай бер казакъның хезмәтчеләре булып чыктылар. Без алар белән аманлашканнан (исәнлек-саулык сорашканнан) соң, шулар янында кунып китәргә карар биреп, аркаларыбыздагы капчыкларны алып куеп, аларның чәй кайнатырга яккан утлары янына җылынырга утырдык. Ярты сәгать эчендә алар безнең кемнәр икәнебезне һәм кайда баруыбызны әнәсеннән-җебенә чаклы сорашып беттеләр. Безнең алай-болай шикле кешеләр түгеллегебезне белеп алгач, үзләренең яннарына чәйгә утырттылар. Чәйдән соң без, чабаталарыбызны чишенеп, читекләребезне салып, утка каршы утырып, чыланган чолгауларыбызны киптереп, яңадан киендек. Безнең аякларның кай җирләре читекләрнең ямаулы җирләренә туры килеп кабарган, кайбер урыннары чиләнеп киткәннәр иде. Теге хезмәтче казакълар, безне кызгана төшеп, аякларыбызга сөртергә сары май бирделәр. Сары майны сөртеп, җылы чолгауны урагач, рәхәт булып калды.

Безнең ятарга теләвебезне сизү белән, алар тагын безнең хәлгә керделәр. Астыбызга коры печән җәеп, өстебезгә ябынып ятарга калын киез бирделәр.

Бу өч ялчы казакълар, үзләре шушы хәлдә торып, бер байның ялланган батраклары булуларына карамастан, дәртле, күңелле егетләр булып чыктылар. Аларның берсе — араларында иң яшьрәкләре — шунда торган бәйләүле атка сикереп менде дә сабан сөрә торган үгезләрне сугарырга алып китте һәм, бераз китү белән, озын көйгә, салмак кына иттереп, үләң (җыр) әйтә башлады.

Аның иркен күкрәгеннән чыккан тавышы тирә-якка таралып, моңлы һәм яңгыраулы авазы тын даланы уятып, җанландырып җибәрде.

Урыннарыбыздан торып киендек, алар бездән тыныч йоклавыбызны сораштылар һәм, без киенеп, аркаларыбызга капчыкларыбызны асып, үзләре белән рәхмәт әйтеп күрешкәч, безгә юл өйрәтеп җибәрделәр. Без алардан аерылганда, кояш яңа гына чыгып, сабан тургайлары югары күтәрелеп, сайрый-сайрый уйнарга керешкәннәр иде.

Бүген көндез елга буенда чәй эчеп хәл җыйдык та, Тарутин авылына туктамый үтеп, кичкә каршы Яманчал авылы дигән бер казакъ авылына җитеп, ярлы гына бер казакъ өенә кунарга кердек.

Без, казакъларның үзләренә генә махсус булган гореф-гадәтләрен һәм мөсафир кешеләрнең йорт хуҗасы белән ни рәвешле мөгамәлә итәргә тиеш икәнен рәтләп белмәгәнгә күрә, күңелсез бер хәлдә, тартынкырап торган идек тә, өй хуҗасы, моны сизеп, борынгы танышларча мөгамәлә итә башлады. Чәй эчерү белән генә калмый, алар безгә ит тә ашаттылар. Күптән күрмәгән итне туйганчы ашау безнең өзелгән йөрәкләребезне ялгап җибәргән кебек булды.

Ул бездән күп нәрсәләр сорашты. Туйганчы ит ашап, җылы өйдә юрган ябынып (алар безгә ябынып ятарга юрган да биргәннәр иде) яткач, без таң атып кояш чыкканын сизми дә калганбыз.

Без торгач, ул, үзенең без бара торган якка бер йомыш белән барачагын һәм безне утыртып алып китәчәген әйтеп, безне тагын шатландырды. Китәргә ат җиккәч, без аның хатынына үзебезнең актык егерме тиен акчабызны бирмәкче булган идек тә, ул:

— Уй-бай, бу нә кылган эш! Кесе мосапирлардан акша алучы идәбе,— дип, безнең акчаны алмады. Без ул хатынга

рәхмәт әйтеп аманлашып чыктык та арбага утырып алга киттек.

Шәп кенә атка утырып, төрле сүзләр сөйләшеп бару безнең юлны кыскартты, егерме чакрым җир киткәнебезне белми дә калганбыз.

Ике юл чатлыгына җиткәч, безне алып килүче Аманбай атын туктатты да:

— Сез усы юл мән туры карап, алга җөрә биреңез, мин монау юл мән китәмен,— дип, безне арбасыннан төшерде дә үзе, безнең белән исәнләшеп, атына утырып, сул якка киткән юл белән алга китте.

Без барган саен «алтын тавы»на якынлашабыз, йөз чакрым җир килдек инде дип шатланабыз һәм Троицкидан чыккан вакытка караганда да күтәренке рух белән алга барабыз.

Шулай бара торгач, «Восьмой» приискасына барып җиттек. Бик озын бер казармага барып кереп, ишек төбендәрәк бер җиргә басып, тирә-якка каранып: «Инде нишләргә, монда тәртип ничек?!» — дигән уйга калдык.

III

Без кергәндә, казармада ямау ямап, яшь баласын имезеп, камыр басып, кер юып, җырлый-җырлый кечкенә иске сандыгын актарып утырган берничә хатын-кызлар һәм төрле җиргә таралып уйнап йөргән эреле-ваклы берничә дистә балалар гына булып, алар башта безнең керүебезгә игътибар итмәделәр. Бездән ерак түгел генә камыр басып торган бер хатын:

— Монда гаиләле кешеләр генә торалар, сез әнә теге буйдаклар тора торган казармага барыгыз, анда урын күп,— дип, безгә икенче казармага барырга тиеш икәнен әйтеп бирде.

Буйдаклар казармасы бу казармага якын иде.

Бу казарма үзенең озынлыгы, тәрәзәләренең сирәк һәм кечкенәлекләре ягыннан караганда, нәкъ гаиләле кешеләр торган казарма төсле булса да, эчендәге күренеш ягыннан бөтенләй башка, чүпләр күрәп алырлык булып күбәйгәннәр иде...

Чынлап та, без үзебезне әллә нинди ташландык, куркыныч бер хәрабәгә кергән кебек сиздек. Казарманың кайсыдыр бер почмагыннан ишетелгән «Уф-уф, ай-ай!» дигән сызланулы ыңгырашулар һәм аңа каршы:

— Җә, нәрсәгә балалар төсле чыдамсызланасың! — дигән сүзләр ишетелмәсә, без бу казармадан кире чыгып киткән булыр идек.

Безнең алдыбызда кызыл түбәтәен башына кыңгыр салып кигән таза гына бер җегет утыра иде.

Ул безгә башын күтәреп карады да, никтер бер сүз дә әйтми, безнең сүз башлауны көткән кебек, үткер күзләрен безгә терәде.

Шул вакытта теге авыру тагын да: «Уф, уф! Монысы миңа булсын, уф хәлем бетте бит»,— дип ыңгыраша һәм саташа башлады.

Теге таза егет, авыруга карап:

— Яткан җиреңнән самородкы таптыңмы әллә? Монысы миңа булсын дисең. Самородкы төшеңә генә керә торгандыр, өнеңдә тапсаң да, аны синең кулыңда тотмаслар! — дип сөйләнә-сөйләнә урыннан торып, авыруның янына барды һәм керләнеп, әвәләнеп беткән мендәрен рәтләп куйды.— Шахтада эшләгәндә авырды да шуннан терелә алмыйча ята. Шуны карап мин дә эшкә чыга алмадым, ул терелсә, бу каһәр приискадан китәр идем.

Эшчеләр кайтып, казармада икенче бертөрле хәрәкәт башлангач, без, алардан буш калган бер урынга утырып, капчыкларыбызны сәкегә куеп, бер-беребезгә караштык.

Эшчеләрнең кайберләре үзләре чәй кайнатып эчәргә, кайберсе бәрәңге ашарга утырдылар.

Без, капчыктан күмәчне алып, инде ашыйбыз гына дип торганда, матур гына бер карт, кереп, маңлаена кулын куеп, кемнедер эзләгән кебек карый да башлады:

— Монда яңа гына килгән ике егет булса кирәк, шуларны эзли идек,— диде.

Ул, безнең янга килеп, безне бер кат карап алды да, исәнләшеп, сәкегә утырды һәм тиз генә арада кайдан килүебезне, кайсы яктан икәнлегебезне сорашып үтте. Без аңа теге казармадагы хатынга биргән җавапларыбызны бирдек.

— Шулай икән! (Миңа карап.) Син безгә якташ буласың икән. Мин үзем дә Бәләбәй өязенеке булам. Булмаса, әйдәгез безнең казармага. Анда әзрәк сөйләшеп утырырбыз,— дип, безне үзенең торган казармасына чакырды.

Без назланып тормадык.

Бабай безне, үзе артыннан ияртеп, озын казарманың бер башындагы мич артындагы почмакка алып барды.

— Әйдәгез, түрдән рәхим итегез әле! — дип, безгә түрдән урын күрсәтте. Без кыяр-кыймасрак, чабаталарыбызны чишенеп, сәке өстенә менеп утырдык. Без бу казармага беренче рәт

кергән вакытта камыр басып торган җиңги килде дә, безнең белән тагын да исәнләшеп, чәй урынын хәзерләргә кереште.

Без һаман да ачылып, сөйләшеп китәрлек сүз таба алмыйбыз. Сәлим бабай бу сүзсезлекне үзе генә бетереп бара:

— Мин үзем дә шулай, яшьтән үк ятим калып, кешегә эшләп үстем. Шуннан эш эзләп читкә чыгып киттем. Башта шулай сезнең кебек кыен булды, бара-бара өйрәнеп китәсең аны. Йәгез, чәйләп, нигъмәттән рәхим итегез әле!

Без казармага кергәндә, теге авыру янында гына өчле лампа яна, эшчеләрнең мышнап йоклаган тавышлары гына ишетелә иде.

Без, капчыгыбыз янына килеп, аякларыбызны чишендек тә, астыбызга кыска җиңле бишмәтләребезне, баш астына бүрекләрне салып, өстебезгә җиләннәребезне ябынып йокларга яттык...

Озак та үтмәде, казармада хәрәкәт көчәйде. Бездән ерак түгел берәү безнең үзара сөйләшүебезне тыңлап торган, күрәсең, ул, безгә карап:

— Ну, сез кайда барырга җыенасыз? Тотыгыз да конторга барыгыз. Анда көнлекләп эшләргә яллыйлар,— дип, безгә юл өйрәтергә кереште.

Без конторга барып җиткәндә, контор алдында бер төркем халык, эш көтеп, конторның ачылганын көтәләр иде.

Озак көттерми, контор ишеге ачылып, бер кеше чыгып, күтәрмәгә басты. Кайберәүләрнең исемнәрен әйтеп, кайберәүләрен бармак белән төртеп күрсәтеп, төрлесен төрле якка эшкә җибәрә башлады.

Байтак кешеләргә, шулар рәтеннән безгә дә, эш җитми калды.

Чәй янында иптәш Зиннәт Иванов приискасына китәргә, анда эш булса, миңа хәбәр итәргә, булмаса, кире кайтырга, ә мин хәзергә монда торырга карар бирдек.

Мин конторга барып кергәндә, каравылчы карт тәбәнәгрәк, уйчан гына бер урыс белән нәрсәдер шунда сөйләшеп тора иде. Ул сүзне артыкка сузмады: теге урыска карап, минем эш эзләп килгән бер укучы икәнемне әйтеп тә бирде.

Эш эзләү мәсьәләсе шуның белән чишелде. Ул миңа иртәгә иртүк эшкә килергә кушты.

Иртән иртә торылды. Мин конторга барганда, теге урыс карты эшчеләр белән сөйләшеп тора иде. Ул мине шул эшчеләрнең берсенә тапшырды. Озак та тормый, без ул эшче белән

шахтага киттек. Мин бадьянга[1] утырып, арканга тотынып, караңгы җир астына төшеп киттем.

Карт җайлап кына бишмәт чабуларын, кайтарып, билбавына кыстырды. Күн бияләйләрен киеп, кәйләсен кулына тотканнан соң, җиргә тезләнеп утырды да, миңа карап:

— Ну, ярый, энекәш, син ул балчыкларны шахта авызына ташлый башла инде.

Ул шушы сүзләрне әйткәннән соң, вак ташлар белән бергә укмашып каткан балчыкларга чык-чык бәреп төшерә башлады.

Мин, ул казыган балчыкларны кыска саплы көрәк белән чиләккә тутырып, кармана-кармана шахта авызына таба киттем.

Песокларны чиләккә тутырганда да, шахта авызына алып барып бушаткан вакытта да, зур алтын кисәге табармын төсле, сарырак булып күренгән ташларны алып карыйм. Алар минем күзгә сары самородкы төсле булып күренәләр. Ләкин аларның берсе дә самородкы булмыйлар.

Миңа да җир өстенә чыгарга чират килеп җитте.

Иртәнчәк, мин шахтага төшкән чакта, минем куркуымны сизеп, миннән уйнап көлгәннәре, мине күргәч:

— Әле син кире чыга алдыңмыни? — диләр...

Минем өчен үзем белән бергә эшләгән карт җавап биреп:

— Егет малатчина күренә. Кемгә дә иптәш булырга ярарлык, аны өйрәтеп торасы да юк! — диде.

— Шулай кирәк! Ату укыган кешеләрнең күбесе камыр кебек йомшак булалар... Ярый, Сибгат агай, яшь кешене эшкә өйрәт...

Мин аларның үзем турындагы сүзләреннән үзем көләм, үзем аларны һаман үземә якын иптәшләр кебек күрә барам. Аларның керсез сүзләре күңелгә ягымлы тоела.

Болар яхшы, болар белән эшләү күңелле булыр, ләкин миңа хәзер ашарга юклык эчне тырный.

Сибгат агай (минем белән эшләгән карт), минем хәлне аңлаган кебек:

— Соң син кем белән ашап-эчәсең? Чәйнек-мазарың бармы? — дип сорап та алды.

— Хәзергә мин ялгыз гына. Чәйнек-фәлән дә алганым юк әле.

---

[1] *Бадьян* — зур агач чиләк.

— Әйдә, алай булса, безгә. Нәрсәгә алай адашкан каз бәбкәсе кебек ялгыз йөрергә!.. Безнең монда алай йөрү килешми.

Сибгат карт мине туп-туры үзләренең тора торган почмакларына алып барды һәм, миңа үзенең бер кунагы кебегрәк карап:

— Әйдә, рәхим ит әле. Менә хәзер чәй эчәбез. (Карчыгына карап.) Карчык, мин бүген үземнең янымда эшли башлаган иптәшемне дә алып килдем әле.

Әби минем белән исәнләште дә:

— Бик әйбәт! Без икәү генә бит, өчәүләп чәй эчү күңелле булыр, — дип, ачык йөз белән каршылады.

Чәй эчелеп беткәнче минем хакта да сүз булды. Сибгат бабайның кузгатып җибәрүе буенча, әби үзе теләп үзләрендә ашап-эчеп йөрүне мәслихәт бирде. Аларның киңәшләре буенча, мин, болар белән ашап-эчеп, тик кунарга гына буйдаклар казармасына барачак идем.

Без ишектән чыкканда, Сәлим бабай безгә очрап, дөнья күргән олы кешеләрчә исәнләшеп, минем Сибгат карт белән бер җирдә эшләвемне белде һәм, аңа карап:

— Бик яхшы булган! Синең кебек дөнья күргән кеше белән бергә эшләү яшь кеше өчен яхшы булыр,— дип, үз эшенә китте.

Бу юлы миңа шахтага төшү иртәнчәк төшкәндәге кебек кыен да, күңелсез дә, куркыныч та булмады. Хәзер мондагы эшчеләр дә миннән көлмиләр, алар миңа күптәнге иптәшләр кебек күренәләр иде. Без шахтага төшкәндә, кояш безнең артыбыздан көлеп карап калды.

Бүген якшәмбе — эшчеләрнең ял итү көннәре. Казармаларда бүген икенче төрлерәк тормыш.

Минем әби һәммәсеннән иртә өлгергән. Сибгат бабай белән мин ашъяулык янына килеп утыру белән, ул гөжләп кайнаган самоварын китереп утыртты. Аның артыннан ук зур гына таба белән коймак китереп куйды.

Сибгат бабай салмак кына рәвештә:

— Төшемдә забой казыганда бик зур — мона шушы баш бармак чаклы булыр — самородкы таптым. Инде алып чыгыйм дигәндә генә, күршенең баласы елаган тавышка уянып киттем,— дигән сүзләр белән чәй мәҗлесен ачып җибәрде.

Мин кайтып кергәндә, буйдаклар казармасы бөтенләй икенче төс алган. Озын чәчле бер егет гармун уйный. Мәҗлес

казарманың эчендә генә сыеп тора алмады, казарманың тышына да чыкты.

Гармунның сикереп-сикереп уйнаган тавышына шул ук көйгә җырланган җыр тавышы кушылды. Бию көе уйнала башлау белән, кызыл күлмәгенең якасын ычкындырган бер егет, уртага төшеп, ике кулын җәеп, гәүдәсен әрле-бирле сыгылдырып, аякларын җиргә ныклап тибеп, түгәрәкне әйләнеп йөри башлады. Икенче бер егет, аңа каршы төшеп, үзенең биюгә осталыгын күрсәтергә керешге.

IV

Беркөн иртән, эшчеләр эшкә китәргә җыенганда, беренче номерлы шахтаның җимерелүен хәбәр иттеләр.

Аның төнлә белән, эшчеләр юк вакытта җимерелүе анда эшләүчеләр өчен шатлыклы бәйрәм булды.

Шахта җимерелү аркасында, күптән эшләп килгән эшчеләрнең байтагы эшсез калганда, стажлы эшчеләр кул астында эшләгән минем кебек яшь кешенең эшсез калуы бик мәгълүм һәм табигый иде.

Өч-дүрт көн эшсез йөргәннән соң, миңа да эш табылды. Мин вашгердта[1] алтын песогы юучыларга су тартып тору эшенә яллапдым.

Бу эш, үзе яхшы ук авыр булса да, бердән, җир өстендә булганга, икенчедән, күп кешеләр, шулар арасында хатын-кызлар да эшләгәнгә күрә, җиңел төсле күренә.

Эшләрнең барышын карау, аерым хәл җыярга туктаган вакытлардан башка вакытларны эшчеләрне бер минут та тик тотмыйча эшләтү — нарядчикларның бурычлары.

Байлар килгәннән соң, бу контрольлек тагы да көчәйде.

Менә бүген шулай эш кайнап торганда:

— Байлар килә! — диделәр.

Без башыбызны күтәреп караганда, теге яшел түбәле өйләр ягыннан байлар белән управляющийлар әкренләп кенә без эшләгән җиргә таба киләләр иде.

Алар безгә якынлашкан саен, нарядчикның йөзе үзгәрә башлады. Эшчеләргә күзләре белән боерык биргәндәй булып, төрмә каравыллаган борынгы солдатларча, вашгердлар тирәсендә әрле-бирле йөрергә керешге. Ул үзенең эчке тойгысын,

---

[1] *Вашгерд* — суны кул белән тартып, алтын комын юа торган иләк.

байларга ярарга тырышуын үзенең эчендә генә саклап тора алмады.

— Байлар килгәндә кулларыгыз эштә булсын! Алар сезне күрер өчен түгел, мондагы эшнең порядкасын карарга киләләр! — дип боерык бирде һәм юар өчен вашгердлар янына китерелеп түгелгән алтын песокларын шунда ук бер җиргә өйдереп куйдырды.

Эшчеләр, туктаусыз рәвештә, аерым бер кызулык белән эшкә керештеләр.

Байлар буаның теге башыннан башлап, һәрбер вашгерд янында бераз туктап, управляющийлар белән нәрсә турындадыр сөйләшеп бераз торганнан соң, әкренләп алга атладылар. Алар шулай әкренләп безнең янга килеп җиткәнче, сәгатьләрчә вакыт үтте. Байлар килгәндә, эшчеләр эштә булырга тиеш булганга күрә, эш туктаусыз дәвам итте. Беләкләр талдылар, күз аллары караңгылана башлады. Йөрәкләр еш-еш тибеп, тын алу авырлаша башлады.

Алар безнең янга килеп җиттеләр дә тагын туктадылар. Аларның күзләре безгә түгел, иң элек безнең эшкә ташланды.

Байлар, гүяки, монда бер кеше дә юк кебек, тик нарядчикның баш июенә каршы ияклөрен кактылар да эшчеләргә бер сүз генә дә әйтмәделәр.

Байлар икәүсе дә — гәүдәгә бертигез, озын һәм пар аргамак кебек килбәтле, таза кешеләр. Аларның зур кара мыеклары тулы битләренә матурлык биреп, байлыкларын күрсәтеп торгандай күренә.

Эшчеләргә алар алдында эштән туктарга ярамаганга күрә, эш гадәткә караганда да кызурак бара. Тимер иләк өстендәге вак таш катыш балчыклар юылып читкә ташланалар.

Күңелләр аларның тизрәк китүләрен, сәгатьләр буенча һичтуктаусыз эшләп арган беләкләрен ял иттерүне көтәләр. Ләкин алар эшчеләрнең, бигрәк тә хатын-кызларның аяктан егылырлык аруларын сизмиләр яки, сизсәләр дә, алар белән исәпләшергә кирәк тапмыйлардыр, ахры.

Шул арада теге яшел түбәле өйләр ягыннан җәйнең эссе көненә карап киенгән, чәчәкләргә очып йөргән күбәләкләр кебек, сигез-ун яшьләрендәге ике кыз йөгереп килделәр.

Аларны әтисе, аркаларыннан сөеп, кызыл ефәк тасма белән бант ясалган чәчләреннән сыйпады да:

— Былбылларым, шулай балчык арасында йөрергә ярыймы? Башыгызга эссе кабар бит!.. Монда нигә килдегез? — диде.

— Әниләр сезне көтәләр...

Шул кызлар килгәннән соң гына, байларның берсе түш кесәсеннән алтын сәгатен алып карады һәм үзенең туганына нәрсәдер әйтте. Шуннан соң гына алар әкренләп алга киттеләр.

Көн аяз. Кояш Урал тауларына карап, түбән төшеп бара.

Бүген дә эшкә бара алмаган кешеләр капыл гына, нигәдер, приискадан сөзәкләнеп, югары күтәрелгән кыр өстендәге вак кына каенлыкка таба йөгерешә башладылар. Без дә, ашыга-ашыга, шулай таба йөгердек.

— Нәрсә бар анда?

Ашыгып баручыларның берсе, бик зур әһәмият биреп:

— Ат башыдай алтын табылган! — диде дә безне узып китте.

— Ат башыдай алтын!

Без баруыбызны әкренәйтә төштек тә «ат башыдай алтын» турында сөйләшә башладык.

— Аны табучы — нинди бәхетле кеше!.. Башкалар монда күгәрчен күкәе чаклы самородкы таба алмыйлар, ә ул кеше «ат башыдай» алтын тапкан.

Ниһаять, без, бара торгач, вак кына каенлык арасындагы бер ялан җиргә барып чыктык.

Анда җыелган халык төркеме, түгәрәкләнеп, исләре китеп карашып торалар.

Иң элек кечкенә мәйдан уртасына җәелгән кып-кызыл иран паласы өстендә утырган байларга күзебез төште.

Ни күзебез белән күрик, чынлап та, байларның алдында ат башы чаклы кызгылт һәм кытыршы бер таш. Ул гына да түгел, шул зур кисәк янында йодрык һәм аннан кечкенәрәк тагын берничә кисәк кызгылт нәрсәләр торалар. Аларның иң зурысы, чынлап та, ат башы чамасында булса да, ул саф алтын булмый, тимер рудасы кебек кызгылт тузанга манчылган таш белән аралаш булып, шул ташның арасыннан йөргән бармак юанлыгы алтын тамырлары күренеп торалар иде. Кечкенә кисәкләрдә дә алтын шулай ук кызгылт таш белән аралашкан.

Бу «ат башыдай алтын» үзенең кечкенә балалары кебек булган бәләкәй алтын кисәкләре белән өч чирек чамасында гына тирәнлектән, чирәм астыннан чыккан икән.

«Ат башыдай алтын»ны табучы — Урал ягыннан килгән башкорт агае. Ул һаман байлар һәм стражник карамагы

астында шул тирәне казый. Хәзер ул үзенең аруын да, ашауэчүен дә оныткан төсле күренә.

Без хәзер җайлап, рәхәтләнеп кайтабыз. Юлда кайтып баручыларның авызларында тик шул «ат башыдай алтын» хакында сүз бара:

— Вәт, малай, ат башыдай алтын кайда гына яткан бит!.. Без шуның өстеннән атлап йөргәнбез...

Иртән торуга, кичә безнең сөйләгән хыялларыбыз күңелләребездән юылып алынып ташланган бер хәлдә эшкә киттек...

Алтынның бер пот та утыз биш кадак икәнен ишетү белән һәркем бер-берсеннән:

— Ә аны тапкан башкорт агайга күпме, ничә мең тәңкә наград бирделәр икән соң? — дип сораша башладылар.

«Бер йөз тәңкә награт биргәннәр икән...» хәбәре шунда ук таралып өлгерде.

Башкорт агайга йөз генә тәңкә наград бирелүенә һәркемнең эче пошты.

Шимбә көн акча алабыз.

Шуны алыр өчен Фәйзулла белән Лотфулла конторга киттеләр.

Әнә алар кайтып киләләр. Малайлар бик шат күренәләр. Ахрысы, безгә акча тигәндер.

— Алтмыш ике сум кырык тиен!..

Бер-беребезгә караштык. Унбиш көндә шулчаклы акча эшләгәнбез, бу әз түгел.

Фәйзулла белән Лотфулла, бер-берсенә карашып алганнан соң:

— Сезгә яңа хәбәр әйтикме? — диләр.— Безгә Орски ягына разведкага барырга кушалар.

— Без сөйләштек-сөйләштек тә барырга карар бирдек.

Кич белән мин гаиләлеләр казармасына Сибгат һәм Сәлим бабайлар белән күрешеп китәргә бардым.

Сәлим бабайлар тора торган як башында байтак кешеләр, җыелышып, нәрсә өчендер аптырашта торалар һәм кемнедер кызганып сөйләшәләр иде. Сәлим бабайның хатыны мине күрү белән:

— Абзаң имгәнде бит,— диде дә күзләрен яшьләндерде.— Югарыдан агач төшеп, шуның бер башы аның кулбашына килеп бәрелгән.

Мин Сәлим бабайның янына бардым.

Аның күзе миңа төште:

— Исәнме әле!

— Яхшы әле. Сезгә күрешеп китәргә килгән идем дә, сез бик күңелсезлеккә очрагансыз икән...

— Хәерле булсын... Кайтканда безгә төш.— Аның күзе яшьләнде, мин, тагы исәнләшеп, башымны иеп, аның яныннан киттем.

Сибгат бабайлар, әбиләр һәм башкаларның һәммәсе белән дә күрештем. Алар һәммәсе дә, мине үзләренең бик якын кешеләре кебек кайта-кайта күрешеп, кайтканда үзләренә төшәргә кушып озаттылар.

Иртәгесен без бөтен кораллары төяп, шагыйрьнең алтын приискасыннан көньяк-кояш батышына карап чыгып киттек. Көн матур, чиксез матур иде.

Прииска әкренләп артта калды. Шуның белән бергә, анда минем йөрәгемнең бер кисәге калган кебек булганга күрә, прииска биек кырның артында калып югалганчы карап бардым.

Без артыбызга әйләнеп карауга, аннан өчәр ат җигелгән өч көймә (повозка) килә, җирне җимерердәй булып шәп киләләр иде.

Без юлдан чыгып өлгермәдек, көймәләр безнең яныбыздан үтеп киттеләр. Анда прииска хуҗалары һәм аларның хатыннары вә балалары иде.

Еллар үткәннән соң гына, «Дәрдемәнд» имзасы белән язылган шигырьләрнең иясе Закир әфәнде булып, аның шул ук приискаларның хуҗасы икәнен белдем.

1929 ел

Биремнәр

1. Әсәрне ике генә өлешкә калдырып бүлегез.
2. Әсәрнең фокусын табыгыз.
3. Эчтәлеген сөйләгез.

КАРА ЙӨЗЛӘР

(*Иске тормышның миллион корбаннарыннан берсе*)

I

Бу эш моннан утыз еллар элек иде.

Без, яшь шәкертләр, ястү намазыннан алдарак чыгып, мәдрәсәгә кайттык. Шул арада ишек ачылды. Сафи хәзрәт бик акрын гына керә башлады. Без шунда ук, һәммәбез дә аягүрә

басып, кулларыбызны күкрәкләребезгә куеп, баскан урыннарыбызда таш багана кебек катып калдык.

Дәрес тыңлаучы шәкертләр һәммәсе дә, шаккатып, хәзрәтнең авызыннан чыккан сүзләрнең берсен дә калдырмый тыңларга керештеләр.

II

Хәзрәтнең дәресе шулай иң кызу җиренә җиткән чакта гына, мәдрәсәнең ишеге ачылып, әллә кемнәр, бик нык тавышланып, эчкә керә башладылар.

Хәзрәт күзлеген маңгаена күтәреп куйды да, ишеккә табан карап, ачулырак бер тавыш белән:

— Ни бар? Нәрсә булды?.. Төн белән ут чыккан кебек нәрсәгә шаулашып йөрисез?..— дип сорашырга кереште.

Бердән, эчкә кергән кешеләрнең соң дәрәҗәдә җитди кыланулары, шуның өстенә кайберәүләрнең кулында күсәкләр булуы, икенчедән, тыштан ачулы һәм куркынычлы тавышлар ишетелүе ни дә булса берәр мөһим эшнең барлыгын күрсәтеп тора иде.

Хәзрәт өченче мәртәбә тагын да ачулырак рәвештә:

— Йә, нәрсә бар? Нигә берегез дә сөйләмисез, кыямәт куптымы әллә? — дип җикерде. Бу юлы хәзрәтнең йөзенә ачу галәмәте бик нык чыккан иде.

Ниһаять, ишектән кергән кешеләрнең берсе, башка иптәшләреннән алгарак килеп, өзек һәм калтыравыклырак тавыш белән:

— Хәзрәт, эш зур!.. Бозыклар аяк астында яталар икән!.. Шуларны тотып, сездән шәригать сорарга килдек! — диде.— Хәзрәт, сөйләргә дә авыр инде... Әнә теге Шакир малае Закир белән Фәхри кызын тотканнар... Гайфулла белән Сәлим, авыл картлары да шаһит булсыннар дип, әле генә безне алып чыктылар.

Бу вакыйга, бу куркынычлы эш миңа яшен кебек килеп бәрелде.

«Фәхри кызы!.. Ул бит — безнең күрше һәм этинең бертуган абзасы Фәхри бабайның кызы Галимә апа!.. Ул ничек болай булды икән?.. Ул, мескен, хәзер бу хурлыкка ничек чыдый икән?.. Теге тышта нечкә тавыш белән әрнеп елаган кеше Галимә апа икән...»

Хәзер дәрес кайгысы бетте, алдагы китаплар онытылдылар, бөтен шәкертләр һәм бу эш артыннан йөрүчеләр, хәзрәт

авызына карап, аның мөһим эш хакында, адәм гаҗиз калырлык вакыйга турысында, нәрсә әйтәчәген көтә башладылар.

Хәзрәт тә эшнең соң дәрәҗәдә мөһим икәнлеген белдерер рәвештә тамагын кырды һәм бераз уйлап торганнан соң:

— Кемнәр күргән?.. Шаһитлар бармы?.. Мондый эшләрне исбат итәр өчен, шәригать каршында дүрт шаһит кирәк,— диде.

— Бар, бар! Шаһитлар әзер! — дип кычкырып җибәрделәр. Хәзрәт тагын да җитдиләнә төште һәм:

— Алар кайда соң? Аларны монда алып килегез! — дип әмерне бирде.

Ишек ачылды. Ишеккә якын торган кешеләр икегә аерылып юл бирделәр. Бу вакытта йөрәкләрнең кагулары ешайды, тамырларның тибүе көчәйде.

Менә бервакыт Закир абыйны ике егет кулыннан кысып тотып алып керделәр һәм алгарак китереп бастырдылар. Аны күрү күңелгә бик авыр тәэсир бирде: аның бишмәте ертылган, бүреге яньчелгән, сул як битеннән кан агып төшкән һәм уң күзенең өсте күгәреп, кара янып чыккан...

Аның артыннан Галимә апаны алып керделәр. Аның кулларыннан кысып тотучылар булмаса да, качмасын дигән кебек, тирә-ягын әйләндереп алганнар иде. Ул үзенең йөзен шәле белән бик нык бөркәү сәбәпле, йөзе күренми, шуның белән бергә, елавы һаман бетмәгәнгә, йөрәк ярсуы басылмаганга күрә, очкылык тоткан кебек, өзек-өзек тавышлар чыгара. Үзе калтырап, селкенеп-селкенеп куя иде...

Күзләре ут кебек янган Сәйфулла, билен яшел билбау белән буып, бияләйләрен шунда кыстырган Гәрәй, аның янында бик зур эш күрсәткән кеше кебек тыпырчынып торган Гайфулла, бүреген кырын киеп, озын шарфын муеныннан уратып, очларын билбавына китереп кыстырган һәм ерткыч җанварлар кебек булып күренделәр.

Хәзрәт, бу гөнаһлыларга бик ачу белән күз йөртеп алганнан соң, сүз башлап:

— Йә, кемнәр күргән? Кемнәр шаһит булып, үзләренең гуаһлыкларын[1] бирәләр? Шулар алгарак чыксыннар әле,— диде.

Гайфулла белән Сәлим, алгарак чыгып, кулларын намаздагыча алларына кушырып:

---

[1] *Гуаһ* — таныклык бирүче шаһит.

— Башлап без күрдек, хәзрәт, аннан соң Сәйфулла белән Гәрәй күрделәр... Шуннан соң башкалар да килделәр инде,— дип җавап бирделәр.

— Сез дә күрдегезме? Кайда күрдегез? — диде хәзрәт. Сәйфулла белән Гәрәй берьюлы:

— Күрдек, күрдек, хәзрәт! Бер-берсенә якын ук утыралар иде,— диделәр.

Шунда Гайфулла, урыныннан кузгала төшеп:

— Кочаклашып торалар иде диң,— дип өстәп куйды. Шул вакытта Закир абый, курыккан рәвештә, әкрен генә бер тавыш белән:

— Юк, хәзрәт, нахак әйтәләр, без сөйләшеп кенә утыра идек. Болар шул вакытта үчлек белән...— дип сүз башлаган иде, теге кешеләр бердән:

— Тик тор син, кара йөз! Монда килеп, оялмый сүз сөйләгән буласың тагын! — дип шаулаша-котырыша башладылар. Әгәр дә хәзрәт, урыныннан торып:

— Сабыр итегез, шаулашмагыз! Шәригать хөкемен көтегез,— дип тынычландырмаса, Закир абыйны шунда ук бәргәләп, кыйнап ташлаячаклар иде.

Шул вакытта Галимә апа бик әрнеткеч, үзәк өзгеч тавыш белән:

— И Ходаем, нахак бәла ягалар!.. Безнең һичбер гөнаһыбыз юк...— дип елап җибәрде.

Галимә апа белән Закир абыйның үзләрен аклар өчен әйткән сүзләре халыкның ачуларын гына кабартты. Хәзрәт тагын, урыныннан торып, халыкны тынычлыкка өндәде һәм үзе нәрсәдер сөйләргә генә керешкән иде, мәдрәсә ишеге ачылып:

— Кайда ул кара йөзләр?! — дип акырган тавышка аның сүзе бүленеп калды. Бөтен халык, сискәнеп, ишектән кергән кешегә карадылар.

— Кайда ул кара йөзләр?! — дип акырып керүче кеше Галимә апаның атасы Фәхри бабай иде. Мин аның коточкыч куркыныч күзләрен, агарган йөзен, соң дәрәҗәдә ачуланып әйткән сүзләрен күреп, утырган урыныма сеңеп, әллә кайда батып киткән кебек булып калдым.

Фәхри бабай, күзләрен Галимә апага терәп, берәр минут чамасы карап торды да, соңра капыл гына Галимә апага таба омтылып:

— Син, кара йөз, карт көнемдә ак сакалыма оят китердең, бөтен галәм алдында рисвай иттең! — дип, кулындагы таягы

белән Галимә апаның аркасына бәрә башлады. Мондагы халык аның бу эшен сизми дә калган кебек булдылар.

Шул чакта, искиткеч ачы тавыш белән үксеп елаган Галимә апаны күреп, мин дә елый башладым. Хәзрәт, урыныннан кузгалып:

— Тотыгыз, кыйнатмагыз, әле хөкем бетмәгән...— дип кычкырды.

Фәхри бабай, берничә кеше арага төшүгә карамастан, һаман Галимә апага таба тартыла, аны кыйнамакчы була иде, ләкин аны җибәрмәделәр.

Ниһаять, хәзрәт тагын сүзгә башлады һәм бик җитди рәвештә:

— Фәхри, син сабыр ит. Бу зур эш булса да, дөньяда булмый торган бер эш түгел, шуның өчен бу хакта шәригать хөкеме бар,— дип, бик озын сөйләп алып китте.

Хәзрәтнең шушы сүзләреннән соң теге гуаһларның берничәсе шиккә калгансымак булдылар. Калган берничәсе берьюлы:

— Хәзрәт, без күргәнне әйтәбез, без аларны өйләреннән алып чыгып, монда килмәдек инде. Бая әйткәнчә, келәт белән койма арасында бергә торалар иде... Шуны үз күзебез белән күрдек...— диделәр.

Шулвакыт хәлфәләр арасыннан берәү, чыгып:

— Хәзрәт, без бит дарелхәребтә[1] торабыз, монда хәт[2] фарыз түгел,— дип сөйләп алып китте. Аның сүзенә икенче хәлфәләр кушылып киттеләр. Күгәрчен Сәлим дә катнашып китте, ул башкалар сүзе өстенә, гуаһларның бертөрле генә сөйләмәүләрен, кыз белән егетнең зина кылулары исбат кылынмавын да әйтеп китте.

Мин мәсьәлә болайга киткәч сөенеп киттем. Бигрәк тә Күгәрчен Сәлим матур һәм яхшы булып күренде. Кечкенә гәүдәсе белән аның бу чаклы батырчылык итүенә, курыкмавына хәйран калдым.

Сүз байтакка тартылды, бәхәс киткән саен кызды.

Шул вакытта теге кешеләр арасыннан бер егет, чыгып:

— Юк, хәзрәт, алар сөйләшеп кенә утыралар иде. Эш болар әйткәнчә түгел,— диде.

Ләкин аның бу сүзләре җыелган халыкның йөрәкләренә без белән чәнечкән кебек булды. Шунда ук теге Сәйфулла,

---

[1] *Дарелхәреб* — сугыш мәйданы, монда: изге урын мәгънәсендә.
[2] *Хәт* — җәза.

Гайфулла, Сәлим һәм Гәрәйләр, аларга кушылып башкалар да:

— Сезнеңчә, шулай намәхрәм[1] белән аулакта, төнлә утырырга ярыймы?! Бу ни дигән сүз? — дип, зык куптарып, кызышып, теге егетнең өстенә һөҗүм итә башладылар. Теге егет шәкертләр арасына кереп тыгылды. Хәлфәләр, уртага төшеп, теге ут кебек кызган халыкны чак бастырдылар...

Хәзрәт тә, урыныннан кузгалып:

— Сез кызасыз да китәсез, эшнең асылын сорашып бетәргә ирек бирмисез? — дип ачуланып, хәлфәләргә карап: — Мин дарелхәребтә хәт сугуның дөрес түгел икәнен беләм. Ләкин бозыклыкка каршы тору өчен, мондый эшләрне җәзасыз калдырып та булмый,— дип сөйләде.

Мәсьәлә тиз генә чишелмәслек бер төскә керде. Хәлфәләр дә бәхәсне сузганнан-суздылар. Хәзрәт, мәсьәләнең болай зурга киткәнен күргәч, бераз уйлап торды һәм:

— Җәмәгать, бу эш бүген генә тәмам булмас. Иртәгә шаһитлардан берәм-берәм җавап алырбыз. Бүген боларның икәүсен ике урынга куеп, каравыл куегыз, һәрберегез кул белән хөкем итүче булмасын! — диде.

Хәзрәтнең сүзләре һәм мәслихәте кабул күренде. Теге егетләр Закир абыйны каравыл өенә, Галимә апаны Габдерахман бабайларга алып китәргә, шунда каравылларга булдылар.

III

Башка вакытта безнең өй эче күңелле була; мин кайтып керү белән, әни каршы алып, хәлне сораша торган иде. Бүген алай булмады: әни күңелсез генә чәй урыны хәзерли, әти бик тирән уйда утыра иде.

Минем әти, Фәхри бабайның киресе, бик йомшак күңелле, юаш кеше булып, үз эшеннән башканы белми, авылдагы төрле талашлы эшләргә катнашмый, бернәрсәгә дә артык ачуланмый торган басынкы кеше иде.

Әмма минем әни — әтигә караганда үткер, җитез, күбрәк сөйләүчән кеше, ләкин усал табигатьле түгел, шуның өчен алар бүген күңелсез булсалар да, артык кызулык күрсәтмиләр. Әти дә, әни дә Галимә апаның бу эшенә бер мәгънә дә бирә алмый аптырыйлар иде.

---

[1] *Намәхрәм* — шәригать буенча тыелган нәрсә.

— Ни генә булды икән бу Галимәгә? Бер дә андый-мондый эше сизелгәне юк иде. Бөтен нәсел-ыруга оят китерде,— диде әни.

Әти, бик озак уйлаганнан соң:

— Нәрсә булсын? Аларның сөйләшеп торуларын күреп, дошман егетләр эшне шулай зурга җибәргәннәрдер,— диде.

— Булмаса да, булды дип күрсәтәләр бит әле, бөтен авыл алар өстенә сөйли. Галимә ни эшләр инде? Кайнага: «Кайтып кермәсен, күземә күренү белән сугып башын ярырмын»,— дип тора... Ул хәзер кайда барыр? — ди әни.

— Кайда барсын? Менә үзебезгә алырбыз. Мин Галимәне беләм, ул бозыклык эшли торган кыз түгел, бөтен авыл түгел, бөтен дөнья сөйләсен, мин аларга ышанмыйм! — ди әти.

IV

Мин үзебезнең капка төбенә чыктым.

Бөтен авыл шау килә... Һәркемнең авызында шул. Төркем-төркем җыелышып, шул хакта сөйлиләр. Безнең турыдан үткән бер кеше, Фәхри бабайның өенә карап, «анда нәрсәләр бар?.. Бу йортны каһәр сукты...» дигән кебек үтәләр, кайбер яшьрәкләре, үзара сөйләшеп:

— Матурлык белән дан чыгарган кыз шулай була ул!

— Үзен бик югары тота иде!..

— Ирләрдән кача белми иде!..— диләр иде.

Менә бервакыт Закир абыйны җиде-сигез кеше, ныклы каравыл астында, каравыл өеннән алып чыктылар, җыелган халык, аны күрү белән сырып алдылар, аның үзенә ишеттереп үк:

— Менә шәп егет, никахсыз-нисез кыз алган!..

— Туй белән булгач, акча чыга бит... Ә болай ансат!..

— Малайның бүген башы түбән төшкән!! — дип кычкыралар иде.

Халыкның ачулы рәвештә шулай кычкыруларын күргәч, миндәге курку тагын да артты. Боларның хәзер берсе дә кичәге безнең авыл кешеләре түгел, һәммәсе дә безгә, Галимә апага, Закирга чит кешеләр — дошманнар кебек куркыныч булып күренделәр. Һәммәсе дә бу эшнең булуына шатланган кебек сизелделәр.

— Әнә тегесен дә алып чыктылар! — дигән тавыш күтәрелде. Шул сүзне ишетү белән, халык дулкыны икенче урамга чайкалды. «Әнә тегесе!..» дигәннәре Галимә апа иде.

Галимә апаны бер минут эчендә халык чолгап алды.

Халык арасыннан:

— Бүген оялган була бит әле! Оятсыз!..

— Кыз башы белән ни эшләп йөри!..

— Матур кыз шулай була ул!..— дигән тавышлар чыкты.

Мин кайтып бераз гына тору белән, урамда тавыш күтәрелде. Әллә ничаклы кешеләрнең авызларыннан чыккан бу тавышларның аерым сүзләрен аңлап булмый, тик зур базардагы тавыш кебек, һәммәсе бергә кушылып, бөтен урамны яңгырата иде.

Мин бу тавышны ишетү белән, тагын урамга чыктым һәм безнең якка агылып килә торган халык ташкынына очрадым. Боларның иң алларыннан Галимә апа белән Закир абыйны китерәләр иде. Хәзер Галимә апаның шәле битен капламасын өчен, аны башына уратып артка бәйләгәннәр, йөзе ачык булып, бөтен битен кара белән буяганнар һәм аның сул кулын Закир абыйның уң кулына бәйләп куйганнар иде. Шулай ук Закир абыйның да йөзен карага буяганнар, аның да күзләре генә агарып күренеп торалар иде.

Бу күренешне күргәч, куркуымнан ни эшләргә белмәдем. Галимә апа хәзер җансыз бер сын кебек, үзенең иркеннән башка алга килә. Икенче төрле әйткәндә, аларны халык дулкыны ихтыярсыз йомычка кебек алга этеп китерә иде. Әллә нәрсәләр шалтыраталар, Галимә апа белән Закир абыйның өстенә иске чабаталар ыргыталар иде. Шушы җирдә Галимә апа, һуштан язган кебек, җиргә бөгелеп төште. Аны күтәреп алдылар. Ул хәзер еламый да, эндәшми дә иде.

Шул минут эчендә Фәхри бабай йортыннан йөгереп чыкты да, туп-туры Галимә апа янына килеп, битенә чабып җибәрде һәм, аның йөзенә төкереп: «Моннан соң минем йортыма кайтып керәсе, ишегалдыма аяк басасы булма!.. Теләсәң кайда югал!..» — дип, бер-ике сүз әйтте дә, кире борылып, капкасыннан кереп китте.

Шуннан соң аларны тагын алга алып киттеләр. Тагын баягы төсле кычкырулар, төрлечә мыскыл итүләр башланды.

Теге кешеләр безнең турыдан үтеп китү белән, әни, өстенә киенеп, тунының төймәләрен эләктерә-эләктерә, теге халык артыннан китте. Ул үзе кызган һәм:

— Тапканнар аю биетүне! Һичбер гөнаһсыз кешеләрне хурлыкка төшерделәр! — дип сөйләнә-сөйләнә бара иде. Әти, капка төбенә чыгып, әнинең артыннан:

— Юкка йөрисең, эт кебек котырган халык үзеңне изеп ташламасын,— дип әйтеп калды. Бу вакытта әтинең ияге селкенә, еларга торган кеше кебек, сүзләре калтыравыклы чыга иде.

Әтинең артык дәрәҗәдә кайгыруы мине тагын да үзем дә аңлап бетерә алмый торган чуалчык уйларга батырды. «Тормыш шулай икән: кыз белән егет бер-берсе белән аулакта бер генә минут та күрешеп тормаска, бер сүз дә әйтмәскә тиеш икән! Бу ник болай соң, бу эш нигә бөтен авылны зык куптара? Әйбер урлап тотылган кешеләргә дә болай кызмыйлар, аларны да болай урам буйлап, битләренә кара ягып йөртмиләр».

V

Бик күп вакыт үткәннән соң (ул вакытта миңа шулай тоелды), безнең урамда тавышлар ишетелә башлады. Мин чыкканда, әни, Галимә апаны җитәкләп, үзебезгә таба кайтып килә, арттан ияреп килгән сирәк кенә кешеләргә әйләнеп, әллә нәрсәләр әйтә, Галимә апа бер сүз дә дәшми, шәле белән йөзен бөтенләй каплап, башын түбән иеп, атлар-атламас кына кайта.

Шул вакытта Галимә апа, шәлен аз гына ачып, әнигә дә, миңа да карап алды. Аның бу каравы бик тәэсирле булу белән бергә, өмит белән өмитсезлек арасында күренә, гүяки «әле миңа дөньяда торырга ярыймыни? Әле мине адәм санына керткән кеше калганмыни?..» дигән сөальләрне биргән кебек иде.

Галимә апа кичә генә нинди шат иде! Кичә төштән соң мин мәдрәсәдән азык алырга дип кайткан вакытта, ул безнең өйгә кергәндә, без чәйгә утырырга тора идек. Шунда ул, безгә керү белән төрле сүзләр табып, безнең һәммәбезне дә көлдерде. Әнинең эштән бушамаганын күрү белән, үзе чәй ясарга тотынды. Үзе дә чәй эчеп алды. Чәй арасында һәммәбезне җанландырды, бөтен өй эчен матурландырып, нурландырып җибәрде.

Үткән җәй печән өстендәге, урак вакытларындагы аның шатлыкларын әйтеп бетерерлек түгел иде. Ул, бер яктан, Фәхри бабайларның үз кызлары булып, шуның өчен яратсалар, минем әти-әни дә үз кызлары кебек күрәләр, мин аны бертуган апам кебек кенә түгел, бәлки аннан да артык күрә идем. Ул шушы ике өй, икенче төрле әйткәндә, шушы ике гаилә арасында иркә дә, аларның кызлары да, матурлык бир-

гән чәчкә дә иде. Ул үзләрендә ничек булса, бездә дә шулай иркен кылана, безне дә үзенең гаилә әгъзасы кебек күрә, теләгән чагында безгә дә эшкә килеп, печән җыярга, урак урырга булыша торган иде.

Аның үткән елгы печән җыеп кибән куйган вакыттагы шат йөрүләре әле дә күз алдымда тора: ул, чабынлыкка барып җитү белән, һәммә кешедән элек беләген сызганып, кулына тырмасын алып, үзе теләгән җирдән пакусны җыярга кереште. Башкаларыбыз, аның рәтеннән тезелеп, тырмалар белән, хуш ис чыгып торган, яңгыр күрмәгән калын пакусны алга тәгәрәтә башладык. Галимә апа печәнне үз биеклеге булганчы тәгәрәткәч, этинең: «Галимә кызым, бик ерак китмә, башкаларга авыр булыр, югыйсә чүмәлә салырга җайсыз булыр»,— дип әйткәнен ишеткәч кенә туктады. Шунда да ул тик калмады, ирләргә карап:

— Көчегез җитмәсә, үзем салырмын, күтәрәмнәрне ястык кебек кечкенә итмиләр аны! — дип көлдерде. Ул, кеше ике рәт алып барганчы, өч рәт алып бара. Үзенең шул шатлыгыннанмы, югыйсә үзенең янып торган күңеленең ялкыныннанмы рәхәтләнеп көлә, башкаларның да күңеле булуларына сәбәп була иде.

Хәл җыярга туктап, ирләр күләгә астында бозлы әйрән эчкәндә, Галимә апа үзенең ике иптәш кызы белән әрәмә арасына китте. Мин атларны эчерер өчен шул якка барганда, ул бик матур көй белән җырлый иде, мин аның җырлаганын тыңлап тордым һәм шундый шат кешенең моңланып җырлавына гаҗәпсендем.

Кибән куйганда, ул күбә (чүмәлә) җибәреп торды. Күбәләр түшәлеп беткәч, кибән тирәсенә җыелдык, шунда Галимә апа этинең кулындагы озын кибән сәнәген алып зур итеп күтәрде. Карап торган кешеләрнең:

— Юк, булдыра алмассың! Кулыңны авырттырып куйма, белмәгән эшкә тотынма! — дип әйтүләренә карамастан, түшәк зурлыгындагы печәнне «ә» дигәнче күтәреп, югары ыргытты. Ул берничә рәт шулай күтәреп югары ыргытканнан соң гына, эти, аның кулыннан сәнәкне алып:

— Җитәр, Галимә, имгәнеп куярсың, рәхмәт көчеңә,— дигәч кенә, эштән туктады.

Моннан соң ул кызлар белән, мондагы вак-төяк эш беткәнче дип, җиләк җыярга киттеләр. Алар киткәч, Гыймай абзый:

— Бу Галимә менә дигән егетләрдән калышмый, кыз булып кына әрәм булган...— дип сүз башлады. Аңа каршы әти:

— Артык үткер, артык булдыклы инде, һич аны-моны карап тормый, Фәхри абзыйның ярты эшен ул алып бара бит; ул шулай артык үткер булганга күрә, аны күралмаучылар, «иржәнкә» дип әйтүчеләр дә бар инде. Менә аның шундый булдыклы икәнен күргәч, нәрсә әйтәсең, башкалар аны аңламыйлар,— диде.

— Шулай кирәк ул... Башка хатын-кызлар җебеп төшкәннәр бит, ничек инде шулар кебек булмаганы өчен гаеплисең,— ди Гыймай абзый.

Без өйгә кайтып кергәндә, кояш баеп бара иде инде. Галимә апа ул вакытта һаман шат иде. Хәл дә җыймый, кайтып сыерларын савып, безгә ашка килде.

Бүген шул шатлыкның һәммәсе дә беткән, бөтенесенең өстенә кара пәрдә ябылган.

Бүген ул безнең өйгә дә, төрмәгә кергән кебек, авырсынып керде. Башын да калкытмый утырды; шулай аз гына утыргач та селкенә башлады, бераз селкенгәчтән соң үксеп елап җибәрде.

VI

Мин кергәндә, Галимә апа юынып, башына шәл ябынып, чит кеше төслерәк булып, читкә карап утыра, әни чәй урыны хәзерли, үзе һаман да, өзелеп-өзелеп:

— Үзләренең йөзләре кара булсын!.. Шулай бинахак рәнҗеткән өчен, үзләре беркөн хур булсыннар! — дип сөйләнә иде.

Борын булса, Галимә апа башлап үзе чәй янына килеп утырыр иде, үзе безне чакырыр иде. Ә хәзер ул чәйгә таба әйләнеп тә карамый, бөтенләй икенче якка карап уйланып, эчендәге чиксез хәсрәтен кайда куярга белми, хәйран калып утыра.

Мин: «Эх, аның күңелендәге бөтен хәсрәтен алып ташлап, аны кичәге шат вакытына кайтарасы иде!» — дигән уйда калдым.

VII

Мин, үземнең йокы килүгә карамастан, төрле күренешләрне күз алдыма китереп уйлау аркасында йоклый алмадым. Менә бервакытта шушы тирән тынлыкны тыштан ишетелгән шомлы җыр тавышы бозып җибәрде. Бу тавыш барган саен безгә якынайды. Урам уртасында берничә дистә кешеләр

туктап торалар иде. Әз генә дә үтмәде, аларның арасыннан берничә кеше берьюлы, бер көйгә салып җырлап җибәрделәр:

Галимәнең калфагында бөрчек-бөрчек сары бар,
Галимәгә без кирәкми — аның сөйгән яры бар...

Кырда йөргән туры атымны танып алам төсеннән,
Галимәнең ике күзе елый-елый шешенгән...

Фәхри картның чапкан җире очырады давылга,
Матур дигән Галимә кыз дан чыгарды авылга...

Болар берничә җырны җырлагач та, Галимә апа үксеп еларга керешге. Әти тиз генә кызып ачулана торган кеше түгел иде. Бу юлы ул кызып китте:

— Минем боларның бу эшләренә чыдап торыр хәлем юк!.. Чыгам да, берәрсен балта белән чабып үтерәм! — дип, киемнәрен эзли башлады. Әни хәзер көндезге кебек түгел, бәлки артык юашланган иде. Ул, бер яктан, Галимә апаны юата, икенче яктан, әтинең ачуын басарга тырыша, аңа карап:

— Зинһар, дим, чыга күрмә, үзеңне бәреп үтереп ташларлар... Этләр өрерләр-өрерләр дә китәрләр, сабыр ит! — дип ялына иде.

Бераздан соң урамдагы егетләр киттеләр.

Мин уянганда, әни, тагы да урыныннан торып, Галимә апа янында утыра, Галимә апа әллә нәрсәләр сөйләп саташа иде: «Кит-кит!.. Кирәкми, мин бармый калам... Менә син агай, нәрсә әйтәләр бит?.. Әти ачуланды бит, юк, мин үлсәм дә өйгә кермим... Минем битләрем агармас инде!.. Закирны үтерәләр бит!..»

VIII

Иртәгесен мин өй эчендә бөтен кешеләрдән дә соңгарак калып тордым. Торуым белән, күзем Галимә апага төште. Ул урыныннан торып утырган булса да, авыру кешеләр кебек күңелсез иде. Ул миңа күзләрен тутырып карады. Мин, аның янына барып: «Галимә апа, башың авыртамы?» — дип сорадым. Ул әкрен генә бер тавыш белән: «Авырта шул!..» — диде. Башка сүз әйтмәде. Шулай да мин аның сөйләшә башлавын, кичәге кебек битен шәле белән каплап утырмавын күргәч шатлана төштем. Моннан соң аны борчучы кеше булмаса, Галимә апаның күңеле күтәрелә төшеп, халык тарафыннан күргән чиксез зур хурлыгы онытыла башлар кебек күренә иде.

Әни чәй хәзерләп беткәч, Галимә апа уранып кына чәй янына килеп утырды һәм, бераз каймак ашау белән бергә, әни кайнатып биргән карлыган суын эчте. Шуннан соң аның йөзе кызыллана төшеп, бит һәм маңгаенда вак кына чык кебек матур тир бөрчекләре күренде. Галимә апа да, төнгә һәм иртәнгә караганда кәефлерәк булып, ятарга хәзерләнгәндә генә, Хәмидә әби килеп керде. Ул әнинең бик түбәнлек белән аның күңелен икенче якка борырлык рәвештә әйткән:

— Әйдә, Хәмидә килендәш, югары уз,— дигән сүзенә дә колак салмады, аның күзләре туп-туры Галимә апа өстенә ташланганнар, аны йотарга торган кебек тоелалар иде. Ул бик әрнегән тавыш белән:

— Әй балам, балам!.. Сиңа ни булды?.. Безне дә хурлыкка төшердең, үзең дә хур булдың, бөтен бәхетеңне югалттың! — дип тезеп алып китте. Галимә апаның өченче көннән бирле җәрәхәтләнгән, әле аз гына да уңала[1] башламаган йөрәгенә чәнчә һәм аны тагын да ныграк авырттыра торган бу сүзләрне тезү өстенә, үзе үксеп еларга кереште.

Галимә апа әнисенең йөзенә карап калтыранырга кереште, соңра, бөтен көчен җыйган кебек булып:

— Мин гөнаһлы түгел!.. Әни, мине үтермәгез, мин үләм, уф Алла!..— дип еларга да еламаска да белми, артык сүз дә әйтә алмый туктады, иреннәре күгәреп, күзләре башкачаланып китте, шәленең бер як очын алып, ике кулы белән шуны бөтәрләргә кереште.

Шулвакыт, капыл гына ишек ачылып, Фәхри бабай килеп керде. Аның күзләре акайган, йөзе агарган. Кергәч тә, Хәмидә әбигә туп-туры карап:

— Кереп тә өлгердеңмени әле, каһәр суккыры нәрсә?! Мин сиңа, аның янына кереп, аның кара йөзен күреп йөрисе булма, миннән мәңге бәхиллек юк дип әйттем бит! — дип җикеренергә һәм Хәмидә әбине, шуның белән безне тиргәргә кереште.

Галимә апа, аның кыяфәтенә аз гына күз салган, аның әйткән сүзләренең берничәсен генә ишеткән кебек булды да:

— Әткәй, мин гаепле түгел!.. Юк, юк, мин куркам... Кайда барыйм? Мине коткарыгыз! — дигән сүзләрне әйтеп, янында торган мендәргә ауды, ауды да кулларын селкеп, аякларын кузгатып, мәгънәсе безгә беленмәгән рәвештәге тавышлар чыгара башлады.

---

[1] *Уңалу* — сәламәтләнү.

Әти шунда ук урыныннан торып, зур куркынычка барган кеше кыяфәтендә Фәхри бабайның алдына төште һәм:

— Абзый, нишлисең син? Балаңны һәлак итәсең бит!..— дигән сүзләрне әйтте.

Хәмидә әби, нәрсә әйтергә белми аптырап торганнан соң:

— Сиңа әйтәм, эткәсе, үз балабызны һәлак итмик...— дип, тагы еларга тотынды.

Фәхри бабай, Галимә апаның нәкъ өстенә карап:

— Минем ишегалдына аяк басасы, минем күземә күренәсе булма! — дип әйтте дә ишекне шап иттереп ябып чыгып китте.

IX

Галимә апа төн буе тыныч йоклый алмады. Ул берничә рәт саташып, урыныннан ыргып торып, кайдадыр чыгып китәргә теләгән кебек тартына башлады.

Безнең өй эче таң алдыннан гына тынычланды.

Бүген иртән торгач та, әти миңа карап:

— Гали, мәдрәсәгә бар инде, кичә, өченчекөн дә сабагың калды бит,— дип, мәдрәсәгә барырга кушты.

Хәзер мин, ул мәдрәсәгә барырга, анда керергә, андагы кешеләрне күрергә җаным-тәнем белән каршы булуга карамастан, әти белән әнигә тагын да күңелсезлек арттырмас өчен барырга булдым.

Мин өйгә кайтып кергәндә, безнең өйдә түбән очның Гыйльми әби белән әни Галимә апаның янында утыралар. Галимә апа Гыйльми карчыкка куркыныч бернәрсәгә караган кебек карый иде.

Гыйльми карчык, авыруны дарулау, аның сырхавына шифа бирерлек киңәшләр бирү кебек иң «ашыгыч чаралар» сөйләп бетергәннән соң, шул ук авыру алдында, өч көннән бирле, аның хакында авыл арасында йөргән сүзләрне тезә башлады. Галимә апа өчен ишетүе бик күңелсез һәм авыр булган бу сүзләрнең аның алдында кабатлануы, йөрәгенә бик начар тәэсир итүе билгеле булуга карамастан, сүзләрне сузганнан-сузды. Әни дә аңа кушылып, кушылмаган урыннарында бик ихлас тыңлап, бу хакта сүзнең озаюына сәбәп булды.

Боларның сүзләрен ишетеп торган Галимә апа, ни эшләргә белмәгән кебек, башын бер түбән төшерә, бер боларга карап ала, бер йөзен чыта, бер читкә карап, ике күзен бер ноктага текәп тора иде. Болар Галимә апаның өстенә кайгы чүпләрен өя генә бирәләр, аны үзе ерып чыга алмаслык сазга батыралар

иде. Галимә апа, нәкъ үрмәкүч авына чорналган чебен кебек кысылып, бераз торды да, капыл гына урыныннан торып, ишеккә таба бара башлады. Әни, тиз генә урыныннан торып, аны барып тотты да:

— Галимә, кайда барасың? — дип сораганын сизми дә калды. Галимә апа, әнигә дә, башкаларга да күзләрен тутырып караганнан соң:

— Мин китәм, китәм дигәч китәм!..— дип тартына башлады.

Бу эштән Хәмидә әби дә аптыраашта калды һәм елау катыш тавыш белән:

— Балам харап булды! Балам, китмә...— дигән сүзләр белән кулыннан тотып, сәкегә таба тарта башлады. Әти йөгереп өйгә керде.

Галимә апа һаман тартыша һәм:

— Мин китәм!.. Мин тормыйм!.. Нигә мине җибәрмисез?..— дигән сүзләрне әйтә, тизрәк боларның кулларыннан ычкынырга тырыша иде.

Әти керү белән:

— Балам, кайда барасың? Тышка чыгасың киләме? Әйдә, утыр әле,— дигән сүзләр белән иплән кенә кулыннан тотты, шуннан соң гына Галимә апа, бераз басылган кебек, болар алдында буйсынганлык күрсәтте.

Төнен Галимә апаның йокы тынычсызлыгы үткән төнгә караганда да артык булды. Ул мин күргәндә генә берничә мәртәбә саташып, әллә нинди бер-берсенә бәйләнешсез сүзләр әйтеп, берничә рәт торып утырды.

XI

Соңгы ике көн эчендә Галимә апа, уяу вакытында, җиңеләеп китте. Шуның өчен әни дә, әти дә аның бу җиңеләюенә куркып карый башладылар. Әти берничә рәт Фәхри бабайларга кереп чыкты. Бүген Фәхри бабай ачулы түгел, бәлки, бик басынкы, юаш булып күренде. Галимә апага карап торды да тирән сулады, соңра, аннан күзен алып, бик көчәнеп кенә:

— Балам, үзем әйтәм, кайт, балам... Син минем балам, хәзер мин сиңа ачуланмыйм, ялгыш кына ачуланганмын, әйдә, балам, әйдә! — дигән сүзләрне чак-чак әйтте дә үзе, икенче якка карап, күзләрендәге яшен сөртте. Галимә апа аның бу сүзләрен сабыйларча тыңлады, ләкин үзе, никтер, бер сүз дә әйтми елмаеп, тик торды.

Хәмидә әби белән әни, икәүләп:

— Әйдә, Галимә, тор, үзебезгә кайтыйк, анда барысы да бар, башка кешеләр юк, әйдә,— диделәр.

Галимә апа торды һәм, боларга карап:

— Әйдә, әйдә! — дип, шәлен алды һәм әни белән Хәмидә әби арасында ишеккә таба китте. Фәхри бабай, алдына карап:

— Әй бала, әй бала!..— диде дә башка бер сүз дә әйтә алмады. Алар шулай әкрен генә чыгып киттеләр. Алардан соң безнең өй эчен авыр тынлык басты. Яңа гына мәет чыккан өйгә охшап, бер яктан, бушлык сизелде, бер яктан, авыр кайгы эчендә калдык.

XII

Өч-дүрт көн үткәчтен, безгә килүчеләр була башлады. Бу керүчеләр, безнең өй эчендәге кайгы-хәсрәтләрне чын күңелләре белән уртаклашудан бигрәк, «мондый авыр хәсрәт эчендә ничек торалар икән?.. «Кара йөз»ле Галимәләре ничек адәм күзенә күренә икән?..» дигән сымак, эчке бер сер белән керәләр, шуның өстенә авыл арасындагы төрле гайбәтләрне безнең өйгә китереп түгәләр иде.

Шушы килүчеләр аркылы без Закирның һәм аның ата-аналарының ни рәвештә торганнарын белеп алдык.

Закир үзе урамда йөртелгән көнне өйләренә кайтып кунган да, иртән кешеләр тормас борын ук, кайдадыр чыгып киткән. Аның чыгып китүе хакында төрлечә сөйлиләр.

Кайберәүләр:

— Закир теге көнне бик нык кыйналып имгәнгән, башындагы яраларны төзәттерү өчен, калага докторга киткән, ул тиз генә төзәлерлек түгел икән,— дип әйтсәләр, кайсыбер кешеләр тагын да арттырып җибәрәләр:

— Юк, бер дә алай түгел, ул үзләрен тотып кыйнаган кешеләр өстеннән дә, йөзләренә каралар ягып йөрттергән кешеләр өстеннән дә судка бирергә киткән, имеш! — дип сөйлиләр.

Шулай итеп, безнең өй эчендә һәр көн Галимә апа белән Закир турысында әллә ничаклы сүзләр сөйләнә. Ләкин бу сүзләрнең хәзер Галимә апа өчен һич файдасы юк икәнен һичбер исләренә дә китермиләр иде.

Галимә апаның авыруы болай гына бетмәгәнгә күрә, аны төрлечә им-том иттерә башладылар. Ләкин «дару»ларның,

им-томнарның һичбер файдасы тими, ул һаман безнең өйдә торгандагы кебек иләс-миләс тора. Куркынып, сискәнеп китә, йә булмаса, шатлык күрсәтеп, әллә нәрсә сөйләп ташлый, күп вакытта бер урынга карап, бик тирән уйга бата иде. Шуннан без аның эше һаман артка киткәнен белеп тора идек.

Хәзер Галимә апа чит кешеләргә түгел, безнең үзебезгә дә вакытлыча гына авырган кеше түгел, бәлки, чынлап та, «җенләнгән» яки «җенләнә» башлаган сымак, куркынычрак күренә башлады. Хәзер ул читтән карауга, атасы, анасы, туганнары булган өстеннән дә ятимдер, ялгыздыр, аның бер дә күңел ача торган кешесе юктыр кебек күренә иде.

XVII

Закир китеп, югалып, бер айлар чамасы үткәч кенә аның кайту хәбәрен ишеттек: ул кайткан иде.

Мин аны беренче тапкыр күрүемдә аптырап киттем: хәзер аның ике бите борынгы кебек кызарып янып тормыйлар. Күзләре эчкә бата төшкән, үзе арыкланып киткән. Сул як күзе өстендә ат типкән кебек бер эз калган. Уң як күзе кысылыбрап калган кебек тора. Гәүдәсе дә борынгы кебек бик үк туры түгел, бәлки эче яки биле авырткан кеше кебек, алга таба иеленкерәп йөри.

Соңгы вакытларда Закирның анасы да безгә бик еш килеп, кайгы-хәсрәтләрен уртаклашып китә торган булды.

Әнинең:

— Закир бик исән кайтканмы? — дип соравына каршы, көрсенеп кенә:

— Болай исән кайткан да кайтуын... Әллә нишләп бик ябыгып, бетеренеп кайткан, докторлар эшләми өйдә генә торырга кушканнар, «авыруың эчкә төшкән», диләр икән.

XVIII—XIX

Кыш көннәре үтеп, яз җитте.

Галимә апа хәзер һәр көн дип әйтерлек үзебезнең койрыктагы елга буена төшә, шунда бик озак утыра, күп вакытта өйгә кайтуын да исеннән чыгарып, Хәмидә әби яки әни барып алып кайтмаса, үзе белеп кайтмый да торган булып китте. Башта әниләр аның ялгыз калып, суга-мазарга төшүеннән куркып, һәрвакыт карап торсалар да, бара торгач, күзәтеп торуны да сирәкләттек, тик искә төшкәндә генә барып карый торган булып киттек.

Аның шулай ялгыз утырганын, курчак уйнаган кебек үләннәр, чыбыклар белән уйнаганын, кайчакта ияген кулына куеп, моңланып җырлаганын очрата торган идем.

Беркөн шулай иртән торгач, Хәмидә әби миңа:

— Бар әле, балам, Галимә апаңны карап кайта күрсәнә...— дигәч, аның артыннан киттем.

Мин эзләп барганда, Галимә апа һичбер гамьсез кеше кебек, ярдан аякларын салындырып, суга карап утыра иде.

Казлар, үрдәкләр суда һаман йөзәләр, кагыналар, аларның бер төркеме суда йөрүдән туеп ярга чыгалар. Икенче төркемнәре ашыгып килеп шыпырдап суга төшәләр. Төшү белән су эчеп, чумып кагына башлыйлар.

Боларны карап торган саен карыйсы килә. Бу матурлыкны карап тора торгач, мин кайтуны да онытканмын. Күзләремне алмый, шуларга карап торам. Тик елга буйлап килгән бер кешенең аяк тавышын ишеткәч кенә, күзләремне елга өстеннән алып, теге кешегә карадым: бу килүче Закир иде.

Закир, безнең янга килеп җитеп, Галимә апаны күргәч, баскан урынында катып калды. Галимә апа, аны күргәч, төсен бөтенләй үзгәртте, калтыранып, куркып киткән кебек булды.

Закир, агарынып, һичбер сүзсез бераз торганнан соң, Галимә апаның каршына килеп басып, калтыранган бер тавыш белән:

— Галимә!.. Бу синме, Галимә?..— дип, ике генә сүз әйтеп, җавап көткән кебек карап, тик торды.

Галимә апа Закирның соравын ишеткәч, башта күзләре мөлдерәп, кызганыч булып китте, шуннан тиз генә төсе үзгәреп, елмаеп куйды да, бик җиңеләеп:

— Әй Закир, син кайттыңмыни? Сине көтә-көтә аптырап беттем... Менә бу казларның бер оясы безнең казлар бит... Каз өмәсе ясарбыз. Юк, юк! Син кит, безне күрсәләр харап итәрләр,— дип, тирә-ягына карана башлады, тагын да сүзен үзгәртеп,— утыр әле, утыр!.. Алар килмәсләр. Казлар карарбыз... Бәй, синең йөзеңдә кара беткән икән!..— дип гаҗәпләнү белдерде.

Закир, аптыраганлыктан нәрсә әйтергә белми, бераз торганнан соң гына, Галимә апага нәрсәдер аңлатырга теләгән кебек булып:

— Менә син терелерсең дә шуннан соң бергә торырбыз, бик күңелле булыр. Менә шунда без дә, шушы казлар кебек

казлар, шундагы үрдәкләр кебек матур бәбкәле үрдәкләр асрарбыз,— дип, күңел юата торган сүзләр тезеп китте. Ләкин Галимә апа аның сүзләре беткәнне көтеп тормый:

— Нигә, син мине ташлап китәсеңмени?.. Әни шулай, «терел-терел, туй булыр», ди. Әйтерсең мин авырыйм, ди,— тагын төсен үзгәртеп,— мине тиле диләр шул...— дип, тирән уйга баткан кебек алдына карап алды да:

Ак киндерләр суккан чакта,
Тала минем беләгем.
Учактагы утлар кебек
Яна минем йөрәгем...—

дип көйләп җырларга керешә.

Галимәнең җырын ишеткәч, Закирның күзләрендә яшь бөртекләре күренделәр.

Без шулай бик күңелсез хәлдә торганда, безнең утырган җиргә таба Хәмидә әби килә иде.

Хәмидә әби ничек тә тизрәк алып кайту, бу авыр күренешне күрәсе килмәү уе белән:

— Әйдә, балам, кайтыйк инде... Өйдә этиең чәйгә көтә торгандыр...— дигән сүзләрне кабатлады.

— Әйдә, алай булса,— дип, Галимә апа тиз генә урыныннан торды да, алга атлый башлап, Закирга карап:

— Син кал... Бездә Закир бар... Ул мине көтәдер... Ул һәркөн безгә килә... Миннән башка беркемгә дә күренми, ул сине күрсә ачуланыр...— дип, ашыгыч рәвештә алга китте...

Закир ни эшләргә белми, баскан урынында шаккатып безгә карап калды.

XXI

Печән җыйган, кибән куйган чакларда, урак урган вакытларда, Галимә апаның юклыгы, ул булган еллардагы эшләрнең күңелле булуы хакында сүз чыкмый калмый иде.

Күп вакытта әни:

— Галимә булганда, бу печәннәрнең җыелулары да, кибәнгә куюлары да беленми дә кала иде...— дип сүз башлый. Фәхри бабай белән этинең берәрсе:

— Язмыш шулайдыр инде... Аларны уйласаң, йөрәкләр әллә нишләп китә! Һәлак иттеләр мескен баланы! — диләр дә, сүзләрен артык алып бара алмый, тирән уйга батып, эшләрен уй катыш дәвам иттерәләр.

XXII

Күз җитте. Басуда игеннәр урылып, күптән ындырларга ташылып бетте. Әти минем үз ихтыярыма куйган кебек:

— Йә балам, укыр вакыт җитте бит, син нишлисең? — дигән сөальне бирде. Мин бер дә уйлап тормый:

— Юк, мин үзебезнең авыл мәдрәсәсенә бармыйм! — дип кенә куйдым. Әти, бераз уйлап торганнан соң:

— Ярый. Бу ел шәһәр мәктәбенә барырсың. Анда бөтенләй башкача икән. Көч җитәр әле,— дип, мине бу елдан башлап шәһәр мәктәбенә җибәреп укыттырырга теләвен белдерде.

XXIII

Хәзерлек бетеп, китәр көннең таңы туды. Минем шатлык артканнан-артты. Ат җигелеп беткәннән соң, безне озатып калыр өчен, Фәхри бабай белән Хәмидә әби, алар артыннан Галимә апа безгә керде. Фәхри бабай:

— Укысын инде. Менә без укымау аркасында харап булдык. Үзебез генә түгел, башкаларның да харап булуына сәбәп булабыз. Наданлык белән эшләгән эшкә соңыннан үкенәсең дә, эш үткән була,— дип, Галимә апага карап алды да башын түбән төшерде.

Дога кылынып беткәч, һәммәсе белән дә күрешеп чыктым. Галимә апа янына барып:

— Исән бул инде, Галимә апа,— дип, кулны суздым. Ул, миңа кулын бирер-бирмәс торгач:

— Күреш, балам, күреш, ул шәһәргә китә,— диделәр. Шуннан соң гына ул минем белән күреште дә, һичбер әсәрләнми:

— Кайчан кайтасың, ә? Миңа сабын алып кайт! Әти, мин дә калага барам ла... Анда кызык булыр,— дип, өйдән чыга башлады.

Без арбага утырып чыгып киткәндә, ул бер генә чиләк тотып суга таба бара, үзе безгә карый да әллә нәрсәләр әйтә иде. Арба тавышы белән мин аның соңгы сүзләрен ишетә алмадым.

XXIV

Авылдан килгән беренче хат мине чиксез шатландырды. Хатта үзебезнең кешеләрдән атап-атап сәламнәр язылган иде. Галимә ападан да сәлам әйткәннәр.

Икенче хат килде. Бу хатны үзебезнең күрше китергән иде. Хат китерүчегә беренче сүзем:

— Безнекеләр исәннәрме? — дип сорау булды. Ул аны-моны уйлап та тормый:

— Башкалар исәннәр дә, Галимә апаң гына дөнья куйды,— дигән сүзне әйтте.— Бәкегә төшкән, мескенкәй, ике көннән соң гына табып алдылар.

— Мескен апам әрәм булды!..

1926 ел

Бирем

Повестьның фокусын табып, әсәргә анализ ясагыз.

Иҗади эшләр

1. Язучы болытларга карый да: «Көне буе сыкрады сыкрады да түзмәде, кичен елап җибәрде»,— ди.

2. Күз яшеннән аерылды. Яше аерылдым дип елады.

Бирем

Югарыда бирелгән ике өзекнең эчтәлеген үзегез аңлаганча дәфтәрләрегезгә язык. Аларда авторның ничек катнашуын әйтегез.

3. Күз үзеннән-үзе йомыла башласа: «Йокы килә»,— дибез. Берәү: «Йокы басты»,— ди. Шагыйрь болай дию белән генә дә канәгатьләнми: «Йокы миңа канаты белән кагылып китте»,— ди.

Бирем

Өч әйтелмәнең уртак сыйфатлары бар: өчесендә дә йокыга кеше сыйфатлары бирелгән. Аермаларын табыгыз.

4. Дуслыкта син сабыр булсаң, һичшиксез,
Тамчыдай дуслык та булыр нәкъ диңгез.

Мөхәммәдьяр

КҮЗ КҮРЕР ӘЛЕ

Карчыгы картына:
— Күзең бөтенләй күрми башлагач нишләрбез?
Карты:
— Сукырайгач күз күрер әле.

Бирем

Карт ялгышамы?

Дөньяның малы кими торткан саен,
Өстәлә белем — сарыф иткән саен.

Утыз Имәни

Бирем

4 нче бүлек текстларының мәгънәсен языгыз.

5. Таз малай капчыктагы сохариларны бушата да капчык эченә үзе кереп утыра. Капчыкны тыгыз итеп бәйләп куя.

Бирем

Вакыйгадагы хатаны табыгыз.

6. Трамвайда бер кыз кесә телефонын югалта. «Син урладың! Бир!» — дип, артында утыручы егетне гаепли. Тегесе баш тарта. «Алмадым, менә кара!» — дип кесәләрен капшап күрсәтә.

Пассажирлар кызга ярдәм итмәкче булалар. Трамвайны туктатып: «Милиция чакырырга кирәк»,— диләр. Кайберәүләр кыз каныккан егетне яклыйлар: «Тотылмаган карак карак түгел әле ул»,— диләр.

Шул арада артта утырган укучы бала кызга бик матур киңәш бирә. Аның киңәше белән кесә телефоны шунда ук табыла.

Бирем

Малай кызга нинди киңәш бирә?

7. — Әни, монда нindидер «гомуми»не өлешләргә таркатырга кушкан. Нәрсә ул «гомуми»? Аның өлешләре нинди була? — дип сораган дәрес әзерләп утыручы кызы.

— Самовар куйдым. Самовар куйганда мин ниләр эшләдем? Әйтә алсаң, «гомуми»не өлешләренә таркаткан буласың,— дигән әнисе.

Биремнәр

1. Ана әйткән мисалда бөтенне һәм аның өлешләрен табыгыз.
2. Гамәлне атап әйткән җөмләне гамәлләргә (өлешләргә) таркатыгыз.

Су салды, чыра телде һ. б.

Күрәсез, язучы җансыз әйберләрне дә, күренешләрне дә җанландыра. Аларны кеше итеп сөйләштерә, көлдерә, елата, утырта, яткыра, кош итә дә канат кактыра...

Тынлыкны җанлы бернәрсә итеп күз алдына китерегез. Тынлык белән бәйле вакыйга уйлап табыгыз.

Фатих Кәрим
(1909—1945)

«Фатих Кәрим һәрвакыт иптәшләре белән исәпләшеп яшәде. Иптәшләрен, оешмасын, халкын һәрвакыт үзеннән өстен куйды. Һәм шушы сыйфаты аны алдынгы кеше итте»,— дип язган күренекле татар язучысы Мирсәй Әмир дусты Фатих Кәрим турында.

Шагыйрьнең башка уңай сыйфатлары арасыннан Мирсәй Әмир үзе иң әһәмиятле дип исәпләгәнен тотып алган: кешеләрне үзеннән күбрәк хөрмәт итү кешене алдынгы итә дигән.

Фатих Кәрим Башкортстан Республикасы Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә туган. Сигез яшьтән этисез калган. Үз авылында мәдрәсәдә укыган. Казанга килеп җир төзү техникумын тәмамлаган. Шуннан соң ул гомере буена үзлегеннән белем алган.

Тырыш, һәрвакыт шат, ягымлы, башкаларны үзеннән ныграк ярата белә торган кеше икейөзле, хәйләкәр була алмый. Фатих Кәрим большевиклар вәгъдә иткән матур, якты, бәхетле тормышка чын күңелдән ышана. Яңа кеше Ватанын үлеп яратырга, матур киләчәкне аз гына булса да якынайта торган эш бәрабәренә җанын да кызганмаска тиеш, дип уйлый. Ул кешеләрдә дә шул сыйфатларны күрергә тырыша. Шул хакта шигырьләр, поэмалар яза. Бик күпләр кебек шагыйрь тормыш авырлыкларының төп сәбәпчесе кулаклар, корткычлар — сыйнфый дошманнар булуына ышана. Үзенең әсәрләрендә уйдырма дошманнарга каршы аяусыз рәвештә көрәшә. Ә көннәрнең берендә аның үзен дә дошман итәләр: комсомолга кергәндә этисенең мулла булуын яшерүдә гаепліләр.

Шагыйрь төрмәдә чакта Бөек Ватан сугышы башлана. Ул, фронтка җибәрүләрен сорап, гариза артыннан гариза яза. Бәхеткә каршы, аның үтенечен канәгатьләндерәләр. Ул сугышны, гади солдат булып, башыннан ахырына кадәр алгы сызыкта үтә. Ике мәртәбә каты яралана. Ләкин госпитальдән кабат үз полкына әйләнеп кайта. Ниһаять, аны гаепсез дип акласалар да, дүрт елдан соң гына взвод командиры итеп билгеләмиләр.

Өзлексез чигенүләр, атакалар арасында шагыйрь иҗат эшен дәвам итә. Бик азга гына сулыш алырга туктаганда да ул шигырьләр, поэмалар, хәтта повестьлар һәм пьесалар яза. Аның иң яхшы әсәрләре шул елларда, сугыш тынган арада, ял, йокы исәбенә язылган.

1945 елның 19 нчы февралендә шагыйрь батырларча һәлак була.

Мирсәй Әмир, «Үзебез турында» китабында Фатих Кәрим иҗатына бәя биреп, болай язды:

«Фатих Кәрим шундый кыска гомер эчендә гаять зур эшчәнлек күрсәтте. Поэзия өлкәсендә үзенең исемен мәңгеләштерерлек гүзәл шигырьләр иҗат итү белән бергә, талантлы журналист буларак та күп эшләр башкарырга өлгерде. Әдәби очерклар, публицистик мәкаләләр, фельетоннар, балалар өчен фәнни-популяр әсәрләр дә язды ул. Күп кенә әдәби китапларның редакторы да булды».

Мирсәй Әмир Фатих Кәрим иҗатының үзенчәлеге турында да яза:

«Фатих Кәрим иҗатына, гомумән, хас булган көчле оптимизм, һәрвакыт биеккә, югарыга омтылу, җиңүгә ышану, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «Башлангыч җыр»ларында ук бик ачык күренә иде инде».

СИБӘЛИ ДӘ СИБӘЛИ

Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми.
Уема да кертмәдем мин
Аның бу төн үләсен,
Разведкадан кайткан чакта
Тиде немец пулясы.

Өс-баш юеш. Көрәкләргә
Үзле балчык сылаша;
Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.
Кайгыдан каралып торган
Япь-яшь нарат төбенә
Япь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.

Япь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми;
Күзге төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

1942 ел

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз. Сугышчылар ни өчен дәшмиләр, иптәшләрен күмәләр бит? Шул хәлне аңлата алсагыз, эчтәлекне тапкан буласыз.

АК КҮБӘЛӘК

Урман арасында чәчәкле юл,
Барам карап тирә-ягыма;
Каеннарның яшел яфраклары
Шыбырдашып канат кагына.

Чәчәкләргә карыйм — куаналар,
Баш ияләр миңа — елмаям;
Тик күңелгә нидер җитми кебек,
Эчтән генә сызып моңаям.

Моңаям мин, бер көч, бер мәхәббәт
Хыялыма кереп бәйләнә;
Чия чәчәгедәй ак күбәләк
Баш очымда очып әйләнә.

Дөрес микән, дуслар, халык сүзе:
Урманнарда йөргән чагында,
Ак күбәләк калмый, бертуктаусыз
Әйләнгәләп очса янында —

Күнли-күнли янып сөйгәнеңнән
Хат килә, ди. Көтәм... Ерактан,
Мәхәббәтне канатлары итеп,
Коштай очып килгән бу хатта

Булсын иде серле коңгырт күзен
Миңа текәп төшкән бер рәсем...
Ак күбәләк, әйлән баш өстемдә,
Йөрәгемдә сагыш дөрләсен!

1943 ел

Шигырьнең баштагы өч строфасы лирик геройның хисе турында. Лирик герой урман матурлыгын күреп хәсрәтләнә. Хәсрәтенең сәбәбе мәхәббәт булуын белдерә. Ләкин кемне яратуы турында әйтми.

Бирем

2, 3 нче строфаларда лирик герой хисенең дәрәҗәсен таптык. Соңгы ике строфада лирик герой хисенең сәбәбе ничек ачыклануын һәм ничек юануын аңлатыгыз.

КАЛА ЯШЬЛЕК

Карап торам: шаулап бозлар ага,
Ярга сыймый Идел ташкыны;
Язгы хисләр кайный һәм күңелдә
Идел ташкынындай ашкыну.
Ташкыннарга карап уйланам,
Яшьлегемне сагынып моңланам:
— Тик хатирә булып кала яшьлек,
Үтә гомер, чәчләр агара,
Ә күңелдә яшәү омтылышы
Чәч агарган саен яңара.

1943 ел

Биремнәр

1. Шигырьгә анализ алымнарын язып, план төзегез.

2. Планыгызга карап анализ ясагыз.

3. «Ак күбәләк»һәм «Кала яшьлек» шигыренең темалары охшаш булуын исбат итегез.

ГАЗИЗ ӘНКӘЙ

Сабый чагым иде, әнкәй беркөн
Миңа юган күлмәк кигезде;
Кочаклады мине, калтыранып,
Маңгаема иренен тигезде.

Газиз әнкәй, хәзер исән булсаң,
Күз өстенә салып кулыңны,
Кайгы белән шатлык уртасында
Күтәр идең сагынып улыңны.

Миңа озын гомер тели-тели,
Кем булды, дип улым-алтыным,
Өйдән өйгә йөреп укыр идең
Окопларда язган хатымны.

Кайнар яше тамды маңгаема
(Искә алган саен кызганам!),
Яшен йотып, пышылдады мәрхүм:
— Кем булырсың икән син, балам?

Халкым өчен хаклык даулаганда,
Үч алганда, дошман үтерсә:
«Батырларча үлде сөйгән улың!» —
Язмыш шундый хәбәр китерсә,

Еллар буе әрнеп елар идең,
Кайгы дөрләр иде башыңда;
Вөҗданың саф булыр иде ләкин
Табигать һәм халык каршында.

1943 ел

Биремнәр

1. Кайгы белән шатлык уртасында
Көтәр идең сагынып улыңны,—
юлларындагы ана хисенең каршылыгын аңлатыгыз. Ана нигә шатлана? Нигә кайгыра?

2. Шигырь ана хисе турында. Ләкин эчтәлек башка. Эчтәлекне табыгыз.

Нәтиҗә

Фатих Кәрим сугышка кадәр дә, сугыш елларында да бик күп әсәрләр язган. Сез әдипнең сугыш елларында иҗат иткән шигырьләренең берничәсе белән генә таныштыгыз. Өч-дүрт әсәрен генә өйрәнеп, язучы иҗатын берьяклы итеп кенә күз алдына китерә алабыз. Әмма без бит әле язучы иҗатына бәя бирү юлларын да өйрәнәбез. Шуңа күрә тулылыкка дәгъва кылмыйча, эшне дәвам итик.

Язучы иҗатын өйрәнү — беренче чиратта андагы үзенчәлекне табу дигән сүз. Ә әдип иҗатының үзенчәлеген белү өчен, ул иҗат иткән әсәрләрнең уртак сыйфатларын табарга кирәк.

Өйрәнгән әсәрләрнең күбесе сугыш темасына багышлануын күрдек. Бу тема шагыйрь әсәрләрендә Ватанга мәхәббәт һәм өйдәгеләрне сагыну булып ачылды.

Фатих Кәримнең лирик геройлары Ватанга мәхәббәтләрен Ватан өчен сугыш кырында үлүләре белән раслыйлар.

«Газиз әнкәй» шигырендә сугыш кырында батырларча үлү — ана өчен горурлык һәм юаныч.

«Аның җыры» шигырендә кыз сугышка киткән егетен сагына. Ул да, егет үлә калса, аның батырларча үлүен теләп юана.

Сөйгәнемнән мине, яшь килеш,
Аерса да... үлем аерсын.
Данлы булсын ләкин бу үлем
Ватан өчен сугыш кырында.

«Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасының да төп темасы — сугыш кырында батырларча үлү белән горурлану. Егет яраткан кызына атап болай җырлый:

Мин үлсәм, башка берәүне
Миңа тиң итеп яратып,
Салырсың йөрәгеңә.
Сайлаганың минем кебек
Иркәли, сөя белсен;
Кирәк чакта Ватан өчен,
Аямыйча яшьлек көчен,
Көрәшә, үлә белсен.

Берничә шигырендә Ватан өчен үлүен лирик герой үзе дә бәхет саный.

Мәсәлән, «Ватаным өчен» шигырендә лирик герой Ватан өчен үлүен бөек җырга тиңли.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе,—

дип тәмамлый.

«Алга бара идек» шигырендә авыр яраланган лирик герой соңгы тамчы канын, соңгы сулышын Ватанның «изге сугышы»на бирергә ант итә. Җиргә тамган һәр тамчы каны илдә үсәчәк бәхет гөле булачагына ышана.

Ватан өчен сугышта үлем күп була. Икенче бөтендөнья сугышында ул аеруча күп булды. Алар да җиңүгә зур өлеш керттеләр. Бу елларда сугыш кырында үлүчеләрне батырлар

дәрәҗәсенә менгереп мактау һәм андый үлемне Ватанга мәхәббәт белән тиңләштергән шигырьләр күп язылды. Әлбәттә, алар, мәрхүмнәрне кызганып һәм аларның җиңүгә керткән өлешләрен күрсәтү өчен, ихлас күңелдән язылган шигырьләр.

Фатих Кәримнең яшьлеген, хатынын һәм баласын, туган-үскән җирен сагынуын, бер сүз белән «өен сагына» дип кыскартыйк. Сугышчының өен сагынуы да — Ватан сугышы темасы.

Шагыйрь бу ике эчтәлекле мәхәббәтнең (Ватанга һәм туганнарга мәхәббәтнең) үзара мөнәсәбәте турында күп уйланган булырга тиеш. Күп очракта ул бу хисләрне әле бер-берсенә каршы куйган да өстенлекне илгә мәхәббәт хисенә биргән, әле икесен бергә килештерергә тырышкан. Әлеге шигырьләрендә әдип аеруча зур камиллеккә ирешә. «Сибәли дә сибәли», «Кемгә сөйлим серләремне», «Ак күбәләк», «Кала яшьлек» шигырьләре, мәсәлән, татар әдәбиятының бу елларда язылган иң күркәм әсәрләреннән санала.

Язучы иҗатына бәя биргәндә, әсәрләрдә кабатланган сәнгать алымнарына (стильгә) игътибар итәләр. Фатих Кәрим үзенең хисләрен метафоралар ярдәмендә сурәтләргә ярата. Ә метафора итеп табигать күренешләрен ала.

Кәрим Тинчурин
(1887—1938)

Кәрим Тинчурин хәзерге Пенза өлкәсе Бедный Демьян районы Таракан авылында туа. Татар язучыларының күбесе кебек, мәдрәсә тәртипләре белән риза булмый, укудан куыла. Яшьтән үк үз тамагын үзе туйдырырга тиеш була. Төрле эшләр башкара, үзлегеннән белем ала.

Кәрим Тинчурин менә дигән артист — бу эшен гомеренең соңгы көненә кадәр ташламый. Бик оста режиссер — революциягә кадәр иң танылган «Сәйяр» труппасында режиссер булып эшли. Талантлы оештыручы — безнең бүгенге Татар дәүләт академия театрын да ул ача. Театрның режиссеры, артисты, драматургы булып эшли.

Кәрим Тинчурин беренче чиратта драматург булып танылa. Хәзер дә аның «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», «Американ», «Җилкәнсезләр» пьесаларын белмәгән яки карамаган татар кешесен табуы кыен. Сәхнәдә «Зәңгәр шәл» кебек күп мәртәбә уйналган бүтән бер пьеса да юк.

Кәрим Тинчурин — фәлсәфи фикерле, үткен сүзле кеше. Ул кешеләрнең һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән аның холкын абайлап алган. Кеше күз яшендә — аның шатлыгын, елмаюында хәсрәтен күрә белгән. Иң мөһиме, заманга хас типларның аңа кадәр берәүнең дә күзенә чалынмаганнарын күрә алган.

Кәрим Тинчуринны иске тормыштагы ямьсез күренешләрне бик оста фаш итүче дип бәяләргә гадәтләнгәнбез. Әмма әдипкә иске заманга әйләнеп кайту үзе яшәгән чорга бәя бирү өчен кирәк булган. Бу аның үзенә күрә бер алымы гына. Кайсы заман турында язса да, аны һәрвакыт безнең арада яши торган типлар кызыксындырган. Кешеләр холкын сүзләре,

хәрәкәтләре, гамәлләре аша күрсәтүдә аңа хәзер дә тиңнәр табылмый.

Кәрим Тинчурин күп әсәрләрендә милләтчеләрне фаш итә. Шомлы 1937 елда аның үзен дә милләтчелектә гаепләп кулга алалар һәм аталар.

Милләтнең күпме талантларын харап иткән бу еллар!

ЗӘҢГӘР ШӘЛ

(*Мелодрама*)

Биш пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Мәйсәрә — ятимә кыз.
Җиһанша — Мәйсәрәнең атасы белән бертуган.
Булат — Мәйсәрәнең сөйгәне, шахтер.
Заһирә — Булатның сеңлесе.
Мәйсәрәнең дус кызлары.
Авыл егетләре.
Ишан.
Хәдичә, Мәрфуга, Сабира, Фазыйлә — ишанның хатыннары.
Галәви — ишанның хезмәтчесе.
Малай.
Шәйхи бабай.
Пәтрәй.
Миңлегали.
Тимуш.
Хәйри.
Мишка.
Качкыннар.
Картлар.
Карчыклар.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урта тормышлы авыл йорты. Кое. Өйгә керә торган ишек. Капка. Эңгер-меңгер вакыт. Мәйсәрә ялгыз, коедан су ала. Артта хор белән «Газизәкәй балдыз» көенә җырлыйлар.

I. Мәйсәрә ялгыз.

Хор.
Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз,
Елама, калдырмам ялгыз.

Мәйсәрә.
Саф-саф кынай булып киек казлар
Үткән саен хәбәр көтәмен.
Киек казлар төсле очар идем,
Белсәм әгәр торган җирләрен.

Кызлар керәләр.

Кызлар. Кыраулар тигән, ай, ак гөлдәй
Ятимлектә сула яшь җаным...
Оясын җуйган, ай, аккоштай
Нигә, ахирәт, болай моңландың?

Хор. Тау астында салкын чишмә
Чылтыр-чылтыр агадыр.
Дөньясында ямь күрәлми,
Гомерең үтеп барадыр.

IV. Шулар ук һәм Заһирә.

Заһирә (*ашыгып, шатланып керә*). Мәйсәрә, ахирәт, сөенеч, сөенеч, сөенеч!
Дусларым, чит илләрдән абыем кайтты туйга дип.

Егетләр җырлап керәләр.

Егетләр. Сабан тургайлары сайрый
Мактап Сабантуйларын.
Сукага җиксәң ярарлык
Безнең авыл кызларын.

Булат «Шахта» көенә җырлап керә.

Хор. Булат, Булат кайткан,
Бүләк алып кайткан.
Сабан җилен каян,
Каян сизгән наян!

Булат. Дусларым, каңгырап кайттым,
Дусларым, ерак илләрдән.
Шахтерлар — батыр егетләр,
Дусларым, сәлам әйттеләр:
Матур кызларга, якын дусларга,
Син дә, кодача, өлешсез калма.
Анда юк урак, анда юк сабан,
Анда икмәкне алалар сатып.
Эшчеләр санын номерлар тагып,
Меңәрләп кенә саныйлар анда. Һай!..

Хор. Булат, Булат кайткан... (*Ахырына кадәр.*)

Әптери. Ну, Булат малай, егет икәнсең, йөрәктәгене әйттең дә салдың бит. Булмаса булган икән, киткәндә мине дә үзең белән алып кит, мин дә шахтер булам, малай. Синең шикелле писер булып кайтам да Заһирәне ябыштырып чыгарам.

Булат. Мин дә авылдан киткәндә шулай уйлаган идем дә, менә кайткач, муенга асылынмыйлар әле. Алып кайткан бүләкне кире алып китәргә туры килмәсен дип курка башладым...

Нурый. Хәбәрне салды бу.

Көлешәләр.

Нәсимә. Бүләге нәрсәдер бит әле. Мәйсәрә, әйеме?

Нурый. Тәтене бу яктан икән. (*Мәйсәрәгә күрсәтә.*)

Әптери. Тәтене генәме, Мәйсәрәнең битләрендә утлар күренә, яулыгына капмаса ярар иде.

Көлешәләр.

Нәсимә. Бүләкне аны муллага садака биргән төсле яшереп бирмиләр. Җырлап, биеп бирергә кирәк аны.

Булат. Алай барып чыкмас, кызлар! Минем бүләгем бер генә бит.

Мәйсәрә. Бүләге нәрсәдер бит әле. Шахтер бүләге әллә ни булмас, корымлы яулыктыр әле.

Нәсимә. Иске чабата төреп килгәндер әле.

Булат. Чабатамы?

Нәсимә. Чабата.

Булат. Чабатамы? Чабатаңны күрсәтим әле мин сиңа. (*Шәлне күрсәтә.*) Менә.

Барысы да. Шәл — зәңгәр шәл!..

Булат. Чабатамы, киермә борын!

Нәсимә. Кемгә бу шәл?

Булат (*шәлне җыеп*). Кемнең кулы җитсә, шуңа. Кем дә кем биеп, кулымдагы шәлне алса, шәл шуңа булыр.

Әптери. Ну, усал икәнсең, Булат малай, кызларны шүрләттең бит.

Нәсимә. Шүрләгән кеше юк әле монда. Биибезме, кызлар?

Кызлар. Биибез, биибез.

Балет.

Бию беткәндә Мәйсәрә шәлне урап ала.

Барысы да. Һап!..

VII. Шулар ук, Җиһанша.

Җиһанша (*керә*). Бу нинди эт көтүе! Югалыгыз хәзер, мәккә кяфирләре!

Барын да куып чыгара. Мәйсәрә белән Булат качып кала.

Ишан хәзрәтне каршы алу юк, чиркәү сакчылары, кяфирләр... Йортымда шайтан туе ясап яталар... (*Чыга.*)

Мәйсәрә. Харап булабыз, Булат җаным, җибәр.

Булат. Кайда күрешәбез?

Мәйсәрә. Кичкә кил, көтәрмен.

Качалар. Җиһанша керә.

Җиһанша (*тегеләрне күреп*). Сез монда ни эшлисез, мәккә дуңгызлары. Ә син, шахта шайтаны, кяфир, җаныңа сусаган булсаң, мордар!.. (*Күсәк күтәрә.*)

Булат. Җиһанша агай, синең белән исәнләшкән дә юк бит әле. Хаҗиларча бер исәнләшеп алыйк булмаса. (*Каршы бара.*)

Җиһанша (*куркып*). Ах, мәккә кяфире. Ишан хәзрәт, ишан хәзрәт. (*Кача.*) Караул, караул, караул!..

Булат чыгып китә.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урта тормышлы татар крестьяны йорты. Киртә койма, киртә капка, бер почмакта кое, өйгә керә торган ишек һәм каралтылар.

Карчыклар капкадан керә-керә җырлыйлар.

I. Карчыклар, картлар һәм Байгура.

Карчыклар. Ишан хәзрәт килгән, ди,
Фатихасын бирә, ди,
Сулышы шифалы, ди,
Сүзләре хикмәтле, ди.

Капкадан **картлар** керә.

Картлар. Ишан хәзрәт кая соң,
Аласы иде догасын.
Карабодай ярмасын
Аз-маз китергән идем...

Бергә. Ишаннарның эше рәт,
Эшләре тәрәт-мәрәт.
Дөньяда да рәхәт,
Ахирәттә дә җәннәт.

Картлар. Хатын дисәң, дистәләп,
Берсе берсеннән шәп,
Ул яклардан эш рәт
Шәригатьчә торалар.

Ишан керә.

Картлар. Әссәламегаләйкем. (*Кулын үбеп күрешәләр.*)

Ишан. Вәгаләйкемәссәлам. Болар сезнең садакаларммы? Бу печән кайсыгызныкы?

I карчык. Өшкереп кенә бирсәгез лә, ишаным.

Ишан. Соң ничек, ягъни мәсәлән, эш нидә?

I карчык. Сыерыбыз сөт бирми, ятим балалар ач торалар.

Ишан (*Җиһанша белән колактан колакка сөйләшә*). Алла сакласын, кем кортка, сыерыгызның хәле яман. Сезнең сыерыгыз хайваннарның кяфире икән. Аның сөтен төннәрен шайтаннар, йорт ияләре, шүрәлеләр вә һәм дә төрле-төрле гыйфрит һәм пәриләр савып эчәләр икән. Өшкерергә кирәк, өшкерергә. Хуш. Ә, ягъни мәсәлән, фараз кылдык, бозавы ни хәлдә, бозавы?

I карчык. Бозавы бик таза, бик көр, көтүдә бер бозау.

Ишан. Күрер күзгә генә бозау ул, асылда бозау түгел... шайтан, ягъни мәсәлән, пәри ул...

Барысы бергә. Пәри!.. Кара син Ходайның хикмәтен.

I к а р ч ы к. Булмас, ишанкаем, булмас, пәри булмас. Бозау төсле үк, синдәй-миндәй бозау ул, сикерә дә, акыра да.

И ш а н. Пәри ул, мотлак пәри... Бозау кыяфәтендәге кяфир пәрие асраган кеше оҗмах йөзе күрмәс, дигән китап. Хак мөслимә, мөэминәләргә мөселман бозаулар асрарга кирәк. Сарыкларның гына Алла иманнарын саклый күрсен, Алла сакласын, Алла сакласын...

I к а р ч ы к. Хәзрәткәем, зинһар, берәр чарасын күрегез, ул кяфир бозау бәласеннән безне коткарыгыз.

И ш а н. Әгәр дә тәүбә, иман, Коръән чыгу садакаларын бирә алсагыз, мин аны иманыгызның ныклыгын саклап калыр өчен эшләрмен. Аның садакасы дүрт аяклы мал булырга кирәк, дигән, дөя, үгез булса да ярый, филне дә дөрес күргәннәр. Кяфир җирендәге ярлы халык өчен ике яшьлек сарык яки утыз сигез кадактан ким булмаган бәрән дә дөрес, дигән кыйль бар.

I к а р ч ы к. Садакасыннан тормабыз, ишанкаем, бирербез. Хәзрәткәем, ул кяфир бозауны хәзердән үк сезнең кулыгызга тапшырсак, сез аны догалар белән богаулап куеп, ярканат булып әверелергә ирек бирмәс идегез.

И ш а н. Сез аны беренче әтәч кычкырганда менә шунда китереп бәйләп калдырыгыз, мин ул кяфирне, үз йортыма алып кайтып, бая әйткәнчә, иманга китерермен. Аллаһе әкбәр. Ярый, хәзергә өйләрегезгә китеп торыгыз, мин тәһарәт яңартып, намазларымны укып алыйм. Син, кем, Җиһанша, миңа су бирергә куш. Ерак булмаса, үзең шул кяфир бозауны барып кара, Алла сакласын, Алла сакласын.

Б а р ы с ы да чыгалар.

Җ и һ а н ш а. Баш өсте, хәзрәт, ерак түгел, күршедә генә (*ишектән кычкыра*). Ишан хәзрәткә тәһарәткә су чыгарыгыз. (*Капкадан чыга.*)

И ш а н. Бозавы яхшы булса, токымга калдырырбыз, симез булса, суеп ашарбыз, хи-хи-хи... Алла сакласын, Алла сакласын.

М ә й с ә р ә чыгып, комган һәм сөлге тотып, йөзен каплап басып тора.

IV. И ш а н һ ә м М ә й с ә р ә.

И ш а н. Әтиең бик әйбәт мужик иде, урыны оҗмахта булсын, амин, Аллаһе әкбәр... Йөзеңне ач, чибәр, ишаннар алдын-

да һәрнәрсәне ачарга китап рөхсәт итә. Менә шулай. (*Йөзен ача.*) А, а, а, бәрәкаллаһ, бәрәкаллаһ!.. Тәмам пешеп җиткән икәнсең. Хуш, йөзеңә караганда синдә күкрәк авыруы булырга охшый. Өшкерергә кирәк сине. Күкрәкләреңә җен оялаган, күрекле Мәйсәрә, аны туздырырга кирәк. Кая тагын карыйм әле... Ул кяфирне кысып чыгарырга кирәк аннан... (*Тотмакчы була.*)

Мәйсәрә. Кагылма миңа, хәзрәт, кагылма, дим...

Кача башлый, ишан куа. Мәйсәрә өйгә кереп китә. Җиһанша кайта.

V. Ишан һәм Җиһанша.

Җиһанша. Ишан хәзрәт, теге кяфир бозауны карадым, бик көр, бик симез, таза бозау. Ыруга калдырырга да ярарлык.

Ишан. Хода кулындагы эш, бәлки, ыруга да калдырырбыз.

Пауза.

Әле, Җиһанша, сиңа сөйләргә дә онытканмын икән, бая аштан соң яткач, гаҗәеп хикмәтле төш күрдем. Синең белән икәү йортта, менә шулай утырабыз, имеш, алдыбызда ап-ак бер күгәрчен җим җыеп гөлдерәп йөри, имеш... Шуннан соң әнә шул иннектән Хозыр галәйһиссәлам чыкты да, яшел таягын сиңа таба күтәреп, шуннан соң әлеге ак күгәрченне күрсәтеп, әнә шул күгәрченне ишан хәзрәткә, ягъни мәсәлән, мине күрсәтеп, шушы әүлия бәндәгә тотып һибә[1] итеп бир, диде. Шул арада Сөләйман пигамбәр, кереп, әлеге күгәрчен белән миңа никах укыды. Никах укылгач, Ходаның хикмәте, карасам, әлеге ак күгәрчен, синең тәрбияңдә үскән мәрхүм Мифтахетдин кызы Мәйсәрә булып чыкты.

Җиһанша. Бу төш — хәзрәт, чынлап та хикмәтле төш. Сез ни теләсәгез, шул булыр, китап кушса, үз хәләл хатынымны аерып, сезгә бирергә риза, калганын үзең кара инде, хәзрәт.

Чыгалар. Җиһанша капканы бикли. Китәләр.

VI. Булат һәм Мәйсәрә.

Мәйсәрә. Булат бәгырем, озакка кайттыңмы? Илдә кал. (*Елый.*)

---

[1] *Һибә* — бүләк.

Булат. Син елыйсың, бу ни хәл?

Мәйсәрә. Булат бәгырем, шулхәтле сагындым, шулхәтле сагындым. (*Сыена.*) Ике ел бит. Хатларыңны кат-кат укып, төннәр буе елап үткәрә идем. Заһирә синең кайтканыңны әйткәч, шашам дип торам. Булат бәгырем, безгә монда озак калырга ярамый, хәзер ястүдән кайтырлар. Булат бәгырем, бу йортта торырлык хәл калмады. Бер яктан, төрле начар сүзләр белән Җиһанша абый тирги, кыйный, икенче яктан, төннәрдә әллә нинди шикле кешеләр килеп, эчеп, сугышып бетәләр, төрлечә мине мыскыллыйлар.

Булат. Җиһанша абзаң әле һаман шул ат караклыгын ташлый алмыймыни? Аны әллә кайчан приговор җыеп, авылдан озатасы иде...

Мәйсәрә. Төрмәдә утырган чагында җаным бер тынычлап киткән иде. Менә шул ишанга кул биргәч, бигрәк тә явызланып китте.

Булат. Мин ул ат карагына күрмәгәнен күрсәтермен әле. Менә нәрсә, Мәйсәрә җаным, мин туй итәргә кайттым. Туйлар уздырырлык акчам бар, синең уең искечәме?..

Мәйсәрә. Мин әйтергә дә оялам инде, бүген алып китсәң дә риза...

Булат. Алайса, булды гына, берәр атнадан шаулатып туй ясыйбыз икән. Их, Мәйсәрә, ике ел буена йөрәктән китмәдең бит. Туйлык сума ясар өчен, ике ел буена ике сменада эшләдем. Күпме йөрдем, Мәйсәрә җаный, үзебезнең авылдан матур җирне, синнән матур кызны күрә алмадым. Их, мин әйтәм...

Мәйсәрә. Харап булдык, кайттылар!

Булат. Су буена төш, көтәрмен.

Мәйсәрә. Ярый, ярый. (*Йөгереп кереп китә.*)

Ишан, Җиһанша Булатны күреп калалар.

VIII. Ишан һәм Җиһанша.

Ишан. Бу ни хәл бу, Җиһанша, күгәрченнең карчыгасы бармы әллә?

Җиһанша. Кайгырма, хәзрәт, карчыгасы булса, аучысы да бар аның... (*Күсәк алып урамга чыга.*) Караул, карак, карак! Тотыгыз, тот! Караул!.. (*Куа китә.*)

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Агач келәт. Крестьяннар өчен кирәкле нәрсәләр. Бикәч урыны хәзерлиләр. Кызлар җырлашып чыбылдык тегәләр. Мәйсәрә бер читтә кайгылы утыра, шәле салынып төшкән, башы ялангач, Заһирә, бакчага карап, келәт бусагасында утыра, кызлар «Мәйсәрә» көенә җырлыйлар.

Заһирә. Мәйсәрә җаным, болай җебеп торуың бер дә килешми инде, сиздерерсең. Син булдыра алмасаң, үзем яңаклап чыгарырмын моннан, ишан дип тормам... Мин Мәйсәрә урынында булсам, өйрәтер идем ул сасы дуңгыз түшен.

Мәйсәрә (*кычкырып елап*). Түгел, түгел, ул минем киявем түгел. Дусларым, үтерегез мине, аның куенында булганчы, җаным тәнемнән чыксын... Коткарыгыз мине, коткарыгыз!

Тавыклар куып, Җиһанша керә.

II. Әүвәлгеләр һәм Җиһанша.

Җиһанша (*Заһирәгә барып*). Син явыз кяфир, нишләп монда кеше котыртып торасың!

Заһирә. Канатларыңны җәймә миңа, мин Мәйсәрә түгел... Мин кайтарып та бирә белермен.

Җиһанша. Йә, нәрсә каттың, чык, дип сиңа әйтәләр бит, чык!.. Әй, үз теләгең белән чыкмасаң, мин сине. (*Һөҗүм кыла.*)

Мәйсәрә. Абый, тимә аңа, ул миңа килгән, минем кунагым.

Җиһанша. Син шул хәерче Булатлар көненә калдыңмыни, себерке!.. Юк, тора тор. Ә син, чучка борын, хәзер моннан чыгып кит! Чык, дим мин сиңа, вон, чык! (*Бәрә.*)

Заһирә. Кагылма миңа, карак баш.

Җиһанша (*ябышып*). Ах, чучкадан туган үләт, кайчан тоттың! (*Кыйный.*) Нәрсәңне урладым, йә, нәрсәңне урладым?!

Кызлар чыркылдыйлар, Мәйсәрә аерырга маташа, Җиһанша Заһирәне кыйнап чыгара.

Ә сез ни дип котырган чучкалар төсле чиныйсыз, әллә сезгә дә кирәкме? (*Кызларга ташлана.*)

Кызлар чыгып качалар.

Әзегез булмасын монда, үләт калдыклары, кяфирләр!.. Син кая китәсең, кадал урыныңда! (*Этеп ега.*)

Мәйсәрә елый.

Нәрсәгә шыңшыйсың, эттән туган... Иртәгә никах, ә ул җыен эттән туган зимагурлар белән маташа. Кара аны, алай-болай качарга уйласаң, балта белән башыңа бер генә бирермен.

Мәйсәрә (*каты кычкырып, ташланып*). Үтер, үтер, хәзер үк үтер. Мин ишанга бармыйм, барыбер качармын, никахтан соң качармын... Анамны сугып үтердең, мине дә үтер.

Җиһанша (*котырынып, ташланып*). Чәнчел булмаса, бетерәм хәзер сине дә, бетерәм.

Еракта «Анда юк урак» көенә җыр ишетелә. Җиһанша Мәйсәрәне куып йөреп кыйный.

Мәйсәрә. Булат, Булат, коткарыгыз!.. Коткарыгыз!..

Җиһанша. Чукын булмаса! (*Балтаны атып бәрә, балта тими.*)

Җиһанша шәлне алып буарга хәзерләнә. Мәйсәрә кача. Җиһанша тотып буа башлый, озак көрәш.

Җиһанша. Ризамы?

Мәйсәрә. Юк, юк!..

Җиһанша ыржаеп буып, үлгән дип белеп, ташлап чыгып китә. Җыр һаман дәвам итә. Бераздан Мәйсәрә һушына килә башлый, торып ишеккә бара, артта Булат тавышы.

Булат керә.

III. Мәйсәрә һәм Булат.

Булат. Мәйсәрә, ни эшләдең син? Авызың-борының кан!

Мәйсәрә. Булат, Булат, коткар, коткар!.. Качыйк, качыйк... Кайтып килсә, икебезне дә харап итәр, качыйк...

Булат. Юк, тукта, Мәйсәрә, киткәндә ул ат карагы белән исәпне бетереп китәргә кирәк. Анда Заһирәне канга батырып эштән чыгарган, монда сине...

Мәйсәрә (*ялынып*). Булат бәгырем, мине дә, үзеңне дә харап итмә, әйдә качыйк, качыйк.

Булат. Барыбер ул эт моның җәзасын татыр, әйдә!

Чыга башлыйлар.

Җиһанша (*каршы очрап*). Ә, менә ничек икән, мин сине, егет, күптән көткән идем. (*Ишек ябып, балтасын күтәреп ташланырга тора.*)

Булат (*зур пычагын чыгарып*). Шулаймы?

Тавышсыз һөҗүм бара, әйләнеп йөриләр.

Мәйсәрә (*катып торып, тиз генә ишектән чыгып кычкыра*). Караул! Үтереш, караул! Ярдәм, ярдәм!..

Җиһанша балта белән чабам дигәндә, Булат пычагын Җиһаншаның йөрәгенә кадый.

Җиһанша. Караул!.. Кар... (*Егылып үлә.*)

Булат (*шашып Җиһаншага карый, артта тавышлар ишетелә, борылып*). Мәйсәрә!.. (*Карана да чыгып йөгерә.*)

Артта шау-шу. «Тот! Пычагын ал!..» дигән тавышлар ишетелә.

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кара урман эчендә яланда шалашлар, землянкалар. Төн уртасы. Зур ут янып тора. Чиләкләр, казаннар асылган. Качкыннар төрлесе-төрле якта утырышканнар, ятканнар. **Миңлегали** ут яга. **Пәтрәй** чабата тукый. **Шәйхи бабай** бүрек ямый. **Булат** ялгыз читтә утыра.Тәмәке тарталар. Булат җырлый.

I. Булат, Миңлегали, Пәтрәй, Мишка, Шәйхи бабай, Хәйри һәм башка качкыннар.

Булат (*җырлый*). Кара урман кара күләгәсе
Яшерә алмый качкын эзләрен.
Кара йөрәк — патша күрәзәсе
Эттәй чаба качкын эзеннән.

Кара урман шаулый,
Йөрәкләр ярсый,
Йөрәкләр ярсый,
Тоткын җәнлектәй.

Кара урман шаулый,
Эчтә ут кайный,
Эчтә ут кайный,
Кайда син, бибкәй?

Шәйхи. Булат улым, карап торам-торам да сиңа, тагын бер карап куям. Чынлап әйткәндә, качкын даны әрәм сиңа. Сөйгән кызың дию пәрие кочагында аунаганны күрә торып, моңланып, уйланып тору батыр егеткә килешми. Син егет булсаң, икенең берсен тот, йә аны оныт. Оныта алмыйсың икән — монда алып кил.

Булат. Хәбәр биргәнемә ике атна булды, үзе килеп чыкмасмы, дип көтәм.

Пәтрәй. Булат молодец ул, аны обижать итәргә ярамый. Пин дә Марияне сагынып җырлый торган идем.

Тимуш. Җырлый идем, дигән була тагын, хөлдерүш танау.

Пәтрәй. Җырлый идем жул. Ә вот син җырлый белмисең, җырлар өчен туша кирәк. Булатта туша пар, пиндә дә туша пар, синдә туша юк. Син начар, уңмаган пальшивый монетчик кенә.

Тимуш. Ә син кем?

Пәтрәй. Пин чисный кеже, пин чапата тукыйм, скрипкәдә уйныйм, пашкаларга пиндә усаллык юк. Закон чыкса, пин авылга да кайтырмын, мир пине какмас, ә син авылга кайта алмыйсың.

Тимуш. Авылга кайтып бояр урманыннан ун тиенлек юкә урлап, яңадан төрмәгә керерсең, урманнарда хәзерге төсле кырмыска туйдырып йөрерсең.

Пәтрәй. Син дә пит пулатта тормыйсың.

Тимуш. Мин кайчан да булса бер пулатта торачакмын. Үлсәм үләрмен, авылга кайтып чабата тукымам. Закон чыгып, иреккә чыгарга туры килсә, иң элек егерме бишәр сумлык, аннан йөзәр сумлык, аннан бишәр йөз сумлык акча суга торган станоклар ясап, дөньясын шундый кыздырыр идем, төтене күтәрелер иде.

Хәйри. Тимуш агай, бер фараз, закон чыгып, безгә авылга кайтырга рөхсәт булса, бер фараз, син чынлап та баесаң, син миңа бер мең сум биреп торырсыңмы?

Тимуш. Юк, бирмәм!

Хәйри. Ни өчен?

Т и м у ш. Әгәр дә мин урмандагы, төрмәдәге, каторгадагы бөтен танышларга меңәр сум бирә башласам, акча ясарга бөтен дөньядагы акча кәгазе түгел, тәмәке кәгазе дә җитмәс. Син, шәкерт, кеше кулына карап көн итәргә маташма, алданырсың.

М и ң л е г а л и. Син, шәкерт энем, егет кеше буласың килсә, минем арбага утыр. Валлаһи газим, мин сине кеше итәрмен. Их, егетләр, ат урлауның тәмен, рәхәтен белмисез сез...

П ә т р ә й. Яхшы кеше ат урламый...

М и ң л е г а л и. Их, егетләр, ат дигәч тә йөрәкләргә зәмзәм сулары койган төсле булды. Белмисез, егетләр, ат урлауның рәхәтен, ләззәтен белмисез. Менә караңгы төн, ди. Ындыр аркылы корсак өстеннән килеп, сырт капканың алдына туктыйсың. Йортта эт өрә башлый, син, тыныңны чыгармыйча, күләгә төсле тын торасың... Аргамакның ишегендә чабата хәтле бикләнгән йозак була. Бисмилла әйтеп, отмычка белән келт итеп бер борасың да, йозак шылт итеп борынын күтәреп куя. Абзар ишеге ачылуга, карабодай басуындагы төсле хуш исләр аңкып китә. Аргамак җаныем, көяз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, шыгыр-шыгыр печән кимереп ята, сылу кызлар көлгән төсле, көязләнеп пошкырып куя. Барып ялыннан тотып сыйпагач, бәгырем килдеңме, дигәндәй пуф итеп бер сулап ала. Шуннан иренен боргычлап, акрын гына сырт капкадан чыгарасың да, әгузе-бисмилла әйтеп атланып, әйдә... Тф! Менә шул чагындагы рәхәтне әйтәм, йөрәкләрең оҗмах рәхәтләрен сизә инде шул чагында. Аның көче күкрәгеннән болыт-болыт булып чыккан сулышларын, дулкын-дулкын булып җилбердәп уйнап торган яллармын, тояк тавышларын, матур кызлар кулында уйнаган кайчы төсле колак уйнатуларын, барысын-барысын да йөрәк белән сизеп торасың. Их, егетләр, ат урлауның тәмен, ләззәтен белмисез. Ул әле сезнең борыныгызга кермәгән. Их, шайтан алгыры, тел юк аны аңлатырга!.. Шуңа күрә бик күп кеше аның тәмен дә белми...

Ш ә й х и. Йә, ярый, син аргамак урладың, ди, син миллионер булдың, ди, шуннан ни була, илгә ни файда?

Т и м у ш. Илдә минем ни эшем бар, үз рәхәтем миңа рәхәт.

Ш ә й х и. Шул шул. Сезнең ул һөнәрегез коры матурлык кына, үзегез коры юлбасарлар гына.

Миңлегали. Ә синең урәтник, стражник үтергәнеңнең кемгә файдасы бар?

Шәйхи. Илгә файдасы булды, илгә. Әгәр дә мин ул вакыт стражник белән землямерны чәнчелдермәгән булсам, безнең түбән болын боярга китә иде. Ил өстенә төшкән бәлане бер ялгызым күтәрдем дә, илне бәладән коткардым.

Мишка. Правильно, Шәйхи бабай!

Тимуш. Правильно, дигән була, чучка танау, авылыңа кайтсаң, приговор җыеп, аягыңнан асып куячаклар бит сине.

Мишка. Никогда мин авылга зарар китерде юк, мин бояр имениесен яндырган, еще яндыра. Мин ундүрт боярны яндырган, ә син жулик, фальшивый монетчик, вот кто син!

Тимуш. Ничек мин жулик, чучка танау! Нәрсәңне урладым! (*Ябыша.*) Әйт, нәрсәңне урладым, сукин сын?!

Сугыш.

Булат (*араларына кереп аера*). Тимуш дус, яхшы чакта күз алдымнан югал, вон!

Тимуш (*сызгырып*). Югалмасам, ни эшләрсең?

Булат. Югалмасаң, менә шулай тотармын да, вон!..

Тотып этеп җибәрә, Тимуш егыла.

Тимуш. Ах син, кеше үтерүче каторжник! Син әле монда командовать итәргә уйлыйсың икән. (*Пычагын ала.*)

Булат (*пычагын чыгарып*). Әйдә, сынашып карыйк.

Әйләнә башлыйлар.

Барысы да. Ташлагыз пычакларыгызны, ташлагыз!

Миңлегали. Аралама, ул маңка малай җанына сусаган! Тимуш, када бугазына, када!

Барысы да. Син урыныңда утыр, карак баш.

Миңлегалине камыйлар. Хәйри, Шәйхи, Булат Тимушны камап, пычагын алалар.

Шәйхи. Таралыгыз, балалар, болай ярамый, ярамый. Татулык кирәк, татулык. Качкын башларыгыз белән урманда сыеша алмасагыз, белмим инде, кем генә сезне юньгә кертер икән.

Паузa.

Йә, утырышыгыз, бәрәңге дә булган.

Ут тирәсенә утырышалар. Берсе ипи кисеп тарата. Һәркайсы үз кашыкларын төеннәреннән алып килә.

Шәйхи. Рас та, Булат. Карап торам-торам да мин сиңа, тагын бер карап куям. Егет дисәң, егетләрнең асылы, ир дисәң, ирләрнең батыры, кеше дисәң, кешеләрнең әүлиясе...

Тимуш. Әүлия кеше үтерәмени?!

Булат. Минем урынымда булсаң, син кеше түгел, Алланы да үтерер идең.

Миңлегали. Син, Булат энем, телеңне кыскарт, Алла белән маташма! Синең үзеңнең динсезлегең җиткәч тә, монда мөселманнар бар.

Булат. Синең мөселманлыгың ат урларга гына ярый бит.

Миңлегали. Тукта, дим, чучка, юкса иманым кяфир булып чәнчелеп китсә китәр, Алла өчен чукынып китәрмен. Бел аны!

Булат. Чукын...

Барысы да. Ха-ха-ха!..

Миңлегали. Егетләр, Алланы мыскыл итәргә рөхсәт юк, белегез аны, юкса чукынып шаһит китсәм китәрмен... Бер Алланы хурларга ирек бирмәм!

Көләләр.

Шәйхи. Аллаһе әкбәр. Бүген дә көн үтте.

Тарала башлыйлар.

Булат. Да, егетләр, уен да көлке. Көннәр атналарны, атналар айларны куа, айлар елларны тутыра, гомер уза, киләчәкнең башы-аягы күренми.

Барысы да (*авыр сулап*). Да, күренми.

«Яңа кара урман» көенә җырлыйлар.

Хәйри (*башлый*). Җитәсе ләй җиргә җитә дә генә алмыйм...

Хор. Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Хәйри. Канаткайлар гына куеп, ай оча алмыйм...

Хор. Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Хәйри. Туган-үскән илләр, ай, күренми икән...

Хор. Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Хәйри. Зарыгып көткән хәбәр ай ирешми икән...

Хор. Кара урман аша,
Кошлар сайраша шул, башлар адаша.

Шәйхи. Йә, егетләр, урыс әйтмешли, утро вечера мудренее. Үз бәхете үз ризыгы белән килер, көтәргә кирәк. Бу көннән, егетләр, бу көнге иректән, сезнең шикелле егетләрдән аермаса, шушы кара урманда үләргә дә ризамын... Уйлап-уйлап торам да, егетләр, тагын бер уйлап куям: староста, старшина, урәтникләр табаны астында изелеп ятудан кара урман уртасында үз ирекле булып яшәүне артык табам. Дөньяның тәгәрмәче бер борылыр әле, шул чагында безне дә искә алучылар табылыр.

Мишка. Правильно, Шәйхи бабай!

Булат. Егетләр, минем дә сезгә бер йомышым бар: мин авылдан качканнан соң, минем кәләшем Мәйсәрәне әлеге ишан дуңгыз бишенче хатынлыкка алып китте. Менә шул Мәйсәрәгә ике атна элек Мишка аркылы хат язып, үзен монда чакыруым да сезгә билгеле... Менә күрәсез, ул әле һаман да юк. Значит, ул ишан тозагыннан ычкына алмый, яисә ишанның зур пулатлары, ефәк күлмәкләре мине оныттырганнар. Менә, егетләр, Мәйсәрәне ишан тозагыннан коткарырга кирәк, мине оныткан булса (*пычагын чыгарып*), менә шушының белән исенә төшерергә кирәк. Бүген мин шул сәфәргә керешмәкче булам. Кайсыгыз кияү егете булып барырга риза?

Барысы да. Барабыз, барабыз!

Миңлегали. Мин бармыйм.

Шәйхи. Ни өчен?

Миңлегали. Ишан хәзрәтнең бәддогасыннан куркам.

Пәтрәй. Куркак ул, трус ул.

Миңлегали. Тик тор син, побыңны таларга мине чакырып кара, курыкканымны, курыкмаганымны күрерсең...

Ш ә й х и. Туктагыз, балалар, тавышланмагыз. Кайчан юлга чыгабыз? Мин үзем тимерне кызуында сугу ягында.

Б у л а т. Хәзер чыгарга кирәк булыр.

Ш ә й х и. Шулай шул, хәзер чыкканда да иртәгә төнгә генә барып җитәрбез. Йә, егетләр, юл кешесенең юлда булганы яхшы...

Б у л а т. Егетләр, минем туйны шундаен итәрбез! Кызыл әтәч койрыгының шәүләсеннән бөтен дөнья ялтырар, шулай бит, Мишка?

М и ш к а. Думаю, что ишанның пулаты яхшы янар.

Ш ә й х и. Йә егетләр, булган булсагыз, утырышыгыз.

Юлга чыгучылар кайсы күсәк, кайсы кистән яки берәр башка нәрсә тотып утырышалар, «Качкыннар» көенә җыр башлана. Музыка.

Б у л а т (*җырлый*).
Туган илләреннән аерылып,
Киек-җәнлек төсле боегып,
Гомерләре сүнә качкыннарның,
Кара урманнарга сыенып.

Х о р.
Без качкыннар, киек-арысланнар,
Урман безнең ватаныбыз, илебез. (*Тагын бер кат.*)

Б у л а т. Зур калалар безгә.

Х о р. Кара урман.

Б у л а т. Таш пулатлар безгә.

Х о р.
Киң ялан.
Аргамаклар, йон түшәкләр,
Кама бүрек, пустау камзул кирәкми,
Падишаның сенаторы, үрәтниге,
Прокуроры кирәкми.
Чум, чум, чум, чум — закон безгә нипочом.

Җыр кабатланып, бию башлана. Әүвәл берәм-берәм, аннары бары бергә биешәләр. Шау-шу, ыгы-зыгы.

Пәрдә.

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур бакча. Уңда ярым бояр, ярым шәрык стилендә эшләнгән йортка керә торган терраса һәм баскычлар. Сулда каралтылар. Бакча рәшәткә койма белән ихаталы. Уртада капка. Капканың ике ягында фонарьлар. Артта авыл мәчете, тегермәннәр һәм авыл күренә. Мәйсәрә эскәмиядә утыра, җилкәсендә зәңгәр шәл.

«Зәңгәр шәл» көенә җырлый.

I. Мәйсәрә ялгыз.

Мәйсәрә.
Башкынаем ялгыз, күңелем боек,
Далаларда ялгыз калган,
Абау, җаныем, тал кебек.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл.
Базарларда сатыла торган
Маллар төсле безнең хәл.

Хәдичә (*чыгып*). Менә җирбит, остазбикә башы белән оялмыйча җырлап утыра, халык икендегә җыела. Тапкан эш, оятсыз. Ни әйтсәң дә шул: мажик кызы мажик кызы була икән.

III. Мәйсәрә, Хәдичә һәм Мәрфуга.

Мәрфуга (*чыга*). Гайбәтемне чәйнәргә шуннан да уңайлырак урын тапмадыгызмыни, мескеннәр, әй үләтләр!..

Хәдичә. Сине ялчы Гaләви тикшерсен. Ишан хәзрәтнең фатихалы йортын уйнаш итеп бетердегез инде, оятсызлар.

Мәрфуга. Тоттыңмы, шакшы танау! Йә, әйт әле, кем белән тоттың?! (*Тарткәли.*)

Мәйсәрә. Туктагыз, кешедән оялыгыз! (*Аермакчы була.*)

Мәрфуга (*Мәйсәрәгә*). Нәрсә!.. Нигә син безнең эшкә тыгыласың, себерке...

Хәдичә (*Мәйсәрәгә*). Төшкәненә көн булмаган, мажик башы белән хуҗалык итмәкче була, кортлы баш. Җыен юлдан язган, җыен эштән чыккан, җыен урам себеркеләре безгә җыелган.

Мәрфуга. Каян килгән мунча әүлиясе... Безне сукыр суфый белән тоткан кеше булмады әле.

Хәдичә. Тукта, дим, уйнашчы!

Мәрфуга. Кычкырма миңа, корчаңгы эт!

IV. Шулар ук һәм Сабира.

Сабира (*чыгып*). Бу ни эшегез, җирбитләр, хәзрәткә йокларга ирек бирмисез!

Мәрфуга. Әй сәләмә борын, кыланышыннан үләрсең бит.

Хәдичә. Алай.

Сабира. Көнләшәбез, диген, әй мескеннәр.

Хәдичә. Дөньяга сыя алмый, карак!

Сабира. Карак булып нәрсәләреңне урладым?

Хәдичә. Барыгыз да бер, бер-берегездән артык җирегез юк. Берегез карак, берегез уйнашчы, берегез юлбасар калдыгы, барыгыз да бер.

Мәрфуга. Нәрсә?

Бергә бәйләнәләр, төрткәлиләр. Кыйныйлар.

Мәйсәрә (*аерып*). Туктагыз, туктагыз!.. Ярабби, нинди хурлык.

Мәрфуга, Хәдичә, Сабира (*сугышуларыннан туктап, бергә*). Ай-һай-һай!.. Каян килгән хан кызы соң син, ә? Абзаң ат карагы иде, сөйгән егетең кеше үтерүче-юлбасар.

Мәйсәрә (*аяк тибеп, бик кычкырып*). Туктагыз яхшы чакта!

Мәрфуга (*өстенә барып, төртеп*). Туктамасак, ни эшләтерсең? Менә мә! (*Кукиш күрсәтә.*)

Хәдичә (*чеметеп алып*). Азгын эт.

Сабира. Башкисәр...

Мәйсәрәне кыйный башлыйлар.

Мәйсәрә (*каты кычкырып*). Үтерәләр, үтерәләр, коткарыгыз!..

V. Шулар ук һәм ишан.

Ишан камчы тотып чыгып, барысын да камчы белән кыйный башлый. Мәйсәрә егылган җирендә кала, аны да кыйный.

Ишан. Кяфирләр, шайтан арбалары, иблис ялчылары, рәхәтләнеп йокларга да бирмиләр. Әрәмтамаклар! Сиңа ни җитмәгән тагын, мордар, хәерче...

Мәйсәрә. Үтер мине, үтер, синең йортыңда яшәгәнче, кабер газабы артыграк булыр.

И ш а н. Чинама, юньсез! Бар, бар, дуңгыз, бар!.. (*Мәйсәрәне кыйнап кертә, үзе дә керә.*)

Пауза.

М а л а й (*капкадан кереп*). Әссәламегаләйкем. (*Як-ягына карана.*) Кеше юк икән... (*Терраса ишегенә барып.*) Карт абыстай! Ау-у, карт абыстай, дим. Нишлиләр анда?.. Кемнедер кыйныйлар бугай. Инде нишләргә кирәк? Керсәң, мулла абзый кыйный, өйгә кайтсаң, әни кыйный... Карт абыстай!.. Галәви агай!.. Ни булган боларга?.. Абыстайларны күрми китте юк, үлмәгәннәр булса, бер чыгарлар әле. (*Террасага менеп.*) Карт абыстай! Икенче абыстай, дим!.. Өченче абыстай, дүртенче абыстай, бишенче яшь килен абыстай!.. Юк, әллә чебен даруы ашап дөмеккәннәр микән?.. Галәви агай!..

И ш а н ч ы г а.

VII. И ш а н һәм м а л а й.

И ш а н (*малайны ишек белән бәреп*). Нәрсә акырасың, дуңгыз малай?

М а л а й. Әссәламегаләйкем.

И ш а н. Дуңгыз, сафсата! (*Таягы белән малайга суга.*) Ишектән тыңлап йөрүең өчен күрсәтермен мин сиңа, чучка сафсата! Югал, дуңгыз малай!

М а л а й (*каушап, елап, аркасын кашый-кашый*). Әни әйтә, абыстай куера, ди, токмачлар килсеннәр, ди әни... Әй, әни әйтә, абыстайлар...

И ш а н. Нәрсә туглыйсың, сафсата!

М а л а й (*бөтенләй каушап*). Әни әйтә, абыстайлар өстәлгә... Әй ни, токмач куера, ди... (*Елый.*)

И ш а н. Эшсез фиргавеннәр токымы, монда чыгыгыз! Алла сакласын, Алла сакласын. (*Чалма, чапаннан намазга китә.*)

А б ы с т а й л а р берәм-берәм чыгалар.

VIII. М а л а й һәм Х ә д и ч ә.

Х ә д и ч ә (*чыгып*). Нәрсә бар!

М а л а й. Әни әйтә, хәзер килсеннәр, ди, токмачым куера, ди.

Хәдичә. Мине генә чакырдымы? Карт абыстаң килсен, дидеме?

Мәрфуга чыга.

IX. Шулар ук һәм Мәрфуга.

Мәрфуга. Сине генәдер шул. Сине үзеңне генә әнә зиратка чакыралар, ди, кабер дә хәзерләнгән, ди...

Сабира чыга.

X. Шулар ук һәм Сабира.

Сабира. Юк инде, алай икәү генә сыйланып йөрмәгез, бу юлы минем нәүбәтем.

Малай. Әни әйтә, барысы бергә, көтүләре белән җыйналып килсеннәр, ди, аш җитәрлек, ди...

XI. Шулар ук һәм Фазыйлә.

Фазыйлә (*кучтәнәчләр күтәреп керә*). Барысы да җыйналып, көтүләре белән киләләр, диген... Ашыйсым да, эчәсем дә бер генә дә килми, юри сезгә үч итеп барам... Әнкәй шулкадәр сыйлады үземне, тутырган тавык, пилмән, гөбәдия, бәлеш, ике төрле паштет, ак майга гына пешкән коймак, бал, конфет, варенье, чикләвек. Шартлыйм дип торам.

Мәрфуга. Юкка шартламагансың.

Малай. Токмач куера, ди.

Хәдичә. Хәзер, хәзер киләләр, диген, бар, акыллым.

Малай китә.

Сабира. Бу юлы Коръәнне мин укырмын.

Мәрфуга. Ай-һай, каян килгән мулла кызы! Тот капчыгыңны, минем нәүбәтем, садака да миңа.

Фазыйлә. Коръәнне теләсәгез кайсыгыз укыгыз, анда минем эшем юк, садакасы миңа булыр...

Хәдичә. Тагын тотындылар. Наданнар белән надан булыр хәлем юк, садакасын үзем алам...

Төртешә-төртешә өйгә кереп китәләр.

XII. Галәви һәм Хәдичә.

Бер яктан Галәви, өйдән Хәдичә чыга. Музыка. Җыр. Хәдичә, кулы белән Галәвигә изәп, эскәмиягә утыра.

Хәдичә (*җырлый*).
Без китәбез мәҗлескә,
Мәйсәрә кала эчтә.
Кача-нитә күрмәсен,
Китеп йөремә читкә.

Барысы да киенгән-ясанганнар, чапаннар бөркәнгәннәр. Берәм-берәм чыгалар.

XIII. Шулар ук һәм Мәрфуга.

Мәрфуга.
Нигә яптың шәлемне,
Һәм үз шәлең җәлмени.
Кая, сал-сал, карт убыр,
Шәлсез дә син бик матур.

Хәдичәнең шәлен йөзенә ташлый, үз шәлен алып ябына.

XIV. Шулар ук һәм Сабира.

Сабира.
Ниткән эшегез бу тагын,
Кайсыгызда чапаным?
Ник дәшмисең, себерке,
Ник монысын алмадың!

Кулындагы чапанны Мәрфугага ташлый, Мәрфугадан чапанын алып бөркәнә.

XV. Шулар ук һәм Фазыйлә.

Фазыйлә.
Кәвешемнең сыңгарын
Кайсыгыз кигән тагын?
Синдә ич, әйт, кигәндә
Нәрсә генә карадың!

Кулындагы кәвешне ташлый. Сабираның аягыннан кәвеш алып кия.

Хәдичә. Төпсез, тузган әрҗәләр,
Юк өчен әрләшәләр.
Килбәтләрен күр инде,
Нәкъ кысыр, мут кәҗәләр.

Барысы да. Ә син елан, карт убыр,
Үзеңне бел, тик утыр.

Галәви. Җыеныгызның хакы
Сукыр груш — бер бакыр.

Борылып, пыр итеп китәләр. Караңгылана башлый. Мәйсәрә чыга да паузадан соң «Зәңгәр шәл» көенә җырлый.

XVII. Мәйсәрә һәм Заһирә.

Заһирә (*куак артыннан*). Мәйсәрә!

Мәйсәрә (*куркынып*). Син кем? Тукта, саташаммы юкса мин? Заһирә җаным, ничек киләсе булдың?

Заһирә. Абыйдан хәбәр алдым.

Мәйсәрә. Булат бәгырем исән? Йә, йә, тизрәк-тизрәк сөйлә, кайда, ни эшли? Миңа ачуланмыймы, минем хәлне ишеткәнме?

Заһирә. Ишеткән. Язган хаты синең турыда. (*Хатны чыгара, Мәйсәрәгә бирә.*) Бу хатны алганыбызга ике атна узды. Вакытында тапшыра алмадым шул. (*Елый.*) Әни үлде. Аны җирләдек. Урак җитте.

Мәйсәрә. Әй мескеннәр, әй мескеннәр!.. Ярый әле, Булат исән икән, үтергәннәрдер дип уйлый-уйлый акылдан шаша яздым.

Заһирә. Ул сине үзе янына чакырган. Сыерчык авылы янындагы бояр урманы авызына килергә кушкан, шунда көтәрмен, дигән. Ерак түгел — бер көнлек юл.

Мәйсәрә. Көткәндер-көткәндер дә, Мәйсәрәнең киләсе килми дип кайтып киткәндер. Бик уңай чакка туры килде, берсе дә өйдә юк... Әйдә, китәбез.

Заһирә. Ничек чыгабыз, капка бикле бит.

Мәйсәрә. Көтеп тор шунда, карт үләтнең баш астында ачкычлар ята, берәрсе ярамасмы?

Мәйсәрә, ашыгып, өйгә кереп китә. Кайтып килә торган ишанның Галәвигә кычкырган тавышы ишетелә. Зәһирә тәрәзә астына поса, аннары ишанны бәреп егып кача, ишан тора алмый кычкыра. Остабикәләр кайтып керәләр.

Мәрфуга, Сабира. Ни булды, хәзрәт?

Ишан. Качты, кяфир, качты, тотыгыз, тот! (*Хатыннарын куа башлый.*)

Хәдичә. Кем качты?

Ишан. Карак, карак.

Хәдичә. Минем генә нәрсәләргә тимәгән булса ярар иде. (*Кереп китә.*)

Мәрфуга. Гөнаһ шомлыгына каршы, сандыгымны бикләмичә киткән идем ләбаса. (*Йөгереп кереп китә.*)

Сабира. Калфагым гына исән булса ярар иде. (*Ашыгып кереп китә.*)

Ишан. Кем, Галәви, бүген төн йокламассың, шакылдавык белән йорт тирәсендә әйләнеп йөрерсең. Явызларның ниятләрен белә алмассың, Алла сакласын, Алла сакласын. (*Кереп китә.*)

Галәви икенче якка керә.
Ерактан «Зәңгәр шәл» көенә җырлаган җыр тавышы ишетелә.
Зур паузадан соң Галәви шакылдавыкны шакылдатып чыга.
Булат белән бер качкын Галәвине артыннан кочаклап әләктереп алалар, авызын куллары белән каплыйлар.

XXI. Булат, Пәтрәй, Хәйри, Мишка, Галәви һәм башка качкыннар.

Булат. Егетләр, эшегезне белегез!

Барысы да йорт тирәсенә тарала. Мишка ут сала, Булат берничәсе белән өйгә керә. Өйдә чыр-чу башлана. Йорт яна башлый. Булат Мәйсәрәне кочаклап алып чыга, алар артыннан качкыннар чыгалар. Ыгы-зыгы.

Булат (*Мәйсәрәгә*). Бөркән зәңгәр шәлеңне!

Ишан һәм хатыннары эчке күлмәкләрдән, кычкырышып, мендәр-кием күтәреп чыгалар. Йорт яна. Качкыннар качалар. Ишан күлмәк-ыштаннан чаба.

И ш а н. Галәви, Хәдичә, Сабира, Мәрфуга, Фазыйлә, тотыгыз, тот кяфирләрне!..

Х а т ы н н а р ы. Янабыз, янабыз, янабыз!..

Пәрдә.

1926 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Беренче пәрдә вакыйгаларын өлешләргә бүлегез.
2. Беренче пәрдәдә «зәңгәр шәл»нең мәгънәсен табыгыз.
3. Шул ук пәрдәдә авыл егетләренә бәя бирегез.
4. Икенче пәрдәне дә шул рәвешле өлешләргә бүлеп сөйләгез. Авыл картлары һәм карчыклары сәхнәгә бергә килеп керәләр, бергә чыгып китәләр. Авыл картларының һәм карчыкларының уртак сыйфатларын әйтегез.
5. Дүтенче пәрдәдәге качкыннар холкы турында сөйләгез.
6. Бишенче пәрдәдәге абыстайлар холкы турында сөйләгез.

Әсәргә анализ

Кәрим Тинчурин бу әсәрен «мелодрама» дип атаган. Борынгы греклар җыры, көе булган сәхнә әсәрләрен шулай дип йөрткәннәр. Ләкин мелодраманың үзенә генә хас тагын дүрт сыйфаты бар.

1. Аның сюжеты мавыктыргыч була. Аеруча киеренкелеге белән аерылып тора.

2. Төп геройларның кичерешләре юри күпертелеп сурәтләнә.

3. Автор геройларына үзенең мөнәсәбәтен ачыктан-ачык күрсәтә.

4. Шулай булса да персонажларның кичереше эчке конфликт дәрәҗәсенә менеп җитә алмый.

Мелодрама жанрының үзенчәлеге белән таныштык. Жанр үзенчәлекләре дә, эчтәлекне тапкан кебек, әсәргә анализ ясап табыла. Әсәрнең исеменә игътибар итәбез. Матур исем. Әсәрдә кабатланса, «Зәңгәр шәл» образы фокус була ала. Әгәр дә фокус әсәрдәге вакыйгалар белән бәйләнешкә керә-керә мәгъ-

нәгә баеса, эчтәлекне табарга ярдәм итә. Шуңа күрә, пьесаны укыганда ук, зәңгәр шәлнең вакыйгалар белән бәйләнешкә керүенә аеруча игътибар итәбез.

Әсәр өлешләрен өйрәнеп чыктык. Алар шактый үзенчәлекле. Аларның һәркайсы, үзенә бер мөстәкыйль әсәр кебек, үз персонажлары, тәмамланган үз вакыйгалары белән яшиләр. Пьесада өлешләрне ялгап торучы сюжет бар. Ул — Булат һәм Мәйсәрә мәхәббәте белән бәйле вакыйгалар. Сюжет мелодрама әсәрләренә хас мавыктыргыч булса да, өлешләр эчтәлеген үзара тоташтыра алмый. Беренче пәрдәдә егетләр Булатка ярдәм итә алмыйлар. Авыл картлары хәсрәтләрен сөйләп зарланалар. Абыстайлар үзара талашалар. Ләкин Булат һәм Мәйсәрә кичерешләре әсәрнең төп темасы түгел. Төп теманы өлешләр арасындагы бәйләнештә табабыз. Ул бәйләнеш — өлешләр охшашлыгы.

Беренче пәрдәдә яшьләр үзара шаярышып үртәшәләр, мактанышалар, шул мохиттә генә булса да, үзләрен иркле, горур кешеләр итеп күрсәтмәкче булалар. Ләкин Җиһанша күсәк күтәреп чыгуга куркып качалар. Яшьләрнең үз-үзләрен тотышы белән гамәлләре арасындагы каршылык — юмористик, чөнки кешеләрнең бер сыйфаты кинәт кенә үзенең киресенә әйләнә. Димәк, автор егетләрдән көлә, дибез.

Икенче пәрдәдә әби-бабайларның җырларына игътибар итегез. Җырларында алар ишаннан көләләр, әмма ишан үзе күренү белән, мескен колга әйләнәләр. Ишан әйткән җыен тузга язмаган сүзләргә ышаналар. Үзләре ишан турында эшләмичә халык биргәнне ашап ятучы әрәмтамак, диләр, үзләре шул ук кешегә соңгы ярмаларын, йомыркаларын алып киләләр. Авылның карт-карчыклары, шулай итеп, ирекләрен җуйган, коллыкта яшәргә ризалашкан, мескенлекләре белән бөтен бер образ тәшкил итәләр. Автор картларны кызгана да, алардан көлә дә.

Абыстайлар, Коръән чыгып, башкаларны әдәпкә, бер-береңне хөрмәт итәргә өйрәтеп йөриләр (малай аларны шуның өчен чакыра да). Әмма үзләренең телләре генә ни тора: «дәҗҗал карчыгы», «шайтан анасы», «мунча пәрие», «корчаңгы эт», «карт убыр», «юлбасар үләксәсе», «азган эт», «дуңгыз», «надан»... Абыстайларның һәркайсы башкаларга үзен генә яхшы дип исбат итмәкче була. Ләкин, күз ачып йомганчы, башкалар кебек үк, җирбиткә, каракка, бозык кешегә әйләнә.

Хәдичә Мәйсәрәне җырлаган өчен «җирбит», «мажик кызы» дип сүгә. Ул да булмый, Мәрфуга, чыгып, минем гайбәтне сатасыз, «үләтләр» дип ачулана. Хәдичә белән Мәрфуга үзара талаша башлый. Мәйсәрә икесен дә тыярга теләгәч, ике дошман абыстай кинәт уртак тел табалар һәм, бергәләп, Мәйсәрәгә ташланалар. Сабира чыгып, үз чиратында көндәшләрен «җирбитләр» дип сүгә. Әле генә үзара ызгышкан Хәдичә белән Мәрфуга шунда ук уртак тел табалар һәм, парлап, Сабирага һөҗүм итәләр. Фазыйлә чыгып мактана гына башлый, өч дошман абыстай, хәзер инде өчесе дә бер булып, Фазыйләгә ташланалар.

Дүрт абыстайның дүртесе дә бертөслеләр: наданнар, тупаслар, тәрбиясезләр, көнчеләр, усаллар, холыксызлар. Аларда оят, намус кебек хисләр бөтенләй юк. Дүртесе дә мин-минлек колына әйләнгәннәр. Шулай итеп, Кәрим Тинчурин колларның тагын бер төрен күрсәтә, бу юлы мин-минлек коллары булган төркем образын иҗат итә.

Пьесадагы өч вакыйганың өч төркем образлары төрле-төрле: яшьләр, картлар, бай хатыннары, ләкин алар бар да — тыштан ялтырап, эчтән калтырап яшәүчеләр. Кәрим Тинчурин аларның барысын да коллар итеп сурәтли. Егетләр — түрәләр колы, карчыклар — наданлык колы, абыстайлар — минминлек колы.

Качкыннарның да уртак сыйфатлары бар. Җырларын тагын бер мәртәбә укып чыгыгыз, андагы ихлас юксыну, моңсулыкка игътибар итегез, ирек алу хыялларын исегезгә төшерегез. Шулай итсәгез, хәсрәтле, моңлы гап-гади кешеләр белән очрашырсыз. Качкыннар — барысы да диярлек хаклы рәвештә хөкемгә тартылырга тиешле, закон бозучы кешеләр. Алар урманда да күп еллар буена караклык белән яшиләр. Шулай булса да, күңел почмакларында туган якларына, якын кешеләренә карата җылы хисләрен саклап кала алганнар. Алар хокуксызлар, әмма авыл халкы кебек коллар түгел. Кара урман эчендә генә булса да, тапкан ирекләренә канәгать булып, горурланып яшиләр. Автор пьеса эчтәлеген аңлау өчен, Шәйхи карт авызыннан гаять дәрәҗәдә әһәмиятле сүзләр әйттерә. «Староста, старшина, урәтникләр табаны астында изелеп ятудан кара урман уртасында үз ирекле качкын булып яшәүне артык табам»,— ди Шәйхи. Аның ирек турында әйтелгән сүзләрен хуплап Мишка: «Правильно, Шәйхи бабай!» — дип кычкыра.

Автор аларның һәрберсенә холыктан өлеш чыгара. Бер пәрдә арасында һәрберсенең язмышын, холкын, хыялын ачарга өлгерә. Миңлегалине исегезгә төшерегез.

Рәхимсез, ерткыч, киребеткән бу ат карагы күңелендә шигъри хисләр ята икән. Миңлегали дусларына ат урлау турында сөйләми — шигырь әйтә. Караклык белән бәйле һәр гамәлендә әллә никадәр гүзәллек, матурлык, дәрт, шатлык эзләп таба. Миңлегали сүзләренә караганда, капка астын казып йортка керү дә, «салават әйтеп» эт агулау да, чабата хәтле йозакны отмычка белән ачу да, абзар исе дә — һушың китәрлек илаһи бер тормыш, бәхет. Кәрим Тинчурин шундый ерткыч кешедә дә катлаулы хис дөньясы күрә белгән.

Бирем

Тимуш, Шәйхи, Пәтрәй, Хәйриләрнең каршылыклы хисләре, нигезсез хыяллары белән юанып яшәүләре турында үзегез сөйләгез. Бу персонажларның холкында Кәрим Тинчуринның иҗади уңышын, табышын күрергә тырышыгыз.

Качкыннар пьесадагы башка социаль төркемнәрдән нык аерылып торалар. Ә егетләр арасында менә монысы башкалардан аерылып тора дип күрсәтерлек егет юк. Картлар, карчыклар һәм ишан хатыннары арасында да андыйлар күренми. Бар да бертөсле.

Кәрим Тинчурин ни өчен качкыннарны яхшы, ә ректә яшәүчеләрне начар иткән?

Яшьләр Җиһаншадан куркалар, чөнки ул авылда кечкенә генә булса да түрә — ишанның куштаны. Авыл картлары ишаннан куркалар, чөнки ишан — ул заманда авылның иң зур түрәсе.

Түрәләрнең берсе — ат карагы, ачуы килгән бер кешегә балта күтәреп һөҗүм итүче, ә икенчесе — Коръән сүзләрен бозып халыкны алдый-алдый малын үзләштерүче бозык кеше.

Качкыннар язмышы белән танышканнан соң, мондый нәтиҗәгә киләбез: алар ирексезләр (урманда качып ятарга мәҗбүрләр). Ләкин шул ук вакытта бар да иреклеләр. Җырларына игътибар итик.

Киң ялан.
Аргамаклар, йон түшәкләр,
Кама бүрек, пустау камзул кирәкми,

Падишаның сенаторы, үрәтниге,
Прокуроры кирәкми.
Чум, чум, чум, чум — закон безгә нипочом.

Законнан качып ятсалар да, хәтта законны да санга сукмыйбыз, дип мактаналар һәм шуңа ышаналар.

Кәрим Тинчурин әсәрендә ирексез мескен кешеләргә эчке ирекләре булган горур качкыннарны каршы куйган. Закон бозучы качкыннар яхшырак, димәгән. Хәтта ирексез качкыннар да иректә яшәүче халыктан ирекләрәк, дигән.

Фокус әсәрнең исеменә чыкса, өлешләр белән бәйләнешкә керергә тиеш, дидек. Шул бәйләнешләрне эзлик.

Зәңгәр шәлнең мәгънәсен беренче пәрдәдә таба алабыз. Шәл — Булатның яраткан кызына мәхәббәтен белдергән бүләге. Димәк, зәңгәр шәл — мәхәббәт, бәхет билгесе. Автор Мәйсәрәне Җиһаншадан шул шәле белән будыра, карт ишанга кияүгә чыгарга тиешлеген белгәч, Мәйсәрәнең «шәле салынып төшкән», ди. (Өченче пәрдә.) Ишан йортына килгәч, драматург шәлне тагын да түбәнрәк — Мәйсәрәнең җилкәсенә төшерә. Булат Мәйсәрәне коткарырга «Зәңгәр шәл» көенә җырлап килә. Ниһаять, пьесаның ахырында Мәйсәрәгә: «Бөркән зәңгәр шәлеңне»,— ди. Димәк, яшьләрнең кавышу өмете зур чакта, шәл башта була, өмет бетте дигәндә, шәл муенны кыса, кыз ишанга бирелгәч, баштан салынып төшә, аннары җилкәдә була, ә өмет чынга ашкач, тагын башын каплый. Шәл, шулай итеп, барлык сюжет сызыгына мәгънә биреп, аларны үзара бәйләп тора.

Форсаттан файдаланып, әдәбият теориясендәге безгә таныш булмаган тагын бер күренешне ачыклап үтик. Зәңгәр шәл сыйфатлары белән мәхәббәт, бәхет, кавышу эчтәлекләре арасында һичнинди уртаклык юк. Димәк, ул берничек тә метафора да, гади чагыштыру да була алмый. Шәл — мәхәббәт, бәхет билгесе. Ул бәхетне, мәхәббәтне алыштырып, аларның вазифаларын үтәп кенә килә.

> Башка әйбер яки күренеш вазифасын үтәп килүче әйбергә билге яки **символ** диләр.

Ләкин шәлгә әдип тагын бер бик мөһим мәгънә бирә: зәңгәр шәлне җыр эченә кертә. Мәйсәрә:

Базарларда сатыла торган
Маллар төсле безнең хәл.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк жәл,—

дип җырлый, ә соңгы ике юлны өч тапкыр кабатлый.

Зәңгәр шәл, кеше язмышы белән янәшә килеп, авыр язмыш мәгънәсен дә белдерде. Автор аны әсәрнең исеме иткән. Димәк, әсәрнең исеме аша авыл халкының авыр язмышына да, качкыннар язмышына да бәясен белдергән.

Ләкин зәңгәр шәлнең тагын бер аеруча мөһим мәгънәсе бар: шәл бүләген бүләк, ләкин аны көрәшеп алырга кирәк. Булат, «Кемнең кулы җитсә, шуңа» дип, кызларны ярыштыра. Ә без зәңгәр шәлнең мәгънәсе мәхәббәт, бәхет булуын беләбез. Шуңа күрә автор безгә бәхет күктән төшми, бәхет өчен көрәшергә кирәклеген әйтә дип нәтиҗә ясыйбыз. Фокус әсәр идеясен аңлатты.

АМЕРИКАН

(*Комедия*)

Дүрт пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Апуш, Искәндәр — студентлар.
Муса — элеккеге җәмәгать хадиме[1], татар киеменнән, жилет кигән.
Шәехмирза — элеккеге адвокат.
Габдуллаҗан — спекулянт.
Сәлим — тарихчы.
Насих Николаевич — мирза.
Сәлимгәрәй — элеккеге полиция чиновнигы.
Дилбәр — Мусаның кызы.
Мәйсәрә — Габдуллаҗанның кызы.
Разия — Габдуллаҗанның хатыны.
Нигъмәт — карт интеллигент.

---

[1] *Хадим* — хезмәтче.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Студентлар торагы. Касыйм китап укып кроватьта ята. Апуш, идәнгә ятып, җырлап, плакат яза.

Апуш. Без бүгенге көн җепләреннән,
Без киләчәккә юл сузабыз,
Без үткән көннәрне күмәбез,
Без тарих белән узышабыз.

Мулла малае Касыйм бу мәгънәсез җырга бик дөрес бәя бирә: «Шыңшыма әле, укырга уңайсызлыйсың. Иртә җыр, кич җыр. Каян чыга бу кешедә бетмәс-төкәнмәс җыр. Ирек бирсәң, җырлап кына торырлар иде. Нәрсәгә дәртләнә торгандыр?!» — ди. Чыннан да, дәртләнерлек сәбәп юк икән. Студентлар ач утыралар. (Кәрим Тинчурин —шундый астыртын иониягә бик оста язучы.) Апушның җырына игътибар итегез: «Без үткән көннәрне күмәбез»,— дип җырлый тарихчы булырга әзерләнүче кеше. Шуннан соң тарихны күмүчеләр, җыелып, Габдуллаҗанның бик кыйммәтле борынгы ханнар ярлыкларын алдап үзләштерү планын коралар. Арада иң яхшы укучы Касыймны мулла улы, дип гаеплиләр, уку йортыннан куу белән яныйлар. Беренче пәрдәдә үк Искәндәрнең кеше корсагына бармагы белән төртеп сөйләшә торган яман гадәте барлыгы беленә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уртада җыйналган кабинетка охшашлы бүлмә.

I. Муса ялгызы.

Муса (*ишектән карап*). Анасы, анасы, пәрәмәчне карап пешерегез. Кунак ни җитте кеше түгел. Америка профессоры. Бу профессор Америкадан нинди максат белән килде икән? Тәгаен өйләнергә килгәндер. Туп-туры миңа килүе мәсьәләне тагын да мөһимләштерә. Шулай ук минем шөһрәтем Америкага кадәр барып җиткәнме икәнни? Хәер, гаҗәп түгел. Җитсә дә җитәр шул. Милләт өчен кулдан килгән кадәр эшләдек инде. Ай, бу мәдәният бик зур нәрсә шул. Хуш. Бу хакта кызым белән сөйләшеп алырга кирәк. Хатын-кыз бит ул ахмак була.

Муса, Искәндәр һәм Апуш.

Муса. Хуш киләсез, мәрхаба, таныш булыйк. Муса Мәхмүди.

Искәндәр. Чикаго дарелфөнүненең[1] профессоры. Нью-Йорк академиясенең әгъзасы, профессор Булат Сон.

Муса. Сезне ханәбездә күрү белән бәхетлебез, әфәндем. Боерыгыз! (*Урын күрсәтә.*)

Искәндәр. Рәхмәт. (*Төртә.*) Гафу итегез, мин шулай. Муса әфәнде, мин сезне дә, гаиләгезне дә Америкада чагында ишетеп белгән идем... Минем сезнең белән якыннан дуслашасым килә. (*Торып кулын сузып төртә.*) Гафу итегез!

Муса. Бик рәхмәт. Мин бик шат.

Искәндәр. Шәһәрегездә Габдуллаҗан исемле спекулянт бар икән.

Муса. Әйе, бар. Бик саран, ахмак бәндә.

Искәндәр. Менә шул Габдуллаҗан спекулянтта Арслан ханнан калган тарихи ярлыклар бар икән. Сезнең шул хакта хәбәрегез юкмы?

Муса. Әйе, бар, дип әйтәләр. Ләкин үз күзем белән күргәнем юк. Ул аларны һичбер кемгә күрсәтми.

Искәндәр. Шулай дигәннәр иде. Хәер, ул мәсьәлә минем өчен мөһим түгел. Муса әфәнде, бер стакан кайнар су булса, мин бик шат булыр идем.

Муса. Бәлки, чәй эчәрсез?

Искәндәр. Лимон белән булса, мөмкин.

Муса. Була, була. Рәхим итегез, менә бу әфәнде сезне пәрәмәч ярата дигән иде.

Искәндәр. Аһ, бик, бик!.. Шул яраткан ашымны егерме ел ашаганым юк. Россиягә килгәч тә берьюлы егерме пәрәмәч ашап бетерергә ант иткән идем. (*Төртә.*) Гафу итегез!

Муса. Сез бик күңелле кеше икәнсез, профессор хәзрәтләре. Гафу итегез, мин хәзер! (*Чыга.*)

Апуш. Сайрый беләсең, малай. Көлмичә чыдап булса ярар иде. Син ул корсакка төртүеңне куй. Килешми...

Искәндәр. Тес-с-с!..

Муса керә.

Муса. Менә нинди милли пәрәмәчебез... Рәхим итегез!

Искәндәр. Мин инде тансыкка күбрәк ашармын. Сез

---

[1] *Дарелфөнүн* — университет.

миңа, Муса әфәнде, бик ошадыгыз. Пәрәмәчегез дә бик ошады.

Муса. Җитешегез, җитешегез!.. Ә монда беткән икән. Кайнарын китерик.

Муса чыга.

Апуш. Ну, пәрәмәче, малай. Тагы бер егермене сыпырырмын, ахрысы.

Муса керә.

Муса. Менә кайнарыннан рәхим итегез. Профессор хәзрәтләре, сезнең ата-анагыз исәннәрме?

Искәндәр. Мәрхүмнәр.

Муса. Үзегезнең ничек, рәфикагыз бармы?.. Ягъни хатыныгыз бармы?

Искәндәр. Юк. Мин үземә милли татарлардан зыялы татар кызын рәфика итәргә ант иткән идем. Аннан соң мәрхүм әткәй белән әнкәйнең васыятьләре дә шулай иде. Хатының милли булсын дип кычкырып үлделәр.

Муса. Бәрәкалла, бәрәкалла. Ә менә бездә сез эзләгән, ягъни сез теләгән милли туташлар бар инде. Ә, профессор хәзрәтләре, минем бердәнбер кыз балам бар. Әгәр теләсәгез, мин аны сезнең белән таныштырыр идем. Бик тәрбияле бала инде. Дилбәр, Дилбәр, кызым, монда чык әле.

Дилбәр керә.

Дилбәр. Нәрсә, әткәй?.. Аh, пардон, мусио, гафу итегез. (*Реверанс ясый.*)

Искәндәр. Мин бик шат. (*Дилбәргә төртә.*) Гафу итегез, туташ. Мин шулай инде.

Дилбәр. Аh, пардон, мусио.

Муса. Әйе, әйе, кызым, профессор хәзрәтләре сөйгән кешесенә шулай төртергә ярата икән. Без инде, профессор хәзрәтләре, азрак кызыбызны французча да укыттык. Кызым, хәерле көн французча ничек була?

Дилбәр. Бон жур, мусио! (*Реверанс ясый.*)

Искәндәр. А-а-а! Французчаны бик һәйбәт беләсез икән.

Муса. Тырыштык инде, профессор әфәнде. Кулдан килгән кадәр балаларыбызны милли рухта тәрбияләргә тырыштык инде. Шуның белән бергә, милли музыка белән дә таныштыр-

дык. Кызым, Дилбәр, профессор хәзрәтләренә берәр милли көй җырлап алмыйсыңмы?

Дилбәр «Әллүки» көенә тамак төбеннән европача тавышлар чыгарырга тырышып җырлый. Җырлап бетергәч, һәммәсе дә кул чабалар. Дилбәр кат-кат реверанс ясый.

Искәндәр. Яшәсен милли көй!

Муса. Яшәсен милләт!

Искәндәр. Пианинода уйный беләсезме, туташ? (*Төртә.*)

Дилбәр. Аh, пардон, мусио! (*Реверанс ясый.*)

Дилбәр бер бармак белән «Галиябану»ны ялгыш-йолгыш уйнап чыга. Кул чабалар.

Муса. Шулай булгач, милләтебез бетмәс бит, профессор хәзрәтләре?

Искәндәр. Һич юк, бетмәс. Бетәргә рөхсәт юк. Әгәр дә милләтебез тагын биш-ун ел шул юлыннан аерылмыйча барса, һич шөбһәсез, Американы узып китәчәк. Чөнки бездә аларда булмаган хосусиятләр бар. Милли пәрәмәчебез бар, милли «Галиябану»ыбыз бар, милли туташларыбыз бар, милли татарларыбыз бар. Кирәк-яракларның һәркайсы бар. Ә аларда ул юк.

Муса. Аларда юк икән, профессор әфәнде?

Искәндәр. Аларда машина, автомобиль, һөнәрдән башка һичбер милли нәрсәләр юк.

Шәехмирза керә.

Шәехмирза. Кайда ул Америка профессоры, кайда?

Муса. Кызым, ир-ат бар, чык.

Дилбәр чыга.

Милли адвокатларыбыздан Шәехмирза Юкабашев әфәнде.

Искәндәр. Мин бик шат. (*Кулын бирә һәм төртә.*)

Шәехмирза. Ай, профессор әфәнде, минем бүсерем бар. Шуның өчен утенәм.

Искәндәр. Миллидер инде ул.

Муса. Әйе, әйе, ышанычлы милләтчеләребездән.

Шәехмирза. Профессор әфәнде. Сез моны күрәсезме? (*Тазын күрсәтә.*)

Искәндәр. Шактый шома икән.

Ш ә е х м и р з а. Мине таз диләр, ә мин әйтәм, мин әйтәм, ул мәдәнилек, галимлек галәмәте, дим. Сезнең пеләшегез бармы, кайда?.. Менә, Муса әфәнде, һәрбер мәдәни галим кешенең башы пеләш булырга тиеш. Ә сез таз дисез.

М у с а. Сезнең пеләш түгел, таз, Шәехмирза әфәнде. Атагызның да башы таз иде. Тазлык — сезнең нәселдән килгән милли авыру инде ул. Сез милли тазлылыгыз белән мактанырга тиешсез.

Ш ә е х м и р з а. Сезнең атагыз бирән авыруыннан үлгән. Анагызның уң аягы ярты аршин кыска булган.

И с к ә н д ә р (*араларына кереп, төртә*). Әфәнделәр, сез икегез дә бик маһир ораторлар икәнсез.

Габдуллаҗан керә.

Г а б д у л л а җ а н. Әссәламегаләйкем! Америка профессоры кайда!

М у с а. Габдуллаҗан бай, рәхим итегез! Менә ул!

Г а б д у л л а җ а н. Ничек, профессор әфәнде. Үзегезнең җәмәгатегез бармы?

И с к ә н д ә р. Юк.

Ш ә е х м и р з а. Профессор әфәнде, сез кайсы шәһәрнең университетында эшлисез?

И с к ә н д ә р. Вашингтонда.

М у с а. Чикагода түгелмени?

И с к ә н д ә р. Чикагода да, Нью-Йоркта да, мин бөтен Америка университетларында эшлим.

Ш ә е х м и р з а. Профессорлыкка бирәр буш урын юкмы?

И с к ә н д ә р. Кем өчен?

Ш ә е х м и р з а. Үзем өчен. Мин факультет ярым бетердем бит. Гыйльми әсәрләрем дә бар.

М у с а. Таз башың белән кайда үреләсең инде син! Син гомереңдә бер әсәр нәшер иттең, аңар да кибетләрдә тоз тутырып саталар.

Ш ә е х м и р з а. Ә синең әсәрләрең кәгазь капчык ясарга да ярамый.

И с к ә н д ә р. Муса әфәнде, бик рәхмәт хөрмәтегезгә, безгә рөхсәт итегез. Әгәр дә Америкага барсагыз, миңа кунак булып төшегез. Ниопост урамында. 16818 нче йортта, 84 нче катта, 9987 нче номерлы фатирда, 1189 нчы бүлмәдә мин булырмын.

Г а б д у л л а җ а н. Профессор әфәндене кунарга мин үземә алып барам.

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Бездә кунак.

Габдуллаҗан. Юк, безгә барыр. Әйдә безгә!

Муса. Җибәрмим!

Соңгы сүзләрне тәкрарлап, Искәндәрне як-якка тарткалыйлар.

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мещаннарча җыйналган кунак бүлмәсе.

I. Разия, Мәйсәрә бүлмә җыештыралар.

Разия. Кызым, тузаннарны яхшы сөрттеңме икән инде? Кунак ни җитте түгел, ди, американ, ди. Алла сакласын, шакшы торалар, дип бөтен дөньяга яман атыбызны таратыр.

II. Разия, Мәйсәрә һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Кайда, буласызмы инде? Кирәк-яракның барысы да булдымы инде?

Разия. Булды, атасы, булды.

Габдуллаҗан (*үчекләп*). Булды, атасы, булды, атасы. Мин сиңа талчукчы да, читекче дә түгел. Сүз сөйләшә белмисез. Һи, атасы, атасы... Кайчан гына шул тупаслыкларыгыздан котылырмын икән инде. Һичбер төрле итеп тәрәккыйпәрвәрләндереп[1] булмый үзегезне. Кара аны, Разия ханым, актык мәртәбә әйтәм, әгәр дә тагы атасы дип эндәшкәнеңне ишетсәм, билләһи газим дип әйтәм, яңагыңнан утлар чыгарырмын!.. Шул бер-ике сүзне өйрәнмәскә миегез черемәгәндер бит.

Разия. Ярый инде, сиңа әйтәм, юк өчен...

Габдуллаҗан. Нәрсә, ничек, ничек?.. Сиңа әйтәм? Сиңа әйтәм?! Әллә син мине авылдан базарга кәбестә төяп килгән гыйбди дип уйлыйсыңмы? Яңадан шул «сиңа әйтәм»еңне авызыңнан чыгарсаң, телеңне кадак белән тишәрмен. Гыйбди дисәң гыйбди. Мужик, надан... Бу кадәр заманны аңламаган, тәрәккыйгә күнмәгән хайваннар булырсыз икән!..

Разия сүзсез генә төртә.

Нигә миңа төртәсең? Телеңә җен кагылмагандыр бит?

---

[1] *Тәрәккыйпәрвәр* — алдынгы кеше.

Разия. Аптырадым инде мин, аптырадым. Атасы дисәң ярамый. Сиңа әйтәм дисәң ярамый. Әй дисәң ярамый. Төртсәң тагы ярамый. Соң нихәл кылыйм инде? (*Елый.*) Тәрәккыйпәрвәрлегең үзеңә булсын, нигә чәнчелмисең шунда! (*Елый.*)

Габдуллаҗан. Елама, елама, миңгерәү тавык. Үзең өчен тырышам бит, Разия ханым. Теге утынлыктагы иске китапларның тузаннарын сөртеп монда кертегез. Аннан соң малайны базарга җибәреп, бик күп итеп, татарча һәм русча гәзитләр, журналлар алдырып, өстәл өсләренә куегыз. Берәр заграничный сурәтле журналлар табылмасмы, барысын да алсын, акча кызганмасын.

Разия. Ярый, ярый, алдырырбыз. Әрәм булмаслар. Бәлеш асларына җәяргә дә ярарлар. Юкса йортта им өчен бер кәгазь кисәге юк бит. Бу америкаң бигрәк расходлы кунак булды.

Габдуллаҗан. Расходсыз гына синең ул аңгыра тавыгыңны... Йә, ярый, ярый, бар, ашларыңны кара. Пәрәмәч, кабартмаларың яхшы булсын. Пәрәмәчкә ихласы зур ди аның.

Разия. Кунак ашы җирдә калмас, дигәннәр. Алла хәерле итсен инде. (*Чыга.*)

IV. Габдуллаҗан ялгызы.

Габдуллаҗан. Син Америка профессоры булсаң, без дә үз эшебездә профессор, әфәндем. Америка профессорының бабасы. Ә, һи-һи-һи, уйласам, йөрәкләр кытыкланып китә. Тукта әле, бу чүпрәк башларны шул хакта агаһландырып[1] куярга кирәк. Анасы!.. Әй, тфү, Разия ханым, кызым, монда керегез!.. Тиз булыгыз инде. Имгәкләр!

V. Габдуллаҗан, Разия, Мәйсәрә.

Разия. Син чакырдыңмы?

Габдуллаҗан. Килегез, утырыгыз... Кызым, син дә утыр. Менә нәрсә, кызым, Мәйсәрә туташ. Хатыным, Разия ханым. Мин иске фикерле, тупас кара татар бае түгел, ишаннарга кул биреп дөньямны ахирәткә алмаштыручы-

[1] *Агаһландыру* — кисәтү.

лардан да түгел. Мин замана кешесе, тәрәккыйпәрвәр, милләтче татар углы татармын...

Разия. Мөселман диең, атасы.

Габдуллаҗан. Тик тор син, ишәк. Менә шулай, кызым туташ. Хәзер эшне заманча, тәрәккыйпәрвәрләрчә йөртү модада. Менә шуңа күрә мин сине үзең теләмәгән кешегә көчләп кияүгә бирү ягында түгел, кызым. Бүген безгә киләчәк американ — бик зур могтәбәр кеше. Әгәр дә чәчләрегез бәйләнгән булса, кызым, гомерең буена автомобильдә генә йөрерсең. Әгәр дә насыйп булып аңарга кияүгә чыксаң, Америкага китәрсез. Ел саен берәр кат без дә барырбыз. Сез аннан вагонлап-вагонлап мал җибәрерсез. Без монда сатарбыз да, алтынга әйләндереп, сандыкларга тутырып, сезнең янга Америкага торырга китәрбез.

Мәйсәрә. Әем, мин аңарга чыкмыйм.

Габдуллаҗан. Мин, кызым, тупас татар бае түгел. Әгәр дә күңелеңә ошамый икән, мин сине көчләп бирмим. Ә инде минем сүземә каршы килүең өчен яңагыңнан утлар чыгарырмын. Мин синең белән ике сөйләшмәм. Мин заман кешесе. Дәшмисең?..

Разия. Дәшмәү ризалык галәмәте ул, атасы.

Габдуллаҗан. Син тик тор, әрәмтамак! Дәшмәү ризалык галәмәте дип эш кылырга мин кадим[1] бай түгел. Миңа үз теле белән шартлатып әйтеп бирсен. Мин аны көчләп бирергә теләмим. Инде минем планнарымны җимерә икән, үзенә үпкәләсен. Яңагын кабыргалы бозау кәтлитеннән ким ясамам. Йә кызым!.. Мин көтәм!..

Мәйсәрә. Риза.

Габдуллаҗан. Менә, бәрәкалла, кызым. Менә бу эш чын җәдит[2], зыялыларча булып чыкты. Бар һәйбәтләп борыныңны, йөзләреңне юып, теге мутный күлмәкләреңне киеп, рәхәтләнеп, хәзерләнеп тор. Ә син, Разия ханым, ашларыңны кара.

Разия. Ярый, ярый, Алла хәерле итсен иде инде. (*Чыга.*)

Звонок.

---

[1] *Кадим* — иске карашлы кеше.
[2] *Җәдит* — яңача фикер йөртү.

VI. Габдуллаҗан, Нигъмәт.

Габдуллаҗан. Әйдә, әйдә, Нигъмәт әфәнде. Дөньяда ниләр бар? Гәзитләрендә ниләр язган булалар?

Нигъмәт. Һаман шул бер балык башын чәйниләр. Тегеләй эшлибез, болай эшлибез дип мактанудан уза алмыйлар әле. Юньләп эшләгән бер эшләре юк. Мәмләкәт тоту бунт чыгару түгел икән шул.

Звонок.

VII. Габдуллаҗан, Шәехмирза, Сәлим, Нигъмәт.

Күрешәләр.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, сөйләшәсе сүзегез булса, сөйләшеп бетереп куегыз, профессор алдында, зинһар, сынатмагыз.

Шәехмирза. Син, Габдуллаҗан әфәнде, бер сәүдәгәр генә. Зыялылар сөйләшкәндә тыңлап торырга кирәк.

Габдуллаҗан. Мин үз өемдә үзем хуҗа. Теләсәм сөйләшермен, теләмәсәм тыңлап торырмын.

Звонок.

VIII. Әүвәлгеләр, Муса, Дилбәр.

Муса. Әле килмәдемени?

Габдуллаҗан. Хәзер килергә тиеш. Рәхим итегез.

Күрешәләр.

Нигъмәт. Муса әфәнде, американ профессоры сездә булган, ди... Нинди тәэсир калдырды?

Муса. Чын зур галим икәнлеге һәрбер сүзеннән, хәрәкәтеннән күренеп тора.

Шәехмирза. Мин профессор хакында моннан биш ел элек ишеткән идем. Һәм үзенә бер хат та язган идем...

Сәлим. Әллә сез, Шәехмирза әфәнде, профессор белән якын мөнәсәбәттәме?

Шәехмирза. Ә, әй-йе, әй-йе... Мин аның философ икәнлеген тәгаен беләм. Европада миннән кала иң зур галимнәрдән саналырга тиешле.

Нигъмәт. Муса әфәнде, профессор сезгә шулай туп-туры үзе килеп төштемени?

Муса. Әй-йе... Ул минем бөтен әсәрләремне укып чыккан. Мин дә аның хакында француз журналларыннан шактый гына нәрсәләр моталәга кылган[1] идем. Профессор хәзрәтләре ана ягыннан безгә кардәш тә була икән.

Сәлим. Бу Советлар хакында нәрсә ди?

Муса. Ул хакта озак сөйләшмәдек. Шулай да Советларга кире икәнлеге күренә.

Габдуллаҗан. Советлар яклы булган профессорларның профессорлыклары да Шәехмирза әфәнденең адвокатлыгы шикелле генәдер инде.

Шәехмирза. Габдуллаҗан әфәнде, сез, беренчедән, мещан, икенчедән, торгаш. Шуңа күрә, гыйлем-фән хакында сүз барганда, тыңлап кына торырга тиеш.

Габдуллаҗан. Сез, Шәехмирза әфәнде, юләр балык. Башка түгел.

Шәехмирза. Ә син идиот...

Звонок.

IX. Әүвәлгеләр, Насих, Сәлимгәрәй.

Насих. А-а-а, татарның бөтен могтәбәрләре монда икән. Хәерле кич, әфәнделәр.

Күрешәләр.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, банкетыбызны алып бару хакында берәр мәслихәт бирүегезне үтенәм.

Шәехмирза. Менә монда мәсьәләнең иң зур ноктасы бар. Кемгә алдан сүз бирелергә тиеш?

Габдуллаҗан. Ә минемчә, банкетның рәисе баштан сөйләргә тиеш.

Нигъмәт. Юк, алай түгел ул.

Шәехмирза. Үзем баштан сөйлим, үзем.

Муса. Әфәнделәр, башлап мин сөйләргә тиеш.

Насих. Нигә мин түгел, син кем булдың соң?

Барысы. Мин, мин сөйләргә тиеш! Мин!..

Искәндәр керә.

---

[1] *Моталәга кылу* — танышу.

Искәндәр. Әфәнделәр, сәлам!

Барысы. Мәрхаба, профессор хәзрәтләре!..

Башларын иялэр. Искәндәр баскан килеш кала.

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук бүлмә.

II. Дилбәр, Мәйсәрә, Искәндәр, Габдуллаҗан, Насих, Шәехмирза, Сәлим, Нигъмәт, Апуш, Муса, Сәлимгәрәй.

Искәндәр. Әфәнделәр, сезнең белән бер мәҗлестә булуыма мин бик шат! (*Төртә.*) Гафу итегез.

Сәлим. Профессор әфәнде, татар тарихы хакында Америка голәмасы[1] берәр нәрсә эшлиме?

Искәндәр. Бик нык эшли. Ул хакта, гомумән, эшләр бик кызу бара. Татар тарихын тикшерү өчен махсус алтмыш биш катлы бина төзелде. Һәм дә йөз дә сигез автомобиль хәзерләнде.

Сәлим. Нәрсә соң ул алай, Америка голәмасын татар тарихын тикшерергә мәҗбүр итте?

Искәндәр. Мөһим бер ярлык[2]. Ул ярлык хакында мондагы матбугат та бик шаулаган, дип ишеткән идем.

Сәлим. Теге бер мулланың бер мужиктан урлап алган ярлыгымы әллә?

Искәндәр. Әйе, мужиктан бер мулла, мулладан бер хәлфә урлаган ярлык. Аны аэроплан белән бер спекулянт Америкага китереп, миллион долларга сатты. Менә инде шул ярлык татар тарихына нык нигез ителеп алынды. Аннан соң иске Болгар ханнарының ярлыкларын, Арслан ханның бөтинамәсенең бер нөсхәсен Һинд голәмаларыннан берсе безгә, Америкага китереп тапшырды. Икенче нөсхәсен Русиядә дигәннәр иде. Шуны эзләргә дип мин монда килдем.

---

[1] *Голәма* — галимнәр.

[2] *Ярлык* — указлар кәгазе. Товар бәясен күрсәткән кәгазь.

С ә л и м. Соң берсе булгач, аның икенчесе нигә кирәк?

И с к ә н д ә р. Дөрес, артык кирәге юк. Ләкин без аларны чагыштырып карамакчы булабыз. Сез, Габдуллаҗан әфәнде, шул ярлыклар хакында миңа бирәр мәгълүмат бирә алмыйсызмы?

Г а б д у л л а җ а н. Миндә, профессор әфәнде, ярлыклар юк.

С ә л и м. Профессор хәзрәтләре, Чыңгыз хакында Америка голәмасы нәрсә ди?

И с к ә н д ә р. Бик шәп, ди. Әле мин китәр алдыннан гына Чыңгыз гаскәрләренең Америкага килеп сугышканлыгы һәм Американы алуы турында бик зур гыйльми бәхәсләр булды. Чыңгыз ханның Тимер Йөрәк исемле бер бик көчле батыры булган икән. Шул батыр, үз янына кораллы йөз кеше алып, бик каты сугышлардан соңында, Американы алган. Җон даласына очрап, шунда бөтен гаскәре белән харап булган.

С ә л и м. Җон даласы, дисезме?

И с к ә н д ә р. Әйе, Джунгылы дигән мәшһүр җирне ишеткәнегез бармы? Менә ул Джунгылының асыл исеме Җон даласы икән. Аңар ул исемне башта татарлар кушканнар икән.

С ә л и м. Ай... Рәхмәт!

Н а с и х. Менә мәрхүм падиша хәзрәтләренең кучере, ат караучысы татар булган. Менә бит падиша хәзрәтләре дә татарларга ничек ышанган. Менә хәзерге Совет власте, төрле халыкларга җөмһүриятләр биреп, утарларны талап алып, халыкны узындырды.

С ә л и м г ә р ә й. Әле тагын көчләп татар телен укыталар.

Н а с и х. Да, да, бусы инде — бик зур ахмаклык. Безгә татарларга культура кирәк, ә алар татарча укытып маташалар. Мәдәни һичбер мәмләкәттә татарча укытмыйлар. Ә монда татар теле укытырга уйлап чыгарганнар. Җитмәсә, урысларга да укытып маташалар бит.

М у с а. Юк, татар телен бөтенләй онытырга ярамый. Милли тел сакланырга тиеш. Минемчә, урысларга тел өйрәткәнче ислам динен өйрәтү артыграк булыр иде.

Г а б д у л л а җ а н. Кунаклар, бераз ашап аласы иде. Кызым, кызым, Мәйсәрә, кая югалдың, чүпрәк баш?

М ә й с ә р ә. Нәрсә, атакай?

Г а б д у л л а җ а н. Кызым, профессор абзаң белән сөйләш.

Б а р ы с ы чыгып китәләр.

III. Искәндәр һәм Мәйсәрә.

Искәндәр. Туташ, дөньяда сезнең иң зур теләгегез нәрсә?

Мәйсәрә. Кияүгә чыгу. Һи-һи-һи...

Искәндәр. Бик яхшы. Рәхмәт, акыллы сүз әйттегез. Билгедә торкан киявегез бармы?

Мәйсәрә. Бар.

Искәндәр. Кем?

Мәйсәрә. Электәгесеме, хәзергесеме? Электәгесе — энҗечe Хәбибрахман улы.

Искәндәр. Ә хәзергесе?

Мәйсәрә. Хәзергесе — син.

Искәндәр. Рәхмәт. Бу да акыллы сүз. Сез, туташ, бик акыллы икәнсез.

Мәйсәрә. Әти генә мине юләр дип тирги. Шуның өчен тизрәк кияүгә чыгасым килә дә бит. Син мине тиргәмәссең бит?

Искәндәр. Юк, юк, мин сине автомобильдә генә йөртермен.

Мәйсәрә. Синең үз автомобилең бармы?

Искәндәр. Минем йөз дә биш автомобилем бар.

Мәйсәрә. Йөз дә биш? Бик күп икән. Ә син миңа күптәннән гыйшык тотасыңмы?

Искәндәр. Биш елдан бирле.

Мәйсәрә. Мескен. Нигә соң сәлам хатлары бер дә язмадың? Ә туебыз кайчан булыр?

Искәндәр. Теләсәгез бүген үк мөмкин. (*Төртә.*)

Мәйсәрә. Пәрәмәч!.. Нигә төртәсең. Әле никах укылганы юк ич!

IV. Әүвәлгеләр һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Нәрсә, ни бар?

Мәйсәрә. Әти, без туй хакында сөйләштек.

Габдуллаҗан. Ничек, профессор әфәнде, сез ризамы?

Искәндәр. Риза, ләкин бер шартым бар. Миңа сез придан итеп Болгар ханнарының тарихи ярлыкларын һәм Арслан ханның бөтиен бирергә тиешсез.

Габдуллаҗан. Миндә һичбер төрле ярлык юк.

Искәндәр. Бирсәгез, иртәгә туй. Бирмәсәгез, гафу итегез.

Мин, бүген үк Дилбәр туташка өйләнеп, Америкага китәм.

Дилбәр күренә.

Габдуллаҗан. Бирә алмыйм. Мирас ул.

V. Әүвәлгеләр һәм Дилбәр.

Габдуллаҗан белән Мәйсәрә яшеренеп каранып утыралар.

Искәндәр (*тегеләрнең караганнарын сизеп*). Дилбәр туташ, әткәгез миңа сезнең фикерегезне ирештергән иде. Мин башта Мәйсәрәгә өйләнмәкче идем, хәзер инде сезгә өйләнергә булдым. Сез ризамы?

Дилбәр. Мирси, мусио!.. (*Реверанс ясый.*) Риза!..

Муса керә.

Муса. Профессор әфәнде, сез мине бик хафага салдыгыз. Гүя сез Габдуллаҗан байның кызына өйләнмәкче буласыз, имеш, дөресме?

Искәндәр. Шулай уйлаган идем.

Муса. Сез ул эшегез белән бик зур ялгышлык эшлисез. Аның кызы юләр, шыр тиле, надан, тәрбиясез, авыру. Аның әбисе дә шашып үлде. Габдуллаҗан үзе дә урлашып кына баеды. Революция вакытында халыкны талап баеды. Жулик, карак ул, дивана.

Габдуллаҗан (*чыдаша алмыйча атылып чыгып*). Кем карак? Кем юләр? Кем жулик? Нәрсәңне урладым? Кем күргән, ә, кем күргән? Тоттыңмы? Ә?.. Син үзең шифырт, син үзең күмер карагы.

Сугышалар. Халык җыела.

Габдуллаҗан. Җәмәгать, менә шаһит булыгыз, менә бу күмер карагы мине карак дип атады!

Искәндәр. Җәмәгать, бернәрсә дә юк. Сабыр!.. Болай үзара гына. (*Габдуллаҗанны читкә алып.*) Габдуллаҗан әфәнде, ярлыкларны бирсәгез, хәзер туй итәрбез. Юкса Дилбәр туташ минем хатыным дип хәзер игълан итәм.

Габдуллаҗан. Ярый. Аллага тапшырдым. Риза. Хәзер алып килермен. У-у, сине, күмер карагы! Йә, Мәйсәрә минем хатыным дип игълан итегез!

Искәндәр. Әфәнделәр, хәзер мин сезнең алдыгызда бик зур эш ачачакмын... Әфәнделәр, мин өйләнәм...

Б а р ы с ы. Өйләнәсез! Кемгә?

И с к ә н д ә р. Мин... (*Габдуллаҗанга карый, Дилбәргә карый.*)

Г а б д у л л а җ а н. Ярый, ярый, риза. Алып киләм... (*Чыгып барганда.*) У-у... сине, күмер карагы! (*Кизәнә.*)

М у с а. Профессор әфәнде, зинһар, байлыкка кызыкмагыз, кызы юләр бит. Җырлый да, бии дә, пианинода уйный да, французча сөйләшә дә белми. Минем кызым милли алтын бит!..

Г а б д у л л а җ а н керә.

VII. Әүвәлгеләр һәм Г а б д у л л а җ а н.

Г а б д у л л а җ а н. Менә, кияү, рәхим ит! Бөтен бәхетемне кызым белән сиңа тапшырам!.. (*Искәндәр алып язуларны карый.*)

Ш ә е х м и р з а. Профессор әфәнде, Америкага баргач, зинһар, миңа берәр профессорлыкка урын хәзерләп куегыз әле.

И с к ә н д ә р. Ничек, Мәйсәрә, бу кешегә профессорлыкка урын хәзерлимме?

М ә й с ә р ә. Хәзерлә.

И с к ә н д ә р. Ярый, профессор буласың. (*Төртә.*)

С ә л и м г ә р ә й. Профессор әфәнде, полициядә берәр урын табылмасмы?

И с к ә н д ә р. Табылыр. Әфәнделәр, мин бүгенге милли тарихи кичәне яңача үткәрмәкче булам. Шуның өчен карт-лардан бер биш минутка гына чыгып торуларын үтенәм.

Б а р ы с ы. Чыгабыз, чыгабыз!..

Г а б д у л л а җ а н. Ярый, ярый, әйдәгез, кунаклар, кияү белән кызның саулыгына бераз пирәшләп ала[1] торыгыз!

Чыгалар.

И с к ә н д ә р. Ә син, Мәйсәрә, бар, ак күлмәгеңне киеп чык. (*Төртә.*)

М ә й с ә р ә. Төртмә әле, юньсез, никах укылганы юк ич әле. Һи-һи-һи!.. (*Чыга.*)

---

[1] *Пирәшләп алу* — кәефләнеп, бәйрәм итеп алу.

X. Искәндәр.

Искәндәр. Мондагы халык үзләре тарихи ярлыклар икән. (*Ярлыкларны күтәреп чыгып китә.*)

XI. Мәйсәрә, соңыннан башкалар чыга.

Мәйсәрә (*кереп, Искәндәрнең киткәнен күреп*). Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм, кая киттең?! Качты, качты!.. Әткәй, әткәй, әткәй!..

Габдуллаҗан. Нәрсә, ни бар?

Мәйсәрә. Әткәй, киявең качты!..

Габдуллаҗан. Ә?

Барысы. Тес-с-с!

Габдуллаҗан. Харап булдык! Нәрсә карап тордың! Соң син, чүпрәк баш, ни карап тордың!..

Барысы. Тес-с-с!.. Тегеннән булмасын.

Габдуллаҗан. Ә?

Барысы. Утларны сүндер!..

Габдуллаҗан. Тес-с-с!..

Барысы. Тес-с-с!..

Утлар сүндерелә.

Пәрдә.

1923 ел

Әсәргә анализ

Үткән тормыш турында язганда персонажларга бәяне беренче чиратта аларның җәмгыятьтә тоткан урыннарына карап бирү гадәткә кергән. Персонаж, мулла яки бай булса, һичшиксез, холкы начар, кире тип, ә ярлылар уңай сыйфатларга ия булганнар. Әкият, мәзәк, мәкальләрне генә искә төшерегез. Аларда байны мактап, ярлыны яманлаган урын күрмәссез.

Революциядән соң, теләсә-теләмәсә дә, язучылар байларны яманларга, алардан көләргә, ярлыларны мактарга тиеш булдылар. Ә бит, кем булуына карамастан, кеше юньсез дә, юньле дә була ала. Юньсезлекнең дә, яхшылыкның да төрләре күп. Сатирик әдип, гадәттә, булдыксыз, юньсез кешеләр

турында яза, юньсезлекнең тирәнрәк яшеренгәннәрен эзли. Шуңа күрә сатирик типлар һәр заман өчен дә актуаль типлар булып калалар. «Американ» комедиясе персонажлары да шундыйлар.

«Зәңгәр шәл»дә автор персонажларыннан көлсә дә, мелодрама жанры кысаларыннан чыкмый. Персонажларын мыскыл итми, үз итеп көлү белән чикләнә.

«Американ» исә — комедия. Сатирик әсәрләр жанры. Сатира жанрында, персонажлар яки автор ни әйтсә дә, укучы шуның капма-каршы мәгънәсен аңлый. «Американ» комедиясенең исеме үк шул кагыйдәгә буйсынган. Автор әсәренә «Американ» исеме биргән. Ләкин әсәрдә америка кешесе юк.

«Американ» комедиясенең төзелеше «Зәңгәр шәл» әсәренең төзелешенә охшаган. Пәрдәләрнең һәркайсы мөстәкыйль сюжетка ия. Һәркайсының үз конфликты бар.

Беренче пәрдәдә студентлар, «бүгенге көн җепләреннән киләчәккә юл сузабыз», тарихны күмеп яңа тормыш төзибез, дип җырлыйлар. Күрәсез, яшьләрнең дәгъвасы зурдан.

> Искә төшерик. Сатирик әсәрләр зур дәгъвасы[1] булган кешенең эчке бушлыгын ачып салалар. Әртыру — сатираның иң яраткан алымы.

Биремнәр

1. Беренче пәрдәдә студентларның дәгъвасын беләбез. Шуңа ирешү өчен, алар нинди чаралардан файдаланалар?

2. Мусаның да дәгъвасы тау хәтле. Дәгъвасы белән теләгенә ирешү мөмкинлеге (эчке бушлыгы) турында сөйләгез.

3. Габдуллаҗан үзен алдынгы, әдәпле, укымышлы кеше итеп күрсәтә. Гамәлдә шуларның киресе булып чыга. Исбат итегез.

Муса белән Габдуллаҗанның уртак сыйфатларын табыйк. Алар икесе дә революциягә кадәр баеп калганнар. Яңа тормышта дан һәм байлык бирерлек җылы урын эзлиләр. Икесе дә үзләренең башкалардан өстенлегенә аз гына да шикләнмиләр. Ләкин икесе дә — надан, тәрбиясез, үзләрен генә кай-

---

[1] *Дәгъва* — мәгънәләренең берсе: мин-минлекле, ләкин нигезсез омтылыш.

гыртып яшәүче кешеләр. Аерма дәгъваларының эчтәлегендә генә. Муса Америкага китеп, милләтче буларак шөһрәт казанмакчы була, ә Габдуллаҗанга шөһрәт кирәкми, аның дәгъвасы — баю. Сандык-сандык алтынлы булу.

Пьесада катнашкан элеккеге адвокат, галим, түрә дә Муса белән Габдуллаҗан ишләре. Муса аларны Искәндәргә: «Шәһәребезнең голәмасы, могтәбәр милли кешеләр»,— дип мактый.

Шундый «шөһрәтле галимнәрнең» берсе — адвокат Шәехмирза.

Шәехмирза мактану ягыннан Мусадан да арттырып җибәрә. Нибары факультет ярым белеме белән Америкада профессор булып эшләргә хыяллана. Ул да үзен арада иң акыллы кеше дип исәпли, алай дию белән генә дә канәгатьләнми, үзен бердәнбер акыллы кеше дип уйлый. Башындагы пләшлеген дәлил итә.

Әнә шул «шәһәрнең танылган галимнәре», Америка профессоры янында ялагайланып, мактана-мактана, үзләренең буш кеше булуларын ачып бирәләр.

Пьесаның беренче өлеше яңа тормышның булачак яшь түрәләре турында. Икенче өлеше, хәтта холыклары да охшагач иске чиновниклар турында.

Автор илне күтәрмә хәленә калдырган элеккеге түрәләрне, милләтчеләрне фаш итә. Шул ук вакытта Искәндәр һәм Искәндәрдән бер яклары белән дә аерылмаган яңа заманның «яңа кешеләренә» үз бәясен бирә.

Нәтиҗә

Язучы иҗатының үзенчәлеген белү өчен, аның әсәрләренең уртак якларын табарга кирәк дигән идек. Кәрим Тинчуринның ике пьесасын өйрәндек. Жанрлары төрле булса да, охшашлыкны тиз таптык. Кәрим Тинчурин ике әсәрендә дә төркем-төркем кешеләрнең барысын да уртак холыклы иткән. Мескен авыл халкын, горур качкыннарны, дорфа абыстайларны, яңа тормыш төзүчеләрне, иске тормышны юкка чыгаручыларны күрдек. Төркемнәрнең һәркайсы уңай сыйфатларын күрсәтергә өлгерми — шунда ук, үзе дә искәрмичә, кире сыйфатын ача. Алар — илдәге төрле иҗтимагый төркем вәкилләре. Төрле тарихи чорларда ил язмышын хәл итәргә тиешле, ләкин бу эшне булдыра алмаучы иҗтимагый төркемнәр.

Кәрим Тинчурин — үз психологиясе, холкы булган масса образын тудыру остасы. Ләкин үзенчәлекле шәхес холкын һәм кичерешләрен аның кебек оста ачучы драматург бармы икән?

Кәрим Тинчуринның тагын бер үзенчәлеге — хәтта кызганыч вакыйгаларны да юмор аша күрсәтә алуында. Татар әдәбиятында өч күренекле сатирик бар: Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан һәм Кәрим Тинчурин.

Әсәрләренең үткен фикер белән сугарылуы — Кәрим Тинчуринның тагын бер үзенчәлеге.

Әхмәт Фәйзи

(1903—1958)

Әхмәт Фәйзи (Әхмәтсафа улы Фәйзуллин) Уфа шәһәрендә һөнәрче гаиләсендә туа. Монда ул мәдрәсәдә укый. Малай чакта ук шигырьләр, пьесалар яза башлый. Унтугыз яшендә Оренбург шәһәренә килә һәм Көнчыгыш институты дип аталган югары уку йортына укырга керә. Ләкин 21 нче елгы ачлыктан качып Төрекмәнстанга китә. Анда балалар укыта. Өч елдан кабат туган шәһәре Уфага әйләнеп кайта һәм балалар укытуын дәвам итә. Татар язучылары элек-электән ил гизәргә яратканнар. Әхмәт Фәйзи дә шулай итә: көннәрнең берендә Донбасска юл тота. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Арча төбәгендә эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Күп әсәрен сугыш кырында, сугыш турында яза. Аннан кайткач, Мәскәүдә яши башлый.

Әхмәт Фәйзи үзенең каләмен төрле жанрларда сынап карый. Ул танылган юморист-сатирик та, драма әсәрләре, опералар, балетлар да яза. «Тукай» исемле тарихи роман, поэмалар, лирик шигырьләр, балладалар, җырлар да иҗат итә.

Мәскәүдә даими яшәсә дә, шагыйрь Казанга еш кайта. Авырый башлагач, Казанда яши һәм, августның эссе көннәренең берсендә, шунда вафат була.

Әдипнең иҗат юлы илдәге хаксызлык, хәерчелек, нигезсез шапырыну, «иң-иң» дип макталган юлбашчыларга табыну еллары аша үтә. Бу елларда әдипләргә, иске тормышны сүгеп, хәзергесен мактап, тормыш авырлыгының сәбәпләрен ниндидер эчке дошманнарга сылтап язарга кушыла.

Әмма илдәге хәлләрне үз күзе белән күреп, үз колаклары белән ишетеп, үз җилкәсендә татыган шагыйрь намусы мондый чикләүләр белән килешми.

Әхмәт Фәйзи дә, башкалар кебек, мактый да, зурлый да, дошманнар да эзли, әмма ничек кенә булмасын, үз сүзен, кичерешләрен әсәрләренә кертергә тырыша. Кайберен төрле алымнар эченә яшерә, кайберен интонация белән әйтә.

ЧЫК ҺӘМ КЫРАУ

Чын гөлчәчәк рәхәтләнеп чыкны эчте,
Кәгазь чәчәк кенә никтер җебеп төште.
Кырау төшеп гөлчәчәкне суык алды,
Кәгазь чәчәк кенә шунда исән калды.

1938 ел

Бирем

Шигырьнең тормыштагы ниндидер бер күренешкә метафора булуына шик юк. Шул күренешне тапсагыз, әсәрдәге образларның мәгънәсе ачыла. Автор әлеге әсәре белән ни әйтмәкче була? Шигырь язылган елга игътибар итегез. Бу еллардагы вакыйгаларны искә төшерегез.

УМЫРЗАЯ

Боз катлавы эрегәч, җир өстенә
Умырзая чыга, карагыз:
　　Умырзая чыга,
　　Умырзая калка,
　　Умырзая суза сабагын.
Боз катлавы кебек көнкүрештән
Чыгасым ла килә тизрәк,
　　Умырзая кебек,
　　Умырзая кебек,
　　Умырзая кебек тиз үрләп...
Умырзая бик тиз үсеп чыга,
Бик аз гына яши тураеп;
　　Умырзая бик тиз
　　Башын аска ия,
　　Умырзая сула моңаеп...
Юк, мин яшәр идем озак, озак.
Минем килми алай буласым:
　　Умырзая кебек,
　　Умырзая кебек,
　　Умырзая кебек суласым...

Юк, мин яшәр идем җәй ясаучы
Зур чәчәкләр белән җыелып;
Юк, мин үлмәс идем
Умырзая кебек,
Умырзая кебек боегып...

1933 ел

Бирем һәм сорау

1. Шигырьгә анализ ясагыз.

2. Әсәр үткән гасырның 30 нчы еллар вакыйгасын чагылдыра. Автор лирик герое аша нинди тип кешеләргә бәя бирә?

ЯШЬЛЕК

Зур таш багананың төбенә
Яшь гөл чыккан шытып.
Сыгылып тора яшь гөл, багананы
Җилкәсендә тотып.
Тик ул гөлнең зәңгәр күзләрендә
Шундый шатлык, көрлек.
Әйтерсең ул багананы түгел,
Тауны күтәрерлек.
Яшь гөл ничек авыр багананы
Күтәрсен ди, тиле!
Әмма никтер шушы әкияткә
Ышанасы килде.

1938 ел

Биремнәр

1. Әсәргә анализ ясагыз. Аның ике эчтәлеген табыгыз.

2. «Яшьлек» шигыренең эчтәлеге «Умырзая», «Чык һәм кырау» шигырьләренең дәвамы була ала. Шуны исбат итегез.

* * *

Әй мактала берәү. Мактау сүзе
Кабык булып үсә өстенә.
Үсә-үсә кабык, теге кеше
Булып кала нәни төш кенә.
Үсә-үсә кабык калыная...
Күп көннәрнең ләкин берсендә
Ватып карасалар, имеш, күптән
Бернәрсә юк кабык эчендә.

Биремнәр

1. **Шигырьгә исем бирегез. Исем аның эчтәлеген чагылдырырга тиешлеген онытмагыз.**
2. **Шигырьне «Чык һәм кырау» шигыре белән чагыштырыгыз. Эчтәлекләрендәге охшашлыкны табыгыз.**

БҮРЕК ҺӘМ МИН

(*Мәсәл*)

Соры бәрән бүрекне мин,
Кеше башында күреп,
Кызыктым бит, үзем шундый
Бүрек алдым тектереп.

Килдем көзге каршысына,
Башка кидем бүрекне.
Карыйм: бүрек, әллә ничек,
Һич күтәрми күрекне.

Башны бераз иңкәйтеп тә,
Бераз иеп тә карыйм.
Бүрекне кырын салып та,
Артка чөеп тә карыйм.

Юк! Әй, тетәм бүрекчене:
— Ай-һай гамьсез икән син!
Әрәм иткәнсең товарны,
Килештерми теккәнсең!..

Җиде тапкыр төзәттердем,
Җидесе дә ошамый.
Хатын тирги, нигә дисәң,
Көзге миннән бушамый.

Көзгедән күп карап торгач,
Мин, ниһаять, төшендем...
. . . .

1952 ел

Бирем

Әсәрнең беренче өлеше шундый. Икенче өлешен үзегез табыгыз. Юмор өлешләренең бәйләнеш үзенчәлеген исегезгә төшерсәгез, ахыры тиз табылыр. Автор аны шигыренең бер юлына сыйдырган.

Нәтиҗә

Әхмәт Фәйзи шигырьләренең эчтәлеген ике өлешкә җыя алабыз.

Лирик шигырьләрнең эчтәлеге — борчылу, ярсу, кайгыру, сызлану. Бу хисләрнең сәбәбе — тормыштагы гаделсезлек, хаксызлык, ирексезлек. «Умырзая» шигырендә әдип аларны боз катлавы белән тиңли; «Яшьлек»тә — тимер багана; «Чык һәм кырау» шигырендә кырау, ди. Бу әсәрләрендә Әхмәт Фәйзи — мескен, көчсез, моңлы, зарлы кеше. Ә бит ул куркак та, мескен дә түгел. Сугыш елларында, хәрби журналист буларак, куркыныч урыннарны үзе эзләп йөргән кеше.

Бүтән шигырьләрендә әдип тормышның ваграк вакыйгаларын сурәтли. Заманга ярашып яшәүче кире типларга бәя биргәндә иелгән башын күтәрә. Көлкеле шигырьләренең һәр строфасында көр тавышы белән үзен сиздереп тора. Бу әсәрләрендә әдип үзен гипербола (арттыру), үткен фикер (каршы якларны куша алу) остасы итеп күрсәтте.

Тормыш гаделсезлеге белән берничек тә килешә алмаучы әдипнең ирекка сусавы һәр шигырендә диярлек ят, ләкин көчле тавыш булып көй эченә килеп керә.

Мөстәкыйль эш

Әхмәт Фәйзинең түбәндәге ике шигыренә анализ ясагыз.

ЯФРАК ҺӘМ ЧИКЛӘВЕК

Көзге җилләр исте күңелсез,
Корган яфрак төште өзелеп.
Һәм әйтте ул шунда көрсенеп:
— Бар да бетте... Бар да гомерсез...

Озак тормый аның артыннан ук
Өзелеп төште күрше чикләвек,
Һәм дәште ул: «Минем яшисем юк
Яфрак кебек тарыгып[1], чикләнеп».

Яфрак гомере сүнде, кабынмады
Һәм калмады исеме яшьләргә.
Ә чикләвек шытып тамырланды
Һәм тотынды яңадан яшәргә.

1939 ел

---

[1] *Тарыгып* — яшәү шартларыннан, ялгызлыктан һ. б.дан кыенсыну, ялыгу.

КӨЗ

Алтынланган куе әрәмәлек
Үзе моңлы, үзе сөйкемле.
Яфраклары төшә бөтерелеп,
Үлгән күбәләкләр шикелле.

Агачларның алтын яфракларын
Күлгә таба әйдәп җил исте.
Кургаш төсле авыр дулкыннарын
Акрын гына чайкый күл өсте.

Шаулаштылар күлнең камышлары,
Нәрсәдәндер боегып, зарыгып.
Ахры ташлап киткән аккошлары
Белән үткән җәйне сагынып.

1939 ел

Клара Булатова

(1936 елда туган)

Талантлы шагыйрә, гомере буена балаларга татар әдәбиятының матурлыгын тоярга өйрәткән укытучының берничә шигыре белән танышыйк. Шагыйрәнең «Каурый канат — Җил Атым» китабын кулыгызга алып, өч-дүрт шигырен аңлап укысагыз, җыентыкны ахырына кадәр укып чыгуыгызны сизми дә калырсыз. Үзегез дә аңлап бетермәгән рухи халәтегезне шигырьләрдә күреп уйга калырсыз, авторның сезгә, күптәнге якын дусты итеп, серләрен ачуына сокланырсыз. Ә тойгы-кичереш кебек серле халәтне ничек итеп сүз, сурәт белән күз алдына китерүен күреп уйга калырсыз.

«Шәкертләремә» шигырендә лирик геройның автор үзе булуына шик юк. Әсәрне укыганда ук, көн дә диярлек, борчылуларын, сөенечләрен яшерергә тырышып дәрес бирүче укытучының рухи халәтен күрерсез.

ШӘКЕРТЛӘРЕМӘ

Кәефемне күпме бозды болар,
Үзәгемә күпме үттеләр!..
Тик һаман да янга якын шулар,
Минекеләр, үземнекеләр.

Минекеләр, үземнекеләр шул,
«Үземнекеләр» дип үстерәм.
«Үземнекеләр» дип гаеплим дә
«Үземнекеләр» дип кичерәм.

Көннең ямен, тәмен, борчуларын
Тик шулардан җыям, таратам.
Плюс-минусларын бергә кушып,
Үземнеке итеп яратам.

Мәктәптә балаларга белем бирү лирик геройны тынычландыра, юата. Юанычым шунда гына, тик дәрестә генә «көннең ямен алам», борчуларым таратам ди, лирик герой.

«Зилзиләне кабат уятма» шигырен игътибар белән укып, эчтәлеген аңларга тырышыгыз.

ЗИЛЗИЛӘНЕ[1] КАБАТ УЯТМА

Кичтән бөтен бакча шаулап торды,
Төне буе барды зилзилә.
Иртән әллә ничек кабат тынды —
Нидән тынганлыгын кем белә?

Карлыганнар арасына посып,
Җиргә сеңеп йоклап җил ята.
...Кодрәтең киң, Тәңрем, инде тынган
Зилзиләне кабат уятма!

Шигырь табигать күренеше турында. Алай да безне соңгы ике юл шикләндерә: лирик герой, давыл кабатланмаса ярар иде дип, Аллага ялвара. Давыл чыгу лирик герой өчен Аллага ялварырлык хәсрәтме? Давыл мәгънәсен Клара Булатованың башка шигырьләреннән эзлибез. «Нәрсә булды?..» шигыренә тукталыйк.

* * *

Нәрсә булды? Ни дип әле
Төнге сәгать икедән
Уяндым да (мөмкинлек бар!)...
Йоклый алмый интегәм.

Йокы качар ни сәбәптер?
Әйтә алмыйм үзем дә.
Кайдан, нинди хәбәр килер
Февральнең бу көнендә?

Юкса инде гомерем буе
Шул йокыга мохтаҗ мин,
Ятсам йокыларым килмәс
Хәлгә нишләп җиткәнмен?

Әле Кадер кич тә түгел,
Иртәгәдер анысы.
...Йокы бүлеп яңа афәт
Кузгалмаса ярыйсы.

[1] *Зилзилә* — давыл.

Биремнәр

1. «Зилзиләне кабат уятма» шигырендәге давылның һәм җилнең мәгънәсе бу шигырьдә әйтелгән. Аңлатыгыз.
2. «Яшиселәр инде яшәлгән дә...» дип башланган шигырендә (өзек) без эзләгән хис сәбәбенең берсе ачык әйтелә. Шуны аңлатыгыз.

* * *

Яшиселәр инде яшәлгән дә,
Яшәлеп тә әле бетмәгән.
Бу дөньяда инде безнең башка
Ниләр килеп, ниләр китмәгән...
Безнең буын ниләр кичмәгән...

Илдә булды күпме кайнашулар,
Җиргә килде күпме афәтләр,
Ничә тапкыр туздь, тапталынды,
Кайтарылды гореф-гадәтләр.

Искеләре калкып яңардылар,
Яңалары тумый искерде —
Уңнан сулга, сулдан уңга бәрелү
Тинтерәтә байтак кешене...

«БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» ДИГӘНГӘ

«Бәхетлеме син?» дигәнгә
Әлегә җавап бирмим.
Бәхетлеме мин, түгелме —
Әлегә анык белмим.

«Бәхетледер син» дисәләр,
Мин тагын җавап тапмыйм.
«Юк» дип башымны чайкамыйм,
«Әйе!» дип ияк какмыйм.

«Бәхетле бит син!» дисәгез,
Ни әйтергә дә белмим.
...Мин бүгенге бәхетемнең
Үсүен көтеп йөрим.

Сорау

Лирик герой бәхетлеме?

БЕЛЕМЕБЕЗНЕ НЫГЫТУ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР

Һади Такташ

АЛСУ

(*Өзек*)

Урам ташларына карлар ява,
Кар томалый чана юлларын,
Карда шуа-шуа Алсу килә,
Җиң эченә тыккан кулларын...
Җилгә каршы җылы сулышлары
Туңып бөдрә чәчен ак ясый...
Юл буена аны тирги-тирги,
Сүгенә-сүгенә кайта Газзәсе:
«Алсу, тукта инде акыллым,
Абау,
Тагын карга батырдың!..» —
Ул үпкәләп читкә китә. Аны
Алсу тагын ялынып чакыра:
«Кил, уйнамыйм, бетте...
Кил инде!»
Үзе — килсә, карга батыра.

Салкын карга басып Алсу килә:
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә —
Усал түгел кебек шикелле...

Алсу, бүлмәсенә керү белән,
Өске киемен алып ташлады;
Ватык көзгесенә карый-карый
Карлы чәчен сүтә башлады...

Аңа бүген әллә нәрсә булган
Бер җырлыйсы килә, бер көлә,
Бер онытылып, кинәт керфекләре
Бер ноктага килеп төртелә...

1929 ел

Сибгат Хәким

ҖИТЕНЧЕ КЫЗ

Мин чыгам иртән кырларга,
Кырларга — тугайларга;
Үзем җитен арасында,
Күңелем әллә кайларда.

Зәңгәр җитенем, җилләрдә
Уйнап сөендерәсең;
Килә бөтен кешеләрне
Матур киендерәсем.

Җитенкәем, тик бер көндә
Коела синең чәчәгең;
Мин менә мәхәббәтемнең
Телим озак яшәвен.

Мин чыгам иртән кырларга,
Кырларга — тугайларга;
Үзем җитен арасында,
Күңелем әллә кайларда.

1953 ел

Хәсән Туфан

ЛАНДЫШ

Минем шактый кара куышка
Ландыш кебек ап-ак киемле
Доктор сеңел керде: тормыштан
Сәлам булып килгән шикелле.

Юатты ул:
— Йөрәгең сау, абый.
— Сау да, сеңлем, көне санаулы...
— Бәлки, абый, васыятең бардыр?..
— Тапшыр илгә... соңгы сәламне...

Якты булып кара төннәрдә,
Бер кат түгел, шулай күп килде.
Аның аша хәлне белергә
Казан үзе килә күк иде.

Ландыш кебек ап-ак киемле! —
Кем идең син, белмим исмеңне?
Мин ул чакта сорый алмадым,
Сорый торган чак түгел иде.

Мин сау, сеңелем,
Син дә сау микән?
Сине бит бер
күрәсе иде:
Кайтмый калган абыйларыңның
Сәламнәрен бирәсе иде.

Эзлим сине, ләкин табалмыйм:
Күп икән, кү-үп
Синең тәслеләр —
Ландыш кебек ап-ак күңелле,
Кояш кебек якты йөзлеләр.

Алар бар да, җанлы ландыш күк,
Хәтерләтә синең төсеңне.
Шул ландышлар арасында тик
Табалмамдыр, ахры, үзеңне...

Күз сал да бер, әгәр сау булсаң,
Бәхетебезне искә ал, сеңлем:
Ландышларны шундый күп итеп
Үстерүче илебез сау безнең!

1956 ел

Шигырьләрнең өчесе дә лирик геройның матурлыкка соклануы турында. Һади Такташ Алсуның матурлыгы турында бер юл да язмый. Ул аның холкына соклана. Автор кызның матурлыгын эш-гамәлләрендә, һәрвакыт шат, шаян булуында күрә. Ләкин шагыйрь шаян, шат күңелле һәм акыллы кыз, дими. Алсуның бу сыйфатларын без аның эш-гамәлләре аша үзебез ачыклыйбыз. Кызның матурлыгы аның бәхетле булуында дип нәтиҗә чыгарабыз.

Сораулар

1. Сибгат Хәким җитенче кызның нинди сыйфатына соклана?
2. Хәсән Туфан табибә кызның нинди сыйфатын мактый?

Такташ, Алсуын читтән күзәтеп торып, ишеткәнен яза кебек. Алсуны без дә автор белән бергә күзәтәбез. Ләкин шагыйрь түзми, шигыренә үзе килеп керә һәм Алсуына бәя бирә:

Салкын карга басып Алсу килә:
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә —
Усал түгел кебек шикелле...—

ди.

3. Сибгат Хәким белән Хәсән Туфан шигырьләрендә авторларның ничек катнашуын аңлатыгыз.

Шагыйрьләрнең матурлыкны ничек сурәтләвен белик.

Такташ Алсуның холкын да, рухи халәтен дә күрсәтеп бирә.

Сибгат Хәким лирик героеның кызга булган мәхәббәт дәрәҗәсен табигать күренешләре аша сурәтли.

Хәсән Туфан табибә кызны яхшы эшләгәнгә һәм Ватанны яраткан өчен мактый.

Ибраһим Гази

МАЛАЙ БЕЛӘН ЭТ

Без барыбыз да бер яшьтәрәк: бик яшь тә түгел, ләкин карт дип әйтеп карасыннар иде әле безгә!.. Әйе, карт түгел, әмма һәркайсыбызның өендә хатыны, бала-чагасы бар. Безнең ярты күңел биредә булса, яртысы алар янында.

Без хәзер фронтка якын гына бер җирдә резервта торабыз. Димәк, вакыт күп, ә эш әллә ни түгел. Дөрес, кайчагында фриц дигәнең, килеп, безнең өскә бомбалар ыргытып киткәли. Ләкин без инде аңа күнеккән. Аның белән генә безнең исне китәрә алмый ул.

Тышта яз. Агачлар чәчәктә. Өй кыегында — сыерчыклар, һавада — тургай. Шундый тыныч, шундый рәхәт, якында гына сугыш барадыр, кешеләр кырыладыр дип һич кенә дә ышанасы килми. Ә бит әле кичә генә диярлек безнең өстә туп ядрәләре үкерә иде, үлем дигәнең, үкчәгә баса-баса, арттан ияреп йөри иде, ә бүген барысы да әкренләп онытыла башлаган, ә иртәгә, бәлки, бөтенләй дә онытылыр. Кеше дигәнең шундый итеп яратылган инде ул.

Кайвакыт без шулай яшел чирәм өстенә түгәрәкләнеп утырабыз да, кесәдә ауный-ауный тетелеп беткән иске хатларны, карточкаларны чыгарып, татлыдан да татлырак истәлекләргә

чумабыз. Бу безнең өчен зур бер юаныч була. Безнең икенче юанычыбыз — бер малай.

Без бара торган ишегалдында өч-дүрт яшьлек бер малай бар. Кап-кара күзле, озын керфекле, түгәрәк йөзле чибәр генә бер татар малае. Ишегалдына чыксак барыбызның да күзе шул малайда. Барыбыз да аңа гашыйк. Барыбыз да аны үз малаебызга охшатабыз. Без, татарлар, охшатабыз икән, моның әле беркадәр нигезе бар, чөнки ул — татар малае. Ләкин безнең белән руслар да, хәтта латышларга хәтле, елтыр күзле бу чибәр татар малаен кай төше беләндер үз малайларына охшатып, аның өчен үлеп китәргә торалар. Кыскасы, малай безнең кулдан төшми. Алты-җиде балага тиешле ата мәхәббәте бичараның берүзе өстенә төшкәч, аңа шактый авырга туры килә торгандыр...

Малай һәркөн иртүк бабасы белән бакча казырга чыга. Аның артыннан, күләгә шикелле тагылып, өч аяклы бер эт килеп чыга. Гади эт дип уйламагыз аны. Ул, инде ике-өч тапкыр бомбежкага эләгеп, арт аягын өздергән. Немец солдатлары аны бер тапкыр атып ташлаганнар инде. Ә ул һаман исән. Исән генәме соң! Ул — гашыйк. Безнең шикелле ул да малайны үлеп ярата. Алар икәүләп бабаларының аяк астында өзлексез чуалалар. Карт үзен тәмам алар ихтыярына тапшыра. Малай бабасының аякларына асылынып, муенына атланып, сакалын тартып, әлләниләр кыланып бетә. Ә эт аның шатлыгын уртаклашып, койрыгын болгый-болгый, малай тирәсендә өч аяклап сикеренгәли. Менә малай бабасына башын иергә куша. Алар бүрекләрен алмашып кияләр. Малайның матур башы бүрек эченә бөтенләй чумып китә. Ул бер кия, бер сала, ләкин бүрекне һичничек ярата алмыйча, үзенекен сорап ала да баш очына гына эләктереп куеп, бабасыныкын җиргә атып бәрә. Эт, шуны гына көтеп торган кебек, бүрекне эләктереп алып, әллә кая илтеп туфракка күмеп килә. Без көлешәбез. Малай да шырык-шырык көлә. Эт тә, бәлки, көлә торгандыр. Бабасы, малайны куып киткән булып, бер урында тыпырдап тора башлый. Ә малай абынып егылганга кадәр артына да борылып карамыйча йөгерә.

Бомбоубежищега да алар өчәү бергә төшәләр. Немец самолетларының гүләвен ишетү белән, эт койрыгын бот арасына кыстырып куя да, артына ялт-йолт карый-карый, алдан чаба, ә малай алпан-тилпән аның артыннан йөгерә. Эчкә кергәч, эт,

бөтерелеп, малайның аяк астына ук ята, колакларын торгызып, бомба гөрселдәгән саен сискәнеп, дустының зур кара күзләреннән үзенең акыллы күзләрен ала алмыйча карап ята. Фриц киткәч, бабасы аларны тагын алып чыга. Икенче бомбежкага кадәр алар тагын шулай уйнап йөриләр. Без бишәү эттән көнләшәбез. Чөнки малай аны керсез күңелдән ярата, ә безне кулыбыздагы шикәребез, печеньебез беткәнче генә ярата да беткәч зарыга башлый. Ул да түгел — тибешергә, тырнашырга тотына. Ә без аны йомарлап алабыз да көчләп-көчләп сөябез — бирелгән печеньенең, шикәрнең хакын чыгарабыз.

Бирем

Хикәянең ахырын языгыз. Башыгызга килгән беренче вариантны язарга ашыкмагыз. Укыган өлешнең темасын, ягъни ни турында булуын белсәгез, вакыйганы тәмамлау җиңел булыр.

Марсель Галиев

КОЯШНЫҢ ДӘВАМЫ

Син, яланаяклы малай! Олыларча, кулларыңны артка куеп, тузанлы юлга баскансың да, пирамида булып күтәрелгән тауга карап торасың. Зәңгәр тау — ераклыгы белән серле, серлелеге белән ерак, ә ераклык үзенә тарта, ашкындыра, каядыр әйди.

Синең өчен зур шәһәрләр, илләр бары тик шул тау артында гына. Зәңгәр күк гөмбәзе астында, офык белән чикләнгән түгәрәкнең нәкъ уртасында торасың, имеш. Синең шул офык пәрдәсен күтәрәсең, чит дөньяларга күз саласың килә. Җир белән күк кушылган урынга кулыңны сузып йөгерәсең, йөгерәсең, ниһаять, тауга менеп җитәрсең, ә офык һаман шул ераклыкта калыр. Син һаман шул зәңгәр түбә белән ябылган күк астындагы түгәрәк мәйдан уртасында...

Беркөнне зәңгәр экранда син Җир шарын якыннан күрерсең. Баксаң, шулкадәр кечкенә икән бит ул һәм никадәр зур да...

Син, гаҗизләнеп, олыларга мөрәҗәгать итәрсең.

— Чиксезлек нәрсә ул?

— Галәм.

— Ә галәм нәрсә?

— Бихисап йолдызлар, планеталар, кояшлар.

— Кояш бер генә булмыймыни?

— Кояшлар күп, улым.

— Ә мин ничәү?

— Бер генә. Әтиең дә, әниең дә бер генә. Туган илең дә...

Менә шул чагында инде син үзеңнең барлыгыңны ачасың. Юк, бу сабый чактагы кебек, менә бу — борын, менә бу — күз дип үзеңне өйрәнә башлаган, уенчыкларны ватып карап эчендә ни барлыгын белергә теләгән чагың гына түгел, ә бөтенләй икенче төрле... Таркатып карап та, кагылып карап та булмый торган илаһи күңел дөньясын ачу тантанасы бу! Менә шул чагында инде синең җиһаның киңәеп китә. Ераклык һәм вакыт чикләре юыла, чөнки син хыялыңда киләчәккә омтыла башлыйсың, ә хыял вакыт чикләрен беләмени!

Синдә эзләнү, хәтер, омтылыш, максат туа һәм җавап табылмаган мең-мең сораулар... Син әле күп сорауларга өлкәннәрнең дә җавап таба алмавын белмисең. Синең өчен әле өлкән кеше уйларга, эшләргә, калкан булып сине сакларга тиеш дип уйлыйсың, һәм беркөнне... син өлкән кешенең урынын алачаксың.

Син тугач та, күктә меңләгән ишләре арасында яңа йолдыз кабынды. Кинотеатрларда, стадионнарда, уку залларында синең өчен бер урын өстәлде.

Җиргә тапчылар җитми. Шагыйрьләр, игенчеләр, тукучылар, рәссамнар җитми. Шуларның берсе — син булырсың. Максатыңа ирешү сәләтеңә, белемеңә, тырышлыгыңа бәйләнгән.

— Читтән караганда Җир шары нигә балкып күренә?

Син аңа үзеңчә җавап табарсың. Миллионлаган кешеләр күзендә чагылган кояш нурларының балкышыннан диярсең син. Миллионнар арасыннан кемнеңдер күзләре сүнеп калса... кояш нурлары ул күзләрдә чагыла алмыйча адашып йөрер иде.

— Һәммә кеше дә яшәргә хаклы! — дип, дөньяга кычкырырсың син.

Бүгенге ачышны күптән инде ачасы бөекләрнең кайсыдыр сугышта корбан булуын белгәч, синдә җирдә барган афәтсугышларга карата нәфрәт уяныр.

Дөнья матурлыкка мохтаҗ. Дөнья моңарчы тудырылган матурлык хәзинәсенә синең дә өлешне көтә.

Табигатьнең искиткеч камиллеге, кешелек акылының тирәнлеге синдә соклану һәм гаҗәпләнү уятыр. Соклану,

гажәпләнә алу, олыгайгач та сабыйларча соклана алуыңны җуймау — кешенең иң изге сыйфатлары түгелмени!

Кешелек — даһи эшләре белән мәңгелек. Кояш гомеренә тиң. Һәм синдә бу танып белү горур фикер уятыр. Кешеләр уйлый һәм фикерли белүче, җирне бизәүче гөлләр икән бит. Ә гөлләр — кояшның дәвамы!

Син, чын кеше булып, кешелек океанына колач салып, йөзеп кереп киткәндә, ярда әниең, туган җирең, Ватаның кул изәп озатып калыр һәм кочагын җәеп каршы алыр. Аларга турылыклы булган кеше генә — кояшның дәвамы.

Конспект язабыз.

Мондый язманы галимнәр публицистика диярләр иде. Марсель Галиев үзе «Фәлсәфи уйланулар» дип атый. Сез аның хикәяләре, шигырьләре белән таныш. «Чатыр тау җиле» исемле бик матур нәсерен дә өйрәндегез.

Бирем

Текстның планын төзегез. Пландагы өлешләрне киңәйтебрәк язсагыз, конспект язган буласыз.

> Озын текстның төп өлешләрен үз сүзләрең белән язуга **конспект** диләр. Максатыбыз — язманың эчтәлеген өлешләп хәтердә калдыру һәм, кирәге чыкканда озын текстны кабат укымыйча, конспектка карап искә төшерү.

Аяз Гыйләҗев

ҮГИ АНА ЯФРАКЛАРЫ

Бер-берсенә сырышып утырган тәбәнәк агач келәтләр арасыннан ургылып чыккан дуамал җил такырда коенты бодайларны чүпләп йөргән эре, ак казларның канатларын каера, аларга тыныч кына ашарга ирек бирми, йолыккалый, туктаусыз бимазалап тора. Келәтләр авылдан шактый еракта, атау сыман калкулыкта, нәкъ жил күзендә тезелешкәннәр. Казлар очып китәргә җыенгандай берара җилгә буйсынып иярeп баралар да кинәт туктыйлар, ка-ка дип кычкырып, ялгыз түгеллекләренә өерелеп куаналар да, сүз берләшеп, тагын келәт алдындагы бодайлы машинага таба тартылалар.

Каравылчы Мифтахетдин, тол дүдәк булганга, төнлә генә түгел, көндез дә келәтләр янында урала. Ул, озын кулларын

җәеп, казларны куа башлый, учларын бер-берсенә сугып шапылдата, яргаланган юка тиреле кызгылт иреннәрен бөрештереп сызгыра:

— Кө-өш! Көш дим, каһәрләр! Фью-фью!

Мифтахетдиннең буйлы-буйлы көрән чалбарының утыра торган җиренә тегәрҗеп белән эре-эре атлатып дәү кызыл ямау салганнар, ул стоп-сигнал кебек янып, әллә кайдан күренеп тора. Ямауны күреп шофер Галимҗан эче катып көлә.

Казлар бер тамчы да курыкмыйлар, алар кемне кемнән аералар, бүрекле ата каз егетләрчә гаярь[1] басып Мифтахетдингә каршы ук китә һәм озын, юан чыбыркы муенын сузып яман ысылдый. Мифтахетдин вак-вак адымнар белән йөгереп кабина кырына килеп ышыклана, анда да шүрләп икенче якка ук чыга.

Вак-вак шадралар чуарлаган киң битен сөртә-сөртә келәт ишегеннән йөкче Хәнәфи килеп чыкты. Амбарчы белән берне көйрәтеп ул кинәнеп кенә тәмәке тарта башлады; Мифтахетдин дә аларга барып кушылды, сүз китте. Ул арада Галимҗан, түземсезләнеп, машинасын кычкыртты. Кычкыртуы булды, Хәнәфи, тәмәке төпчеген җиргә бәреп, тиз-тиз кабинага кереп утырды.

Машина куанып гөрли башлауга, казлар җыйнаулашып алгарак чыктылар. Әллә көчле җил, әллә көзге туклык шаукымы аларның онытылып беткән кыргый, ирекле чакларын искә төшерде; иң элек шәбәеп ата каз аваз салды; ана каз, куштанланып, аның тирәсендә әйләнгәләде; бәбкә икәнлекләрен аермаслык бала казлар, яңа, шук тавышлар белән каңгылдашып, әткә-әнкәләренә кушылдылар. Кузгалып чаба башлаган машина кинәт туктады, авыр, җәһәт эштән соң изрәп барган Хәнәфинең маңгае чак түбәгә бәрелмәде.

— Яп-яланаяк,— дип сүгенде ул, гадәтенчә яратып.— Нәрсә бар тагын, Галимҗан?

— Әнә казлар...

Хәнәфи берәр юньсез бәбкә тапталгандыр дип исәпләп чыраен сытты һәм, кабина тәрәзәсеннән башын тыгып:

— Кырып бетерәсе затлар! — дип кычкырды.— Берәрсе чәнчелдеме?

— Юк,— диде егет юаш кына.

— Ни булды соң?

---

[1] *Гаярь* — гайрәтле, батыр.

— Очалар,— диде Галимҗан, казлардан җемелдәгән күзен ала алмыйча.

Казлар, чыннан да, дәү, ак канатларын җилпеп-җилпеп җил уңаена йөгереп бардылар да келәтләр тезелешкән атаудан аерылып, үзән өстенә һавага күтәрелделәр: һава чуп-чуар булды!

— Моторыңны ник сүндердең?

— Тавышларын тыңлыйм. Ишетәсеңме, очканда гына шулай каңгылдашалар бит алар! Кыр казлары дип белерсең!

Хәнәфи йон баскан кыска муенын кашып алды:

— Бодай тыгынганнар да очалар! Ул Мифтахетдиннең муенын борасы бар! Себереп ал дим, иренә!.. Казлар симергән, түлләре мул, шаярасылары килә.

— Симезлектән очмый алар, Хәнәфи абый,— диде егет, сокланып.— Ерак-ерак бабаларының кыр казлары, ирекле кошлар икәнен оныта алмыйлар! Каннарында бәйсезлекне, күк биеклеген тою уяна! Җилләр белән көч сынашалар алар!

Хәнәфи оеп утырган җылы урыныннан ялт кына калкынды, җиту сакал-мыекларын кул аркасы белән ышкып алды.

— Нәрсә, нәрсә дидең әле син?

Галимҗан йөкчесенең ни әйтергә теләвен бик яхшы аңлады, дөнья, табигать, яшәү кануннары хакында сүз чыкканда алар еш кына әләгешәләр иде, шуңа күрә Хәнәфинең соравын уенга алды:

— Әйттем дә оныттым, Хәнәфи абый!

Бүген Хәнәфи белән тәмсезләнәсе килми иде аның...

Теләсә ни уйласын!

Казлар үзән өсләп очып үттеләр дә аръякка, әрәмә кырына ук барып кундылар. Галимҗан җиңел сулап куйды: шактый ара үтте казлар! Кузгалдылар. Такырны артта калдырып үзәннән бара башлагач, машина тагын шып туктады. Рәхәт ойый башлаган Хәнәфи, йокы тиз эленгән күзләрен көч-хәл белән әйләндереп, тагын сүгенде:

— Яп-яланаяк, нишлисең син? Ятьрәк ташып бетерик тә якты күздә өйгә ычкыныйк әле бүген.

Шофер ияге белән уңга ымлады. Тегермән ягыннан килгән тар сукмакта кабалана-кабалана берәү бу якка таба атлый иде.

— Рәисме? — дип сорады нигәдер пышылдап Хәнәфи.

— Үзе.

Хуҗалар белән очрашудан һәрчак нииндидер хәвеф көткән йөкче ипи калагы төсле эре, саргылт тешләрен күрсәтеп ачуланырга тотынды:

— Ни шайтаныма кирәкте әле ул сиңа? Шыпан-шыпан гына ташып бетерик тә сызыйк инде. Үз юлыбыз, үз эшебез.

— Туктарга кушып кул изәде.

Колхоз былтыр гына «Москвич» машинасы сатып алган иде. Гадәттә, бер дә машинасыннан төшми торган председатель Шәйхулла, урак өсте җиткәч, әллә нишләде. «Москвич»ын калдырып җәяү генә чыгып китә дә юл уңаенда туры килгән машиналардан файдалануны артыграк күрә иде.

— Галимҗан,— диде Шәйхулла, исәнлек-саулык алышканнан соң,— сезнең янга ашыга идем. Семенаны кичкә ташып бетерәсезме?

Егет тын гына һаман казларны күзәтә иде, аерылмады, борылмыйча гына баш какты.

— Бик әйбәт,— диде шуны гына көтеп торган Шәйхулла.— Алайса, менә шул, бодай төяп төнгә Зәйгә чыгасыз. Удар бишкөнлек игълан иттеләр!

— Ярар,— дип, Галимҗан шунда ук ризалыгын бирде.

— Эшне тизрәк очлыйк дисәң, менә Хәнәфи абыйны да ияртерсең.

Галимҗан сүзне беткәнгә санап кулын тормозга сузганда, Хәнәфи аның уң беләгеннән эләктереп алды:

— Бәләкәй генә сабыр ит, энем... миңа да барырга кушуың булдымы, Шәйхулла? Бодайны алып барырга кирәк, анысы хак. Тик үз хәлемне әйтәм: Зәйгә чыгып китә алмыйм!

Рәиснең йөзе кырысланды:

— Нигә?

— Соң, Шәйхулла, уракка чыкканнан бирле гел машинада! Галимҗанга аңа нәрсә? Мокыт бит ул, җиде камыт кидерсәләр дә тарта торган нәмәрсәкәй!

Галимҗанның сабыры бетте, ул шап иттереп машина ишеген япты, газ бирде. Кузгалдылар.

— Кая шулхәтле куасың?

— Үзең тизрәк бул дидең ич, Хәнәфи абый.

— Бая әйткән идем шул. Хәзер кусаң ни дә, кумасаң ни! Ике чабата бер кием!.. Колхоздан, колхоз рәисеннән игелек көтсәң, икенче көнне үк тәпи сузарсың.

Хәнәфи, тәмәке кабызып, таракан кырырлык зәһәр төтенен йота-йота, үзе белән үзе сөйләшеп бара иде. Ул шоферга чын-

лап торып ачуланган иде, тик кайсы яктан чеметергә икән дип җай эзли иде.

— Казлар нигә оча диден әле син?

— Ирекне сөеп, бәйсезлекне тоеп дигән идем.

— Шул шул менә! Казлар булып алар да ирекне яраталар, ара-тирә булса да күккә менәләр, телсез мәхлуклар! Ә синең кебек сары бәбкәләр авыз ачарга да куркып утыралар! Шәйхулла күренүгә тормозларыгыз бушый, тотмый башлый! Егетлек юк синдә, энекәш!

Галимҗан бүген Хәнәфи белән ачуланышмаска, сүзгә кермәскә тырыша иде, бу юлы да мөмкин кадәр сабыр булырга тырышып җавап бирде:

— Син өндәгән нәрсә, Хәнәфи абый, егетлек түгел. Кирелек аның чын исеме. Дөрес әйтәсең, анысы миндә юк. Мәгънәсезгә тәртәгә тибүне җенем сөйми!

Юкка тузан өертеп олы юлдан бардылар-бардылар да борылып басу өстенә керделәр. Тигез кыркылган бодай камылларын сытып аркылы-торкылы машина, комбайн эзләре сузылышып яткан. Ике-өч җир буе киткәч, Галимҗан, уңга каерылып, яңа эз салып бара башлады. Бераздан алар чәчелмичә калган буш җир кырына барып тукталдылар.

Өй урыны кадәр генә өчпочмаклы кишәрлектә котырынып чүп үлән үскән. Сары, ак ромашкалар, ипи чәчәкләре, шартлавыклар, билчән-шепкәннәр бергә-бергә җилдә рәхәт чайкалышып утыралар. Бодай арасында җәй буе интегеп утырган чүп үләннәр иркенгә чыкканнар!

— Нәрсәгә алып килдең син монда? — диде Хәнәфи, ярсып, калкынып.

— Күр әле, дим, нинди матур чәчәкләр!

Хәнәфи иренеп кенә карап тора иде, башын чайкады, авыр сулап әйтеп куйды:

— Чүп-чар диген, әкәмәт! Нинди чәчәк булсын, ди.

— Чүп-чар түгел! — диде кызып егет.— Һәммәсенең дә исе, төсе, исеме бар аларның. Тик без белеп кенә бетермибез. Менә бу кырыйдагылары күзлут дип атала.

Йөкче мәзәк кенә пырхылдады:

— Урыны бәләкәйрәк, чабып алганда ярыйсы булыр иде. Күзлутмы, чүзлутмы, сыерга аңа барыбер, бөтерә дә тыга! Шәйхулладан курмыны барыбер бик каера алмассың.

— Ә менә шушы чәчәкне беренче тапкыр «күзлут» дип атаган кешегә барыбер булмаган ул, Хәнәфи абый!.. Ә син кеше-

ләрне бер калыпка сугалар, дисең! Алай түгел бит... Бик күпләр чүп дип йөрткәннәр, йөзләр, меңнәр уйлап-нитеп тормаган, шуны кабатлаган, ә берәү тоткан да «күзлут» дип исем биргән. Безнең борынгы бабайлар үләнне «ут» дип йөрткәннәр. Шуннан утар, утлык, утау сүзләре калган. Атлар утлап йөри дибез икән, бу инде бахбайлар үлән ашыйлар дигән сүз була. Күзлут — күз кебек үлән. Чыннан да, зәңгәр күзгә охшаган бит чәчәкләре?

Хәнәфинең тирән чокырларда утырган күзләре туктаусыз елтыраштылар, ул борын яфракларын киереп һава сөзде:

— Чәчәген белмим, әмма ачы бал исе килә!

Машина тагын җәлт кенә кузгалды. Киттеләр. Тәгәрмәчләр, сары камылларны чыштырдатып, күңелле генә тәгәриләр. Уңда, Кырынды тавы өстендә, тракторлар борчак җирен сөреп бетереп киләләр. Җил. Коры тузан уйнап тора.

— Ә син боларны каян беләсең? — дип сорады Хәнәфи, бераз баргач.

— Укыдым.

— Шундый гыйлемлегең булгач, нигә колхозда изаланасың?

— Изаланмыйм, эшлим.

— Таптың эш! Теләсә кем теләсә кая куа. Сәгате-минуты язылмаган, их, синең урында булсаммы мин!.. Төкерер идем авылга. Тормышмыни бу, яшәүмени? Шәйхулла типкесендә йөр инде. Сәнәктән кирәк булган нәмәстәкәй!..

Хәнәфинең үзалдына сөйләнә торган гадәте барын белә иде Галимҗан. Ул аны тыңламыйча акрын гына үз уйларын уйлый иде. Аның уйлары да шактый күңелсез, очсыз-кырыйсыз иде бугай бүген.

Чәчәкле кишәрлекне төнәген үк күреп киткән һәм сокланып үткән иде Галимҗан. Төнәген үк аның башында бер план да төзелгән иде. Семенаны ташып бетергәч, эштән соң туп-туры шушында килергә һәм бер кочак кыр чәчәкләре җыеп алырга иде аның исәбе... Бик кирәк иде аңа бу чәчәкләр. Бик кирәк! Ак күлмәкне дә юкка гына кимәгән иде ул. Соңгы рейстан өенә дә кереп тормаска иде аның исәбе. Тик менә соңгы рейс булмаячак. Аның урынына бодай төяп Зәйгә чыгарга кирәк.

Бәлки Галимҗан, чыннан да, куркактыр? Мокыттыр? Киреләнсә, карулашса, йә булмаса чиргә-сырхауга сабышса, мондый көнне (бүген алар семенаны ташып бетерәләр бит!)

Шәйхулла артык кысмас та иде. Дәүләткә дигән ашлык та ташылып бетеп килә. Бер машинадан ни була?

Иртәгә кадәр бу чәчәкләр торырмы-юкмы? Хәзер печән бик кадерле, берәрсе чабып култык астына кыстырып китсә? Иртәгә тагын берәр мәшәкать килеп чыкса? Чыннан да, Галимҗанның көннәре, гомере, Хәнәфи абыйсы әйткәнчә, нәкъ башкаларныкы сыман ук төссез, чырайсыз үтеп китәрмени? Эш, тагын эш, тагын эш...

Хәнәфи һаман үзенекен сукалый:

— Әйтик, менә бүген нигә ризалаштың инде?

Чыннан да, нигә ризалашты әле ул?.. Тик бу сорау да аның күңелен тулаем биләп тора алмады, егет һич тә көтмәгәндә Хәнәфигә борылып сәер генә сорау бирде:

— Ә синең, Хәнәфи абый, айлы төннәрдә, апрель азакларында кыр казларының каңгылдашып килүләрен ишеткәнең бармы? Алар биектә-биектә авыл өстеннән үтеп китәләр!..

Йөкче эндәшмәде, кабина тәрәзәсе аркылы лач итеп төкереп куйды. Ул аптырашта иде. Ни булган бу малайга? Сүгәсең, ачуланасың, тик утыра.

Моннан ары алар телгә алырлык сүз сөйләшмәделәр. Егет таркау һәм уйчан, Хәнәфи турсайган һәм хәтере калган иде.

Семенаны кичкә кырын соң гына ташып бетерделәр.

Районга кузгалганчы, иң элек өйгә кагылып чыгарга кирәк иде. Йөк белән өйгә кайтырга яратмаса да, Галимҗан бүген кереп чыгасы итте.

Хәнәфиләр турысына җитеп аны төшереп калдыргач, Галимҗан җиңеләеп киткәндәй булды. Хәнәфигә кул болгады һәм машинасын урам буйлап алга куды.

Өйгә кайтып аяк өсте генә капкалады, баздан сөт алып чыгып, ишекле-түрле мыраулап йөргән песигә салды. Салкын, дымлы чүлмәкне күтәреп, үзе дә сөт эчте. Өзелеп карыны ачкан икән, рәхәт булып китте.

Эш бетте. Ул аскы иренен тешләп урам коймасы янына килде һәм түбән очка, яңа гына үзе кайткан урамга карап тора башлады. Әнкәсе кайтырга иртәрәк шул әле... Кинәт ул үзенең бөтенләй әнкәсен көтмәвен, өйгә кайтуының максаты да аны күрү түгеллеген, хәтта аның турында уйлап та карамавын, күңелен бөтенләй башка кеше, үзгә уйлар тетрәтеп торуын аңлады.

Ни аяныч! Вакыт үткәреп өйгә кайтып йөрүнең һич кирәге калмаган иде бүген, тамагын элеватор буфетында да ялгый

ала иде, ул тәкатьсез көтеп алган кичтә өметләр акланачак түгел, сабырсызланып, гасабиланып көткән кешесе күзгәбашка күренмәячәк иде! Ничек күрешсеннәр ди, ул да кеше кешесе, үз ихтыярында түгел, хәзерге минутларда җәйләүдә сыерлар савып, эшен бетереп йөридер. Галимҗан авылдадыр дип күңеленә дә китерми торгандыр! Аның эше бетүгә, егет машинасы белән җәйләүгә барып җитәргә тиеш иде! Кабинасында бер кочак хуш исле кыр чәчкәләре булырга тиеш иде аның: ромашкалар, ипи чәчәкләре, күк күзләр, күзлутлар. Кыз чәчкәләрне күреп гаҗәпләнергә, кабина ишеген ачуга: «И-и, монда миңа урын да калмаган икән!» — дип кычкырып җибәрергә тиеш иде...

Егет авырттырып тешләрен кысты, әйе, алар бүген таш яуса да очрашырга тиешләр иде! Очрашырга һәм аңлашырга!

Дөрес, моңарчы да алар күрешми тормадылар. Бер авылда яшәп, бер урам-тыкрыклардан йөргәч, очрашмый каласыңмы соң? Аңлашырга җайлы вакытлары да булмады түгел, тик Галимҗан аның белән аңлашуны ниндидер олы, тиңдәшсез зур, мөһим эш итеп күз алдына китерә һәм ул минутларны гомергә онытылмаслык итәргә омтыла иде. Юк, Хәнәфи абый, кешеләр ахыр чиктә бер калыпта сугылмаганнар! Һич югында бер тармакта булса да кеше үз казанында кайнап пешә! Кеше дигәнең инкубатор чебеше түгел, башка күп җәһәттән алар бер-берсенә охшасалар да, күңел ягына килгәндә адәм уллары үзгәлеккә омтылырга тиешләр!.. Кешенең хет күңеле буйсынмыйча ирекле калсын! Хет бер ягы белән бүтәннәрдән аерылып торсын! Галимҗан шулай уйлый иде. Шуңа күрә егетнең кызга мөнәсәбәте тирән сер иде, күңеле серенә ул үзе, бер башы гына хуҗа иде. Аның күңел капкасы бүтәннәр өчен ябык, бикле иде. Бүген ул шул капканы киң итеп ачарга һәм аны күңел түренә чакырып кертергә тели иде. Егет күңеле мөлдерәмә тулган һәм бүген чайпалырга тиеш иде...

Ә Зәйгә бармаса? Таңнан, караңгыдан чыгып китә ала ич ул!.. Аңа бер сүз дә әйтүче булмаячак. Айлар, еллар буе сүз тыңлап, бер карышусыз эшләп йөргән егеткә кем базып сүз әйтә алыр?!

Бару-бармау мәсьәләсен хәл итүдә ул ирекле диярлек иде. Әнә шул ирекне тою аны юлга ныграк этәрә, тик күңеленең кайсы чирегендәдер туган икеләнү бәҗрасын тиз-тиз өзеп ташлый алмау гына аны сәерсендерә иде. Хәнәфи абыйсының усал хөкеме борчыдымы аны? Яп-яшь Галимҗан

Шәйхуллага башын биреп аның ишәгенә әйләндеме? Кем белсен!

Егет Шәйхулланы ярты сүзеннән аңлады. Менә бу иртәдән бирле котырынган җил тикмәгә түгел, аның артыннан ияреп яңгырлар килә. Ә яңгырлар бер башланса, районның иң кырыена урнашкан авылдан Зәйгә үтеп йөрүләр, ай-һай! Юллар бик начар шул әле, бик начар. Юлларның рәтләнер исәбе дә күренми!.. Һәм Галимҗанның күңеленә ят бер уй кагылып үтте: кайсысыннан ныграк курка Шәйхулла: яңгырданмы әллә район игълан иткән бишкөнлектәнме?.. Район башлыкларыннан ныграк шүрлидер рәис, менә аны кеше кешесе дисәң дә ярый!..

Ни генә булса да, яңгырлар тоташтан шәбәергә керешкәнче, иген үз урынында, коры амбарда булырга тиеш. Галимҗан шуны белә, шушы кагыйдәгә башын бирә...

Ә мәхәббәт? Ә якты хыяллар? Ичмасам, мәхәббәттә булса да үз-үзеңне табарга тырышулар?.. Галимҗанга да башкалар кебек ашык-пошык кына, йә эш арасында, әйтик, клубтан кайтканда, капка баганасын саклап кына аңлашырга туры килерме? Алай икән, апрель азакларында кыр казларын нигә тетрәнеп озаткан ул, кыр чәчкәләренең матурлыгы алдында нигә телсез калган? Күңелендәге иң якты теләкләр, иң сихерле сүзләр шул аңлашу вакытында телгә килерлек булмагач, нигә ул егет исемен күтәреп йөри?..

Мотор телəр-телəмәс кенә кабынды. Урам буп-буш иде. Тик ниндидер мәгънәле серләр яшергән кебек буш иде. Җил тузан уйната, түгәрәк өермә ясап ындырларга, бәрәңге бакчаларына кереп китә. Тузан машинага кара койрык булып тагылып, уйнаклап бара. Кабинага керә, егетнең ап-ак якасына куна, күлмәген каралта. Каралсын, инде хәзер барыбер. Алда юл, алда мәшәкатьле төн, алда Зәй, алда ялыктыргыч ялгызлык...

Кемдер аның исемен яңгыратып кычкырган кебек булды. Ул колагы белән ишетүдән бигрәк күңеле белән сизенеп якягына каранды һәм Галәмәйләр тыкрыгыннан чыгып килүче аны күрде. Ул ап-ак күлмәк кигән иде. Йөгергән, ахры, йөзе, колаклары бурлаттай яна.

— Галимҗан абый! Уф...

Егет үз күзләренә үзе ышанмыйча машинасы белән бергә дерелди, калтырый иде.

— Мине дә Зәйгә утыртып бар әле, Галимҗан абый.

Зәйгә? Каян белгән ул аның Зәйгә барасын? Монда ничек килеп чыккан? Нигә мондый ап-ак өр яңа күлмәк әле аның өстендә?..

Һаман телгә килә алмады егет, сүзсез генә кабина ишеген ачты, утыргычны учы белән кат-кат сыпырды. Кыз утырып киң итеп сулыш алды, җәһәт кенә чәчләрен рәтләде. Кузгалдылар.

—Галимҗан абый, син безнең турдан үтмә инде, яме,— диде кыз оялып кына.

Егет шунда ук борылып тыкрыкка керде һәм ындыр артлатып олы юлга чыкты.

«Олы юлга!» дип уйлады да Галимҗан әсәренеп китте.

Аның белән!

Янында ул утыра!

Кыз ярым көлемсерәп егеткә күз ташлап ала һәм, аның уйларын аңлаган кебек, бер сүз дә эндәшми. Икесе дә, күрешү кинәтлегеннән исәнгерәп, шактый вакыт сүзсез бардылар. Тик гел-гел болай барып булмый ич инде, нидер сөйләшергә дә кирәк! Икесе дә моны аңлыйлар, йөрәксенеп сүз башларга гына базмыйлар иде.

Эштән кайтучылар, юлаучылар аларга борылып-борылып карап калалар иде. Ап-ак күлмәкләр киеп, әрҗәгә бодай төяп кая баралар болар? Ул Хисами Галимҗаныннан әллә ни көтәргә була, юаштан юан чыгар, диләр булыр, аны күрүгә күзләрен тасырайталар. Бәлки, әнә шул ят күз карашлары аларны ятсындырып, телләрен бәйдә тотадыр? Юк, анысына да артык исләре китми иде аларның, ахрысы...

Кичке моңсу төтеннәре, куанычлы ыгы-зыгылары белән авыл артта калды, өянкеләр мул бизәгән Сай чокырны да үттеләр һәм икесе дә сүз берләшкәндәй җиңел сулап куйдылар. Сүз үзеннән-үзе килеп чыкты, ялганды.

— Син бик арыгансыңдыр инде, Галимҗан абый,— диде кыз, аңа җылы карап.

Егет баранкасын кысыбрак тотты:

— Ә үзең, Сөмәя?

— Мин бүген армадым! Юк, кая ди ару! — диде кыз, кабаланып.— Армадым!

Егет өчен бу сүзләр кадерле иде. Кыз бүген диде бит! Ул аның таңнан торып кичкә хәтле ниләр эшләгәнен күз алдыннан үткәрде: мәшәкатьле авыр хезмәт ул сыер саву! Ә ул әнә армаган! Аны көткән!

Кызның ничек итеп үзен көткәнне генә белә алмый иде Галимҗан! Чөнки кыз әбәт вакытында ук егетнең килә алмавын, икмәк төяп Зәйгә чыгасын ишеткән иде инде. Шуның өчен иптәшләре аның кичке савымын бүлешеп алдылар, ул беренче туры килгән машина белән авылга кайтып җитте. Алар бүген, һичшиксез, очрашырга тиешләр иде!

— Юл әйбәт,— диде кыз.

Егет бу сүзләрдә үзенә теләктәшлек, якынлык, җылылык сизде. Шофер өчен юл — ярты гомер дигән сүз...

Аннары бүген сүзләр авыздан чыгуга ук яңачарак мәгънә алалар иде. Сүзләр генә түгел, юл да, күнегелгән тирә-як та икенчерәк, катлаулырак һәм серлерәк иде бүген. Авылдан шактый ерагайгач, бәләкәй, юаш таучыкта сураеп[1] утырган җил тегермәне турына килеп җиттеләр. Күз ияләнгәнгә, кайчагында күрмичә дә үтеп китә торган иде аны ул. Ә бүген тегермәннең япа-ялгыз икәнлеген дә, сукмагын үлән басуын да, канатларының җил-яңгырда чалшаеп, сәлперәеп салынуын да ап-ачык күрде. Гаҗәп: кыз да тегермәнгә текәлеп бара икән!

— Нинди дәү һәм мескен безнең җил тегермәне! — диде ул уйчан гына.

— Картайган инде.

— Урын алып кына тора. Ник сүтмиләр икән үзен? — дип сорады кыз. Шулай дисә дә, тавышында шушы тегермән хәрабәсен кызгану аһәңнәре[2] яңгырады.

— Кемнең кулы барсын? Беркемнең дә сүтәсе килми. Сугышка кадәр әллә кайчан җиткергәннәр аны. Салучы осталар да, тегермәнче дә әйләнеп кайтмаган. Истәлек! Авылдан җитмеш биш кеше үлеп калган. Безнең авылда аларга бүтәнчә һәйкәл юк та диярлек... Алар салган өйләр тузган, яңаларын, ара-тирә, уллары, оныклары җиткерә. Ә тегермән, карт бөркет кебек, һаман барыр, кайтыр юлларны саклый...

— Безнең әткәй: «Күпме утын череп ята!» — ди. Ватып ташларга кыҗрап йөри,— диде кыз, нигәдер әрнеп.

— Юк, Хәнәфи абыйның да кулы бармас! Теле белән әллә ни әйтер, эш сүтүгә барып җитсә уйлар...

— Биектә утыра...

— Биектә!

---

[1] *Сураеп* (сөрәеп) — күңелсез тәэсир калдырып.

[2] *Аһәң* — тавыш.

— Кызганыч, еллар аямас, үзеннән-үзе череп таралыр инде. Һәйкәл дисең бит, Галимҗан абый.

— Кешеләр берәр нәрсә уйлап табарлар әле! Җитмеш бишәү ятып калган бит!

Тегермән боегып артта калды. Бормаланып-бормаланып аккан тар инешне кичтеләр. Күпер култыксалары да кыегаеп, җимерелеп беткән иде. Юл тузанлы, тигез диярлек иде. Иренеп кенә караңгы төште. Аның көндәгедәй иртәрәк иңүен икесе дә сизделәр.

— Менә килеп тә җиткәннәр,— диде егет, күккә ымлап.

— Яңгыр ишә башласа? — диде кыз куркып кына.

— Зыян юк. Брезент йөк өстендә. Хәзер каплыйбыз аны.

— Ә юл? — диде кыз, көлемсерәп.

— Юлны брезент белән каплап булмый. Кыз тыелып кына көлеп җибәрде:

— Җитмәсме?

— Аңа бетон, асфальт кирәк,— дип аңлатты егет.

Егет күз кырые белән кызга күз салгалый иде. Сөмәянең җитди, олы булып үзен тыңлап баруы аңа ошый да, берникадәр сәер дә иде. Алар, чыннан да, икәү баралармы? Янәшә? Зәйгә?! Валлаһи, икәү бит! Алайса, нигә көндәгечә эш, тормыш мәшәкатьләре хакында сөйләшә башладылар әле алар? Сүзләр бүтән кирәк иде бит, башка уйлар, башка фикерләр... Каян, ничек табарга шул яшерен, серле сүзләрне?

— Аклы күлмәгеңне кигәнсең, Сөмәя.

—Үзең дә, Галимҗан абый.

— Каралды инде. Машина акны сөйми.

— Ак кулны да, Галимҗан абый.

Ничек мине эзләп киләсе иттең, дип сорарга теләде егет. Базмады, бу сорау артык гади иде, кызның дәрәҗәсен, очрашуның бәясен төшерә кебек тоелды аңа. Бүген алар очрашырга тиешләр иде бит! Сөйләшеп куйганнар иде!

Машина уты, үзенә юл таләп итеп, һаман алны ялый, алда җил. Җил тузанны кабинага бөркеп кертә, битләргә, колакларга сибә.

— Җил!

— Җил, Галимҗан абый. Бүген урман көне буе гөжләп торды. Чыгам да тыңлап карыйм: гөж-гөж итә. Туктаусыз гөжли. Машина тавышы дип әллә ничә кат алдандым. Күккә карыйм, кояш әле әнә кайда-а!

— Җил! — диде куанып егет.

— Яңгыр китерер микән?

Кызның соравына җавап биргәндәй, кабина тәрәзәсенә беренче эре тамчы килеп сыланды.

Егет шундук машинасын туктатты, җәлт кенә кабинадан чыкты да әрҗәгә сикереп менде. Кабалана-кабалана брезентны җәя башлады.

Сөмәя, башын ишеккә тыгып, аңа карап тора иде.

— Чыкма, чыкма, чыланасың!

— Ява бит, Галимҗан абый!

— Ява! — дип, нигәдер шатланып кычкырды егет өстән.

— Ничек шыбырдый,— диде кыз, учын яңгырга куеп.

— Ужымнарга дым кирәк иде,— диде егет, кабинага кереп утыргач.

— Тоташ яңгырга әйләнеп китмәсме? — дип сорады кыз.

— Әле иртәрәк!

Егетнең тавышында шундый тирән ышаныч, ныклык бар иде, кыз кинәт тынычланды һәм алдан да яннан да коеп яуган яңгырга сокланып бара башлады. Яңгыр астында юлда рәхәт! Әле ул пычранып өлгермәгән, тузан басылган, тәрәзәдән дым исе, юеш кыр исе, нарат урманы исе кереп тулды.

— Кашка тау турысына килеп җиттекме әллә?

— Таулар,— диде егет, уң якка ишарәләп.

— Син күрәсеңме аларны, Галимҗан абый?

— Күрәм.

Кыз да караңгыга текәлеп карады. Яңгыр тоташ стена булып коя иде. Тик шулай да караңгылык арасыннан ул нарат агачларының томанлы очларын күргән сыман булды. Үзе исә:

— Ә мин күрмим... Берни дә күрмим,— дип, борчылып кабатлады.

Егет үз ягындагы тәрәзәне яба башлады.

— Тимә, Галимҗан абый.

— Үтәли җил йөри. Сиңа салкындыр.

Кызга, чыннан да, салкынча иде, тик аның кабина эчендә бернәрсәне дә үзгәртәсе килми иде. Ничек булган, шулай булсын! Менә шулай, менә шулай...

— Үтәли җилдән курыкмыйм мин. Салкыннан да.

— Ява! — диде егет, кулъяулыгы белән битен сөртеп.

— Яусын! — диде кыз тантана белән.— Ныграк яусын. Яңгыр тавышыннан бөтен тирә-як җанлангандай булды, караңгылык хәрәкәткә килде, бу үзгәреш, җанланыш шушы

кара төндә икәү генә калган юлчыларга ниндидер сөенеч, шатлык өсти иде. Алар шулай эчтән генә куанышып, төнге яңгыр шавы астында, бер-берсенә сыенып шактый озак бардылар.

Тирә-як кинәт тынычланып, гадиләнеп калды. Алар сәерсенеп мотор тавышын ишетә башладылар. Ни булды? Җил көчәйгән иде шикелле, ә тавышлар тынды. Егет елмаеп кызга карады:

— Теләгең кабул булмады, Сөмәя, яңгыр туктады.

— Миңа җитәрлек булды, Галимҗан абый.

— Чыландыңмы?

— Бераз бар!

— Туңарсың инде?

— Туңмыйм, туңаммы соң! Җылы ич бүген!.. Ә һавасы нинди?.. Борыныңа төреп тыгарлык, ди безнең әткәй.

— Ул шулай дип әйтә беләме?

— Сирәк-мирәк! — Кыз яңгыратып көлеп куйды.— Тауларны үттекме әле, Галимҗан абый?

— Тауларнымы? Тауларны үтеп булыр иде, алда Тирән чокыр бар әле. Караңгыда дәшми-тынмый гына астан килеп чыга ул! Сагалап тора! Менә аны үтәсе бар!

Кыз егет тавышындагы хафаны аермачык ишетте.

— Шулай бит әле. Истән чыккан. Зәйгә бармаганга да байтак шул. Тирән чокыр ярты юл буламы?

— Ярты юл.

— Шулай рәхәт булып китте, иеме, Галимҗан абый?

— Язгы яңгырлар күңеллерәк. Анда, ичмасам, тамган бер тамчының үлән, иген тамырына сеңүен аңлыйсың, һәрбер нәни тамчыда көч, тормыш яшерелгән. Ә көзге яңгырлар моңсу, әллә ниләр уйлата...

Яңгыр монда шәбрәк яуган, ахрысы. Борылмадан үтүгә, зур-зур җәенке күлләвекләр очрый башлады. Димәк, урта юлга җитеп киләләр. Тирән чокырга... Тирәнлеге Сай чокырдан әллә ни артык булмаса да, атналар буе кипми торган авыр үзле балчыгы өчен аңа шундый исем такканнар. Шоферларның теңкәсенә тия торган әшәке бер урын иде бу. Ел саен нәзек бүрәнәләр тәгәрәтеп яңа күпер сугалар, ел саен яз башында тракторлар, авыр машиналар үтеп-сүтеп ул бүрәнәләрне сындырып, чәрдәкләп бетерәләр. Аннары шоферлар җәй буе күпер төбендәге зирек, тал әрәмәсен аяусыз ботарлыйлар.

Машинаның хәле китте, тәгәрмәчләр, машина авырлыгын тигез тота алмыйча, таеп-таеп китәләр иде.

— Чана кебек салулый!

— Үтә алырсыңмы, Галимҗан абый.

— Үтәргә кирәк иде, Сөмәя.

Күпергә хәтле зыянсыз гына килеп җиттеләр, машина киреләнеп янтаеп-янтаеп алгалады, андый мизгелләрдә кыз күзләрен чытырдатып йома һәм егетнең таза беләгенә ябыша иде.

Ниһаять, машина иләмсез янтайды, әче улап тукталды. Көчәнеп алга ыргылып карады, кузгала алмады, тәгәрмәчләр, сыек балчыкта сыпкы боламыгы болгатып, зыр-зыр әйләнделәр.

— Утырдык,— диде егет, кызга карап. Аның күзләре көлә иде.

— Ныкмы, Галимҗан абый?

— Утырсак нык инде,— диде егет.— Казынтылы, хәтәр урын.

Ул кабина ишеген ачып янтаеп артка карады.

— Күлнең күзенә генә басканбыз. Төшмә, төшмә, Сөмәя.

Егет, чалбар балакларын өскә кайтаргач, чупырдап аска төште. Кыз каерылып аңа карап утырды да, туфля, оекларын салып, аның артыннан ияpде. Су салкын, җил вак дулкыннар куалап кисеп-кисеп исә иде. Галимҗан кабина артына беркетелгән тимер көрәген алып баткан арткы тәгәрмәчләр янына килде.

— Казырга туры килә,— диде ул, учын төкереклэп. Кыз болганчык судан башка берни күрә алмыйча иелгәләп каранды да егетнең максатын аңлады, Галимҗан канау казып чокырга җыелган суны агызырга тели икән.

— Көрәгеңне алай текә тотма, Галимҗан абый,— диде ул йомшак кына. Күпердән ерак та түгел куаклар караеп утыра иде.

— Балтаң бармы? Ә, Галимҗан абый?

— Шунда, кабинада,— диде егет, еш-еш сулу алып. Бераздан шатыр-шотыр агач сынганы ишетелә башлады. Егет сокланып караңгыга карады:

— Сөмәя, өстеңдә ак күлмәк ич!

— Һей, Галимҗан абый!

Егет казыган тар канаудан су түбәнгә, дамба астына ага башлады, кыз кочак-кочак ботак-сатак китереп торды. Шак-

тый озак азапландылар. Тез тиңентен су шәрә балтырларны өшетә, тирләгән аркаларны суык җил үчегеп кыйный иде.

Су күзгә күренеп кимеде, Сөмәя байтак ботакларны тәгәрмәч асларына җәйде.

— Хәзер кузгатып карыйбыз,— диде егет.

— Галимҗан абый, бу юлларны берәр заман рәткә салырлар микән?

— Салырга кирәк иде дә... Тик әлегә мин белә-белгәннән бирле юл төзүче оешмада түрәләр гына алышына! Ә юллар һаман шул килеш!

Агач-магач түшәлгән баткактан машина тиз генә чыгарга ашыкмады. Тәгәрмәчләр, ботакларны туздырып, атып-бәргәләп бер урында әйләнделәр. Кыз, яланаяклары белән тая-тая, иңе белән әрҗәне алга этте. Менә тәгәрмәчләр аны сыек сыпкы белән коендырып кузгалдылар, ул бар көченә:

— Китте, китте! Бара, Галимҗан абый! — дип кычкырды.

Машина үксеп-уфтанып кузгалды, күпер өстенә керде һәм үрне менеп җитеп туктады. Егет кабинадан сикереп төшеп кызны чакырды:

— Монда кил, Сөмәя.

— Бармыйм.

— Нигә?

— Мин сыпкыга, лайга батып беттем, Галимҗан абый.

Егет, эре-эре адымнар белән сикергәләп, кыз янына төште, үргә алар җитәкләшеп менделәр. Ут яктысына чыккач, берберсенә карашып озак кына көлештеләр.

— Миңа ачуланасыңмы, Сөмәя?

— Ник ачуланыйм ди, Галимҗан абый! Шундый күңелле булды, шундый кызык!..

— Монда ерак түгел чишмә бар,— диде егет, кыюсызланып.— Юынып алабызмы әллә?

— Кайда чишмә, кайда елга барын син беләсең инде, Галимҗан абый. Хәтереңдәме, мин бәләкәй чакта син бездәй ыбыр-чыбырны җыеп, Тугай суына көпшәгә алып барган идең?

— Онытмадыңмыни әле шуны?

— Карыным ачып, кайтыйк инде, дип җылаганым да исемдә... Әйдә, юынып киләбез, Галимҗан абый!

Кыр өстеннән дөм караңгыда җитәкләшеп бару нинди рәхәт! Төн салкынча, күк аязган, яңгыр юган күкнең кара

шәленнән йолдызлар тамарга тора. Аяк астындагы юеш үләннәрне кабартырга тырышып җил йөгерә.

— Чишмәгә еракмы әле?

Кызның зур ачылган күзләреннән якты нур ага.

— Менә монда, чокырда.

Алар җитәкләшеп төшә башладылар, егет таеп шуа башлаган иде, Сөмәянең кулларына тотынып калды. Эре-эре яфраклар белән капланган чокыр төбендә тонык кына кара су елтырый иде.

— Менә ул!

— Бу бит Хәйри кизләве!

— Әллә килгәнең бар? Кыз сүзсез генә ым какты.

— Шушы чишмә янына агач утыртырмын дип йөрим, һаман өлгерә алмыйм.

— Алайса, бергәләп киләбез! Мине дә алып килерсеңме, Галимҗан абый?

— Минем бу ярларга өрәңге, имәннәр утыртасым килә. Нык агачлар. Озак үсә алар, ләкин мәңге утыралар. Юын, Сөмәя.

Кыз су өстенә иелде дә озак итеп тавышсыз карап торды:

— Галимҗан абый, кара әле, йолдызлар!

Су өстендә кызның дерелдәп торган тонык күләгәсе белән янәшә сансыз-исәпсез йолдызлар тирбәлә иде. Ул кушучлап, су чумырып алып, шаяра-көлә юына башлады. Егет аннан күзен аера алмыйча текәлеп карап тора иде. «Менә хәзер, менә хәзер!» дип типте аның йөрәге. Ул юынып кына бетерсен дә... Менә хәзер... Үзендә ниндидер арганлык сизеп, егет сөзәк ярга утырды. Кыз, чишмәгә иелгән килеш, аңа борылып карады.

— Нинди салкын, юеш яфраклар.

— Ә син аларның исемнәрен беләсеңме?

— Белмим.

— Үги ана яфраклары дип атыйлар аларны.

— Нигә икән, Галимҗан абый?

Егет кулында үги ана яфракларын бөтереп сөйләп бирде:

— Ул исемне тапкан кеше шагыйрь булган... Гомумән, безнең бабайлар шагыйрь булганнар алар! Күккә караганнар да Киек Каз Юлы дигәннәр. Тимерказык йолдызын белгәннәр. Җиргә караганнар да менә шушы иң төссез, салкын чокыр яфракларына үги ана исемен биргәннәр.

— Сәер исем...

— Бу үләннең чәчәге яз башында, кар китүгә үк чыга. Кайбер авылларда аны умырзая дип тә йөртәләр. Бездә кимәшә башы дип атыйлар. Кимәшәсе нидер тагын, яздыр, мөгаен.

— Күргәнем бар! Чәчәге сап-сары була, яр буенда сибелеп утыра.

— Чәчәген ата, ә яфрагы һаман юк. Яфрак белән чәчәк бервакытта да очрашмыйлар. Яфрак үсеп чыкканда, чәчәге беткән була инде.

— Бер дә, бер дә очрашмыйлармы? Кызганыч...

Егет тә, кыз да ниндидер серле мәгънә алган салкын яфракларны җыя башладылар. Яфраклардан ниндидер төче саз исе, ләм исе аңкый иде. Галимҗан үз кулындагы яфракларны кызга сонды[1].

— Менә!

Алар икесе дә тавышсыз гына көлеп җибәрделәр. Бик, бик рәхәт, күңелле иде. Кайдадыр еракта машина гөжләгән тавыш ишетелеп китте.

— Сәгать ничә икән, Галимҗан абый?

— Белмим, Сөмәя.

Ул, көннең озынлыгын уйламас өчен, сәгатен өйдә калдырган иде.

— Ишетәсеңме, Галимҗан абый?

— Ишетәм, Сөмәя. Зәй ягыннан берсе кайта. Беравык тын алырга да базмыйча тыңланып тордылар.

— Йөгердекме, Галимҗан абый? Җир өсләп кенә юлга йөгерделәр.

— Сиңа салкын тимәсме?

— Бүген юк!..

Юлда аларның машинасы юаш кына көтеп тора иде. Зәй ягыннан килүче машина һаман якыная, гөжләве ачыграк ишетелә.

— Галимҗан абый!

— Әү, Сөмәя.

— Нинди машина булыр бу?

— Ибраһим булырга тиеш.

— Мин аның белән кайтып китәм.

Егет үз колакларына үзе ышанмады:

— Син миңа үпкәләдеңме?

Кыз егеткә сыеныбрак, аңа иркәләп эндәште:

---

[1] *Сонды* — бирергә дип сузды.

— Мин бүген бик бәхетле, бик... Тик соң инде! Син әйләнеп кайтканчы әле... Миңа иртәнге савымга өлгерергә кирәк... Аннары көн яктысында бу өс-баш белән кайтып керү дә уңайсыз булыр.

Кызның сүзләре хак, мәгънәле иде. Егет карышырлык дәлилләр тапмады, тик аңа нигәдер бик күңелсез булып калды. Тагын шулай гына, сүзсез-аңлашусыз аерылырлармы алар? Ул ниндидер тирән мәгънәле сүзләр эзләп азапланды. Шул арада теге машина килеп тә җитте.

— Син нәрсә, ватылып ятасыңмы әллә? — диде Ибраһим күрешкәч.

— Юк. Сине көтәм. Менә Сөмәяне утыртып кайт инде син.

— Ә ул каян кайта?

— Киек Каз Юлыннан! — дип көлде кыз һәм Галимҗанның зур, кытыршы учын үзенең нәни, кайнар кулына кысты.

— Рәхмәт сиңа, Галимҗан абый!

— Хәерле юл, Сөмәя!..

Кабинага кереп утыргач кына, Ибраһим кызның өс-башы шактый юеш, пычрак икәнлеген абайлады һәм, кулындагы яшел яфракларга күрсәтеп:

— Шушы себеркене җыярга килдеңме әллә? Әйт әле, нинди ырымы бар аның? Үзебезнең Чүке буенда да күп ич алар,— дип тезеп китте.

Кыз эндәшмәде, яфракларны күкрәгенә кысты.

* * *

Сөмәя дөрес әйткән икән, яңа көн тугач кына әйләнеп кайтты Галимҗан. Хәнәфиләр турысына җиткәндә, ул ирексездән машинасын акрынайтты. Йорт янындагы бакчада алмагачлар арасына тартылган кер бавында очып китәргә җыенган дәү аккош кебек ак күлмәк җилферди, бакча як тәрәзә төбендә зәп-зәңгәр вазада яшькелт үги ана яфраклары балкып утыра иде. Егет туктап тормады, урамдагы бозауларны, казларны өркетә-өркетә, урам буйлап Югары очка менеп китте.

1961—1964 еллар

Биремнәр

1. Хикәядә ике вакыйга бар. Берсе — Галимҗанның эчке каршылыгы. Аңлатыгыз.
2. Бу вакыйгага казлар эпизоды метафора була аламы. Була алса да, алмаса да исбат итегез. Хикәягә анализ ясагыз.
3. Метафоралар ярдәмендә хикәянең эчтәлеген табыгыз.

Туфан Миңнуллин

КУЛЪЯУЛЫК

(*Ике пәрдәле бүгенге заман риваяте*[1])

Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин традицияләрен сүндермәскә тырышып язам бу әсәремне. Яшьләр дәвам иттерсеннәр иде. Безнең милләтнең иң яраткан жанры бугай ул — музыкаль драма.

КАТНАШАЛАР:

Хатирә.
Данияр.
Айнур.
Айдар.
Әминә.
Хәйдәр.
Диләрә.
Камил.
Шамил.
Баязит.
Вәсимә.
Асия.
Хәния.
Нәфисә.
Гөлсем.
Гадилә.
Карчыклар.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кереш музыка. Шул көйгә иртә туа, кояш күтәрелә. Яп-якты көн. Кыя-тауның итәге. Ямь-яшел үзәнлек. Аста бөдрә таллар, кыя өстендә ялгыз каен. Хатирә белән Данияр керәләр.

Хатирә. Менә күл янына да килеп җиттек, балакаем. Куй әйберләреңне, ял итеп алыйк.

Данияр. Күл кайда?

Хатирә. Сөйләдем ләбаса, балакаем, күл кыя өстендә. (*Ашыгып кыя өстенә үрмәли башлаган Даниярга.*) Әкрен, балакаем, әкрен кылан.

Данияр (*кыя өстенә менеп җитеп*). Әби-и!..

Хатирә. Күрдеңме инде күлне? Торамы? Үз урынындамы?

Данияр. Менә ул күл. Якында гына. Ә ничек ул бу тауны ишеп аска агып төшми?

Хатирә. Төшми шул инде. Шундый күл инде ул.

Данияр. Ә сез кулъяулык салган урын кайда?

Хатирә. Минсез таба алмыйсың аны, балакаем.

---

[1] *Риваять* — борынгылардан буыннан буынга сөйләнеп килгән вакыйга.

Д а н и я р. Мен, әйдә, күрсәт.

Х а т и р ә. Ашыкма, балакаем. Миңа бит унсигез яшь түгел. Утырып ял итик, барысына да өлгерербез. Шөкер, кайтып күрергә насыйп булды. Күрмичә үләрмен, дигән идем. (*Ул бу сүзләрне Даниярдан бигрәк үзенә сөйли. Хәер, Данияр кыя өстендә күренми дә инде.*) Илле ел гомер аккан да киткән. Танымам, дигән идем. (*Карт өянке янына килеп.*) Исәнме, өянке? Танымыйсыңмы мине? Хатирә ич мин. Хәтереңдәме, синең күләгәңдә утырып ял итә идек? Син бит — минем мәхәббәтемнең шаһиты. Юк инде ул, юк Фәтхерахманыбыз. Еракта, Сахалин дигән утрауда аның кабере. Шуннан кайттым шул. Оныгыбызны алып кайттым. Бабаларының нигезен күрсәтергә алып кайттым, Кыя-тау өстендәге серле күлне күрсәтергә алып кайттым. Бәлки әле, мәхәббәтен дә шушында очратыр. Саклап үстердек. Үз телебездән биздермәдек. Үз денебездән көлдермәдек. Чит-ят җирләрдә йөрсәк тә, тамырыбызны өзмәдек. Кичерә күр инде, кичерә алсаң, кайтып йөреп булмады.

Д а н и я р (*кыя өстендә пәйда булып*). Әби-и!.. Монда матур. Мен, әйдә. Әйдә, күтәреп алып менгезәм. Әби-и!.. Әнә тегендә нинди авыл.

Х а т и р ә. Томбай, балакаем, Томбай авылы.

Д а н и я р. Матур!.. Әби-и!.. Бабайның җырын ишетәсең киләме?

Х а т и р ә. Бик кычкырма, балакаем, талларны куркытырсың.

Д а н и я р. Ә бу каен куркамы?

Х а т и р ә. Ул да курка. Кычкырганны кем яратсын?!

Д а н и я р. Мин бабай шикелле әкрен генә җырлыйм. Ә син шул агачка сөялеп тыңла.

Х а т и р ә. Агач димә, исеме бар аның. Өянке ул... Йә, сөялдем...

Д а н и я р. Исәсе лә җилләр исәр, исәр инде,
Исә-исә диңгезләрне кичәр инде.
Озатканда искән җилне туган якка
Сагнуларым бәгырьләрне кисәр инде.

Булдымы, әби?

Х а т и р ә. Рәхмәт, балакаем. Рәхмәт, бәгырь кисәгем.

Д а н и я р. Әби-и!.. Мин тагын бер йөгереп киләм. Мине югалтма. (*Китеп югала.*)

Хатирә үз уйлары белән өянкегә сөялеп кала. Куыша-куыша, этешә-төртешә бер төркем яшьләр керә.

Айдар (*алга атылып чыгып*). Егетләр, кызлар көтүе! Минем әмерне тыңлагыз! Тын калыгыз! Соңгы имтиханны көч-хәл белән биреп, мәктәптән котылу шатлыгыннан мин сезгә бәйрәм бүләк итәм.

Айнур. Без — кызлар — ул бүләкне кабул итмибез. Итмибез бит, кызлар?

Кызлар. Итмибез!.. Итмибез!..

Айнур. Безгә син бүләк иткән бәйрәм кирәкми. Без бәйрәмне үзебез ясыйбыз, әйеме, кызлар?

Кызлар. Ясыйбыз, ясыйбыз...

Айдар. Егетләр! Минем янга тезелеп басыгыз. Кызлар бездән башка гына бәйрәм ясамакчы булалар. Карап карыйк, нишләрләр икән?

Айнур. Акылыгыз алтын икән. Күрми генә торыгыз. Килегез әле, кызлар.

Кызлар Айнур тирәсенә җыелалар да нидер пышылдашып көлешәләр.

Айдар. Егетләр!

Егетләр Айдар тирәсенә җыелышып көлешәләр.

Шулай әле кызлар, әле егетләр чиратлашып көлешәләр.

Әминә (*егетләр янына килеп*). Нигә көләсез, ә?

Хәйдәр (*Әминә каршына атылып чыгып*). Ә сез нидән көләсез?

Айдар (*иңенә аскан сумкасыннан магнитофон ала да*). Алар бәйрәм ясый торсыннар, без бии торыйк. (*Магнитофонны кабыза. Татар аһәңе рухында заман ритмында язылган музыка яңгырый. Шул музыкага егетләр, кызлар бергә бииләр. Кыя өстендә Данияр аларның биюләрен карап тора. Хатирә дә, якынрак килеп, биюне күзәтә. Биючеләр, музыка беткәч, биюдән туктап шаулашалар, төрткәләшәләр.*)

Хәйдәр (*Хатирәне күреп алып*). Егетләр, нинди фокус бу? Кызларның кайсысы шул арада картаеп өлгерде? (*Хатирәгә якын ук килеп карый.*)

Хатирә (*елмаеп*). Танымассың шул, балам. Бабаң булса, бәлкем, таныр иде. Синең бабай Сәлимҗан исемлеме?

Хәйдәр. Сәлимҗан иде.

Хатирә. Бигрәк охшагансың шул. Безнең авылныкылар инде сез, алайса, барыгыз да? Бортаслар. Безнең авылныкыларга охшагансыз шул. (*Айнурга карап.*) Син Нәфисә ахирәтнең оныгыдыр, ахры. Шулаймы, кызым?

Айнур. Шулай.

Хатирә (*Диләрәгә*). Синең әбиең Мәйсәрәме?

Диләрә. Юк шул. Минем әбием Шәмсеруй. Мәйсәрә — минем әбиемнең сеңлесе.

Әминә. Әби, син кем?

Хатирә. Кем булыйм инде? Бортасныкы. Менә кунакка кайттым. Би-ик еректан. Сахалин дигән җирдән. Беләсездер?

Камил. Анда татарлар бармыни, әби?

Хатирә. Бар. Менә без шулар ич инде. Әнә минем оныгым утыра анда. Күрсәтергә алып кайтып киләм. Данияр, балакаем, төш монда, менә авылдашларың белән күреш.

Кызлар Даниярны күзәтәләр.

(*Айнурга.*) Нәфисә ахирәт исәнме, кызым?

Айнур. Исән.

Хатирә. Алайса, без сезгә кайтабыз инде (*төркем янына килеп җиткән Даниярга*). Күреш, балакаем, күреш авылдашларың белән. Данияр аның исеме, бабасы куштырды. (*Данияр күрешеп чыккач.*) Инде минем улымны да түгәрәккә алып биегез бер. Карап тордым, сокланыплар туялмаслык үзегез.

Айдар (*Хатирә янына килеп*). Әби, мин кем малае, беләсезме?

Хатирә. Кем малае икәнеңне белмим, сөйләшү фурмыңа караганда бабаң Гафият булырга охшый.

Айдар. Дөрес! Син әллә сихерчеме, әби?

Хатирә. Сихерче. Безнең авыл кызларының барысы да сихерче. Тирә-якның иң матур егетләрен сихерләп үзебезгә карата идек.

Көлешәләр.

Айдар. Әби, безнең белән биисеңме?

Хатирә. Нигә биемәскә? Безнең авыл кызлары бию дигәндә...

Айдар магнитофон кабыза. Егетләр, кызлар бииләр.
Аларга Данияр да кушыла. Хатирә карап тора.

А й д а р (*бераз биегәч, магнитофонны туктатып*). Әби, нигә биемисең?

Х а т и р ә. Безнең бию түгел шул бу. Безнең биюне кичкә биеп күрсәтермен.

Ә м и н ә. Ничек кичкә?

Х а т и р ә. Кичен. Шушы урында. Җыеласыздыр ич?

А й н у р. Ә нигә монда җыелырга? Без клубка барабыз.

Х а т и р ә. Ничек инде? Әллә оныттыгызмы?

К ы з л а р. Нәрсәне?

Х а т и р ә. Соң, без кыз чакта ел саен шушы көнне бирегә җыела идек. Безгә чаклы да шулай эшләгәннәр. Тирә-юньнән егетләр-кызлар килә иде. Өлкәннәр дә ияреп иде. Әллә алай түгелме хәзер?

К ы з л а р. Ю-у-ук...

Х а т и р ә. И-и-и... Бүген көне шундый бит. Бүген бит кыя өстендәге күлнең ташый торган көне. (*Кызлар, егетләр аңламагач.*) Әллә белмисезме?

К ы з л а р. Ю-у-к...

Х а т и р ә. Менә әкәмәт! Ә соң бу аерымрак торган кыяның исемен беләсезме?

К ы з л а р. Белмибез.

Х а т и р ә. Менә әкәмәт! Минем балакаем Сахалинда туып та аны белә. Сөйлә әле, балакаем. Оялма, балакаем, оялма, сөйлә.

К ы з л а р, е г е т л ә р. Сөйлә инде, сөйлә.

Д а н и я р. Безнең авылдан бер чакрым ераклыкта кыятау бар. Аның өстендә зур гына күл бар. Шул күл елга бер тапкыр җәй башында ташый. Ташыса да, ярларыннан чыкмый. Ташыганын аның кыя астында гына белеп була. Ул чакта кыя астыннан су бәреп чыга да, үзәндәге ермак буйлап, Томбай авылы ягына ага. Зур кыя янында аерымрак торган бер кыя бар. Аны тирә-якта Кызкөткән дип атыйлар.

Ул кыя шуның өчен «Кызкөткән» дип атала: борынборын заманда йола булган. Тирә-як авылларның егетләре-кызлары күл ташыган көнне кич белән кыя янына киләләр икән. Кызлар бу көнне үзләре чиккән кулъяулык алып килгәннәр. Алар кыя өстенә менеп, шул кулъяулыкларга таш бәйләп, күлдәге бөтерчекләнеп торган бер урынга ташлаганнар. Егетләр кыя итәгендә шул кулъяулыкларның агып чыкканын көткәннәр. Агып чыккан һәр кулъяулыкны бер егет ала барган. Кайсы егеткә кайсы кызның кулъяулыгы туры килсә, шуларны ярәшкәннәр.

Д и л ә р ә. Нәрсә соң ул «ярәшкәннәр»?

Х ә й д ә р. Шуны да белмисеңмени, өйләндергәннәр инде.

Ә м и н ә. И-и-и... Кызык та түгел... Минем кулъяулыкны Айдар алса, мин аңа кияүгә чыгаммыни? Чыкмыйм! Алай дөрес түгел.

А й д а р. Сине алырга җыенган кеше дә юк.

К а м и л. Сөйләп бетерсен инде. Нәрсә бүлдерәсең һаман. Иң кызыгын сөйләмәде ич әле.

Х а т и р ә (*риваятьне үзе дәвам итә*). Бер елны шулай кыя янына егетләр, кызлар җыелган. Кызлар үз теләкләрен җыр белән әйтеп, кулъяулыкларын чиратлашып күлгә салганнар... Данияр әйтми калдырды — кызлар җыр белән теләк әйтергә, егетләр кулъяулыкны алгач, кулъяулык иясенә җыр белән җавап бирергә тиеш булган... Йола буенча егетләр белән кызларның саны тигез булырга тиеш булган... Менә шул елны егерме кызның кулъяулыгы агып чыкканын егерме егет көтеп торган. Унтугыз кулъяулык агып чыккан, бер кулъяулык чыкмаган. Кулъяулыксыз калган егет, аның чыкканын көтеп, бер атна кыя төбендә утырган. Кулъяулык чыкмаган. Өч көннән соң күл ташудан туктагач та көткән егет. Ай көткән, ел көткән. Менә безнең заманга истәлек булып шушы кыя һәм егетнең җыры калган.

К а м и л. Җырын да беләсеңме, әбекәй?

Х а т и р ә. Беләм. Менә минем балакаем да белә. (*Даниярга.*) Җырлап күрсәт әле, балакаем.

Д а н и я р (*җырлый*).

Мин көтәрмен язмыш насыйп иткән ярны,
Көтәрмен мин үзе мине көткән ярны.
Мәрхәмәтле язмыш, миңа бүләк итче
Хыялымның канатында йөрткән ярны.
Бәхет гөле чәчәк ата
Көтә белгәннәргә генә;
Кылдан нечкә сукмаклардан
Үтә белгәннәргә генә,
Күккә ашып, күк читенә
Йолдыз элгәннәргә генә.

Х ә й д ә р . Җүләр. Шул егетне әйтәм. Булмаганны көтәргә соң...

Ә м и н ә. Ул җүләр түгел, син җүләр. Чөнки син көтә белмисең. Әби, сез үзегез кулъяулык ташлап карадыгызмы?

Хатирә. Без дә карадык, бүтәннәр дә эшләп карады бугай.

Камил. Чыннан да, минем күргәнем бар — бервакытны менә бу урында су күбәя. Чыннан да, күргәнем бар. Әби, ялгышмыйсызмы, бүген ташыячакмы күл?

Хатирә. Бүген булырга тиеш. Шулай иде. Хәзер ничектер. Бәлкем, үзгәргәндер. Әллә нишләтеп бетерделәр бит җир өстен.

Әминә. Әйдәгез, кызлар, бүген киләбез.

Хәйдәр. Әй, кульяулыкларыгыз да юк бит әле сезнең.

Әминә. Каян беләсең, ә, каян беләсең? Бәлки, сиңа дип чиккән кульяулыгым бардыр.

Хәйдәр. Әллә?

Әминә. Әллә шул менә.

Хәйдәр. Егетләр, без дә киләбез, болай булгач. Кара аны, Әминә, әгәр дә кульяулыгың миңа эләксәме? Син минем хатыным буласыңмы?.. Айдар, киләбезме?

Айдар. Килмим. Йә Әминәнең кульяулыгы чыгар.

Диләрә. Минем дә кульяулыгым бар.

Айдар. Синең дә бармыни? Юк шул, синең кульяулыгың кирәкми.

Хатирә. Ямьсез сөйләшмәгез, балалар.

Айнур. Әби, әйдә, кайтабыз.

Хатирә. Кайтабыз, кызым, кайтабыз. (*Даниярга.*) Балакаем, ал әйберләрне.

Шау-гөр килеп китәләр. Бераздан Айдар әйләнеп керә. Кыяга карап тора да йөгереп өскә менеп китә. Диләрә дә әйләнеп керә.

Ул кыяга үрмәләгәндә, кыя өстендә Айдар пәйда була.

Айдар. Син нишлисең анда?

Диләрә. Менәм.

Айдар. Нәрсә калган сиңа монда?

Диләрә. Күлне күрәм.

Айдар. Әллә, чыннан да, кульяулык ташларга җыенасыңмы?

Диләрә. Карыйм гына ич мин.

Айдар. Карыйм гына дигән була.

Диләрә. Айдар, әгәр дә Айнур күлгә кульяулык ташласа, әгәр ул агып чыкмаса, син теге әкияттәге егет кебек кульяулыкның чыкканын көтәр идеңме?

Айдар. Әллә мин җүләрме?

Диләрә. Айдар тукта! (*Җыр башлый. Айдар тукталып тыңлый.*)

Яратам да, яратмыйм да, димим.
Утларында янам, ләкин көймим,
Үзем сөям кебек, үзем сөймим.
Лили-лилли, лили-лилли-лиллим...

Айдар *(Диләрәне үртәп)*. Тиле-лиллим, тиле-тиллим. *(Чыгып китә.)*

Диләрә. Сау бул, Айдар. Кич белән кил бирегә, Айдар. Үзем чиккән кулъяулыгым бар минем, Айдар. Ул кулъяулык сиңа чыгачак, Айдар. Мин сине яратам бугай, Айдар. *(Дип Айдар киткән якка китә. Үзе китсә дә, үзәнлектә көе кала. Сукмактан Нәфисә һәм тагын берничә карчыкны ияртеп Хатирә атлый. Үзән өстендә тирбәлгән көйне туктап тыңлый.)*

Хатирә. Ишетәсезме, ахирәтләр?

Карчыклар колак салып тыңлыйлар.

Нәфисә. Нәрсәне ишетергә кирәк соң, ахирәт?

Хатирә. Баш очында ниндидер көй йөри ләбаса.

Карчыклар тагын тыңлыйлар.

Гөлсем. Томбай авылында кайтмый калган бозау кычкыра ич.

Хатирә. Колакларыгыз катыланган, ахирәтләр.

Нәфисә. Катылангандыр да инде, Хатирә ахирәт. Шулхәтле гомер яшәп, кирәген дә, кирәкмәсен дә тыңлап-ишетеп катыланыр да.

Гөлсем. Без бит монда кала прәннеге генә ашап ятмыйбыз.

Хатирә. Күл янына сукмакны оныткансыз.

Нәфисә. Онытылгандыр да инде, Хатирә ахирәт. Каян барысын да хәтердә тотасың? Кичә ни ашаган да онытыла кайчак.

Хатирә. Ашаганың онытылса да, монысын онытырга ярамый. Монысы — яшьлек.

Карчыклар кеткелдәшеп көлешәләр.

Гөлсем. Без бит монда каладагы кебек уйнап-көлеп яшәмәдек.

Нәфисә. Яшьлекне искә алырлык булдымы заманасы? Сез киттегез дә котылдыгыз. Без монда изелдек.

Хатирә (*кыя астына килеп*). Хәтерлисезме, менә шушында җыела идек.

Карчыклар хәтерләргә тырышалар.

Нәфисә. Җыела идек бугай шул, җыела идек.

Хатирә. Күлнең ташыганын көтеп уен башлап җибәрә идек.

Гөлсем. Башлый идек бугай шул, башлый идек.

Хатирә. Йәгез әле, килегез әле.

Нәфисә. Нишләтмәкче буласың тагын, Хатирә ахирәткәем.

Хатирә. Уйныйбыз, ахирәтләр. Яшь чакларны искә төшерәбез.

Карчыклар янә кеткелдәшәләр.

Әйдәгез әле, мескенләнмәгез әле, ахирәтләр. Беләм бит мин сезне. Син, Нәфисә ахирәт, урыныңда басып тора алмый идең. (*Карчыкларны кулларыннан тотып түгәрәккә җыя. Үзе җыр башлый.*)

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлыйк әле бишне дә;
Сез дуслар җырлаган җирдә
Җырламый килешми дә.
И дүдәме, дүдәме,
Гармунчыгыз өйдәме?

Җырны искә төшереп, карчыклар да берәм-берәм кушылалар.

Өйдә булса, килсен әле,
Биетеп китсен әле.
Ялындыра, ялындыра,
Ялындыра, килми ул;
Килер иде, уйнар иде,
Бию көен белми ул.
Сандугачны тотсаң иде
Талга тезелгән чакта;
Сөйгәнеңне күрсәң иде
Җаның теләгән чакта.

Кушымтаны җырлаганда карчыклар кызып китәләр — бии-бии җырлыйлар.

Нәфисә (*тәмам кызып киткән*). Әйдәгез әле, «Челтәр элдем читәнгә»не.

Гөлсем. Үзем егетләр булам.

Карчыклар «егетләргә», «кызларга» бүленеп уйнарга керешәләр.

Хатирә (*уртага чыгып такмак әйтә-әйтә биергә тотына. Аңа бүтәннәр кушыла*).

Бие, бие, Хәйбулла,
Биегән кеше бай була;
Биегән кеше бай булганчы
Карт алаша тай була.

Биеп арыган карчыклар, көлешә-көлешә, берәмләп егылалар.

Гөлсем. Уф! Бетте лә хәлкәйләрем!..

Нәфисә. Үләм! Безне биетеп үтерергә генә кайткансың икән, ахирәт.

Гөлсем. Бөтенесе искә төште тагын... Уф!.. Уф, Алла!..

Нәфисә. Үләм!..

Хатирә. Үлмибез әле, ахирәт. Яшибез әле, ахирәтләр.

Гөлсем. Яшибез, яшибез! Чукынып китсен дөньясы.

Нәфисә. Безгә барыбер үләсе. Биеп үлик, ичмасам. Әйт, Хатирә ахирәт, тагын нишлибез?

Хатирә. Нишли идек соң? Әнә теге җирдән инешкә төшеп, салкын суда кул-битләрне юып хәл ала идек. Әйдәгез, ахирәтләр.

Карчыклар. Әйдәгез, әйдәгез... (*Дип көч-хәл белән торып, әмма җыр җырлап тезелешеп чыгып китәләр. Аларның киткәнен, Айнур белән Данияр карап калалар. Ни эшләргә, ни сөйләшергә белми басып торалар.*)

Айнур. Сезнең әбиегез әллә нинди икән.

Данияр. Ничек әллә нинди?

Айнур. Шулай, әллә нинди инде. Без дә алар янына барабызмыни?

Данияр. Белмим.

Айнур. Сез гел шулай әбиегезгә ияреп йөрисезме?

Данияр. Йөрмим. Монда гына бергә кайттык.

Айнур. Сахалин матурмы соң?

Данияр. Матур. Әби белән бабай гел сөйләгәч, бу якларны күрәсем килә иде.

Айнур. Безнең монда күрерлек нәрсә бар инде?

Данияр. Ничек булмасын?! Менә бу урын үзе генә дә ни тора. Кыя өстендәге күл? Мин аны йөгереп әйләнеп чыктым. Ташып шушы урыннан агып чыга, ди, әби.

Айнур. Әкият ич ул.

Д а н и я р. Ышанмыйсызмы?

А й н у р. Ышанмыйм дип әйтмим дә... Әллә ничек ич. Ни дисәң дә, әкият.

Д а н и я р. Әкиятне кешеләр уйлап чыгарган. Беләсеңме нигә уйлап чыгарганнар?

А й н у р. Нигә?

Д а н и я р. Яшәве кызыклырак булсын өчен. Әкият уйлап чыгарганнар да, их, шулай булсын иде ул тормыш дип, үз әкиятләренә үзләре сокланганнар. Җырны да шуның өчен чыгаралар. Күрдегезме, безнең әбиләр ничек яшәреп киттеләр? (*Айнурның үзенә аптырап карап торганын күреп.*) Әйе... Шулай... Без өйдә еш кына бергә җыйналып җырлыйбыз. Әйе... Шулай... (*Айнур көлә башлагач.*) Нигә көләсең, Айнур?

А й н у р. Кызык ич. Син ничәнчедә укыйсың?

Д а н и я р. Укымыйм мин, эшлим. Былтыр унынчы сыйныфны бетердем дә укырга керәсем килмәде. Бәлки, Казан ягына кайтырбыз, ди, әти. (*Кинәт Айнурның кулыннан тотып.*) Әнә! Су бәреп чыкты. Күрәсезме, әнә? Әнә астан бәреп чыга. Инешнең суы да артты, күрәсезме? Сез ышанмаган идегез.

А й н у р (*су бәреп чыккан урынга исе китеп карап*). Шул күлдән микән ул?

Д а н и я р. Суның бәреп чыкканын күрүгә үк җыр башларга, дигән иде әби. (*Җырлый. Айнур кулын Данияр кулыннан алырга да онытып, сихерләнеп тыңлый.*)

Сөбханалла, сөбханалла!
Ни гүзәллек бу дөньяда!
Кояш чыга, кояш бата,
Йолдыз калка, таңнар ата.
Сөбханалла, сөбханалла!
Нинди серләр бу дөньяда!
Диңгез ташып, таулар яна,
Ташлар тишеп, чишмә ага.
Сөбханалла, сөбханалла!
Мин бер бөртек бу дөньяда!
Мәрхәмәтеңнән ташлама,
Мәхәббәтеңнән ташлама.

А й н у р (*Айдар кергәнне күреп, кулын Данияр кулыннан ала*). Айдар, су бәреп чыкты, үзебез күрдек.

А й д а р. Чыкса соң. Әллә су күргәнем юкмы? Егет таптыңмыни?

А й н у р. Нәрсә син, әллә җүләрләндеңме? Кунакка кайткан ич безгә. Беләсең ич.

А й д а р. Кунакка... Синең белән тотаклашып йөрергәме?

А й н у р. Тотаклашса. Синең ни эшең бар? (*Кырт борылып китә.*)

Шаулашып е г е т л ә р, к ы з л а р керәләр. Х ә й д ә р н е ң кулында гармун.

Х ә й д ә р. Һәй... Без аларны авылда эзләп йөрибез. Алар әллә кайчан монда.

А й н у р. Кызлар! Су, чыннан да, бәреп чыкты. Үзем күрдем. (*Дәррәү кыя астына киләләр. Айнур су чыккан урынны күрсәтә.*) Менә шуннан. (*Даниярга күрсәтеп.*) Менә ул беренче күреп алды.

Х а т и р ә белән Н ә ф и с ә керәләр. Айнур Нәфисә каршына йөгереп килә.

Әби, су бәреп чыкты. Әнә ул күреп алды.

Барысы да шау-гөр килеп инеш янында кайнашалар.

Х ә й д ә р. Җәмәгать! Кызлар, кайда кулъяулыкларыгыз? Күрсәтегез.

Ә м и н ә. Әби, чигелмәгән кулъяулык ярамый, әйеме?

Х а т и р ә. Нишләп ярамасын икән? Безнең чакта чигелмәгән кулъяулык юк иде. Шуңа гына әйткәннәрдер.

Ә м и н ә. Кызлар! Әйдәгез, уйныйбыз. Малайлар, сез уйныйсызмы? Айдар, уйныйбызмы?

А й д а р. Әкият ич ул.

Ә м и н ә. Әкият булса уйнама. Без уйныйбыз.

Е г е т л ә р. Уйныйбыз, уйныйбыз.

Д а н и я р (*ул кыя өстенә менеп өлгергән*). Мин күрдем, күлдә бөтерчек бар.

Егетләр дәррәү кыя өстенә менеп китәләр. Кызлар Хатирә белән Нәфисәне уратып алалар. Айнур гына бер читтә тора.

Х а т и р ә. Кулъяулыкларыгыз бармы?

К ы з л а р. Бар, бар...

Х а т и р ә. Кулъяулыкларыгызны кулларыгызга алыгыз. Җыр җырлап шул кулъяулыкларны егетләргә күрсәтеп чыгасыз.

Д и л ә р ә. Ә нинди җыр?

Х а т и р ә. Нинди булса да үзегезнең җырыгызны җырлагыз. Җырлый-җырлый тезелешеп әнә теге сөзәгрәк урыннан кыя башына менәсез. Шуннан һәрберегез аерым-аерым бу якка карап үз теләкләрегезне җыр белән әйтәсез.

В ә с и м ә. Ә җырлый белмәсәң?

Х а т и р ә. Җырлый белмәгән кеше булмый ул, кызым. Монда гаеп итеш юк. Аннан бергәләп күл буена барасыз. Кульъяулыкларыгызга таш бәйләп, күлдәге бөтерелеп торган урынга ташлыйсыз. Ярый, анысын Нәфисә белән үзебез күрсәтербез.

Д и л ә р ә. Егетләр нишли?

Х а т и р ә. Аларның үзләренә әйтербез.

Ә м и н ә. Әй! Малайлар! Төшегез!

Е г е т л ә р өерелеп төшәләр.

Х ә й д ә р. Күрсәгез, кызлар!.. Менә шулай бөтерелеп тора. Күл ярының бу ягында. Ярга якын гына.

Ә м и н ә. Малайлар, тыңлагыз!

Х а т и р ә. Кызлар кыя өстендә теләкләрен җыр белән әйткәч, кыя астындагы егетләр дә үз теләкләрен җыр белән әйтергә тиешләр. Аннары кульъяулык агып чыкканны көтәләр. Кем алдан кемнең кульъяулыгын алып өлгерә, шуның бәхетенә шул була инде.

А й д а р. Агып чыкканы юк диденң ич, әби.

Х а т и р ә. Анда минем эшем юк. Мин миңа сөйләп калдырганнарны сөйлим.

Ә м и н ә. Булды, әби. Малайлар, кызлар, тезелешеп басыгыз. Хәйдәр! Ал кулыңа гармуныңны, уйна без белгән иң матур көйне!

Хәйдәр уйный. Кызлар тезелешеп кульъяулыкларын күрсәтеп, җырлый-җырлый, егетләр яныннан үтәләр.

Кульъяулыгым читләрендә
Чиккән чияләрем бар;
Чигелгән чияләремә
Тимә, ияләре бар.

Теләк телим, теләк телим,
Кабул булсын теләгем;
Күңелем тарткан егеткә —
Кульъяулыгым — бүләгем.

А й н у р. Агымсуга төшеп юдым
Ак кына беләгемне;
Әйтмим әле, үзе белсен
Теләгән теләгемне.

Егетләр, су бәреп чыккан урынга басып, үзләренең теләкләрен әйтәләр.

Аклы күлмәгеңне кисәң иде,
Яннарыма чабып килсәң иде;
Чиккән кулъяулыгың бирсәң иде,
Җаным-җанкисәгем дисәң иде.
Теләгемдә син генә,
Йөрәгемдә син генә;
Гел син генә, син генә,
Үзең белмисең генә.

К ы з л а р югалалар. Егетләр су бәреп чыккан урын тирәсен тезелешеп күзәтәләр. Бөтен тирә-якта тынлык урнаша. К ы з л а р да, тын гына төшеп, аерым төркем булып, бер читкә басып күзәтәләр. Әкрен генә сихри моң тибрәлә.

А й д а р. Әйттем бит әкият дип. Чыга, ди, сиңа кулъяулык. Булмаса, утырыгыз җүләрләнеп. Мин киттем. (*Читкә китеп утыра да магнитофон кабыза. Аның янына Хәйдәр, Шамил, Баязит килеп утыралар. Кызларның да игътибарлары магнитофоннан яңгыраган көйгә күчә. Айдар торып бии башлый, бүтәннәр кушыла. Хатирә, Гөлсем, Нәфисә һәм карчыклар күзен инештән алмый утырган Данияр янына килеп урнашалар. Егетләр, кызлар, бии-бии, читкә авышалар. Камил дә түзми, торып, алар артыннан йөгерә.*)

Х а т и р ә (*Даниярга*). Бар, балакаем, калма яшьләрдән, ияләш үзләренә.

Д а н и я р (*кыя астыннан күзен алмыйча*). Мин утырам әле.

Н ә ф и с ә. Әллә нигә, салкын төшә башлады мы, өшетеп җибәрде. Кайтыйк мәллә, ахирәтләр? Без кыймылдап кайтып җиткәнче...

Х а т и р ә. Кайтыйк соң... (*Даниярга.*) Булды инде, булды, балакаем. Көтмә, чыкканы булмады аның. Без дә шулай көлешеп таралыша идек.

Д а н и я р. Мин кулъяулык көтмим, болай гына утырам.

Х а т и р ә. Яшьләр белән кайтырсың, алайса.

Китәләр.

Хәйдәр (*йөгереп килеп*). Чыкмадымы?

Данияр. Белмим.

Хәйдәр. Алайса, нигә утырасың соң, әйдә? Әйдә, бер кыз белән таныштырам.

Данияр. Барасым килми.

Хәйдәр китә. Данияр суга карап утырып кала, теләгән теләген кабатлый.

Теләк телим, теләк телим:
Кояш-аем, җирем-суым булсын имин;
Имин булсын иртә-кичем, көнем-төнем,
Туган илем, туган телем, иман-денем.
Теләк телим, теләк телим, теләк телим:
Ходай насыйп иткән ярым булсын имин;
Имин булсын күңлем эзләп тапкан тиңем —
Былбыл кошым, назлы гөлем, нечкә билем.

Кыз көткән кыя тавышы. Исәнме, егет? (*Данияр тавышның иясен эзли. Кыяның тавышы дәвам итә.*) Эзләмә син мине әллә кайлардан, егет. Мин синең каршыңда гына. Кыяга әйләнгән, кыз көткән егет мин. (*Паузадан соң.*) Биргән сәламеңне ишетмим, егет.

Данияр. Исәнмесез.

Кыя. Исән бит. Мең еллар буе исән-сау килеш басып торам. Синең борынгы бабаларыңның рухын саклап басып торам. Син минем язмышны кабатларга җыенасыңмы?

Данияр. Бер кешенең язмышын икенче кеше кабатлый алмый.

Кыя. Әйе, язмышлар түгел, ялгышлар гына кабатлана. Ялгышымны кабатларга җыенасың, алайса?

Данияр. Сез ялгыштыгызмыни?

Кыя. Ә син ничек уйлыйсың? Ялгыштыммы мин, насыйп ярымны көтеп?

Данияр. Юк.

Кыя. Ашыкма, егет. Юлыңда сораулар күп булыр, ашыгып җавап бирмә. Көтә белү җиңел эш түгел. Сез — имгәтелгән аталарның балалары. Бабаларыгыз рухын онытырга мәҗбүр ителгән балалар. Хәтере начарланган токым. Хисләре тупасланган буын. Иманы какшаган кавем.

Данияр. Сезнең телегез мине мыскыл итәр өчен ачылдымы?

К ы я. Күрәм, син горур.

Д а н и я р. Минем бабаларым мескен булмаган.

К ы я. Ләкин син бабаңнар шикелле үк хыялый. Көтмә, чыкмаячак син көткән кулъяулык.

Д а н и я р. Чыгачак.

К ы я. Ышанасыңмы?

Д а н и я р. Ышанам.

К ы я. Ә ул чибәр.

Д а н и я р. Кем?

К ы я. Син көткән кулъяулыкның иясе. Айнур.

Д а н и я р. Әкрен!..

К ы я. Кемнән куркасың?

Д а н и я р. Кешенең серен саклый белү — бабамнар гадәте.

К ы я. Мине синнән башка беркем дә ишетми, Данияр дус...

Д а н и я р. Дус?

К ы я. Әйе. Без дуслар булырга тиеш. Мин сиңа көтәргә булышырмын. Сиңа җиңелрәк — без икәү көтәбез. Мин берүзем генә көттем. Бер күрүдә ошаттың Айнурны, әйе-ме?

Д а н и я р. Әйе.

К ы я. Чибәрлеге сокландырдымы?

Д а н и я р. Әгәр дә миңа шундый мәгънәсез сораулар бирсәгез, мин сезнең белән сөйләшмәячәкмен.

Шаулашып е г е т л ә р, к ы з л а р керәләр.

Х ә й д ә р. Карагыз әле, карагыз, балакаема.

А й д а р. Күңелсез булса утырмасын. Әй балакаем, җүләрләнеп утырма, әйдә, кайтабыз.

Д а н и я р. Мин кайтмыйм әле.

А й д а р. Ничек инде кайтмыйсың? Әллә, чыннан да... (*Көлеп.*) Җүләр. Әбисенең әкиятенә ышанып утыра. Мин башта ук ышанмадым. Әйдәгез, егетләр, утырсын җүләрләнеп.

Д и л ә р ә (*Данияр янына килеп*). Әйдәгез, кайтабыз!.. Айнур! Сезгә кайткан ич ул. Ничек инде... (*Иптәшләре артыннан чыгып китә.*)

Данияр утырып кала. А й н у р йөгереп керә.

А й н у р. Әйдә, кайтабыз... Нигә дәшмисең?

Д а н и я р. Мин көтәм.

А й н у р. Кулъяулыкларнымы?

Д а н и я р. Кулъяулыкны.

А й н у р. Чыкмыйлар ич инде алар.

Д а н и я р. Берсе чыгачак.

А й н у р (*паузадан соң*). Кемнеке?

Д а н и я р. Мин теләк теләдем. Минем теләгем кабул булырга тиеш.

А й н у р. Без барыбыз да теләдек.

Д а н и я р. Мин чынлап... Минем теләгем озын иде; калганын эчемнән генә теләдем.

А й н у р. Алай булмый ич инде. Кешеләр көләләр.

Д а н и я р. Мин көтәм.

А й н у р. Көтә-көтә әнә теге кыя кебек кыяга әйләнәсеңме?

Д а н и я р. Юк. Минем теләгем кабул булачак.

А й н у р. Кайтыйк инде.

Д а н и я р. Мин көтәм.

А й н у р. Әллә син чынлап та тилеме?

Д а н и я р. Син тиле дип уйласаң, тиле.

А й н у р. Мин уйламыйм да... Кулъяулыкның, бәлки, син көткәне чыкмас.

Д а н и я р. Ике читендә кызыл чияләр, бер читендә сандугач...

А й н у р (*кулъяулыкның үзенеке икәнен белеп*). Мин кайтам.

Д а н и я р. Сау бул, Айнур.

А й н у р. Әбиең ачуланыр.

Д а н и я р. Әби әйтә, бәхет ул көтә белгәннәргә килә, ди.

А й н у р. Бәхетнең килгәнен көтеп ятмыйлар инде.

Д а н и я р. Мин, көтә белгәннәргә, дидем.

А й д а р (*кереп*). Кая югалдың?

А й н у р. Хәзер, хәзер...

А й д а р. Кызлар көтә. Кайтасың килмәсә, кал җуләр янында.

А й н у р. Сау бул, Данияр. (*Айдар артыннан китә.*)

Д а н и я р. Сау бул, Айнур. Ә мин көтәм. Мин барыбер көтәм.

Мин көтәрмен алсу таңнар атканда да,
Моңсуланып кичке шәфәкъ батканда да,
Көянтәсен иңнәренә салган Зөһрә
Ай-чишмәдән сулар алып кайтканда да.
Бәхет гөле чәчәк ата
Көтә белгәннәргә генә,
Кылдан нечкә сукмаклардан
Үтә белгәннәргә генә.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Моңлы серле күк астында таң сызыла. Кыя-тау итәгендә Данияр ялгызы. Әби-бабасының туган җирендә шундый хозурлык белән очрашкан җаны сихерләнгән. Күңелендә, йөзендә зур шатлык.

Кыя өстендә Айнур пәйда була.

Данияр. Исәнме, Айнур! Хәерле иртә, Айнур!

Айнур. Исәнме, һаман да китмәдеңме?

Данияр. Мондый матурлыкны ташлап китәргә ярыймы соң, Айнур?!

Айнур. Матурлыкка гына сокланып торасыңмыни? Кулъяулыкны көтмисеңмени инде?

Данияр. Көтәм, Айнур. Кояш белән бергә чыгачак ул.

Айнур. Мин әбиеңә әйттем. Борчылмагыз, ул егетләр белән таң каршылый, дидем. Кайтып җитәрсең дип көткән идем дә, кайтмадың. Менә килдем. Ә мин кулъяулыкны суга ташламадым да.

Данияр. Ышанмыйм.

Айнур. Нәрсәгә ышанасың?

Данияр. Сиңа ышанам.

Айнур. Син анда нәрсә ясап куйдың?

Данияр. Талдан үреп киртә куйдым.

Айнур. Ни өчен?

Данияр. Күрми калсам, кулъяулыгың агып китмәсен дип.

Айнур. Яныңа төшимме?

Дания. Егыла күрмә.

Айнур. Шуннан сикерсәм, тотып аласыңмы?

Данияр. Юк.

Айнур. Нигә?

Данияр. Мин ахмакларны яратмыйм.

Айнур. Чыкмаган кулъяулыкны көтәсең ич. Ул ахмаклык түгелмени?

Данияр. Түгел.

Айнур. Дәлилең ни?

Данияр. Син.

Айнур (*кыядан бераз төшеп*). Яратам дип ник әйтмисең?

Данияр. Мәхәббәтем ул сүзгә генә сыймый.

Айнур. Бер күрүдә мәхәббәтме?

Данияр. Гашыйк булу өчен ничә тапкыр күрергә кирәк? Кем санаган?

Айнур. Синең янныңа төшәргә куркам. Син минем яныма үзең мен. (*Данияр кыяга үрмәли башлагач.*) Кирәкми, кирәкми! (*Тиз генә үрмәләп кыя өстенә мендә.*)

Данияр. Нигә курыктың, Айнур?

Айнур. Син сихерчедер әле.

Данияр. Син үзең мине сихерләдең.

Айнур. Мин теләк теләгәндә синең исемеңне әйтмәдем.

Данияр. Күңелеңнән генә уйладыңмы?

Айнур. Ә мин аны чынлап теләмәдем.

Данияр. Син алдаша белмисең, Айнур.

Айнур. Бүген дә кульяулык чыкмаса, нишләрсең?

Данияр. Көтәрмен.

Айнур. Көтеп-көтеп тә чыкмаса?

Данияр. Тагын көтәрмен.

Айнур. Ә мин сине көтәргә теләмәсәм?

Данияр. Барыбер көтәрмен.

Айнур. Бер кыя янына тагын бер кыя өстәлерме? Әгәр дә син кыяга әйләнсәң, мин кош булып синең тирәңдә очып йөрермен, ярыймы? Синең иңнәреңә кунып сайрармын. Көйләр көйләрмен. Ләкин син мине ишетмәссең шул. Кешеләр телен ташлар аңламый.

Данияр. Ташлар телен кешеләр аңламый.

Айнур. Димәк, без синең белән бер-беребезне мәңге аңлый алмаячакбыз. Бәлки, икебез дә таш-тау булырбыз, әйеме?

Данияр. Минем белән көлеп сөйләшүеңә мин үпкәләмим.

Айнур. Ә мин, бәлки, көлеп сөйләшмимдер дә. Бәлки, минем куанычым күңелемә сыймыйдыр. Кош булып очып китәсем киләдер. (*Кулларын очарга җыенган сыман җәеп.*) Менә хәзер очам. Очам!.. Син нигә бер сүз дә дәшмисең?

Данияр. Сүзләрем юк.

Айнур. Миңа әйтер сүзең юкмы?

Данияр. Җырым гына бар.

Сүзләрем юк, сүзем күчкән җырга —
Син шуларны тыңла.
Күңелләрем чумган сихри моңга —
Шул моңнарны тыңла.
Тыңла әле, тыңла,
Тын да алмый тыңла;
Бары сиңа гына —

Туасы таңыма көйләр көйләрем бар —
Тыңла әле, тыңла.

Жыр беткәндә Айнур бөтерелә-бөтерелә биеп чыгып югала.

Данияр. Айнур!.. Айнур!..

Диләрә (*дуэт ахырында кереп тыңлап тора да түзә алмыйча, Данияр җырын дәвам итә*).

Күзләреңне йом да,
Серләремне тыңла.
Хисләремне тыңла,
Тыңла әле, тыңла.

(*Үзенә аптырап карап торган Даниярга.*) Әйе, әйе, мин бу — Диләрә. Айнур түгел. Юк, Айнур түгел мин. Син миңа әйт: нигә мин Айнур түгел? Барысы да аны эзли, барысы да аны югалта. Югалталар да эзлиләр. Нигә мине югалтучы юк? Нигә мин һәрвакытта да үзем табылам? Нигә мине эзләмиләр? Нигә? Әллә мин бик ямьсезме? (*Китәргә борылган җирдән Хатирә белән очраша.*) Әйт, әйт әле, әби, нигә мине берсе дә югалтмый икән? Нигә берәү дә эзләми икән?

Хатирә. Ни булды, нишләвең, балакаем?

Диләрә. Мин ямьсез түгел бит, әйеме, әби?

Хатирә. Нишләп ямьсез буласың ди? Безнең авылда ямьсез кызлар була димени? Яратырлар, балакаем, яратырлар. Үзең дә сизми калырсың әле.

Диләрә. Ходай язган насыйбымны көтиммени, әби?

Хатирә. Чын мәхәббәт көтә белгәннәргә килә, балакаем.

Диләрә. Рәхмәт, әби. Мең рәхмәт сиңа, әби. (*Чыгып китә.*)

Хатирә (*Данияр янына килеп*). Исәнме, балакаем.

Данияр. Исәнме, әбием. Син борчылма, әбием...

Хатирә. Юк, юк... Борчыламмы соң, балакаем. Мин сөенәм генә, сөенәм генә. Егетләр белән калды, ди Айнур. Ышанмадым. Мин сине беләм. Бабаң каны синдә — әйткән сүзеңдә тора беләсең. Менә чәй алып килдем үзеңә, менә май яккан күмәч бирде Нәфисә әбиең. Тамагыңны ялгап ал. (*Данияр тамак ялгаганда сөйләнә.*) Көтүен көтәрсең дә, балакаем, чыкмас шул ул син көткән кульяулык. Чыкканы булмады аның. Чыккан булса, әкият итеп сөйләмәсләр иде кешеләр. Дөньяда булмаслык нәрсәләрне әкият итеп сөйлиләр

шул. Ә син көт, барыбер көт. Килер ул, балакаем, килми калмас. Көтеп алган ярлар кадерле булалар алар. (*Торып, тирәягына карана.*) Булса да булыр икән дөньяның ямьле урыны! Мондый да матур җирдә ничек инде чибәр кызлар тумасын ди? Матур итеп сөйләш кызлар белән, балакаем. Нәфисәнең дә оныгы иртән иртүк чыгып чапты. Иртә торган кызлар уңган булалар алар. Данияр балакаем, мине сорасалар әйтерсең, Томбай болыннарын гына карап кайтам. (*Китә.*)

Айнур (*кыя өстендә күренә. Кулында чәчәкләр*). Данияр!.. (*Чәчәк ыргыта. Данияр аны тотып алырга өлгерми. Айнур өзгәләнеп кычкырып җибәрә.*) Тота алмадың, тота алмадың!..

Данияр. Мин берни дә аңламыйм, Айнур.

Айнур. Аңламыйсың шул, аңламыйсың. Аңлый да алмыйсың. Әгәр дә син чәчәкне тотып өлгерсәң... Тота алмадың, тота алмадың... (*Йөгереп чыгып китә.*)

Ут сүнә. Ут янганда кич. Баеп барган кояш кыяны һәм аның төбендә утырган Даниярны гына яктырта.

Кыя. Тагын бер көн үтте. Кәефләр ничек, егет?

Данияр. Көтәм.

Кыя. Иртәгә күлнең суы ташудан туктаячак. Кульяулык чыкмаса, нишләрсең?

Данияр. Син нишләдең соң?

Кыя. Мин көттем. Ләкин без сезгә караганда түземлерәк һәм сабыррак идек. Хисләребез дә сафрак иде, теләкләребез дә изгерәк иде. Сез бозылдыгыз, сабырсызландыгыз. Яшәвегезнең мәгънәсе арзанайды, гыйшкыгыз саекты.

Данияр. Бәлки, син безне аңлап бетермисеңдер. Бер урында торып мүкләнгәнсеңдер.

Кыя. Мин сиңа сокланам. Син миңа җан өрдең. Мин тыңдәшләреңнең язмышы өчен генә борчылам. Аларны да үзем кебек, синең кебек көчле ихтыярлы итәсем килә. Сиңа мин һәр мизгелдә иң изге теләктә торам.

Айнур керә, сүзсез генә Данияр янына килеп, аның янәшәсенә утыра. Данияр аның үз янәшәсендә икәнен белсә, тойса да, эндәшми, аңа карамый. Эндәшсә, караса, Айнур куркыр сыман да, китеп барыр шикелле. Аларның күңелләре генә сөйләшә.

Айнур. Мин тагын килермен, Данияр.

Данияр. Мин һаман көтәм, Айнур.

А й н у р. Янында бит инде мин.

Д а н и я р. Кулъяулыкны көтәм.

А й н у р. Үзем булгач, нигә минем кулъяулыгым?

Д а н и я р. Кулъяулыгыңа теләкләрең төйнәлгән.

А й н у р. Мин үзем теләгән теләкләр бит алар. Мин аларны кабатлый алам.

Д а н и я р. Кулъяулыкка төйнәлгән теләкне кабатлап булмыйдыр, Айнур.

А й н у р. Димәк, безнең очрашуыбызның дәвамы булмаячак.

Д а н и я р. Мин көтәм.

А й н у р. Өметсез көтүнең нигә кирәге бар?

Д а н и я р. Минем өметем өзелмәгән.

А й н у р. Өзелер дә әле. Мин сиңа кыр чәчәкләре өзеп ыргыттым, тота алмадың. Мин бит юраган идем. Әгәр дә чәчәкләрне тотып алсаң... Син тота алмадың. Күрәсең, кавыштырмас өчен генә очраштырган безне язмыш. Бәлки, син миңа ышанмыйсыңдыр әле. Кызык өчен генә көтәсеңдер кулъяулыгымны да. Сүзеңне сүз итәсең генә киләдер.

Д а н и я р. Бәлки, шулайдыр.

А й н у р. Ничек инде ул шулайдыр?

Д а н и я р. Үземне сынап каравымдыр.

А й н у р. Димәк, мине яратканнан түгел.

Д а н и я р. Үз сүзендә тора алмаган егетнең сиңа нигә кирәге бар?

А й н у р. Әллә нинди син. (*Даниярга борылып карый. Данияр да аңа карый. Карашып торалар.*)

Д а н и я р. Мин сине көтәм, Айнур.

А й н у р. Менә мин килдем, Данияр. (*Айдарны күреп сикереп тора.*)

А й д а р. Исәннәрдәмесез, саулармысыз.

А й н у р. Исәнме, Айдар.

А й д а р (*Даниярга*). Ә син нигә исәнләшмисең, балакаем?

Д а н и я р. Исәнмесез.

А й д а р. Миңа болай гына исәнләшү ошамый. Әйбәтләбрәк исәнләш, балакаем.

А й н у р. Айдар, бәйләнмә.

А й д а р. Яклыйсыңмыни? Балакаеңны яклыйсыңмыни! Кочаклашып утырасызмыни?

А й н у р. Кочаклаштык шул, кочаклаштык. Синең анда ни эшең бар?

А й д а р. Ни эшем бармы? Мин сине беләсеңме нишләтәм?

А й н у р. Нишләтәсең, йә, нишләтәсең?

А й д а р. Ярар, мин сине нишләтә белермен. (*Урынында селкенмичә дә утырган Данияр янына килеп.*) Син нигә безнең авыл кызларын кочаклыйсың? Ник дәшмисең? Беләсеңме, мин сине нишләтәм, балакаем?

А й н у р (*Даниярны каплап*). Тимә аңа.

А й д а р. Әһә, тимәме? Кит! (*Этеп җибәрә. Айнур егыла.*)

Д а н и я р (*Айнур янына атылып барып*). Айнур!.. Айнур!..

А й д а р. Кит аның яныннан! Бар, кит моннан, эзең булмасын. (*Даниярга сукмакчы була. Данияр бик җинел генә аның кулын эләктереп ала да артка каера. Айдар кычкыра башлый.*) Җибә-әр! (*Данияр аны этеп җибәрә. Айдар, якын килмичә генә, Даниярга яный.*) Күрсәтермен әле мин сиңа, балакаем. (*Чыгып китә.*)

Д а н и я р. Айнур, авырттымы?

А й н у р. Юк. (*Тиз генә сикереп тора да Даниярның кулъяулык саклап утырган җиренә йөгереп бара.*) Әгәр дә кульяулык агып китсә... Әгәр дә син күрми калсаң...

Д а н и я р. Ул сине ярата, әйеме, Айнур? (*Айнур эндәшмәгәч.*) Яраткач, нигә ул этеп җибәрә? Яраткан кешене этеп җибәрмиләр, тартып алалар. Нигә эндәшмисең, Айнур?..

А й н у р. Куркам.

Д а н и я р. Нидән?

А й н у р. Әгәр дә чыкмаса... Нигә кайттыгыз инде сез? Рәхәтләнеп яши идек.

Д а н и я р. Ә мин алып кайткан өчен әбиемә рәхмәт укыйм.

А й н у р. Әгәр дә чыкмаса?.. Мин куркам... Нигә инде ул экиятне сөйләде әбиең? Нигә мин шуңа ышандым?..

Чыгып киткән А й н у р н ы сәхнәгә кергән к а р ч ы к л а р төркеме күзәтеп кала.

Г ө л с е м. Бу сезнеке түгелме соң, Нәфисә?

Н ә ф и с ә. Безнеке, безнеке... Ходайга мең шөкер.

Г ө л с е м. Синеке һәмишә утыра диген, ә, Хатирә? Бигрәк үзсүзле бала, ахрысы.

Х а т и р ә. Бабасына охшаган, Ходайга шөкер.

Г ө л с е м. Сиңадыр, Хатирә ахирәт. Җыен юк-барны син уйлап чыгара идең. Менә бит әле кайттың да безне дә уяттың. (*Даниярны күзәтеп.*) Утыра диген, ә? И-и-и... Булды микән, безне дә көттеләр микән? Һәй, парлашып-парлашып йөрсәң

иде ул су буйларында. Утыра, бәгырькәем, утыра. Көтә, җанкисәгем, көтә.

Г а д и л ә. Түземлеге җитәр микән?

Н ә ф и с ә. Җитәр, Алла боерса, көтмәслек кыз түгел кызыбыз.

Х а т и р ә. Туктап яллар иттек, ахирәтләр, инде юлыбызда булыйк. Инешкә төшеп, кул-битләребезне юып хәл алыйк.

Тезелешеп җырлашып чыгып китәләр. К ы з л а р керәләр. Алар, әлбәттә, Даниярны карарга, тикшерергә килгәннәр. Берәм-берәм Даниярны күзәтеп киләләр. Шыпырт кына сөйләшергә тырышалар.

Ә м и н ә. Егет дисәң дә егет, ичмасам. Безнең авыл егетләре мактанырга гына beləлəр.

В ә с и м ә. Кемнең кульяулыгын көтә икән?

Д и л ә р ә. Айнурныкын.

Ә м и н ә. Нәрсә белән бетәр икән, кызлар?

Д и л ә р ә. Өйләнешерләр.

А с и я. Кемнәр?

Д и л ә р ә. Кемнәр булсын? Айнур белән Данияр. Данияр Айнурны алып китә.

Ә м и н ә. Айдар нишләр икән хәзер? Даниярны кыйнамасын тагын.

А с и я. Әйдәгез, кайтабыз.

Ә м и н ә. Туктале, нәрсә син — кайтабыз да кайтабыз. Кайтып нишлибез?

А с и я. Капка төбендә утырабыз. Монда магнитофон да юк.

Ә м и н ә. Әйдәгез, күлне карап төшәбез. (*Китә. Аңа бутәннәр иярә.*)

Х ә й д ә р, Б а я з и т, К а м и л керәләр. Хәйдәр култык астына гармун кыстырган.

Б а я з и т (*читтән генә Даниярны карап килеп*). Башын игән дә утыра. Әллә үлде микән?

Магнитофон кычкыртып А й д а р белән Ш а м и л керәләр.

А й д а р. Нишләп торасыз монда?

Б а я з и т. Теге Сахалиннан кайткан егет тиле икән ул, Айдар.

А й д а р. Китсен моннан — шул.

Х ә й д ә р. Сиңа урын җитмимени?

Айдар. Җитми.

Хәйдәр. Беләм мин сине, Айнур өчен.

Айдар. Телең тый, ярыймы!

Камил белән Данияр якын киләләр.

Данияр. Исәнмесез, егетләр.

Айдар. Исән булмасак, ни әйтерсең?

Кыя өстендә кызлар күренә.

Әминә. Әй егетләр! Килегез монда. Айдар! Әйдә, кил.

Айдар. Әйдә, Шамил, Баязит, Камил киттек. (*Хәйдәргә.*) Барасыңмы?

Хәйдәр. Бармас дип беләсәң мәллә? (*Даниярга.*) Әйдә, безнең белән, Данияр.

Данияр. Мин бара алмыйм.

Хәйдәр. Син курыкма. Буш куык ул Айдар. (*Егетләр артыннан йөгерә.*)

Камил (*әйләнеп кереп*). Данияр, дөнья ул шундый кызык корылган, әйеме, анда кемдер кемгәдер үрнәк күрсәтергә тиеш. Югыйсә дөнья алга бармаячак. Әгәр дә ниндидер бөек эш өчен үзләрен корбан итүче фидакарь җаннар булмаса, кешеләр хайванга әйләнәчәк. Син шуны да аңла: фидакарьләрне бик сирәк кешеләр генә, аларны аңларга сәләтле кешеләр генә хөрмәт итәләр. Мин синнән көнләшәм һәм хөрмәт итәм. Бир әле тагын бер тапкыр кулыңны. (*Даниярның кулын селки-селки кыса да йөгереп кыя өстенә менеп китә. Ә кыя өстендә көлешәләр, чыркылдашалар. Магнитофон көенә бииләр.*)

Хатирә Данияр янына килә.

Хатирә. Балакаем...

Данияр. Нәрсә, әбием?

Хатирә. Нидер әйтмәкче идем инде дә. Көтмә инде, дип әйтсәм дә килешмәс. Әллә соң, балакаем...

Данияр. Тик син борчылма гына, әбием. Сиңа минем өчен оялырга туры килмәячәк. Үз бәхетемне үзем көтим инде мин, әбием.

Хатирә. Көт, балакаем, көт. Мин кайтыйммыни инде, алайса?

Данияр. Иртән мин синең килгәнеңне көтәрмен. Сау бул, әбием. (*Хатирә китә. Данияр таш өстенә менеп уты-*

рып көтә. Әкрен генә Айнур кереп, Данияр янына килә. Сүзсез генә Данияр янында басып тора. Ләкин аның үз янында икәнен Данияр тоя.) Килдеңме, Айнур?

А й н у р. Мин китмәдем дә. Мин әллә нишләдем. Мин китә алмыйм. Мин кешеләргә дә күренергә оялам. Нindidер ярамаган эш эшләдем сыман. Син әллә сихерчеме бәрәр?

Д а н и я р. Әгәр дә мәхәббәт сихер булса, мин — сихерчедер, Айнур.

А й н у р. Һәм мин дә. Мин синең яныңа китмәскә дип килдем, Данияр. Син күпме көтсәң, мин дә синең яныңда шул чаклы көтәм.

Д а н и я р. Әгәр дә мин кыяга әйләнсәм?

А й н у р. Мин дә кыя булып яныңда басып торырмын. Нәрсә ул мәхәббәт, Данияр?

Д а н и я р. Ул сорауга җавап табылмаган, Айнур.

А й н у р. Мин беләм. Мәхәббәт ул — син.

Д а н и я р. Һәм син.

А й н у р. Без синең белән мәңгелек сорауга җавап таптык, әйеме, Данияр?

Д а н и я р. Бүтәннәргә дә әйтербез, эзләп интекмәсеннәр.

А й н у р. Син миннән көләсең, әйеме?

Д а н и я р. Әйе.

А й н у р. Нигә?

Д а н и я р. Сине ачуландырасым килә.

А й н у р. Ни өчен?

Д а н и я р. Ачуланган чагыңны күрәсем килә. Нинди буласың икән?

А й н у р. Кирәкми, Данияр. Ачуланганда бөтен кеше дә ямьсез була. (*Кинәт.*) Данияр!.. Туктады. Су агудан туктады. Әнә, әнә күрәсеңме?! Акмый. Ни була инде хәзер? (*Сүзсез калган Даниярга.*) Нигә эндәшмисең, Данияр? Чыкмады, чыкмады бит минем кульяулыгым. Нигә эндәшмисең? Китик, китик моннан, Данияр. Уен гына иде бит ул. Без бары тик уйнадык кына. Син кайгырма. Мин сине болай да яратырмын. Мин сине беренче күргәч үк... Уен башланганчы ук. Сине бер күрүемдә үк... Әйдә, китик моннан. Икәүләп болыннарны урап йөрербез.

Д а н и я р. Ә кульяулык?

А й н у р. Юк бит инде ул кульяулык. Югалды инде ул. Күл төбендә ятадыр ул.

Д а н и я р. Күл төбендә?

Айнур. Кайда булсын инде? Таш бәйләп салдык ич. Бездән көләр өчен генә синең әбиең уйлап чыгарган әкият. Әкият бит ул, әйеме? Әйеме, Данияр?.. Нигә эндәшмисең?.. Мин куркам, Данияр. Мин синнән куркам. Юк, юк, син... Син миңа кирәкмисең... (*Чигенә-чигенә.*) Мин куркам...

Данияр. Мин яратам сине, Айнур.

Айнур. Юк, юк... Яратмыйсың, яратмыйсың. Син әллә нинди. Сиңа кулъяулык кирәкме? Хәзер... Хәзер мин аны сиңа табып бирәм. (*Кыядан үрмәләп өскә менә. Аңа Данияр иярә. Тау өстендә кызлар, егетләр пәйда була.*)

Хәйдәр. Менә Айнурны югалткан идегез. Айнурыгыз табылды.

Әминә. Кайда идең син, Айнур? Без сине эзләдек.

Айнур. Су туктады.

Хәйдәр. Кулъяулыкларыгыз үтүт, кызлар. Бакаларга бүләк булды кулъяулыклар. Бик яхшы. Кил монда, Данияр. Әйдә, рәхәтләнеп йөрибез. Сахалиннан кайтып тау саклап яту егет эше түгел. (*Җыр башлый, аңа бүтәннәр кушыла.*)

Хәйдәр. Егетләр, кызлар! Үзебезнең урында биеп китмәсәк, харам булыр. Айдар, кабыз магнитофоныңны.

Айнур. Кирәкми! Кирәкми!! (*Чыгып йөгерә.*)

Айдар. Кирәкмәсә әләкми. Диләрә, кил, әйдә, биибез. (*Магнитофонны кабыза, Диләрә каршына биеп килә. Диләрә биемәгәч, магнитофонны сүндерә.*) Син нәрсә?

Диләрә. Мин нәрсә түгел, кем.

Айдар. Нигә биемисең?

Диләрә. Кешедән калган белән биеп ятарга җүләр мәллә мин?

Кызлар кычкырып көләләр.

Айдар (*ачуы килеп*). Алайса, әнә Хәйдәр гармунына сикерегез. (*Чыгып китә.*)

Диләрә. Әйдә, уйна, Хәйдәр. Биик әле туйганчы.

Хәйдәр. Уйныйсы да килми. Киттек, Әминә.

Гармун уйнап чыгып китә. Аңа бүтәннәр дә иярә. Данияр ялгызы кала. Йөгереп кыя янына килә.

Кыя. Күл ташуыннан туктады, егет.

Данияр. Беләм.

Кыя. Һаман да көтәсеңме?

Д а н и я р. Син көтәсең ич.

К ы я. Җавабың тапкыр. Әмма мин яшәгән заман син яшәгән заманнан бүтәнчәрәк иде.

Д а н и я р. Нинди иде?

К ы я. Кешенең күркәм сыйфатларын бәяли беләләр иде. Фидакарьләрне хөрмәтлиләр иде. Мәхәббәте өчен үзен корбан иткәннәргә сокланалар иде. Хәзер көләләр генә... Синнән дә бит әнә көләләр. Тилегә караган кебек карыйлар. Ә миңа сокландылар. Шуңа күрә дә минем турыда риваять сөйләделәр. Ә синең турыда, бар иде бер җүләр, генә диячәкләр. Бер киңәш бирәм — тыңла. Кит син моннан. Кеше көлдермә. Шунысына да төшен: бер урында ике риваять тумый. Мин булган — кешеләргә шул җиткән.

Д а н и я р. Ә син нигә мактанасың? Син бит кулъяулыкны көткәнсең генә. Эзләмәгәнсең.

К ы я. Син эзләргә җыенасыңмы? Кайдан? Әллә күлдәнме? Менә монысы, чыннан да, ахмаклык. Син шуны беләсеңме, егет, бүгенге көнгә тиклем, ул күлнең төбенә төшеп җиткән кеше юк. Суы боздай салкын, син беләсеңме шуны? Ташла мәгънәсез уйларыңны, Айнур сине болай да ярата.

Д а н и я р. Мин эзләргә тиеш кулъяулыкны, табарга тиеш. (*Тау башына менеп китә.*)

К ы я. Язмыш шаярганны яратмый ул, егет. Тыңла мине.

Д а н и я р. Син дә мине тыңла! Ишетәмсең, нинди көй чыңлый минем җанда.

Сөбханалла, сөбханалла,
Ни гүзәллек бу дөньяда!
Мәрхәмәтеңнән ташлама,
Мәхәббәтеңнән ташлама.

Д а н и я р югала. Көе генә яңгырып кала.

А й н у р (*керә. Ашкынып Даниярны эзли. Туктап*). Чү! Ни булды соң миңа?.. Нигә мин шул чаклы?.. Берни дә булмады бит, нигә өзгәләнергә?.. Бер күрүдә күңелемә кереп урнашты. Мәхәббәт дип аталадыр ул. Бу дөньяда гашыйк булганнар мин генә түгелдер. Гашыйк була белү — бәхет, диләр ләбаса. Тынычлан, Айнур... Ә кайда соң ул? Данияр!.. Кайда син, Данияр?! Мин тагын килдем. Инде менә мин сине көтәм. Данияр!.. (*Кычкырыбрак эзли.*) Данияр!.. (*Тау өстенә менеп эзли, аска төшә.*) Да-ни-яр!

Кыя. Данияр юк инде ул, гүзәлкәй.

Айнур (*караныл*). Ничек юк?.. Кем син?..

Кыя. Мин — риваятьче егет, гүзәлкәй.

Айнур. Кайда Данияр?

Кыя. Ул инде риваятьтә. Син аны шуннан эзлә, гүзәлкәй. (*Кыя сөйләгәндә сәхнәгә әкрен генә карчыклар, яшьләр җыйнала. Төрлесе кыяның төрле ягына урнаша.*) Сездән калганнар да эзләсеннәр. Сездән алда килгәннәр мин эзләгән кебек эзләсеннәр. Сагынып, сокланып, гаҗәпләнеп сөйли-сөйли эзләсеннәр. Эзләгез, онытa гына күрмәгез. Безне оныткаъннар үзләре дә онытылалар. Данияр! Җавап бир, җырыңны отып калсыннар.

Данияр**н**ың җыры яңгырый.

Бәхет гөле чәчәк ата
Көтә белгәннәргә генә,
Кылдан нечкә сукмаклардан
Үтә белгәннәргә генә,
Күккә ашып, күк читенә
Йолдыз элгәннәргә генә.

Пәрдә.

Пьесага бергәләп анализ ясыйк

Пьесаны картлар һәм яшьләр турында дип ике өлешкә бүлик. Аннары, гадәттәгечә, өлешләрне берәм-берәм өйрәник.

Карчыкларның сыйфаты

Нәфисә әби әйткәнчә, карчыклар кичә ни ашаганнарын да онытканнар. Алар, Хатирә йогынтысына бирелеп, картлык йокысыннан уяналар. Карчыклар яшәреп китәләр, моң-зарлар онытыла, дөньяга елмаеп карый башлыйлар.

Берара алар хәтта яшьләр арасына кереп биеп, җырлап та алалар. Уртак җырлары да мәхәббәт турында:

Урамнан узып бара —
Кашыннан күзе кара;
Керфегеннән нурлар тама,
Күрсәм — йөрәгем яна.

Карчыклар картлыкларын оныталар. Яшь чакларындагы уенны исләренә төшерәләр. Алар да суга салган яулыкның агып чыгуына да, бәхет китерүенә дә ышанмаганнар. Ләкин яраткан егетләренең исемен кульяулыкларына язып агызу, бик аз арада булса да, үзләре уйлап тапкан өметләре белән яшәп калырга сәбәп булган.

Хатирә әбиләрне ничек шулай тиз арада үзгәртә алды соң?

Кунак үзенең тынгысыз хыялы белән әбиләр хәтерендә йокымсырап яткан яшьлек хисләрен уятты. Аларны кыз чакта уйнап йөргән урыннарына алып килде, шул чакта җырлаган җырларын җырлатты. Әбиләр, аз гына вакыт арасында булса да, хәтерләрендәге күңелле дөньяда яшәп алдылар. Хәтерләре яңарды, күңелләре матур хисләргә баеды. Өлкәннәр өчен борынгы уен — әкият тә, риваять тә түгел, үз яшьлекләренең чынлыгы. Хәзер алар, Хатирә моннан киткәч тә, бу хакта онытмаячаклар. Әбиләр шул сыйфатлары белән бер-берсенә охшаганнар.

Аның каравы яшьләр арасында аерма күп.

Яшьләр сыйфаты

Хатирә карчык яшьләрне дә кыз чактагы уеннарына катнашырга күндерә. Кызлар, борынгы уен кагыйдәләренә буйсынып, күлгә исемле кульяулыкларын агызалар. Егетләр үз исемнәре язылган кульяулыкларның агып чыгуын көтәләр. Шушында көтә-көтә бәхетле булуларына ышанмасалар да, уйныйлар — бәхетләрен көтеп утыралар. Әбиләр өчен кайчандыр бәйрәм булган уен — яшьләр өчен мәгънәсезлек. Хатирә әбинең кодрәте яңа заман яшьләрендә ата-бабаларының йолаларына хөрмәт тудыра алмый. Алай да өлкәннәр күңелен танып белергә ярдәм итә.

Биремнәр һәм сораулар

1. Сезгә пьесадагы персонажларның кайсылары ошый? Хатирәме? Даниярмы? Айнурмы? Айдармы? Хәйдәрме? Ни өчен ошый?

2. Әсәрдә халык телендә фидакарь егетне гәүдәләндерүче борынгы кыя һәм шулай ук халык хәтерендә саклануын дәгъва кылучы яңа кыя — Данияр кыясы бар.

Сүзләре һәм җырлары аша, кылган эшләрен чагыштырып, кыяларга үз бәягезне бирегез.

3. Яшьләр арасыннан Камил: «Дөнья ул шундый кызык корылган, әйеме, анда кемдер кемгәдер үрнәк күрсәтергә тиеш. Югыйсә дөнья алга бармаячак»,— ди. Камил үрнәк кеше дигәндә Даниярны күздә тота. Камил шулай уйлый. Ә сез ничек уйлыйсыз?
4. Укып чыкканнан соң биргән бәягез белән әсәргә анализ ясаганнан соң бирелгән бәяне чагыштырыгыз.
5. Әсәрнең исеме — «Кульяулык». Исемнең әсәргә автор салган төп теманы күрергә ярдәм итүен беләсез. Ләкин пьеса кешеләр турында. Димәк, кульяулыкның мәгънәләрен табарга кирәк. Кульяулык белән бәйле вакыйгаларны искә төшерик.

Кульяулыктагы язуларында кызларның теләге бар. Бар да үзләренә бәхет телиләр. Аннары көтәләр.

Егетләр дә бәхетләрен көтәләр (кульяулыкның күлдән агып төшүен көтәләр). Хәзер әсәрнең исемен «Бәхет көтү» дип үзгәртә алабыз. Исем теманы әйтеп бирде. Димәк, әсәрдә сүз шул турыда барачак.

Әсәр конфликты бәхет көтүчеләр белән бәхетне эзләүчеләр бәхәсеннән гыйбарәт. Бәхәстәге дәлилләрне чагыштырыгыз.
6. Айнур белән Данияр язмышы да бәхетне көтеп алу фәлсәфәсе белән бәйле. Данияр — фидакарь егет. Мәхәббәте өчен җанын да кызганмый. Ләкин Айнур аның нәкъ менә шул сыйфатын яратмый. Ни өчен яратмый?
7. Автор әсәрендә бер авылның берничә кешесе турында язса да, барыбызны да күздә тоткан. Без барыбыз да шундыйлар бит, дигән. Без ниндиләр?
8. Хатирә хәтердә сакланган матурлык белән бәхетле булалар дип уйлый. Уен карчыкларны шатландырып исбат та итә. Ә киләсе бәхетне түземлек белән көтәргә куша.
9. Яшьләр җырына күз салыйк. Алар:

Чәчәк кебек яшь гомерне
Бушка уздырмыйк әле,—

дип җырлыйлар. Димәк, бар булган бәхет белән риза. Кыя бәхетне эзләргә куша.

Һәркайсының үз дәлиле бар. Әйтергә кирәк, шактый нигезле дәлилләр.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3

Кабатлау

Мәкальләр һәм әйтемнәр 6

Җырлар 6

Әкиятләр 7

Алтын кош. (*Татар халык әкияте*) 7

Әдәби жанрлар

Хикәяләр 19

Утыз тиен. *Марсель Галиев* 19

Фәрештәләр бүләге. *О.Генри* 21

Лирик шигырьләр 27

Имин тормыш авазы. *Марсель Галиев* 27

Башка берни дә кирәкми. *Сибгат Хәким* 28

Повестьлар 28

Садри Җәләл 29

Дим буенда 30

Балладалар 61

Кыя һәм кеше. *Шәүкәт Галиев* 61

Сүзсез генә. *Хәсән Туфан* 63

Соңгы сүз. *Мөдәррис Әгъләмов* 64

Новеллалар 65

Шифалы дару. *Нурихан Фәттах* 65
Артист. *Госман Бакиров* 66

Сатирик шигырьләр 67
Бәрәңге турында баллада. *Әхмәт Исхак* 67
Ясыйр. *Шәүкәт Галиев* 68

Поэмалар 68
Таныш моңнар. *Илдар Юзеев* 69

Язучы иҗатына анализ

Һади Такташ 84
Газраилләр 87
Төркстан сахраларында 89
Антым 89
Үтеп барышлый 94
Ак чәчәкләр 96
«Ай кебек без озак яшәмәбез...» 100

Шәриф Камал 104
Матур туганда 105

Мәҗит Гафури 141
Шагыйрьнең алтын приискасында 143
Кара йөзләр 156

Фатих Кәрим 178
Сибәли дә сибәли 179
Ак күбәләк 180
Кала яшьлек 181
Газиз әнкәй 181

Кәрим Тинчурин 185
Зәңгәр шәл 186
Американ 216

Әхмәт Фәйзи 235

Чык һәм кырау 236
Умырзая 236
Яшьлек 237
«Әй мактала берәү...» 237
Бүрек һәм мин 238
Яфрак һәм чикләвек 239
Күз 240

Клара Булатова 241

Шәкертләремә 241
Зилзиләне кабат уятма 242
«Нәрсә булды?..» 242
«Яшиселәр инде яшәлгән дә...» 243
«Бәхетлеме син?» дигәнгә 243

Белемебезне ныгыту өчен күнегүләр

Алсу. *Һади Такташ* 244
Җитенче кыз. *Сибгат Хәким* 245
Ландыш. *Хәсән Туфан* 245
Малай белән эт. *Ибраһим Гази* 247
Кояшның дәвамы. *Марсель Галиев* 249
Үги ана яфраклары. *Аяз Гыйләҗев* 251
Кульяулык. *Туфан Миңнуллин* 270

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник по татарской литературе для 8 класса татарской средней общеобразовательной школы

Издание третье, переработанное

Казань. Издательство «Магариф». 2007

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек

Яңадан эшләнгән өченче басма

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторлары һәм компьютерда биткә салучылары *Ә. Р. Ильина, Ф.К. Гомәрова*
Корректорлары *А. А. Дәүләтова, С. З. Гыймалетдинова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 02.07.2007.
Форматы $60x90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 19,0+форз. 0,25.
Нәшер-хисап табагы 18,46+форз.0,39.
Тиражы 5000 д. Заказ С-807.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http: //magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

интонация